
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.2001





Һади Такташ

1901—1931

# Казан утлары
# Qazan utları

2001

**1**

**(939)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Факил Сафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Иман безне ташламасын ........ 5

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ. Яңа гасыр керә. *Шигырь* ........ 8
Якуб ЗӘНКИЕВ. Өтелгән мәхәббәт. *Роман* ........ 9
Илдар ЮЗЕЕВ. «Татар яши!» дигән өйдән мин. *Шигырьләр* ........ 45
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Албастылар. *Хыялый кыйсса* ........ 49
Наис ГАМБӘР. Югалтырлык түгел... югалтмам. *Шигырьләр* ........ 125
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Сагындырып төшеп исегезгә. *Шигырьләр* ........ 129
Зөлфәт ХӘКИМ. Уйлар уйнавы ........ 133

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлназ ВӘЛИЕВА. Тылсым. Шигырьләр *(Ф. Латыйфиның кереш сүзе белән.)* ........ 139

ПУБЛИЦИСТИКА

Әгъләс БОРҺАНОВ. Урыс сөймәс җан түгелмен, мин—татар ........ 143
Ант һәм өмет. *(Язучылар Адлер Тимергалин һәм Мәгъсум Хуҗин әңгәмәсе)* ........ 154

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Жанрның язмышы һәм янаруы ........ 161

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

6—Әнгам (Мал-туар) сүрәсе ........ 169

ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Рәдиф ГАТАШ. Үзгәрмәячәк мәхәббәт сүзе. *Эссе* ........ 174
Һади ТАКТАШ Мәңгелек әкият. *Шигырь* ........ 180

ГОМӘР БӘШИРОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Зөфәр БӘШИРОВ. Әдипнең мирасы ........ 181

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Күңелдәге сурәт (*Нил Юзиевның тууына 70 ел)* ........ 187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Слово редактора»: Р. ФАЙЗУЛЛИН. «Не покинет нас вера».
«Проза и поэзия»: Я. ЗАНКИЕВ. Роман «Опаленная любовь» *(начало)*; фантастическая повесть Г. ГИЛЬМАНОВА «Лесные демоны»; З. ХАКИМ «Сокровенные мысли»; стихи И. ЮЗЕЕВА, Н. ГАМБАРА, И. ГИЛЯЗОВА, М. АГЪЛЯМА.
«Новые имена»: стихи Г. ВАЛЕЕВОЙ *(с предисловием Ф. Латифи)*.
«Публицистика»: А. БУРГАНОВ. «Я не русофоб. Я— татарин»;
«Клятва и мечта»—беседуют писатели М. Хузин и А. Тимергалин.
«Литературная критика»— статья М. УСМАНОВА «Судьба и возрождение жанра».
Коран на татарском языке.
«К 100-летию Х. Такташа»: Эссе Р. ГАТАША «Вечное поклонение любви», стихи Х. Такташа на латинской графике.
«К 100-летию Г. Баширова»: «Наследие»—статья З. БАШИРОВА и отрывки из дневников писателя.
«К 70-летию Н. Юзиева»: Н. ХИСАМОВ. «Незабываемый образ».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Сказочная Казань»— фотоэтюд С. Исхакова; коллектив редакции журнала «Казан утлары» и члены редколлегии. 2000г. Фото Р. Мухаметзянова.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

Editor's word: R. FAIZULLIN
"Prose and poetry": Y. ZANKIEV'S novel «The burn love» (begining); GILMANOV'S fantastic narrative «The forest demons»; Z. KHAKIM «Innermost thoughts»; the verses of I.UZEEV, V. GAMBAR, I. GILIAZOV, M. AGLAM.
"New names": G. VALEEVA'S verses (with F. LATIFI'S preface).
"Journalism": A. BURGANOV «I'm Tatar».
«Oath and dream» a talk of writers M. HOUZIN and A. TIMERGALIN.
"Literary criticism": M. USMANOV's article «The destiny and revival of a genre».
"Koran in Tatar language".
"Commemorating the 100 th anniversary of Kh. Taktash": R. GATASH'S narrative «The Eternal worship to love». KH. TAKTASH'S verses on Latin grafic.
"Commemorating the 100 th anniversary of G. Bashirov": «The legacy» - Z. BASHIROV'S article and fragments from writer's diary.
"Commemorating the 70 th anniversary of N. Uzeev": N. KHISAMOV «Unforgettable image».
The diary of social and cultural life.
In our covers: «Fairy Kazan»- photoetude of S. ISKHAKOV; editorial staff of «Kazan utlari» magazine R. MUKHAMETZIANOV'S photo 2000 year.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмахәнәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.12.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8519 Заказ Э-523
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.

*Баш мөхәррир сүзе*

# ИМАН БЕЗНЕ ТАШЛАМАСЫН

*Мөхтәрәм Укучыларыбыз!*

Сезнең кулыгызда журналыбызның быелгы беренче саны. Гадәти сан. Тышлык-бизәлешендә дә әлләни үзгәреш юк, кәгазь сыйфаты да шул ук, хәрефләренә дә яңа төсләр йөгертелмәгән, сүзләргә салынган мәгънә дә, бәлки, гел хикмәти ук түгелдер... Әйе, быелгы беренче сан. Чыга башлаганыннан исәпләсәң, журналның 939 саны. Редакциядә дә көндәлек иҗади атмосфера. Тышта—салкын кышның гадәти бер көне. Календарьда—Яңа Ел. Безнең өчен гамәлдә булган григорьян (христиан) календаре буенча—2001 ел, хиҗри-мөселман исәбенчә—1422, яһүдләрчә—5761 ел... Ходайның бирмеш гадәти бер елы... Шулаен шулай да, дөньяның байтак кыйтгаларында (шул исәптән бездә дә): «Яңа гасыр, яңа меңъеллык башлана!»—дип, халык мөш килә бит әле! Әйдә, шулай да булсын. Яшәештә бик күп нәрсәләр шартлы символ-атамалар белән билгеләнә. Яңа гасыр икән, яңа гасыр. Үткәннәр турында уйлану, киләчәк хакында фараз кылу, хыяллану өчен бер уңай форсат.

Телибезме-юкмы, Язмыш тарафыннан бүген татар дип йөртелә торган халыкның Дөнья буйлап сибелгән балалары без. Гыйбрәтле, озын тарихы, заманында шанлы Дәүләте булган борынгы бер кавемнең варислары. Без әле, шөкер, бүген дә исән-сау, һәм, киләчәккә йөз тотып, Кояш астында мәңге яшәү нияте белән хөят кичереп ятабыз. Шундый уйлар белән яшисең икән, табигый, «без каян?», «ни кылабыз?», «кая барабыз?» дигән сораулар бимазаламый кала алмый.

Мәңгелек Кануннар катгый үзгәрешсез булса да, тора-бара, буыннар алышына-алышына, аңыбызда Вакыт һәм Киңлек төшенчәләре дә үзгәрә сыман: вакыт тизрәк ага, киңлек-пространство кысыла бара шикелле... Чынлап, ышанып та куярсың, үткән йөз елдагы үзгәреш-метаморфозалар шаккатырлык! Уйлап багыйк: Җирдә адәм баласы нык үрчеде (димәк, тыгызландык!); Табигать коточкыч таланды (үзебез утырган ботакны кисәбез!); фән-техника өлкәсендә фантастларның да башына килмәгән ачыш-табышлар булды (күбрәк бәхеткә тиендекме?); ил-халыклар арасында, минут-сәгать эчендә дигәндәй, кызу-тиз аралашу-бәйләнешләр урнашты (дуслык-туганлык ныгыдымы?)... Һәр конструктив хакыйкый фактка берничә контрсорау килеп баса. Парадокс: объектив шартлар һәм заманасына хас яшәү шартлары (техник казанышлар уртаклыгы, хәбәр-информация берлеге, максат

юнәлеше...), бер яктан, төрле ил-халыкларны берләшү дәрәҗәсендә якынайтса, ягъни интеграцияләштерсә, икенче яктан, һәр халыкның үзенә генә хас тарихи гадәт-сыйфатларын ныгытып, телне саклап, аерым бер үзгә милләт булып калу тенденциясе, үзсаклау инстинкты көчәя бара... Факт, бу процесс төрле милләттә үзенчәрәк: беренчеләрендә, әйдәүче көч империячелек булса, икенчеләрендә—үзенә бәйсезлек яулау идеясе төп этәргеч булып тора.

XX гасыр—татар милләте өчен аеруча авыр сынау гасыры булды. Алгарыш дәрәҗәсе, табу-югалтулар, стратегик ялгышлар фаҗигаи язмышлар турында Киләчәк үзенең хак сүзен әйтер әле... Хәер, акыл ияләре өчен бүген дә күп нәрсә ачык инде. Бу кыска язмада тирән тарих, сәяси төеннәр, тотрыксыз кануннар, катлаулы икътисад хәлләренә кереп тормыйча, без белгән рухи мирас—якындагы үткән һәм бүгенге әдәбиятыбыз турында чагыштырып уйлану рәвешендә кайбер фикерләребезне бәян итсәк, гайре табигый хәл булмастыр.

Әдәбиятыбыз—байтак дәверләр дәвамында, соңгы гасырда бигрәк тә, милләтне саклап калуда, диннән кала (аларны аерып карап та булмыйдыр), иң төп фактор булды. Халык җаны—догада, китап сүзендә, җыр-моңда сакланды. Нигездә соңгы гасырда оешкан һәм беркадәр үсеш алган сәнгать төрләренең өлешен дә инкяр итәргә җыенмыйбыз—алар да зур рухи чишмәләр—әмма төп чыганак, барыбер, әдәбият бит! Кемнеңдер «нишләр идек фәлән булмаса!» дигәне шикелле, әдәбият (кульязма һәм басмадагысын, халык авыз иҗаты әсәрләрен дә кертеп) булмаса, татар нишләр иде икән дә, кем булыр иде икән? Кимендә, телсез калган, дөресрәге, ана телен күптән югалткан булыр иде. Шөкер, үткән гасырда кан кар-дәшләребез яшәгән төбәкләрдә татар китабы милләттәш-ләребезнең гомер юлдашы булып килде. Күп тә чыкты бит ул китаплар! Дистәләгән мең исемнәрдә, йөзәр миллион данәләрдә... Үткән гасырлардагы акыл ияләре өчен горурланып, авыз тутырып әйтә алабыз: төрки киңлекләрдә генә түгел, тәрәккыятле бөтендөнья масштабында татар әдәбияты дигән зур байлык-хәзинә бар! Бүтән халыкларга да белдерәсе иде, күрсәтәсе иде ул байлыкны, килер буыннар аңына сеңдерәсе иде!

Бүген күңелләрне борчып торган иң төп уйларның берсе шул: яңа гасырда әдәбият үзенең элгәрге миссиясен дәвам итә алырмы? Язучыларыбыз әсәренә ихтыяҗ калырмы? Тере сүзне ясалма аң—компьютер-тамга алыштырып бетермәсме? (Гыйбрәтле хәл: каләмдәшләребезнең байтагы язу машинкасына тиенеп тә өлгермәгән иде әле, инде аларның хаҗәте дә бетеп бара). Әгәр телең югалса, әдәбиятың бетсә, сәнгатең йотылса, нинди мөстәкыйльлек, нинди суверенитет, нинди бәйсезлек булырга мөмкин икән? Бу урында шуны да искәртеп узу урынлы булыр: үзендә милли аң бар дип исәпләгән татар онытмасын иде—коллык кичергән гасырлар буена Дәүләтчелек идеясе тегеңдә йә бу формада иң әүвәл Сүздә—гыйлем ияләренең, шагыйрьләрнең, әдипләрнең язма яки басма хезмәтләрендә ачыктан-ачык, йә Эзоп теле белән эчтән сакланып, үстерелеп килгәндә. 90 елларда беркадәр яуланган суверенитет-мөстәкыйльлегебезнең юл башы—әнә шул ерактагы әдәби офыкларда.

Сер түгел—дөнья тоткан ил-дәүләтләр белән чагыштырганда

без, кызганыч ки, милли байлыкка ия халык түгел. Әйләнә-тирәдә күзгә күренгән хәзинә-байлык, асылда, безнең өчен рәшә генә. (Бер юлаучы, капка ачып, ишек алдындагы кешедән сораган имеш: кем монда хуҗа? Теге Хуҗа исемле кеше икән, әйткән: хуҗасын мин Хуҗа, ә йорт-җир Идриснеке...) Бүгенге көндәге вәзгыять моны бигрәк тә ачык сиздерә. Төп байлыгыбыз—иман, акыл, рухи мирас... Аларның иң күп өлеше—гасырлар буе җыйналып килгән китапларда. Шуңа күрә дә, олуг әдәбият варисларының—бүгенге язучыларның—җәмгыять, киләчәк алдындагы җаваплылыклары ифрат зур дип уйлыйм мин һәм шушы уңайдан, каләмдәшләргә дә искәртәсе килә: тарихи миссиябезне онытмаска, позицияне бирмәскә иде бит! Сүзнең җегәре заман басымына чыдарлык, кешеләрне әйдәрлек булырга тиеш. Юкса, халыкның нинди вөҗданы ди син! Шуңа күрә, хөрмәтле каләмдәш, сиңа да, миңа да үзгәрергә, яңарырга, максат юлларын яңадан карап, барлап чыгарга туры киләчәк. Үзең өчен кадерле, әмма бүтәннәр өчен әлләни әһәмияте булмаган күренешләрне, вакыйгаларны су буе итеп тасвирлау яки хикәяләү чорлары узды. «Фәтхулла хәзрәт»чә фәлсәфә кору дәверләре үтте... Фикерләү рәвеше, язу стиле үзгә булган яңа тип әдипләр заманы килде. Ә без аңа әзерме? «Мин—язучы, мин иҗат иттем, ә каләмхак түләү, китап чыгарып, аны тарату—бүтәннәр вазифасы»,—дип, уйлаучылар күп әле безнең арада. Әйтеп куюлары да бар бит: «Ә кем язарга мәҗбүр итте соң әле сине? Инәлеп сорадыларммы?» Ата-ана үз баласының тормышта урын табуын гомер буе күзәтеп-барлап торган шикелле, язучы да үз әсәренең укучы күңеленә барып ирешүенә инангач кына, беркадәр тынычлана аладыр. Шунсын да онытмыйк: без әлегә талантның халык байлыгы икәнен аңламаган халык мохитендә яшибез.

XXI гасыр—хәтәр гасыр булырга охшап тора. Кояш системасындагы планеталарның Җир белән хәрәкәти мөнәсәбәтләреннән бигрәк (ахырзаман дигән тәгъбир күңелдән китмәсә дә), Табигать белән Кеше, илләр белән державалар, халыклар белән милләтләр (бу төшенчәләр еш бутала...) арасындагы мөнәсәбәтләрнең торган саен кискенләшә баруыннан туган уй бу. Кояш астында, бүтән халыклар арасында туган халкыбызның да үзенә лаек урын алуын теләү—табигый хис. Әмма гасырлар буе коллыкта иза чиккән кавемгә дәүләтле, тулы канлы милләт булу бәхете үзеннән-үзе күктән төшми. Әгәр безнең һәркайсыбыз җанында милли идея формуласы (ул әлегә күбебез аңында эмбрион хәлендә) юк икән, әгәр без тарихи нигезебездә бер йодрык булып тупланмыйбыз (без әлегә һаман таркау һәм дөнья буйлап чәчелгән) икән,—безнең хыялларның буш куык булып калуы бар. Әйе, инкыйраз дигән хәвеф юк түгел. Шунсы куанычлы: булу ихтималы булган бу хәвефне булдырмый калырга көрәшүче көчләр дә бар. Димәк, алда өмет, ышаныч бар!

Ә без—«Казан утлары» хезмәткәрләре, гасыр буе диярлек тупланып килгән күркәм традицияләрне дәвам итеп, журналыбыз яңа XXI гасырда да яшәешебезнең гадел елъязмачысы, килер буыннарның рухи юлдашы булып калсын өчен тырышачакбыз. Яңа Еллар мөбарәк булсын!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре.*

## *Мөдәррис Әгъләм*

### Яңа гасыр кerә

***Үзен саклар өчен баш күтәрде,***
***Мәҗбүр булып баш та иде ул...***
***Яңа гасыр керә...***
***Милләтемә***
***Мәрхәмәтле булса иде ул!***

***Ахырзаман, диләр... Килә икән***
***Киләчәк ул бездән башка да—***
***Яңа гасыр керә...***
***Җылы кулы***
***Кагылыр, бәлки, безнең башка да.***

***Безнең иман калыпланган инде***
***Ата-баба салган калыпта.***
***Яңа гасыр керә...***
***Бәлки, булмас***
***Шул калыпта гына калып та.***

***Үткәннәргә баксак, безнең өскә***
***Зәһәр җилләр исә дә исә.***
***Яңа гасыр керә...***
***Өмет туа***
***Яңа капка ачылды исә.***

***Үткән гасырга без саркып кердек***
***Күз төбеннән тамган яшьләрдә.***
***Яңа гасыр керә...***
***Бар ышаныч—***
***Шул дәвердә яшәр яшьләрдә.***

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



**Якуб Зәнкиев**

## ӨТЕЛГӘН МӘХӘББӘТ

РОМАН

### 1

Төмән педининститутын тәмамлап кайтуына бер атна вакыт узарузмас Зиннурны туган авылы Көмешлесу мәктәбенә укыту эше буенча мөдир итеп билгеләп тә куйдылар.

—Мин үзем авылда укытырга дип соравын сорамадым, тик инде үзебезнең мәктәптә урын барлыгын ишеткәч, каршы сүз әйтмәдем. Сезнең янда булсам, ичмаса кул арагызга керермен, бераз файдам тияр, дип өметләндем,—диде дә әтисенә туры карап:—Берәр ярамаган нәрсә эшләп ташламаганмындыр бит, әткәй?—дип тә өстәде.

Фәтхулла әкәнең кырыс йөзенә елмаю чыкты, маңгаендагы жыерчыклары тәмам язылды.

—Юк, улым, авылга кайтып бик дөрес эшләгәнсең. Алай хата уйлап гөнаһлы булма, бала. Әнкәң белән без бик шат, бик бәхетле. Әлхәмделилла, морадыбызга ирештек. Әйбәт кенә эшләргә, бала-чагага кирәкле белемне бирергә насыйп булсын үзеңә,—диде дә:—Э-эһем!—дип сузып, очланып килгән сакалын сыйпап алды.

Берәр нәрсәгә шик белдерсә, күңеле нидәндер разый булмаса, ул гел шулай «эһем-эһем»ен әйтеп, тамак кыргалап куя иде. Әтисенең гадәтен белгән улы сагая калды:

—Нәрсә әйтмәкче буласың, әткәй?—дип кызыксынды.

---

Якуб ЗӘНКИЕВ *(1917 )—Себердә яшәүче язучы , педагог, фронтовик. Аның Себер татарлары тормышын тасвирлаган, «Иртеш таңнары» роман-дилогиясе «Казан утлары»нда (1994) дөнья күреп, танылу тапты һәм соңыннан ул әсәр Татарстан китап нәшриятында да басылып чыкты. Тубылда яши.*

Әсәрне Кыям Минлебаев редакцияләде.

Ата кеше янә тамагын кыргалады, самавыр янында утырган карчыгы ягына күз салгалады.

—Анаң белән безне икенче нәрсә борчый,—дип башлады ул сүзен.—Гел җәй булып тормас бит, улым, кышы да житәр. Җәй көне җырларсың, кыш көне сызгырырсың, дигән борынгылар. Кышның шул аның корсагы яман зур. Ничек печән житкерербез сыерга, дип төштек әле пошаманга. Хәстәрен хәзердән күрмәсәк, ни хәлләр генә итәрбез икән, дибез.

—Колхоз рәисенә сүз кушасы булыр, әткәй, бер дә кайгырма.

—Иртәнчәк бардым кәнсәгә. Көтеп алдым ул Шыр[1] Шәкүрнең килгәнен.

—Йә, нәрсә ди?

—Нәрсә дисең, Сөенчәл чишмәсе буеннан барып чабарсың, дигән була да бит... Бер дә күңел ятардай урын түгел. Чуп-чар, ботак-сатак басып киткәндер, мөгаен. Рәте булыр микән, дибез... Аннан печән әзерләүче дә юк бугай...

—Нишләп алай итте икән? Карт-корыга юньлерәк урын тапмады микәнни?

—Рәисебез, аптырап, башын кашып утырганда, каһәр төшкере бригадир Хәйрүш кәрбек[2] килеп керде. Шул хәерсезнең «бүләге» ул Сөенчәл...

—Шулай да барып карарга кирәк, әткәй. Бер дә хафаланма, иртәнчәк үзем барып, күз салырмын.

—Каян табасың аны, урман куышлыгын?

—Табармын, әткәй, бер дә кайгырма. Бәлкем әле, кеше аягы асты булмыйча, печәне мул үскәндер... Акбашыбызга житәрлек печәнне йолкыштырып булса да юнәтеп алырбыз, менә күрерсең.

Ниязбикә карчык, иртәнге чәйне эчкәннән соң, улына юлга дип ризык әзерли башлады. Зиннур торып киенгәнче, әнисенең ашъяулыгына төенләнгән азыклары әзер иде инде. Төенчекне улына тоттырды.

—Карурманда ни булмас,—дип, әтисе ау мылтыгы белән патронтажларын чормадан алып төшеп бирде.—Сак була күр, улым, Сөенчәл буенда, Такталда аюлар, бүреләр дә очрый, дип сөйлиләр. Әле генә колхозның иң сөтле сыерын ботарлап ташлаган ул тайга хуҗасы.

Кинәшләр бирелеп, соңгы теләкләр теләнгәч, Зиннур үзләренә печәнлек буласы җирләрне эзләп юлга кузгалды. Актүше дә хуҗасыннан калмады. Тик ул, бичара, ауга барабыз, дип белеп, яшь хуҗаның мылтык алуын хупласа да, чалгының нигә кирәклеген анлый алмады һәм аңардан ераграк йөрү ягын карады.

Аскы ике бүрәнәсе җиргә үк сеңеп барган өйләре егетне яңа юлга моңаеп кына озатып калды. «Азрак күзне ачкач, йортны бераз сипләтәсе бар икән әле... Ихатаны да яңартасы булыр...»—дип егет үзалдына уйланып алды.

Әнисе, бөтен җыерчыклары белән елмаеп, догасын укыды.

—Чат Ибраһим ишан улы Абдулла солдат инде,—диде Ниязбикә карчык улының буй-сынына сокlануын яшермичә карап торгач.—Олатасы[3] да үз гомерендә берәүгә дә бил бирмәде. Көче-осталыгы дисеңме, акыл-белемеме—барысын да Ходай мулдан биргән иде үзенә. Мәрхәмәтле-шәфкатьле булуын әле хәзер дә сагынып сөйлиләр. Алла боерса, Зиннурыбыз да олатасы кебек булдыклы булыр. Белемен дә алды, инде бәхетехәере белән юньле кызга өйләнсен иде,—дип сүзне җайлап кына үзен борчыган мәсьәлә ягына борды.

—Әйе, карчык, ирне ефәккә төргән дә, чүбеккә чорнаган да хатын инде. Аллага шөкер, без синең белән бик матур гомер иттек,—дип сабыр гына җөпләп куйды карт.

---

[1]Шыр—мактанчык.

[2]Кәрбек—тырпайган колаклы.

[3]Олата—дәү әти, бабай.

Картының уйга калуын күреп, Ниязбикә карчык әкрен генә сүзен дәвам иттерде:

—Синайтәм, кара әле,—диде дә сүзенен житдилеген белдереп тамагын кырды,—минем Зиннурга дип күз төшереп йөргән бер кызым да бар бит. Бик унган, булдыклы балакаем, тик менә...—Карчык, әйтергәме-юкмы дигәндәй сөрлегеп, туктап калды. Кешене бүлдерергә күнекмәгән карт сүзнең ахырын көтте.—Бераз яшьрәк кенә...

—Кем дип белик инде ул сылуны?

—Күзенне йомып йөрмәсәң, син дә аны көн дә очратасың булыр. Хәмит белән Хәлимә күршеләребезнен кызы соң?

—Нурия кызымны әйтәсенме, ул әле бала гына лабаса. Аннан килеп Зиннурда укыячак та түгелме соң әле ул?

—Бүрек белән бәреп екмаслык булган кызны элек-электән кияүгә чыгарлык дип санаганнар. Без туй хәзерлекләрен күргән арада унсигезе дә тулыр әле, боерган булса. Өлкән балаларны кайтарып булмый инде, төпчегебезне яныбызда калдыру өчен башлы-күзле итү дәртенә керешә башлау кирәк. Авылны инләп-буйлап эзләсәк тә Нуриядән иплерәк кызны таба алмабыз.

Зиннур аларның көтеп алган кадерле балалары иде. Алдагы дүртесе бер-бер артлы якты дөньядан китә барды. Гомеркәйләре кыска булды шул...

—Шулаен шулай да, улыбыз үзе ни әйтер бит әле.—Сүзне озакка сузып, вакыт әрәм итәргә күнекмәгән карт шушылай фикерен очлап куйды.

Картыннан аермалы буларак, Ниязбикә карчык улларының да Нуриягә битараф булмавын, аеруча соңгы кайтуында кызның артыннан күзләрен тутырып карап калуларын, аның алдында үзен әллә ничек каушаганрак итеп тотуларын сизеп, хәерлегә юрап та куйган иде инде. Ләкин менә кибеттә сатучы булып эшләүче Тансылу гына карчыкның кәефен кырып тора. «Эшне бозып куймаса ярар иде, каһәр төшкән, гел Зиннур тирәсендә бөтерелә ул кызый. Халык юкны сөйләмәс, әллә нинди бозыклыклары ишетелә чибәркәйнен. Бәласеннән башаяк, әйттем исә кайттым»,—дип, як-ягына төкеренеп, ирексездән күнеленә килеп, үзен пошаманга салган бу уйларны тизрәк куарга тырышты карчык.

## 2

Көмешлесу авылының ындыр артыннан ук эрбет урманы башлана. Әллә нинди горур купшылык бар бу агачларда. Каракучкыл озын ылыслы ботаклары жиргә үк тигән, баһадирдай төп-төз кәүсәләре кояшка сузылган. Жиде-сигез йөз ел буе яшәп, ничә буын кешеләрнен бу якты дөньяга килеп, мәнгелеккә юл алуын күргән алар. Йодрык-йодрык зурлыктагы күркәләре купшы койрыклы житез тиеннәр, асыл тиреле кеш малларга[1] , варап кошларга[2] да житәрлек, кыш буе авыл халкын туендырырлык чикләвек бирә торган юмарт агач ул эрбет. Халык өстенә афәт, ачлык килгәндә шул агачлар ничәмә кешеләрнен жанын асрап калган.

Агачлар арасыннан жемелдәп, энже бөртекләредәй күзне чагылдырган кояш нурларына үзе дә сизмәстән елмаеп барган егет, түмгәккә абынып, барып төшкәч кенә, исенә килгәндәй булды. Әллә нинди серле дөнья бу урман! Тирә-як тып-тын булса да, Зиннур монда никадәр жан иясе яшәвен белеп тора. Менә хәзер дә эчке сиземе аны сагаерга мәжбүр итте: кырык-илле адым гына алдарак, агач ботагыдай мөгезләрен тырпайтып, кечкенә бозавын ияртеп, пошы килеп чыкты. Әлегә кадәр тыныч кына барган Актүш тә сырт йоннарын тырпайтып, ырылдарга

[1]Кеш мал—каманың бер төре.
[2]Варап кош—эрбет чыпчыгы.

тотынды. Хуҗасы этен, тынычландыру өчен үз янына чакырып, башыннан сыйпады:

—Аларга тиярга ярамый, Актүш, әнә бит аның кечкенә бозавы бар. Әнкәсен атсак, ул ятим калачак, тимә, яме,—дип пышылдады.

Эт белән хуҗа уртак фикергә килгәнче бернәрсә дә сизенмәгән бозау әнкәсенә сыпыргаланып уйнаклап үтеп тә китте. Әнкә поши, горур башын төз тотып, як-ягына каранган арада, бозавы имеп тә алгандай итенде. Үзенә игътибар җәлеп иттермәскә тырышып, тып-тын калып байтак утырган күрәсең, Зиннур. Актүш тынычсызланып, хуҗасына танавы белән төртеп куйгач кына, исенә килде. Бала чактан битараф булмады шул хайваннарга. «Урман сыеры» дияр иде олатасы пошиларны. Зиннур гына монын белән килешергә бик атлыгып тормый иде: башларын төз, горур тоткан бу җан ияләре аларның Акбашларына түгел, күбрәк әкиятләрдәге Акбүз атларга охшый иде...

Бу әкияти тамашаны күзәтеп утыру никадәр күнелле булмасын, егеткә юлын дәвам иттерү кирәк. Исәпләве буенча, чишмәгә дә ерак калмаган булыр. Зиннур барган урман сукмагының сул ягында колхоз жире булып, уң ягы казна урманлыгы булырга тиеш. Ара-тирә очраган аланлыкларда аз-маз чабарлык печән дә күренгәли. Колхоз жирендә үлән тыгызрак күренә, чырмавык үләннәр арасында клевер, агайрык[1], суыт[2] үләннәре дә бар. Күпчелек урынны абага үләне баскан. Анысын сыер ашамый инде. Арырак күкле-зәңгәрле чәчәкләр үсеп утыра. Бөрлегән, каен җиләкләрен жыючы кыз-кыркын да бу тирәгә үк килеп житмәгән ахры, алар авылга якынрак жирләрдә дә житәрлек. Зиннурның кәгазендә күрсәтелгән уң як жирләрдә печән дигәнең бик сирәк, кәҗә сакалы кебек кенә жилфердәп утыра: күрәсең, бу тирәдән сазлыклар башланадыр. Җиләкләре дә икенче монда: нарат җиләге, саз җиләге, түмгәк өсләренә торнакүз[3] сибелгән. Урманда кеше ачка үлми, диләр, Зиннур да күнеле теләгәненнән авыз итте. Җиләкләрнең кайсы әчкелтем, кайсы төчкелтем тәм белән авызда эреп югала тордылар. Әллә нишләтә әрбет урманы кешене, һавасының сафлыгы күкрәкләрне киңәйтә, беләккә көч, күнелгә дәрт бирә, тәмам сихәтләндерә адәм баласын.

Сөенчәл чишмәсенең чылтыраган тавышы урманның тонык шавына үзенчәлекле ямь өстәгәндәй тоелды. Чишмәгә иелеп, учлап-учлап тешләрне камаштырырлык салкын суын эчте егет, битләрен юып рәхәтләнде һәм чалкан ятып хәл алырга уйлады. Шул арада күктән ингәндәй көтүче Чамакә пәйда булды. Тулы исеме Чамалетдин булса да, авылда аны барысы Чамакә дип кенә йөртәләр. Ул да көтүен бер чакрым чамасы жирдә калдырып, чишмә суына килгән икән.

—Исәнме, Зиннур туган! Нинди жилләр ташлады дисәм, бүген жил дә юк бугай?

—Менә казна жиреннән печәнлек эзләп килүем иде дә, түмгәк башларыннан бүтән бернәрсә дә күренми шикелле.

—Әнә теге яктарак булмадыңмы әле?—Көтүче чишмә суы агып төшеп бөяләнеп тора торган, элегрәк көтүне сугару урыны булган якка чыбыркы сабы белән төртеп күрсәтте.—Анда кибән утыртырлык урын бар-барын, ләкин якында гына көрән аю йөри. Көтүдән бер сыерны ботарлап киткәч, шүрләп куйдым, хайваннарны анда сугармыйм хәзер. Үзенә ташланырга да күп сорап тормас, үзен чын хуҗа кебек тота ул монда. Шыр Шәкүргә әйткән идем—«Көтүеннән колак кагасын килмәсә, аючы тап», ди. Таяк тотып, көтү чыбыркысы белән аюга каршы бара алмыйм бит инде мин!..

Чамакә, үз зарын сөйләп бетергәч, йөзен Зиннурга борды.

—Синең мылтыгың бар барын... Тик, аю күргәч, югалып калмас-

---

[1]Агайрык—актамыр, сарут.
[2]Суыт—кыяк үләне, күрән.
[3]Торнакүз—мүк җиләге.

сынмы? Күп «батырлар» шыр җибәрә, аны күргәч. Син дә теленне йоттың, ахры...

—Безнең нәсел аючылар исемен йөртә, берчак әткәй белән бергәләп ике аюны атканыбыз бар. Институтта да төз атканым өчен «Ворошиловский стрелок» значогын йөрттем. Теләсәм, агач башындагы тиеннең күзенә дә тидерә алам.

—Булдыклылыгыңа бер дә шикләнмим, ләкин аю тиен түгел шул. Тиенне мин үзем дә бәреп төшерә алыр идем, ә күрән аюга якын барсам, тезләрем калтырый. Аждаһадай бакыра бит ул. Мәргән дә булгач, күрсәт егетлегеңне, яулап ал печәнлегенне урман хуҗасыннан.

—Ярый, Чамакә әкә, чүбек чәйнәп май чыкмый, барып карыйм булмаса, мондагы корган план анда барыбер ярамас. Аю саклый дип, печәнсез кайтып булмый бит инде.

Халык әллә ниләр сөйли аю хакында, үзе ботарлаган хайванның итен дә әзрәк исләнә төшкәч кенә ашый, диләр. Бәлки әле, һаман шул элеккеге урынында итен сагалап ята булыр. Шулай да Зиннур тәвәккәлләргә ниятләде, тик инде, ышанычлырак булсын дип, гәптәшенә сүз кушып карады:

—Икәүләп барыйкмы әллә, Чамакә әкә? Беребез алдаштырыр, икенчебез маңгай уртасына мылтыктан кургаш укны кундырыр.

—Юк, малай, миннән булмый ул эш. Аюны еракта күрсәм дә, эчем йомшап китә минем. Син дә кызулык белән генә шыттырасыңдыр әле...

Көтүче күрсәткән якка ара-тирә күз салгалап, Зиннур җайлырак урын тапты, әнисенең төенчегән куеп, чишәргә керешге. Ашъяулыкны җәеп дәстәрхан итте дә, аңа пешкән бәрәңге, йомыркаларны, ипи кисәкләрен тезеп салды. Көтүчене «табын» янына чакырды. Әлегә хәтле аякларына башын салып тын гына яткан Актүш тә, башын калкытып, хуҗасы янынарак елышты. Чамакә исә көтүдәге әлеге аюга ризык булган юаш Мәрүскәне савып, рәхәтләнеп тамак туйдырган чакларын сөйләп алды.

—Бүген теге албасты Туйбикәнең күрән сыеры Сөтлебикәне саварга җыенган идем, тибеп екмасынмы үземне! Шулкадәр дә хуҗасына охшар икән, мәхлук. Син булмасаң, бүген корсакны гына кашып йөрисе булыр иде, Ниязбикә әбигә миннән рәхмәтләр житкерерсең.

Тамак ялгап алгач, Зиннур ау өчен кирәкле нәрсәләрнең барын кабат тикшереп чыкты. Кушмылтыгын әйбәтләп корды, ау пычагын кынынан алып, үткенлеген тикшерде, каешын кысыбрак бәйләде. Бөтен кирәк-яраклары тәртиптә икәненә ышангач, тәвәккәлләп, көтүче күрсәткән якка юл алды. Актүш тә күп күргән хайван, хуҗасының һәр ымын аңлап, җиренә җиткереп үтәргә тырыша. Әнә хәзер дә җирдән шуышып диярлек бара, тукталып тыңлап торгандай итә. Зиннур ашыкмыйча, аяк астындагы чыбык-чабыкны шартлатып сындырмаска тырышып, тычканга ташланырга әзерләнгән мәче кебек атлый.

Печәнлек «хуҗасын» күп эзләргә туры килмәде аучыларга. Бөтен шартын туры китереп, агач күләгәсендә рәхәтләнеп сузылып яткан аюны Актүш әллә кайдан сизеп алды. Җилнең каршы яктан исүе дә алар файдасына булды: күрән җанвар аларның якынлашуын сизмәячәк. Зиннур ату өчен уңайлырак урын сайлап як-ягына каранды һәм кушылып үк диярлек үскән ике эрбет артына яшеренеп, мылтыгын җайлады. Гөрселдәгән тавыш һәм колак артыннан ярып үткәндәй тоелган ут көлтәсе ерткычны чыгырыннан чыгарды. Арт аякларына баскан җанвар, бөтен дөньясын җимерергә теләгәндәй үкереп, үзенең тынычлыгын бозарга җөрьәт итүчеләргә ташланды. Мондый чакларда үзен ничек тотарга икәнне бик әйбәт белгән эт, хуҗасының кушуы белән үк, аюның артына барып ябышты. Бу хәлне көтмәгән аю, борылып, тешләүчене өзгәләп ташларга әзер булып, котырына, бәргәләнә башлады. Үз эшен бик белеп, осталарча башкарган Актүш исә тешләрен ычкындырырга уйламады. Моннан

файдаланган егет аюның борын төбенә үк якынлашты, уңайлы вакытны туры китереп, ерткычның нәкъ маңгай уртасына турылап атып җибәрде. Бер секундта җанварны көзән җыергандай булды, ал аякларын күккә күтәреп, бер үкерде дә тайга баһадиры, гөрселдәп, аучының аяк астына авып төште. Шушы берничә минут эчендә шабыр тиргә баткан Зиннур да, буыннары йомшарып, җиргә чүкте, хәзер генә исенә килгән кешедәй, бар көченә кысып тоткан кулын язып, мылтыгын ычкындырырга тырышты. Бармаклар хуҗасын тыңламыйча интектерде.

Әзрәк хәл алгач, Зиннур бая көтүче белән утырган җирләренә табан атлады. Анда көтүчене тапмагач, көтүлекне эзләп әйләнә-тирәне айкады.

Чамакә аны бер үк вакытта исе китүне дә, ышанып җитмәүне дә белдергән тавыш белән:

—Әллә булдырдың да инде?—дип каршы алды.

—Андый гына эш безгә чүп тә тормый,—дип шаяргандай итте егет.—Авылга кайтарырга булышсаң, сиңа да бер колагы тияр иде.

Үз күзләре белән барып күрмичә, ышанмады Чамакә. Әйе, сынатмады болай булгач егет, сынатмады!

Аюны авылга көтүченең аты белән сөйрәтеп алып кайтырга булдылар. Ат исне сизмәсен өчен, учак кабызып, төтен килгән якка бастырдылар. Аюның корсак астыннан чыгарып ике-өч урыннан ныклап элмәк салгач, арканны атның камытлыгына ныклап бәйләделәр. Зиннур үзе дә атка атланып, ерткычны җирдән сөйрәтеп китте. Төтен булганда аю исен сизмәгән бахбай йөкне җайлы гына тартып юрта башлады. Үзен бу эшнең төп батыры итеп санаган Актүш, койрыгын болгап, әле йөкнең бер ягына, әле икенче ягына чыгып йөгерә, булдырдык бит, дигән кебек, өргәләп тә ала иде. Урман ачыклыгынарак чыккан арада, күрәсең, җил икенче юнәлешкә борылгандыр. Аю исен сизенгән бахбайны алыштырып куйдылар диярсең: борынын киереп пошкырып җибәрде, артын чөеп кушаяклап тибә-тибә, акны-караны күрмәстән алга ыргылды. Зиннур йөрәксегән атның тезгенен никадәр тартмасын, атны чабудан туктата алмады. Алай гына да түгел, өстендәге егетне ыргытып ташлау өчен тагын да ныграк тартыша, котырыбрак чабарга тотынды. Артыннан калмаган җанварны сизенеп, куа килә, дип уйлады бугай. Мондый кискен үзгәрешне көтмәгән Актүш үз-үзен белештермичә өрә, атның алдына чыгып нәрсәдер аңлатырга тырыша. Шул хәйләне дә аңламаган атка ярсып, өзгәләп ташлардай булып ырлый. Котырынып авылга килеп кергәндә, атның корсак астыннан йомры-йомры күбек шарчыклары коела, этнең өрә-өрә әлсерәүдән теле салынган, куркуыннан акылдан язардай булган Зиннур атның ялына чытырдап ябышкан иде. Бу хәйран тамаша яшен тизлеге белән, юл тузанын куптарып авылның югары очына ыргылды. Кигәвеннән качып, агач ышыкларында йокымсырап торган сыер-бозаулар мөгрәшеп, күзләре акаеп, кая барып керергә белми, чабыша башладылар. Котлары очкан этләр, койрыкларын кысып, чинап, ояларына кереп яттылар, кыюраклары җилкапка асларыннан башларын күрсәтеп, бөтен дөньяны җыеп һау-һауларга тотындылар, аючы Кадыйр әкәнекеләр исә, ырлап, җирдән сөйрәлеп килгән җанварга барып ябыштылар. Күзләре маңгаена менгән авыл халкы урамга ташланды, өлгеррәкләр югары очка ук йөгерде. Бер минут эчендә авылда мәхшәр купты.

Мәгәр тамашаның ахыры кызыксызрак очланды: әлләничә чакрым арадан центнерлы җанварны мамык урынына очыртып алып кайткан атны туктатырлык көч юк иде егеттә. Күзе тонган бахбай үзе колхоз амбарының эрбет баганалы зур капкаларына килеп бәрелеп, авып төшмәсә, Зиннур ни эшләгән булыр иде, әйтүе кыен. Ул исенә килеп, ау пычагы белән атны арканнардан ычкындырырга керешкәндә, хайван яткан урынында тартыша ук башлады. Ни эшләргә белмичә, атны торгызырга, башын күтәрергә тырышып карады егет, ләкин эш узган иде инде. Сөлектәй матур хайванның тамагына гырылдавык төште, тәннәре дер-

дер калтырый иде. Бригадир Хәйрүш килеп житкәндә, атнын әле жаны бар иде.

Зиннурнын:

—Ичмаса, ите колхозчыларга ашарга ярар,—дип, атны бугазларга жыенганын күреп:

—Мондый заманда колхоз атын үтергән өчен ни буласын беләсенме, өеңне сатып та түли алмыйсын бит син аны,—дип жикеренде «хужа», үзенең кем икәнен тагын бер кат күрсәтим дигәндәй. Үзе турында уйламыйча да тарткалашкан кешеләргә рәнжеп, тагын бер кат тутырып карады да хайван, жан тәслим кылды...

Әле генә укытучы итеп билгеләнгән егетнен кыюлыгына исләре китеп, тел шартлатучылар аз булмады: хәбәр жил тизлеге белән югары очтан түбән очтагыларга житкерелде, ул көнне телләрдә шул вакыйга гына булды. Сонгы көннәрдә авыл халкын куркуга салган явызны карарга жыелган агай-эне Зиннурга аю тиресен тунарга ярдәм итте. Егет үз табышынын тиресен, бераз маен гына үзенә алып, калган мае белән итен Чамакәгә тапшырды. Аю маенын кадерен авыл халкы бик белә: суык тисә дә, аяк-кул өшесә дә—алыштыргысыз дару ул. Куркыныч чахотка авыруын да шунын белән дәвалаган халык. Шунын өчен аю атучыларга баш иеп килүчеләр күп булган. Менә хәзер дә Зиннур, күршесе Хәмит әкәнен сонгы вакытларда аеруча ютәлдән жәфа чигүен исенә төшереп, мае тамып торган симез жанварнын ин яхшы саналган эч маен умырып кисеп алды да чиләккә салды. Юл унаенда сәбәбен ул әле үзеннән-үзе үк яшерергә тырышты. Хәбәр бу очка да житкән күрәсен, жилкапкада Зиннур күренүгә үк, өйдән Нурия балкып килеп чыкты. Бергә үсәләр дә, егет булып житкән күрше абыйсыннан бераз тартына, ояла башлаган иде яшүсмер кыз. Әле дә күзләренә туры карамаска тырышып, ләкин шатлыгын яшермичә, аны мактады, өйгә чакырды, әллә ничек сүзсез калган күрше абыйсын балачактагы кебек кулыннан житәкләп алып, өйгә әйдәде. Алар килеп кергәндә, кулларын күкрәгенә салып яткан Хәмит әкә күтәрелеп карады, исәнләшкәндәй итте һәм тончыгып, ютәлләп китте. Нуриянен шатлык чәчкән күзләре монсуланып калды, кунак ягына карамаска тырышты. Күршеләреннән хәл-әхвәл сорашкач, Зиннур тиз генә чиләкне хужабикәгә сузды:

—Менә, Хәмит әкәгә шифасы булмасмы дип керткән идем,—дип сүзен йомгакларга ашыкты.

Хәлимә апа, иреннән бүтән үзен ышандырырга тырышкандай:

—Менә рәхмәт, Зиннур улым, исенә төшереп керткәнен өчен, Ходай кушкан булса, сулыш алуларын да жиненәйтер, ютәлләрен дә йомшартыр. Аю маеннан да шәп дәва юк инде ана, бу хәтле маймы, бу хәтле май әле...—дип сөйләнә-сөйләнә, учак астын кабызды, ап-ак майны казанга салып, чыжлатып эретергә үк керешге.

Хәмит әкә исә күзләре белән ымлап, кызны үзенә чакырды һәм нидер пышылдады, ә тегесе түр яктагы сәке буена үтеп, ястыклар арасында казынды да, кызарынган йөзен яшерергә тырышып, абыйсына акча сузды.

Бу хәл егетне тагын да каушатты, ул тизрәк ишек тоткасына үрелде:

—Юк, Хәмит әкә, мин аны сатырга кертмәдем. Шифасы гына була күрсен, терелә күр,—дип, чыгу юлын карады.

Нуриянен озын керфекле күзләре янадан елмайды, кызнын әти-әнисе дә күршеләренен игелекле улларына бәхет теләп, мен рәхмәтле булып калды...

Көтүче Чамакәдән аюнын ит-маен сорап килүчеләр аз булмады, хәтта әле күрше авыллардан да бу могжизаны ишетеп килүчеләр табылды. Аю мае тәбәрлеккә[1] әверелде. Ачлы-туклы көн күргән көтүчегә ризыклар Ходанын кодрәте белән күктән яуды. Ертык чалбарлы көтүче күлмәк-ыштанлы булды, анын исеме телләрдән төшмәде. Ә яшь укытучынын

[1]Тәбәрлек—кадерле нәрсә.

батырлыгы, мәргәнлеге телләрдән-телләргә күчеп, риваятькә әверелде. Тайга авызына урнашкан авыл халкы өчен аю ату дөньяда булмаган хәл дип саналмаса да, Зиннур кебек, җинелдән генә, печән чабарга киткән җирдән аю сөйрәтеп кайтучылар юк иде әле. Аюы да нинди диген әле: алагаем зур, көчле ата аю. Атаклы аючылар да мондый уңыш белән еш мактана алмый...

### 3

Авылның исеме аның уртасыннан челтерәп аккан чишмә исеменнән алынган. Көмешлесу чишмәсе Уба тавыннан агып чыга да кояш нурларында чагылган энҗе бөртекләредәй саф суыннан елгачык хасил итә. Суы шулкадәр чиста аның, төбендәге вак ташлар, кечкенә балык, маймычлар да көзгедәгедәй күренеп торалар. Чишмә агып төшеп, Кытай җирендәге Зайсан күленнән башланган олпат Иртешкә коя. 4248 чакырымга сузылган бу олы Себер елгасының юлында санап бетергесез мондый чишмәләр. Ил төкерсә—күл булыр, ди халык. Әнә шундый меңләгән чишмә-елгачыклар аны туендыра, яшәү көче бирә. Көмешлесу да чал Иртешнең уйнак нәбәрәсе[1] кебек: кояш нурларында күзләрне чагылдырып, яшь килевнәрнең чулпылары чыңлавын хәтерләтеп, чылтырап көлә, назланып ага, уйнаклап боргалана да, иркә песи баласыдай, олатасының култык астына кереп, тынычлана. Мәшһүр Иртеш авылның көньягыннан уза, ә төньягыннан ярымбоҗра булып Уба таулары сузылган. Ындыр артыннан гына Кедрач башлана, ул балыклары белән дан тоткан Йогәр күлгә барып тоташа. Анда сап-сары алтындай тәнкәле табан балыклары дисеңме, кызыл канат, усал чуртанмыдыр—кайнап тора. Кеше күзеннән читтәрәк мыймылдаган симез батар үрдәкләр өер-өер булып балык аулыйлар, камышлыкларында аккошлар бала чыгара. Таң алдыннан, көн кунганда хәйран тамаша монда: күл өстен каплап, пыр-пыр килеп төрле үрдәкләр оча. Әллә нинди хикмәтләләре бар аларның да: кара үрдәкләр, күгәлләр, чумгалар, батарлар, чүрәкәйләр, кылкойрыклар... Үз телләрендә җанашлары, балакайлары белән әңгәмә алып баралар, иркәләнәләр, сөешәләр. Бик белеп, ризыклы урынны сайлап утырганнар Көмешлесу халкының ата-бабалары.

Авыл аша кыш көннәрендә Тубыл каласын икмәккә бай Эшле яклары белән тоташтырган юл уза. Элегрәк көне-төне юлаучылар балык төялгән чаналарын шыгырдатып Зиннурларның тәрәзә төбеннән үтеп китәләр иде. Үшәнгәннәр чәй эчәргә, ат ашатырга да тукталгалыйлар, шуна аларның дәү корсаклы сары самавырлары өстәл өстендә көне-төне пышкылдап утырыр иде.

Хәзер, колхозлар төзелгәч, ул юллар өзелде. Зиннурларның шаугәр килеп торган ике катлы йорты, намазда сәҗдәгә киткән карт кебек, кыйбла ягына авышкан. Әгәр теле булса, бу йорт монда гомер кичергән кешеләр язмышы хакында күп нәрсәләр бәян итәр иде. Вакытында авылның күрке булып торган бу йортны үз куллары белән Зиннурның олатасы—Чиркәс Абдулла салып чыккан. Тәрәзә капкачлары, өй кыеклары күпләрне сокландырырлык итеп бизәкләп, агачны киртләп эшләнгән, югары өйнең көньякка караган ягындагы сәелханә-балкон да Себер татар авылларында гына була торган галәмәт. Май чүлмәге тышыннан билгеле, ди халык. Кыскасы, бу йорт, хуҗасының бик үк гади кеше булмавын раслап торган дәлил кебек, бик горур утырган, оныкларына кадәр күп истәлекләрне саклаган.

... Абдулла дигәнебезнең Себер якларына килеп урнашуын да хәзер кызыклы риваять итеп сөйләрлек. Патша армиясендә хезмәт иткәндә кызу канлы егет бер исерек офицер белән сүзгә килә. Горур халык баласы бит: үзенә кычкыру, кул күтәрүне кичерми. Нәтиҗәдә офицер

[1] Нәбәрә—онык.

үлә, хәрби трибунал солдатны да атарга дигән карар чыгара. Бу хәбәрне ишеткәч, Абдулланың әтисе—Ибраһим ишан Кавказдан Петербургка, патша хәзрәтләренә юл тота. Баш иеп, исән калдыруларын сорый, булган алтын-хәзинәләрен чыгарып сала. Иелгән башны кылыч кисми, улы хакына бөтен нәрсәгә дә риза булып килгән ишанның дини дәрәҗәсе тәэсир иткәнме падишаһыбызга, әллә затлы бүләкләрме—анысы берәүгә дә мәгълүм түгел, әмма карар үзгәртелә, солдат Себергә мәңгелек каторгага озатыла. Күзләрендә очкын уйнап торган кызу канлы чиркәс егете куе тайга, күлләр илендә урнашкан бер татар авылына—сабыр холыклы халык арасына килеп төшә. Гомерлек яшәр урын гына түгел, үзенең мәхәббәтен дә таба ул монда. Авыл мулласының кызы Нәфисәгә гашыйк була егет. Шомырт кара күзле, киң җилкәле, кулларында ут уйнатырлык асыл егеткә Нәфисә дә бер күрүендә гашыйк була. Тәвәккәллек тә юк түгел Чиркәс Абдуллада, кызның риза буласын белгәч, сорап әтисенә керә. Бохар мулла кияү буласы егетне икенче килеп йөрмәслек итеп, кисәү агачы белән «өшкереп» чыгара. Кыз да тешләгән җиреннән өзеп ала торган зат: әтисе риза булмагач, Абдуллага ябышып чыга. Һәм алар Йөгәр күлдән дә арырак, куе урман эченә урнашкан кечкенә бер күл буена качалар. Иң матур, мәхәббәтле көннәрен үзләре корган шалашта үткәрә алар. Күл буенда тамаклары тук була яшь парның, ләкин озакламый салкын көз килә, кышлар якынлаша. Кышның зәмһәрир суыкларын монда үткәреп булмаячагын аңлаган яшьләр аучы, балыкчылар аша әти-әниләреннән ризалык бирүләрен соратып карыйлар. Йомшармый атаның күнеле, теләндә бер генә сүз: «Үтерәм явызларны!» Күл өсте боз белән капланып, җир өстендә ак күбәләкләр өерелә башлагач, яшьләр Көмешлесуга кайтырга мәҗбүр булалар. Туган йортына кереп, атасы алдына тезләнә Нәфисә, башын иеп атасыннан тагын хәер-фатиха сорый, гафу итүен үтенә. Кызының күз яшьләре түгел, иң соныннан әйтелгән сүзләре акылга китерә үзсүзле картны. Ничек тә атасының күнелен йомшарта алмаган кыз иң сонында: «Мин синең алдыңда гаепле, әткәй, теләсәң ни эшләт, ләкин үтерсәң, белеп тор: минем белән бергә карынымдагы оныгыңны да үтерәсен»,—дип соңгы картасын чыгарып сала.

Уйга кала карт, төн буе күз йоммыйча йөреп чыга. Остабикә карчык та, кызы Нәфисә дә картның авызыннан ләм-мим сүз ишетмиләр, сорарга түгел, якын килергә шикләнәләр. Ул-бу булмагач, бәлки кичергәндер дип, үз-үзләрен тынычландыралар.

Бохар мулланың болай гына сабырланасына өмет иткән гаиләсе нык ялгыша: су сибеп кенә бастырам димә икән бәгырьләргә капкан хурлык утын. Юк, болай гына калдырачак түгел, шул килмешәкнең токымын корытачак әле ул. Кызының соңгы сүзләре чыгырыннан чыгара картны, ләкин кул күтәреп сугудан үз-үзен тыеп кала. «Нәфисә түгел, кызының башын әйләндергән әнә шул килмешәк чиркәсне юк итәргә кирәк!» Төн буе керфек какмаган картның карары шул була. Аучылар арасында ышанычлы кешеләре юк түгел картның, «ау»ның бәясе алдан ук билгеләнгәч, эшне озакка сузмыйча, шушы көннәрдә үк төгәлләргә килешәләр.

Ауга өчәүләп чыгып китәләр: Абдулла солдат алдан атлый, ә «аучылар» биш-ун адым арттарак бара. Урманга кереп тә байтак атлый болар. Күнеле нәрсәдер сизенгән егет сүз башлап караса да, кырт өзә тегеләр. «Хәерлегә түгел бу,—дип уйлый күз кырые белән тегеләрнең бер-берсенә карашып, ым кагып куюын күреп калган чиркәс,—кулны куроктан ычкындырмавың хәерлерәк». Аучыларның берәрсе мылтыгын иңбашыннан ала башлады исә, урман мәчесе елгырлыгы белән мылтыгын тегеләргә төбәп тә куя патша хәзрәтләренең башбирмәс солдаты. Күз угы дигәнең шундый буладыр инде, шомырт кара күзләре үк атардай булып карый егетнең, артыннан килгән аучыларны үтәли тишәр кебек тоела. Мылтыкларын сыйпаштырып, бернәрсә дә булмаган кебек, юлларын дәвам итә болар. Көн буе йөреп тә, мулла киявенең көйдерердәй күз карашыннан ычкына алмый аучылар.

—Әүлиядер ул, валлаһи!—диләр аучылар, хәзрәт янына кереп.—Безнең уйны белеп, бер минутка да мылтыгыннан аерылмады, ул түгел, без анын мылтыгы астында йөргәндәй булдык.

—Гомере озын икән бәдбәхетнең,—дип мыгырданып кала мулла, карап торган бердәнбер кызы Нәфисәне нәсел-нәсебе дә билгеле булмаган килмешәк бер чиркәс баласына бирергә ризалык белдерә. Киявенең мөселман баласы булып, ерак Кавказ якларындагы ишан улы булуы гына бераз тынычландыра карт мулланы.

Бу вакыйгалардан соң байтак гомерләр үткән, исәпсез сулар аккан. Абдулла солдат белән Нәфисә берсеннән-берсе үткенрәк дүрт ир бала үстерәләр. Зиннур аларның Фәтхулла исемле балаларыннан туган нәбәрәләре була инде. Сабыр акыл белән булдыклылык, үз дигәненә ирешү кебек сыйфатлар—егеткә әбисе һәм олатасы тарафыннан калдырылган олы мирас. Хәтерли әле Зиннур олатасын, картайганчы кызу канлы, ярсу йөрәкле булып калды ул. Бер вакыйга, уеннан чыккан уймак аеруча исендә калган Зиннурның. Әллә кайчаннан бирле сакланып килгән бер чиләк ат бәкәлләрен шыңгырдатып бушаталар. Кызылга буялган ин саллы бәкәл—«сага» белән унбиш-егерме адымнан, чиратлашып, тезеп куелган бәкәлләргә бәрәләр. Бер олатасы җыя үзе откан бәкәлләрне, бер нәбәрәсе үз ягына ташлый авып төшкән уенчыкларны. Уен кызып кына китте дигәндә, көтмәгән хәл килеп чыга: Зиннур ташлаган сага, очып барып, бәкәлләрне тезеп торган олатасының чигәсенә килеп тия. Нәбәрәсенең бу эшен шаяру дип кабул иткән карт, чигәсендәге ярасын тотып, малай артыннан куып китә. Картның оныгы бит, Зиннур да эшнең кай якка авышканын тиз үк шәйли, ике дә уйлап тормастан, куе кычыткан арасына чума. Кычытканны чабарга дип, чалгы алырга кереп китә олатасы. Ул арада малайның кычыткан арасыннан чыгып, эт оясына кереп ятуын күреп калган Нәфисә карчык исә эт оясын куна тактасы белән каплап та куя.

Өч тәүлек яши эт оясында малай. Олатасы күрмәгәндә сөт, тукачлар[1] чыгара әбисе, печән арасына йомырка тәгәрәтә. Чигәдәге яра төзәлеп, каны суына төшкәч, Абдулла солдат тиктормас нәбәрәсен юксына башлый. Моны сизенгән карчыгы чыгып, Зиннурны җитәкләп алып керә. Малай бабасы алдына килеп, яшьле күзләрен уа.

—Әй, шайтан малай, үземә охшаган шул син,—дип көлемсерәп, анын башыннан сыйпый карт һәм сөеп кенә бармак янап куя.

Олатасы белән булган бу хәлне хәзер дә сагынып искә ала Зиннур, тормыш сабаклары шундый була, күрәсең.

## 4

Нурия авылның күз өстендә каш булып торырлык кызларының берсе. Ышыкта, яфрак астында гына калып, яна пешеп килә торган җиләкне хәтерләтә ул. «Вәт сылу булып үсеп килә бу кыз»,—дип соклана авыл егетләре. Төшләрендә аны күреп, эчтән янучылар да, очратканда оятсызланып сүз катучылар, иреннәрен ялап куючылар да бар. Гайрәтлерәкләре Галиябану көенә кушып, «Нуриякәй, сылуымиркәм, кем бәхетенә үсәсең»,—дип җыр багышлый, эчтән генә әллә ниләр өмет итә. Кыз гына, егетләрнең берсенә дә аерым игътибар итмәстән, үз дөньясы белән яши бирә. Калганнары ярар инде анын, җыен ярлы-ябагай егетләр, ә менә кайчаннан бирле күзе белән тотып ашардай булып йөргән бригадир Хәйрүшне кая куясың? Ул да тиккә йөрсенмени төче телен әрәм итеп. Кичке уенда да, аулак өйләрдә дә гел анын янында гына чуала, тавык чебиен күзләп йөргән тилгән кебек, бер егетне дә кызга якын җибәрми. Һич аңламый аны Нурия, нәрсә кирәктер үзенә? Шуның аркасында рәхәтләнеп күңел дә ача алмый, кая бармасын—күзен тасрайтып шул карап тора, кем белән сөйләшмәсен—тозсыз

[1]Тукач (тугац)—күмәч.

мәзәкләре белән арага керә. Сәхипҗамал белән йөриләр дигән хәбәрләре дә әллә кайчаннан бирле яшьләр телендә, ул да юк сүз түгелдер: тоя бит Нурия кызның күз карашын: ачу катнаш усаллык белән кадала ул «көндәшенә». Нурия гаепләмени соң ана? Шул Кәрбекнең үзенә карап тонган күзләрен күрмәс өчен әллә ниләр бирер иде.

Яшьләрнең эч серләре аулак өйләрдә ачыла. Күмәк уеннар, каракаршы җырлашу-уйнашулар да нәкъ менә анлашу, ачыктан-ачык әйтә алмаган сүзләрне иясенә ирештерү өчен уйлап чыгарылгандыр. Гади дә, тирән мәгънәле дә алар. Аулак өйгә егетләр чакырылмый, ләкин аларсыз кич утырулар да булмый. Кемдә аулак өй буласын, анда кайсы оч кызлары җыелачагын төгәл белеп өлгергән егетләр бүген дә озак көттермәделәр. Тәрәзә пыяласына бер-ике чиртүгә, өйнең хуҗасы Бәдерниса кортка ишек төбенә килеп басты. Кертүләре алдан ук билгеле булса да, кызлар назландырган, ялындырган булды, егетләре исә бөтен тел осталыкларын эшкә җигеп, керергә рөхсәт сорады. Башкача мөмкин түгел, йоласы шулай. Турыдан-туры бәреп керергә урыс клубы түгел бит ул сина! Һәр нәрсәнең үз тәртибе, үз җае бар.

Егетләр кергәч, болай да кечкенә өй эче тагын да тараебрак калгандай тоела. Кызларның күнеле кин икән, өйнең тарлыгы сизеләмени? Кергән бере күнеле тартканча сәке буена, мич кырыена елыша, үзе күз атып йөргән кыз янынарак утыру ягын карый. Шуннан уеннар башлана. Каракаршы җыр әйтешә торганнары да, уртага төшеп, сайлаган парың белән әйләнә торганнары да, «өлешенә тигән көмешен» белән «йолдыз санарга» чыга торганнары да бар уеннарның. «Күршен татумы?» уенында сынала инде мөнәсәбәтләрнең ныклыгы. Әнә әле дә калын бил каешын урталай бөкләп тоткан Хәйдәр һәр пар янына килеп, «күршен татумы?» дип сорап йөри. «Тату» дигән җавап ишетсә, казый икенче пар янына китә. Янына туры килгән кызга күнеле төшмәгән егетләр, «мина фәлән кыз кирәк» дип, икенче берәүләрнең парына күрсәтә. Теге егет риза булса, кызлар алмашынып утыра, җибәрмәсә, җәза бирелә: егетнең учына өч тапкыр каеш белән суга казый. Мифтах белән Камилә кебек, «безгә бәйләнмәсәләр ярар иде» дип, бер-берсенә сыенып утыручылар да, бер урыннан икенче урынга кызлар алыштыручылар да җитәрлек. Казый үз тирәләреннән ераклашкан арада кызларның кылын чиртеп, уйлары кем тирәсендәрәк чуалуын чамаларга, сүз арасында үзенең дә битараф түгеллеген анлатырга тырыша егетләр. Әгәр җәза төшеп, учны уттай көйдереп үткән каешны «эһ» тә итмичә үткәреп җибәрәсең икән, сүзләренә өстәмә дәлил кирәкми дә инде: теләгән кеше үзе анлый.

Ходай кушуыдыр, уенда Зиннурның урыны Нурия белән янәшә туры килде. Күрше кызының оялып кына аска караган күзләрендә әллә нинди шатлыклы очкын күргәндәй булды егет. Күтәрелеп карарга да уңайсызланган кызга кагылмыйча гына хәлен, әтисенең исәнлеген сорады Зиннур. Тел берне сөйләде, күнел икенчене уйлады. Әле кайчан гына кар атышкан, чанада тартып йөргән сабый түгел инде бу, күпләрнең төнге йокысын качырадыр шушы зәңгәр күзләр, йоклап утырма, күрше абый!..

Бөтен уй-фикере яна уку елы, беренче дәресләре тирәсендә әвәрә килгән Зиннур, кызны да уңынчы класска керергә димләүдән гайре акыллырак сүз таба алмады. Теге вакытта очратканнан бирле шул фикерен әйтергә җай таба алмыйча интекте ул. Турыдан-туры кереп сөйләшер иде, әле үзе дә ныклап анлата алмаган бер хис тыеп-туктатып торды егетне. Менә хәзер җай чыгуына куанып, кызны күндерергә ниятләде. Нуриянең дә мәктәпне тәмамлавын тели иде ул. Шулай гынамы икән, әллә инде кызның гел күз алдында булуын да тели микән Зиннур? Өзеп кенә җавап бирүе кыен, ләкин нәрсәдер бар монда...

—Минем классташлар мәктәпне узган ел тәмамлады бит инде, үземнән кечкенәләр белән парта артына кереп утыру килешер микән?

Кыз үзе дә бу турыда күптәннән баш вата иде, әнисе дә каршы килмәс кебек, әтисе дә җайлана төште хәзер. Зиннурның сүзләре

ышандырырлык иде, ни дисәң дә югары уку йортын бетергән, укуның кадерен белгән кеше. Әле дә әнә китап сүзләренә охшатыбрак: «Эх, Нурия, кеше гомер буена укырга, үсәргә тиеш. Син дә укып, зур кеше булырсың, Алла боерса»,—дип пышылдаган була. Күрше абыйсының үзенә иелә төшебрәк сөйләгән сүзләре күнеленә бик тә якын кызның, шулай да әллә ничек...

—Алай үсә-үсә мин ишеккә дә сыя алмый башлармын,—диде Нурия бу житди сөйләшүдән шаяруга күчәргә тырышып.

Икесе дә көлешеп алдылар һәм күршеләренә күз төшереп, үзләренә игътибарны тартмаска тырышып, тынып калдылар. Яшьләрнең күбесе үз күршеләре белән мәшгуль булса да, түрдә үк утырган Хәйрүш бу бәхетле пардан күзен алмады. Зиннурның кызга нәрсәдер сөйләве, Нуриянең башын аска иеп аны тыңлап утыруы, күпмегә бер күзен тутырып күршесенә карап куюлары аны чыгырыннан чыгарды. Аларның бер-берсенә карашып елмаюлары эчендә көнчелек уты кабызды: «Берәрсе килеп аермый да бит шуларны»,—дип сүгенде ул эченнән. Менә Хәйрүшкә дә чират житте, һәм ул Нурия исемен атап, канәгатьләнү хисе белән кызның үз янына килеп утыруын көтте. Аның әле генә казыйны алмаштырган әшнәсе Локман:

—Күршегез татумы?—дип сорады, үзе астыртын елмаюын сиздермәскә тырышты. Бригадирның авызына гына карап торырга күнеккән Локман монда да тиз генә эшне пешерергә өметләнде.

Бөтен яшьләрнең күзе Зиннурга төбәлде: «Бирерме яшь укытучы абый күрше кызын, юкмы?»

—Аллага шөкер, бик әйбәт кенә утырабыз әле,—диде шаян тавыш белән Зиннур.

Кәрбекнең жинелеп калуын теләгәннәр жиңел сулап куйды.

—Кызны сорыйлар, бирәсеңме, жәзасын аласыңмы?—Казый каешын юри егетнең колак төбенә китереп шартлатып алды.

Жавап та егетләрчә булды:

—Безнең тирәдә артык кызлар юк.

Уен барышында күп очракларда исәп өчен генә сугылган каеш бу юлы Зиннурның учына жәйнең челләсендә яшьнәгән яшен кебек чартлап төште. Учы утта пешкәндәй янса да, сиздермәде егет, казый киткәч, Нуриягә борылып, күз кыскандай итте. Кыз да ана елышыбрак утырды, күтәрелеп карамыйча гына, бармак очлары белән Зиннурның кызарган учыннан сыйпады.

Эш моның белән генә бетмәде, уен Хәйрүшкә килеп төртелгән саен ул үҗәтләнеп Нурия исемен атады, тегесе дә егет булып кала белде, кичә буенча кызны яныннан жибәрмәде. Уен чынга китте, күнелле генә башланган аулак өй ике егетнең көч сынашуына, бил алышуына әверелде. Кызлар да бер Нуриягә, бер Зиннурга карап, эшнең асылын аңларга тырышып карадылар: нидер бар булыр болар арасында, югыйсә жибәрер иде егет кызны, нидер бар... Ни булуын Зиннур үзе дә аңламый иде әле хәзергә. Чынлап та Нуриянe башкаларга бирәсе килми идеме аның, әллә соң үзенең авылга кайтуын шулай искәртәсе килдеме яки ачуыннан шартларга житкән Хәйрүшнең борынына чиртәсе килдеме егетнең? Сүзендә тору, әйтелгән сүзеннән хужасы була белү хисе дә юк түгел анарда. Ни булса, шул булды: колхоз бригадирының үҗәтләнүе бер дә уйламаганда Зиннур белән Нурияне бер-берсенә шулкадәр якынайтты, икенче көнне үк яшьләр арасында аларның исемнәре янәшә куелып йөртеләчәге көн кебек ачык иде.

Әшнәсенең күз карашында зәһәр очкыннар күргән Әбләка Локманны алыштыргач, артыграк тырышкан күрәсең, бил каешының тимере Зиннурның кабарып чыккан учын ярып төшерде. Шау-шу купты. Кызлар жыелышып егетне уратып алдылар. Нурия исә, иреннәрен тешләп, ап-ак кулъяулыгы белән абыйсының кулын бәйләргә кереште. Эшнең болайга китүенә икесе дә унайсызлана да, шул ук вакытта эчке бер рәхәтлек,

ләззәтләнү дә кичерә иделәр. Ыгы-зыгы арасында Мифтах Әбләканың күлмәк изүенә барып ябышты:

—Син, хайван, нимәгә алай хәрәмләшәсен? Каеш тимере белән сугалармыни?

Бригадир яклыларның үзе тирәсендә калмавын сизенгән казый, ярсыган Мифтахның кулыннан ычкынып, чыгып таю ягын карады.

Аулак өй бушап калды, шау-шуны ишетеп, кече яктан Бәдерниса корткаяк[1] та килеп чыкты, Зиннур янына килеп, эшнең нидә булуын аңлап алды. Ишек ачылып, аннан дусларыннан алдарак кайтырга чыккан Камилә килеп керде:

—Нәрсә булды сезгә бүген, Зиннур? Үз ишләрен жыя анда теге хайван, ишегалдында. Сине тотып, акыл өйрәтергә жыеналар.

—Чыгыйм булмаса, үзләренә дә юк акылларын өйрәтеп карасыннар алайса,—дип чыга башлаган Зиннурның юлына Бәдерниса корткаяк каршы төште.

—Юк, энем, күрә торып сине имгәтергә бирмибез, күбәү алар, аның кубызына биючеләр.—Егетнең җавап сүзен дә көтмәстән, корткаяк кискен хәрәкәтләр белән ишеккә аркылы бик тә салып куйды.

Зиннурның жиңенә чытырдап ябышкан Нурия эченнән генә карчыкка рәхмәтләр укыды, алай булмаганда ул үзе ишеккә барып ябышыр, сугышуга юл куймас иде. Ишек артында муен астына салып өлгергән Хәйрүшнең гырылдавык тавышы ишетелде:

—Нәрсә, шүрләденме әллә, Зиннур, кызлар итәге астына постың? Егет булсаң, чык, гәпләшик егетләрчә.

Кәрбек белеп эш йөртә, бу сүзләрдән соң Зиннур өйдә кала алмаячак. Шулай булды да. Ачуы кабарган егет, сикереп торып, ишек тоткасына ябышты, ләкин Нуриянең ялварулы карашы аны туктарга, уйлап карарга мәжбүр итте. Ул да булмады, урам яктан әллә ничә кешенең тавышы ишетелеп, тиздән алар бөтен көчләренә ишекне дөбердәтә үк башладылар. Төрле яктан:

—Чыксын! Хәзер үк ачыгыз! Ишекне ватып керәбез!—дигән тавышлар, сүгенү сүзләре ишетелде.

Ишек биген күтәреп ача башлаган егетне янадан өйнең хуҗасы туктатты:

—Чыкмыйсың! Күрмисеңмени, эчеп, батыраеп алганнар, егетләр, имеш, бер дисәткә жыелганнар да бер кешегә бәйләнәләр, адәм имгәкләре!

Тавышлар тынмагач, корткаяк, балтасын тотып, ишек төбенә үк килеп басты:

—Әгәр ишекне ватып керсәгез, башыгызны балта белән чабып өзәм! Валлаһи газыйм дип әйтәм! Яхшы чакта таралыгыз, китегез лүччә. Гәпләрегезне иртә[2] тәгәлләрсез.

Байтак кычкырышкач, урамда тавышлар акрынлап тынды, кызлар да алгы өйгә күчеп, кул эшләренә керește. Зиннур аулак өйдән таң алдыннан гына кайтырга кузгалды. Нурия, Камилә, Туктабикәләр бергәләшеп аны озата бардылар һәм аулак өйгә әйләнеп кайттылар. Төнге «геройларның» берсе чаттагы агач төбендә йоклап ята, күрәсең, артыграк чөмергәндер. Хәйрүшләр очыннан «Галиябану сылуым иркәм» җырын исереклек катнаш йокы көенә сузган тавышлар ишетелә, авылның таң алдында гына була торган сихри тынлыгын бозарга жөрьәт итүчеләр башка юк иде...

Зиннур «жил-давылга» очрамыйча гына келәтенә кереп ятканда, Актүш кенә озак кайтмавына шелтәләп тә, бер үк вакытта куанып та хуҗасын каршы алды, койрыгын болгап, сыпыргаланып өлгерде. Төне буе йокламавына карамастан, егет үзендә әллә нинди бер жиңеллек, эчке күтәренкелек тойды. Әллә инде бүген мәхәббәт дигән серле чишмәнең

[1]Корткаяк—карчык.

[2]Иртә—иртәгә.

саф суыннан беренче тапкыр авыз иттеме чиркәс Абдулланың тынгысыз оныгы? Нигәдер уенда, күз алдында һаман күрше кызы булды. Рәхмәт Кәрбеккә, шулкадәр үҗәт булмаса, үз хисләрен аңларга, кызга белдерергә байтак вакыт һәм батырлык кирәк булыр иде укытучыга. Ә колакларда һаман Нуриянең «мин сине җибәрмим» дигән сүзләре яңгырап торды, керфек астыннан гына оялып каравы күз алдына килеп, йокысын куды. «Мин дә сине беркемгә дә бирмим, бирмим»,—дип кабатлады егет. Институтта уку елларында кызларның карлыгач канатыдай кап-кара кашлылары да, аяз күк гөмбәзедәй зәп-зәңгәр күзлеләре дә сүз катканы булгалады, ләкин егет башын югалтмады. Күрше кызының сүзсез күз карашы әллә нинди сихри тарту көченә ия булгандыр, мөгаен, егет башкаларны күрмәс булды, аның исеме йөрәкне татлы сулкылдата торган бер сызлавыкка әверелде...

## 5

Көмешлесу авылында ике катлы итеп төзелгән алты йорт бар. Бу йортларның кайберсен авылның байлары төзеткән: өске катта яшь хатын торган, астагысында олы хатын көн иткән. Бер ояны икегә бүлү булмагач, байларның хатыннары шуна риза булып, тыныч кына гомер кичергәннәр, ди.

Нуриялэр йортының ике катлы булуының сәбәбе бөтенләй икенче. Эш болай булган: авылда «ясаклы», «йомышлы» дип йөртелгән җирле татарлар белән бергә Бохара якларыннан килеп, шушында төпләнеп калган сарт нәселеннән булган җирсез кешеләр яши. Хәмит әкә дә әнә шуларның берсе. Көмешлесуда җир мәсьәләсе бик каты, хәтта йорт салырлык урын өчен дә әледән-әле зур бәхәсләр чыгып торган. Нуриянең әтисе дә өй урыны ала алмыйча дүрт-биш ел интегә. Менә шунда аны Чәпчүк бабай үзенә чакырып ала. Карт—авыру, йорты бик тузган, кәс белән ябылган түбәсе бөтенләй череп, яңгыр-кар сулары өйгә үтеп җелегенә төшә икән бичараның. Җире булса да, йорт салырлык көч-дәрманы калмаган карт белән хәленнән килсә дә, өй утыртырлык урын булмаган яшь-яшь ир-ат, озак-озак киңәшләшә торгач, уртак бер фикергә киләләр. Хәмит әкә йортны ике катлы иттереп сала да, беренче катында сәламәтлеге начар Чәпчүк картлар яши башлый, икенче катына Хәмит гаиләсе менеп кунаклый. Өй житкерү эшенең бөтен мәшәкатьләрен белеп өлгергән Хәмит әкә бер түбә астында ике гаилә өчен оя коруның уңайлыкларын да төшенеп ала: идән-түшәмгә җәелә торган бүрәнә-такталар да азрак китә, өй кыегын да берне генә торгызасы була.

Яңа өйгә керү шатлыгын күрсә дә, Чәпчүк картка җылы, коры өйнең рәхәтен күреп озак яшәргә насыйп булмый. Бердәнбер улы белән Хәлбикә корткаяк йортның хуҗасы булып кала. Олыгайган көнендә табып, картлыгында ышанычы, арка терәге булыр дип өметләнеп үстергән баласы гына көннән-көн анасына каты бәгырьле, миһербансыз була бара. Моның сәбәбен табу карчык өчен баш житмәслек бер хәл була. «Нәрсә житми бу балага, тагын ниләр генә бирим икән инде?»—дип уйлана карчык, улының да мәрхәмәтле булып китүенә өметләнә. Шулай булмый ни, бөтен гомерен, яшәвенең мәгънәсен бердәнберенә—Әблакәсенә багышлады бит ул. Балам нык, таза булып үссен дип, җиде яшенә кадәр күкрәк сөтен имезде, аркасына гына йөкләп йөрде. Яшьләй эшләп өзлекмәсен дип, суын да үзе ташыды, утын әзерләү, мал-туар карау кебек йорт эшләренә дә үзе өлгерергә тырышты. Сырхау иренең сүзләренә дә колак салмады: баласына җил-яңгыр тидермичә үстерде. Сукыр мәхәббәт күрер күзне күрмәс итте. Ялланып урак урган, печән чапкан, кер юып тапкан акчасына, үз авызыннан өзеп, баласына тәмле-томлылар юнәтте, улы ким-хур булмасын дип өзгәләнде. Бала күнеле моны тоеп, үз файдасына кулланырга да бик тиз өйрәнде: башкалар тир түгеп ата-анага булышканда, белем алганда, ул авыру булып кыланды, урамда трай тибеп

йөрде. Акрынлап тәмәке тартырга, аракы эчәргә, катлы-катлы итеп сүгенергә өйрәнде.

Атасы вафат булгач, бөтенләй азынды бала: анасына жикерү-кычкыру дисенме, самогон-аракы таптыру дисенме—болар барысы гадәти эшкә әверелде. Бала бит, ни хәл итим дип, эчтән тынды ана. Күнелендә бер генә өмет чаткысы калды: өйләнеп, кеше булмасмы? Авылга әллә кайдан гына килеп чыккан Регина исемле хатынны ияртеп алып кайтты улы. Килен үзе йортка аяк басканчы, хәбәре алданрак килеп иреште: ни сәбәпледер, беренче ире ташлап киткән, ди. Ни булса да риза Хәлбикә корткаяк, исемен әйтә алмыйча изаланса да, киленгә ачык чырай күрсәтергә тырышты. Кичтән авыл өстендә Әбләканын өйләнү хәбәре йөрсә, иртән яшь киленнән, төенчеген кыстырып, качып китү хәбәре авыл халкын хәйран калдырып, бер очтан икенче очка таралды. Төрле сүзләр йөрде телләрдә, күптөрле юраулар булды. Ай күрде, кояш алды Хәлбикә корткаякнын зур өметләр баглап көтеп алган киленен. Көн-төн эчүдән башы чыкмаган, булдыксыз, көн итәрлек бер эш-һөнәре булмаган бу адәм затынын ирлеге дә корыган күрәсен,—дип фикер йөртте авыл хатыннары.—Югыйсә, үзе теләп кияүгә чыккан кеше, бер кич куну белән, тавыш-тынсыз качып китмәс иде. Башы түнгәнче эчеп, хатынынын чыгып киткәнен дә сизми калгандыр әле...

Бу хәлләрдән сон Хәлбикә карчык түшәккә ауды, сонгы өметенен дә шартлап өзелүенә йөрәк чыдамады, бәхет-шатлыкларсыз фани дөньядан әрнү белән китеп барды. Очсыз-кырыйсыз тормыш дингезендә ялгызы калды Әбләка. «Әллә сабыраер, акылга килер»,—дип уйлады тирә-күршеләре. Олыларнын акыллы кинәшләрен тынлаудан узган иде эш, аракы колына әверелгән иде инде егет. Ата-анасыннан калган бөтен нәрсәләр самогонга алыштырылды, Хәлбикә карткаякнын кырыгы житкәндә өй эче шыр ялангач булып калды...

Табигать мондый хәлгә артык озак түзә алмый, ниһаять, чик куя.

Көннәрнен ин коры, эссе торган вакытларында Әбләка яшәгән аскы өйдә янгын чыга. Исереп йоклагандыр да, тәмәке төпчегеннән башлангандыр ут, югыйсә учак ягып аш пешерүнен ни икәнен белми хөрәсән. Авыл уртасында эленеп торган сука тимеренә суккан тавышлар, урыс чиркәве чаны кебек, бөтен тирә-якка тарала. Барча халык, эшен ташлап, чиләк-балталар күтәреп, тәрәзәләреннән ургып төтен чыккан йортка таба йөгерә. Зиннур чабып килеп житкәндә, төтенгә тончыккан Әбләканы сөйрәп чыгарып салалар. Нурияләрнен бәхетләре булып, ут әле кызып өлгерми кала, нык ялкынлап янмый, шулай да юрган-ястык йон-мамыкларыннан чыккан көек исе, төтен өйнен ике катына да тула, сулыш алырлык түгел. Чапкан печәннәрне өяр, жиләк-жимеш жыяр чак бит. Нурия белән әнисе өйдә юк, авыру әтиләре генә икенче каттан төшә алмыйча, төтенгә буленеп кала. Сулышы капкан кыз, аны-моны уйлап тормастан, йөгереп кайта-кайтышка, атасына ярдәмгә дип, төтен эченә ташлана.

—Өске катта берәүләр бармы? Хәмит әкә кайда?—дип кычкырды Зиннур.

—Хәмит әкә күренмәде, Нурия әле генә югары өйгә менеп китте, төтенгә тончыга күрмәсеннәр инде,—диде беравыздан хатын-кызлар. Ирләрнен күбесе ерак болынлыкларга киткән жирләреннән кайтып житмәгәннәр, авылдагылары янгын сүндереп маташа: хатын-кызларнын Иртештән, чишмәдән ташыган суларын аскы катка кертеп сибә. Зурга киткәнче утны сүндерергә тырышалар. Һәр яктан шау-шу, ыгы-зыгы: «Өйдә тизрәк су, бу яккарак!»—дигән тавышлар ишетелә. Һәркем хәленнән килгәнчә ут белән көрәшә иде. Ут-су галәмәтләрен ялгызын жинәм димә, мондый чакларда бердәмлек, ярдәмләшүнен генә берәр төрле нәтижә бирүе ихтимал. Жәй чилләсендә чыккан ут—яз башында котырынып ярларыннан чыгып ташыган Иртешкә тин бит ул: авыз ачып утырсан—авылынны ялмап китүе дә бар...

Үз соравына җавап ишеткәндә, Зиннур сәелханәгә озын баскыч терәп, тиен тизлеге белән өскә менеп бара иде инде. Ишекне балта белән каерып, өстенә бер чиләк су аударып, төтен эчендә юк булды, тагын кемдер аның артыннан ярдәмгә ашыкты. Бераздан сәелханәдә янәдан Зиннур күренде, ул ахры, зәһәр төтен эчендә калдырасы килмичә, һуштан язган Хәмит әкәне дә, кызын да берьюлы сөйрәп килгәндер. Ярдәмгә килүчеләргә тапшырды, үзе ишектән янәдан кереп, Нурияне күтәреп чыкты. Бу мизгелдә ялкын телләре йортның ярыкларыннан өскә үтеп, егет белән кызны өтеп алды. Ишек төбенә килеп житкән Мифтах аларны чиләгендәге су белән коендырды.

Ата да, кызы да хәрәкәтсез, йөзләре мунчада ис тигән кешеләрнеке кебек сулып, агарынып калган. Хәмит әкәне читкәрәк алып киттеләр. Бераздан аның янында тыз-быз килеп ут сүндерүчеләр арасында медпунктта эшләүче кызның ак халаты күзгә чалынды. Бермәлгә Зиннур Нуриягә караган килеш катып калды.»Үлсә?!»—дигән ачы уй егетнең миен көйдереп үткәндәй булды. Бу тиле фикерне куарга тырышкандай, тиз-тиз кызны читкәрәк салып, янакларына суккалый, кулларын бөгеп сулыш алдыра башлады. Тырыша торгач, кызга җан кергәндәй булды. Әллә ана гына шулай тоеламы? Болай да кыз күзен ачмагач, тезләнгән килеш, тагын да иелә төшеп, сулыш өрә башлады. Ясалма сулыш алдыруны өч-дүрт тапкыр кабатлагач, әллә чыннан да ярдәме тиде, әллә саф һавада яту файдалы булдымы, Нуриянең керфекләре дерелдәп китте һәм әкрен генә күзләре ачылды. Гаҗәпләнү катнаш битарафлык белән карый иде әлегә ул күзләр. Күрше кызының керфекләре түгел, күк капусы ачылгандай булды Зиннурга.

—Нурия, Нурия, уян!—дип кабатлады ул кызның янакларыннан сыйпап.

Шул мәлдә әллә нәрсә булды, көтмәгәндә артыннан берәү килеп, Зиннурны күлмәгеннән умырып тотып, артка сөйрәп ташлады.

—Яшь кызны мәсхәрә кылуын карагыз әле бу оятсызның!

Ут сүндерергә, ниһаять, Кәрбек тә килеп житкән икән. Күзе-башы тасыраеп, болай да кин борын яфраклары тагын да киңәйгән. Коймага басып, бөтен дөньяга кычкырырга әзерләнгән сугыш чукмары әтәчне хәтерләтә иде бу минутларда. Көтмәгәндә булган хәлдән бер генә секундка югалып калган Зиннур тиз арада аякка басты, кизәнеп, Хәйрүшнең янагына тондырды. Әле генә баһадир кыяфәттә кукраеп торган бригадир кыш агачтай гөрселдәп авып төште һәм байтак вакыт исенә килә алмыйча тырпылдап ятты. Хәйрүшнең бу кыланышын ни дип тә аңламаган халык, Зиннурны якларга керешге. Шул арада ак халатлы Туктабикә килеп, дустының сулыш алуын тикшерә, чигәләренә нашатырь спирты сөртеп, кызга юату сүзләре әйтә, Нурияне тәмам һушына китерергә тырыша башлады. Кыз төтен эчендә азрак булган, таза-сау кеше, ә менә Хәмит әкә күзләрен ачканчы күп тарткалашырга туры килде Туктабикәгә. Олы яшьтә, болай да сулыш алуы авыр булган авыру кеше бит. Әгәр тагын бераз гына төтен эчендә ятса, җан дустының әтисен бернинди уколлар белән дә алып кала алмас иде ул. Ярый әле, Зиннур вакытында килеп өлгергән... Әбләка гына бу ялган дөньядан, тәмуг газаплары күреп, дөньяга килүен акларлык тырнак очыдай изгелек кылырга өлгермичә, китеп барды...

Янгын бик зурга китмичә, әкренләп сүндерелде. Кара корымга буялган, өсләреннән шабырдап тир аккан ир-егетләр әле һаман да зәһәрлеге басылмаган төтен эченнән чыгып, бит-кулларын әле генә чишмәдән алып менгән су белән чылатып торганда, сулышы эченә сыймыйча, йөзе бурлаттай кызарган, шабыр тиргә баткан Хәлимә апа кайтып житте. Кызын, ирен исән-имин күргәч, авыр сулап, җиргә сыгылып төште, аягын күчереп куярлык та хәле калмаган иде аның.

Туган-кардәшләре, тирә-күршеләре Хәмит әкәләрнең йортын җыйнаулашып рәткә китерделәр, икенче көнне Әбләканы да соңгы юлга озаттылар. «Үз башына үзе житте»,—җеназа озатучыларның соңгы сүзе шул булды.

Авыл жирендә бер вакыйга да игътибарны үзендә озак тотмый, яна көн туган саен, икенче хәбәрләр тарала тора. Янгын фажигасе дә акренләп онытыла, хәтерләрдән җуела барды. Хәйрүш кенә озак онытмас әле бу хәлләрне; кеше күзенә күренерлекне калдырмады Зиннур. Чалышайган янагын күрсәтәсе килмичә күрше-күләннән качып өйдә утырганда үзе өчен бик зур нәтиҗәгә килде ул. «Сугышып йөреп, чибәркәйне Зиннурның кулыннан тартып алып булмас,—диде ул үз-үзенә,—берәр хәйлә белән көндәшен авызлыкларга кирәк, кыз үзе килеп куенга керерлек булсын!»

## 6

Авылда печән өсте, әкренләп урак та якынлаша. Колхоз рәисе Шәкүр дә, халыкны җыеп, тагын бер тапкыр искәртеп куйды. Гауғалы булды җыелыш. Ләкин, никадәр кычкырышмасыннар, нәтиҗәсе булмады, рәиснең карары үзгәрмәде. «Бүгенге көннән һәрбер колхозчы гаиләсе колхоз маллары өчен ун кибән печән әзерләргә тиеш, үзләренә шуннан соң гына бер-ике кибән утыртырга рөхсәт» дигән карар колхозчылар башына күсәк булып төште. Шыр Шәкүр чыгарган «указлар» ел саен арта, үтәлергә тиешле планнар чүп үләне шикелле котырып үсә бара. Бригадирлар рәис кушканны җиренә җиткереп кенә түгел, арттырып та үти башладылар. Икенче көнне үк өеп куелган һәрбер кибән исәпкә алынып, биркәләнә[1] башлады. Колхоз башлыгы печән басуында үзе күренмәде, әлбәттә: бу чиләдә җиде кат тир түккәнче, күләгәдә ятып, самогон чөмерүнең никадәр ләззәтле булуын ул гына бөтен җаны-тәне белән тоя, бәяли аладыр. Рәис булып алганчы ана да байтак чиләнергә туры килде андый эшләрдә. «Кемнең кулында—шуның авызында» ди бит халык, кулындагысын ул бервакытта да ычкындырмас!

Зиннур да әтисе белән үзе барлап кайткан җиргә барып, эшкә кереште. Әтисе печәнлекне чыбык-чабык, ботак-мазарлардан арындырып йөри, улы тыгыз мускулларын уйнатып, гәүдәсен бер яккарак кырын салып, чалгы белән селтәнә. Эшкә кулы ятып тора, түмгәк өсләрен чәч китәргәндәй кырып ала. Бер көйгә салынган эш аның хәтер түрендә сакланган истәлекләрне яңартып җибәрде.

Зиннурга унбиш-уналты яшь кенә иде әле ул чагында. 1921 елдагы крәстиәннәр фетнәсендә катнашкан дип, әтисен төрмәгә озаттылар. Нәкъ хәзерге кебек печән өсте... Печән әзерләүнең ни икәнен шунда аңлады яшүсмер, әтисе белән бергә чакта бәйрәм булган икән. Ныгып өлгермәгән беләкләр кичкә тартышып катып кала. Әнисе белән икәү куйган кибәннәре йә очлыйм дигәндә генә авып төшә, йә убырлы карчык кебек бөкре чыга. Шулай калдырсаң, көт тә тор: беренче яңгырда ук печәненә су үтеп, кызып чыгачак. Көчәнә-көчәнә таратып, яңадан өяргә генә калачак. Бәхетенәме, әллә бәхетсезлегенәме шул көннәрдә Көмешлесуга Барис исемле яшүсмер сукбай килеп чыга. Тамак туйдырып үзләрендә яшәтү исәбеннән Ниязбикә апа аны улына ярдәмгә печән әзерләшергә яллый. Яшьләре бер тирәдәрәк булгач, яшүсмерләр тиз танышып, дуслашып та өлгерәләр. Бергә эшләп, югары өйдә бергә йоклыйлар. Барис аларда бер ай чамасы яши, кичке уеннарга да чыга, Зиннурдан калышмый иде. Бер кичтә нинди дер сәбәп табып, Барис өйдә кала. Уен шактый озакка сузылып, Зиннур төн уртасында гына кайта. Утсыз гына үз урынына ятарга җыенганда, тонык кына төшкән ай яктысында Барисның ятагы буш икәнен чамалап ала. «Бәлки, урамга чыккандыр» дип, чишенә дә ята. Алай да, керүче күренмәгәч, күңеленә әллә нинди шик төшә. «Урамда, йорт тирәсендә бер тавыш-тын да ишетелмәде ич кергәндә, кайда булыр бу?» Сикереп торып, сукыр лампаны кабыза һәм өйдәшенең кием-салымын карарга керешә. Барисның киемнәрен генә түгел, үзенә әтисе тегеп калдырган хром итекләрен дә таба алмый Зиннур. Күңеленә төшкән

[1]Биркәләнү—тамга (бирка) салыну, исәпкә алыну.

шом тагын да арта бара. Итекләр генә түгел, кышка әзерләгән пальтосы, олатасыннан калган кеш мал бүреге дә үз урыннарында табылмый. Аскы өйгә төшеп, әнисен уяткач, бүген генә пешергән өч икмәк, ике кадак атланмайның да сукбай белән бергә очканлыгы мәгълүм була.

—Улым, бу чукынган малай безне такыр тактага утыртып качты бугай. Теге пачпорт алырга әзерләгән кәгазьләреңне, акчаны да шудырмады микән, карап кара әле?! И Ходаем, ни күрәселәремә генә йортыма керттем икән шул сукбайны?—дип әнисе дә аның артыннан югары өйгә менә башлый.

—Юк, инә, алар да юк,—ди Зиннур, киштә эчен кармалап.—Туу турындагы таныклыгым да, авыл советыннан алган белешмәм, әзерләп куйган акчаларым да юк, җайлы гына төргәге белән алган да тайган, үзенә атап әзерләп куйганнар диярсең. Инде нишлибез, әнкәй?

—Бар, улым, этне ияртеп, Исхак әкәннәргә кер, Мифтахны уятып, Утырау буйларын карап әйләнегез. Бәлки, ерак китеп өлгермәгәндер әле. Кара аны, сак булыгыз, кулыгызга күсәкләр алыгыз.

Таң атканчы Мифтах белән бөтен Утырау буен айкап чыктылар. Юк, җир йоткандай булды Барисны. Иртән тирә-күршеләрдән сорашты-руларның да мәгънәсе булмады, эзеннән җилләр исте егетнең. Югары өйдән юрган-ястыкларны җыярга менгән Ниязбикә апа Бариска дип җәелгән урыннан иреннән калган кырына торган пәкесен табып, котлары очты. «Йа, Ходаем, балам кайтып кереп өлгерсә, суеп чыгып китәргә җыенганмы әллә бу шайтан, бер Аллам үзең сакла, әллә ниләр күрәселәр булган икән»,—дип, дүрт күз белән улының кайтуын көтте.

Авыл советында, милициядә дә Зиннурның сүзләренә чынлап игътибар итмәделәр. Постында йокымсырап утырган кысык күзле миллиционер, эшнең нидә икәнен дә тыңлап тормастан: «Ярый, ниярбез, малай»,—дип куя да, шуның белән вәссәлам. Паспорт алу өчен аңа янадан, әнисе табыштырган тогы балыгын[1] алып барып, таныклык, белешмәләр юнәтергә туры килә шул...

Моннан байтак вакытлар элек булып узган бу вакыйга исенә төшкәч, Зиннурның йөрәге жу итеп китте. Әгәр дә аның документлары белән паспорт алып, теге сукбай да Зиннур Абдуллин булып йөрсә? Бу ничек була соң әле, бу турыда ник уйлап карамадылар соң әле алар? Чыннан да, ул елларда паспорт алу бик кыен иде бит, ә ул сукбайга кем бирер иде документ? Егетнең башы әйләнгәндәй булып китте, җавап эзләгән шикелле, чалгысына таянып, як-ягына каранды.

Шуны гына көткән кебек, агач араларыннан кызларның чыркылдап көлешкән, сөйләшкән тавышлары ишетелеп, егетне авыр уйларыннан бүлдерде. Болар урман артындагы сазлыктан торнакүз җыеп чыгучы Камилә, Нурия, Туктабикәләр икән.

—Армый эшләгез, Фәтхулла әкә,—диде кызлар бертавыштан олы кешегә игътибар күрсәтеп һәм шунда ук Зиннур ягына борылып:—Түмгәк башларын кыркып буламы?—дип шаяруларын дәвам иттеләр. Кызларның чиләкләре торнакүз[2] белән тулы, өстенә япкан әрекмән яфраклары кырыеннан авызга әчкелтем сулар төшереп карасу-кызыл булып янып тора җиләкләре.

—Фәтхулла әкә, авызыгыз кипкәндер, әйдәгез, утырып ял итеп алыгыз, торнакүз белән сусыныгызны басыгыз.

Чыбык-чабыкка абынып, көне буе ачык кояшта йөргән карт тәмам хәлдән тайган иде. Кызларның, мутланып, әүвәл үзен сыйлаулары юкка гына түгел икәнен бик тиз абайлады.

—Улым, сина да әзрәк хәл алу зыян итмәс,—дип, үзенә әрекмән яфрагына салып сузган җиләкләрне рәхмәт белән кабул итеп, юлның аргы ягында ялгыз үскән чыршы күләгәсенә барып утырды. Олылар

[1] Тогы балыгы—мәрсин балыгы, осетр.
[2] Торнакүз—мүк җиләге.

гәпләшкәндә яшьләр тел озайтмаган кебек, яшьләр арасына ялгыз картның керешеп утыруы да бик матур булмас. Әдәп дигән нәрсә ана, күрәсең, ана сөте белән кергәндер. Әтисенең итагатьлелегенә тагын бер кат сокланды егет.

—Хуш килдегез, кызлар, түрдән узыгыз,—диде Зиннур да кызларга. Яна гына чабылган хуш исле печәнне «казна жиренә дә азрак ямь бирик» дигәндәй көязләнеп үскән пар каен күләгәсенә җәеп салды, шуннан урын күрсәтте. Кызлар да, озак кыстатмыйча, ул күрсәткән урынга килеп утырдылар, күләгәдә рәхәтләнеп бер сулыш алдылар. Аларның хәлен анлап, Зиннур тиз генә чишмәгә юл тотты, су алганда сиздермәстән ул тарафка күз салгалап, бер-берсенә нәрсәдер әйтеп көлешкән кызларны күзәтте. Камилә белән Туктабикә кара тутлы, калын авыр толымлы Себер сылулары. Кояшның кызуы да аларга күп тими төсле. Маңгайлары, борын өсләрендәге бөрчек-бөрчек тирләр генә аларның ерак юл үтүен, эссе кояш астында булуын расльй. Ә Нурия икенче, бу якларда сирәк очрый торган күкчәчәктәй зәңгәр күзле, йомшак сары дулкын чәчле кыз. Әле дә әнә бит урталары алсуланып янып чыккан, көннең кызулыгын аңа карап та чамаларга мөмкиндер төсле. Зиннур чишмәдән су алып килгәндә чибәркәйләр үз җиләкләреннән үзләре авыз итеп, рәхәтләнеп утыра иделәр.

Чатнап торган чишмә суыннан авыз иткәч, кызларның теле тагын да ачылды:

—Сөенчәл суын йөрәк януларына дәва диләр, эч әле, дускаем, эч,—дип төче телләнде Камилә, Нуриягә сулы савытны сузып.—Бу җирнең печәне дә хуш ислерәк булырга тиеш, югыйсә бу түмгәк башлары өчен кеше дигәнең аю хәтле аю белән сугышып йөрмәс иде.

—Дөрестән дә, Зиннур, юлның теге ягында, ә-нә тау астындарак нинди әйбәт печәнлек, нигә дип сез монда, түмгәкләр арасында маташасыз?—дип сүзне чыңга борды Туктабикә.

—Укытучыларга колхоз җирендә чабарга ярамый, диде Хәйрүш. Шуңа күрә дә шушы казна җирендә чокчынабыз. Ә сез, кызлар, ни өчен үзегез генә? Аю-бүреләрдән дә курыкмыйсыз, ахры?

—Янибызда гына чаж-чож печән чабучы арысландай егет булганда, нишләп куркыйк ди икән?—Нурия дә үз сүзен кыстырасы итте, каш астыннан гына егетнең кояшта кызынган киң җилкәсенә, мускуллы беләкләренә карап алды.

Бу якларда электән калган бер гадәт бар: олысы-кечесе укытучыларны хөрмәтләү йөзеннән «абый»-»апа» дип кенә эндәшә. Яшькә олы булмаса да, авылдашлары Зиннурны да акыл, киңәш бирерлек кешегә санап, олылап эндәшә башладылар, егет үзе дә әкренләп бу хәлгә күнегә, чыннан да үзендә ниндидер җаваплылык хисе үсүен тоя башлаган иде. Яшьтәшләре күбрәк исеме белән эндәшсә дә, Нурия күбрәк «абый» дип дәшә, яки бөтенләй исемен әйтмәүне кулайрак күрә. Соңгы арада булган вакыйгалар аның фикерен бөтенләй чуалткан иде күрәсең, кайбер вакытлар дуслары түгел, кыз үзе дә үз-үзен аңлап бетерми. Әзрәк кенә күрмичә торса, «аның» елмаеп эндәшүләре күз алдыннан китми; үзе күренсә, телгә бер генә акыллы сүз дә килми. Ахирәтләре дә әйтелгән һәр сүздән ниндидер мәгънә табып, ирештерергә, бер-берсенә күз кысып, төрттереп алырга гына торалар. Менә хәзер дә Нуриянең күз карашын тоеп, төрткәләшеп, мәгънәле генә елмаешып алдылар.

Агач ышыгында утырып азрак хәл алгач, дуслар кайтыр якка күз төшереп, урыннарыннан кузгалдылар.

—Фәтхулла әкә, Аллам куәт бирсен, армый эшләгез,—диде Туктабикә печәнчеләрнең икесе белән дә берьюлы саубуллашып.

—Рәхмәт, кызлар, узганда-барганда шулай тиеп үтегез, сезнең аякларга ял, безнең күңелләргә дәрман булыр.

Инде карт үз чиратында улының тел осталыгына хәйран калды, карчыгының сүзләрен исенә төшереп, үзалдына көлемсерәп куйды. «Әйе,

анасы белеп сукалый, төшеп калганнардан түгел бу бала,—дип уйлады ул, горурланып, һәм бер үк вакытта күнелен тынычландырып та,—үзен кыерсытырга бирмәс, Аллам боерса».

Камилә белән Туктабикә итәкләрен төзәтеп, ябышкан печәннәрне каккалаган арада, Нурия, иптәшләренә сиздермичә генә Зиннурга сабы белән жыелган жир жиләкләрен сузды. Зәңгәр күзләрен тутырып бер карады да, кулындагы жиләкләредәй кызарынган йөзен яшерергә тырышкандай, тиз генә чиләген эләктереп, авыл ягына атлады. Аның артыннан дуслары да кузгалды. Кызлар китте, Зиннурның яралы жаны да, гуя алардан калмаска теләгәндәй, бәргәләнде, йөрәге ашкынып типте. Нуриянең тагын бер генә борылып каравын, елмаеп кул болгавын көтте ул. Ә кызлар исә, аны үчекләгәндәй, чытлыкланып бер-берсенең колакларына нидер әйтешәләр, бер-берсенә төртешеп көлешәләр. Әйтерсең лә артларыннан күзләрен тутырып карап калган Зиннурны бөтенләй онытканнар.

Ярты гына сәгатькә кызлар тавышыннан чынлап торган чишмә буе тагын тынып, моңсуланып калды. Зиннур да күңел кичерешләрен атасына сиздермәскә тырышып, чалгысын янарга тотынды.

Моңа кадәр дә аңардан кызлар читләшмәде: аның өчен мәхәббәт утында янмасалар да, якын дус итеп эч серләрен сөйләүчеләр булгалады. Зиннур гына аларны күкрәгенә кысып юатырлык, чит-ят күзләрдән сакларлык күңел якынлыгы да, жан тартылуын да тоймады, әллә ничек битараф кала бирде. Студент елларында да дуслары белән бергәләп күңел ача, кызлар белән дә шаяра, уен-көлкедән дә читтә калмый иде. Ләкин Ходайның бирмеше: бүгенге көнгә кадәр берәр кыз белән ялгыз калып аңлашырлык хисләрне тойганы юк иде әле аның. Хәер, үсмер вакытында ук күзе төшеп йөргән кызы бар иде. Беренче егетлек хисләрен уяткан муелдай кара күзле Таңсылу чыннан да аның күзенә ин сылу кыз булып күренгән иде ул чакларда. Чыгарылыш кичәсендә дә алар гел бергә биеделәр. Таңсылу авылда калды, Зиннур укуын дәвам итәргә Түбәнгә китте. Саубуллашканда кызны жайсыз гына кочып, бит уртасыннан үбеп тә алган иде. Киләчәккә зур планнар кормасалар да, хатлар язарга вәгъдәләшеп аерылыштылар. Күп тә үтмәде, кыздан хатлар, алар артыннан төрле хәбәрләр килде егеткә. Ышанырга да, ышанмаска да белмәде ул, читлеккә ябылган кош кебек бәргәләнде. Авылга кайтып дөресен беләсе, кызның күзләренә карап жавап сорыйсы килде. Ләкин аралар якын түгел, кайтып киләм дисәң, әлләничә тәүлек пароходта үткәрәсе бар. Уку елы башы гына. Зиннурның беренче мәхәббәт яралары әкренләп жөйләнә башлады, лекция-семинарлар белемгә сусаган егетне башыаягы белән үзенә суырды. Көн дә почта көтеп хат ала алмаган күнел генә кызларның вәгъдәсезлегенә рәнжеп, үз эченә бикләнде, мәхәббәткә ышаныч югалды. Каникулга кайткач, Таңсылуның Хәйрүш белән йөреп, соңрак Ваһап дигән егетне армиягә озатуын житкерделәр. Йөрәгендә ачу кайнаса да, егет горурлыгын таптап, кызны эзләп китмәде. Алай гынамы, очрашканда да салкын-битараф булып калырлык көч тапты. Кабаттан янында бөтерелгән кыздан әнә шулай сүзсез генә үч алды. Яшьлекнең студент еллары дигән иң гүзәл мизгелләре дә күнелгә утырган шул юшкын астында калып, соры гына, төссез хатирәләргә әверелде...

Нурия турындагы уйлар егетнең тормышын мәгънәле итте дә куйды, үләне такыр булса да печән эше жайлы гына барды. Печәннәр кибә барып, ике атна дигәндә кибәннәре дә байтак куелды. Соңгы көннәрдә Мифтах дусты килеп булышты, кечтүче Чамакә дә аты белән чүмәләләр сөйрәтте, өеште. «Бирәм дигән колына, китереп куяр юлына» диләрме әле, кибән утырткан көнне әлеге дә баягы Нурия белән Камилә торна күз жыеп кайтып килешли туктап, кибән башын очларга булыштылар. Шулай итеп авыр хезмәт тә беләкләргә куәт, күңелләргә дәрман бирерлек бер өмәгә, яшьләрнең көч-осталыкларын сынашу ярышына әйләнде. Фәтхулла абзый да Ходайның бирмешенә ризалык кылып, яшьләр тирәсендә уралгандай итә: әле калган печәнне тырмавычына элеп килә,

әле нык итеп өеп куелган кибәннәргә карап соклануын яшермичә, рәхмәтләрен укый иде.

Тирләп-пешеп эшне бетергәч, яшьләр чишмәгә сугылып, суның салкынын һәм тәмен татып карарга ниятләде. Егетләр, билдән чишенгән килеш, су белән рәхәтләнгәндә, кызлар бит-кулларын юып, кушуч тутырып көмештәй су эчтеләр. Кояш нурларында җемелдәшкән су тамчылары кызларның күзендә чагылыш таба. Күнелләрне әллә нинди шатлык, ашкыну тойгысы биләп алган, моны су салкыннары белән генә басарлык түгел.

Бу юлы инде яшьләр авылга кадәр бергәләшеп кайттылар, торнакүз тулы чиләкләр дә егетләр кулында булды. Авыл буйлап көпә-көндез бергәләп үтүне килештермәделәр, Көмешлесу елгасына җиткәч, кызлар сукмак буйлап авыл ягына күтәрелделәр, Зиннур белән Мифтах, саубуллашып, таллар артында гына чылтыраган инешкә таба юл алдылар. Җәйнен кызу көннәрендә сизелерлек тараеп калса да, борылышларда бөялеп торган җирләрендә рәхәтләнеп су керерлек урыннары бар әле Көмешлесуның. Әнә алардан ерак та түгел бала-чага рәхәтләнеп чупырдаша. Елга буе авыл баласының азга гына эштән бушаган вакытларында бөтен җанытәне белән ләззәтләнеп ял итә, хәл җыя торган бердәнбер урындыр бу.

Кояшта кызган битләрен елга суы белән рәхәтләндереп, таллар ышыгында бераз хәл алгач, кузгаласы иттеләр.

## 7

Санаулы көн тиз үтә: җәйге каникул вакытлары да артта калып, үз җае белән яңа 1940-41 уку елы башланды. Җәй буена бер-берсен сагынышкан балалар мәктәп ягына агылды. Кысан иске мәктәп бинасы да кулларына болын чәчәкләре тоткан, хәлле-хәленчә ыспаймату киенергә тырышкан балалар, укытучы абый-апалар белән яшәреп, җанланып киткәндәй тоелды. Даут абыйлары сыйныф-сыйныф булып тезелгән балаларны бәйрәм белән котлап, уңышлар теләде. Аннан аерымрак торган укытучылар төркеменә күз төшереп, аларга да тәбрик сүзләре әйтте. Чират мәктәпкә инде үзе укытучы буларак тәүге адымнарын атлаган Зиннурга да җитте. Директор аны да институтны уңышлы тәмамлап туган мәктәбенә кайтуы белән чын күнелдән котлады, мәктәпнең физика-математика фәннәреннән югары белемле укытучысы булуы зур горурлык икәнен дә әйтергә онытмады. Алай гына да түгел, аның быелгы уку елында ук завуч булып билгеләнүен бөтен коллектив алдында хәбәр итте. Кат-кат тамагын кыргалап Даут абыйсы приказны укыды, ихлас күнелдән яшь укытучыга изге теләкләрен теләде. Бәйрәмнең тантаналы өлешеннән соң беренче дәрескә кыңгырау тавышы яңгырады. Башта чебеш анасыдай беренче-икенче сыйныф балаларын ияртеп, Әминә апалары мәктәп түренә үтте, алардан соң өченче-дүртенче сыйныф укучылары белән Фәридә апалары атлады, чылбырны урта сыйныф укучылары дәвам иттерде. Иң ахырдан үз олысымак-җитдилекләренә үзләре үк сокланып, тугызынчы-унынчы сыйныф укучылары кузгалды. Зиннур, күзенең чите белән генә алар арасында Нуриянең дә булуын шәйләп калды, оялтырмын дип, янына барырга кыймады.

Директорның Зиннурны беренче елдан ук завуч итеп куюының үз сәбәбе дә бар. «Белемле егет, акылы да юк түгел, ата-анасы да хөрмәтле кешеләр. Эш җаена төшенә торсын, бәлки озакламый директор урынын да аңа ышанып тапшырырга туры килер»,—дип уйланды ул үзалдына, җитәкче булып озак эшли алмаячагын алдан ук сизде. Җаннарына төште директорның, җелеген суырды көнчелеге чиктән ашкан хатыны. Өннәш үзе мәктәп китапханәсендә эшли. Директор булып эшләү дәверендә күп мәктәпләрдә булып, байтак китапханәчеләрне күрде Даут. Эшләрен күнел биреп, һәр китапның үз урынын белеп, укытучыларга файдалану, укучыларның күнелләрен китапка тарту өчен төрле күргәзмәләр оештырып, җан атып башкарган китапханәчеләрне күрсә, үз хатыны исенә төшеп,

йөрәге әрни аның. Эшенен дә, өенең дә атасы-анасы юк Өннәшнең. Тәртипсез, жан көеге булды ир өчен. Мут күзләре уйнап торыр. Яшь чагында типтергән, күп ирләрне кочагында жылыткан хатын хәзер дә оят-фәләнне белми. Азгын кайнана килененең рәтле булуына ышанмаган кебек, Өннәш тә иренең тугрылыгына ышанмый. Коллективтагы укытучылардан гына түгел, өлкәнрәк сыйныф укучыларыннан, алай гына түгел, ире яныннан үтеп киткән һәрбер хатын-кыз затыннан көнләшә. Психикасы бозык авыру дәрәжәсенә житкән хатын ирен эт итеп сүгә, һәр адымын тикшереп йөри, директорның кеше күзенә күренерлеген калдырмады. Моны белеп бетергән укытучылары, Өннәшнең оятсыз теленә керәселәре килмичә, ялгыз гына директорлары янына килмәс булдылар. Эшендә тәм тапмаган хатын, тизрәк өенә кайтасы урынга, бүтәннәрнең гайбәтен сатып, жыен тузга язмаганны сөйләп йөрүдән бушамый.

Беренче эш көнен Зиннур дулкынланып көтте. Белеменең ныклыгына ышанды егет, институтта да гел алдынгылар исемлегендә йөрде. Хәтере яхшы, кызыксынучан студентка уку да бик авыр булмады. Укуын укыды да бит, балаларга аңлату, дәрестә аларга иң-иң катлаулы материалны да адәм рәтле тел белән, аңлаешлы итеп төшендереп бирү бөтенләй икенче нәрсә. Балалар белән уртак тел таба алу сорала монда. Теләсә нинди кыен хәлдән дә чыга алырлык сабыр акыл, түземлелек житәрме аңа? Азмыни яшь укытучы алдында туган сораулар. Беренче кыңгырау, иң беренче дәресе аның күңелендә әллә нинди борылыш мизгеле булып сакланып калыр, чөнки бүгенге көннән ул үзе өчен генә түгел, күзләрен мөлдерәтеп аңа карап торган уннарча малайлар-кызлар өчен дә жавап тотачак.

Бала-чага бик сизгер бит. Үз фәнен белеп, яратып укыткан, моңардан тыш укучыларны фотога төшерү осталыкларына өйрәткән, төрле ярышлар оештырып йөргән Зиннурны да тиз арада үз итеп өлгерде алар. Мәктәп тормышына әкренләп жан керә башлады. Ләкин завуч буларак эше аның үзен канәгатьләндермәде. Дәресләрне жайлы, файдалы үткәрү өчен күргәзмә әсбаплар түгел, хәтта дәреслекләр дә житми. Уку эшләре буенча сораулары да байтак иде, бәлки берочтан китаплар да юнәтә алмамынмы дип, ул Тубылга барырга жыенды. Ләкин мәктәпнең аты-фәләне юк, әлеге дә баягы колхоз рәисенә баш иеп барырга туры килде. Шул көннәрдә генә Шыр Шәкүр үзе торага[1] барасы икән, Зиннур да аңа иярде. Колхозның нәсел айгыры Агаяк очыртып кына барды юлчыларны. Кайтыр юлда сугылып алачагын белдереп, рәис үз юлы белән китте. Ике-өч сәгать үттеме икән, эшләрен төгәлләп бетергән, борыны кишердәй кызарган рәис, әйдә кайтабыз дип, кереп тә житте. Зиннурның әле эшләре күп булуын ишетеп, кул селтәп, кайтыр юлга да кузгалды. Аның әле кайтып, эт юасы кадәр[2] эшләрен бетерәсе бар, имеш. Шулай итеп, мәктәп завучы Абдуллин пароход белән кайтырга өмет итеп калды.

РОНО мөдире Марфа Ивановна бик сирәк очрый торган итәгатьле, кешелекле ханым иде. Күпне башыннан кичергән, чәчләренә чал кергән, ләкин картлыкка бирешмәгән, сабыр холыклы бу житәкче Зиннур кебек тәжрибәсез яшь белгечләргә аеруча игътибарлы булырга, мөмкин кадәр ярдәм итәргә тырыша. Бу юлы да, башка эшләрен куеп торып, Көмешлесу мәктәбе проблемаларын тыңлады, байтак мәсьәләләрне аңлатып, төшендереп бирде. Ахырда китап кибетенә кереп, дәреслекләр сорап карарга киңәш итте.

Марфа Ивановна яныннан әллә нинди бер тынычлану, ышаныч белән чыкты Зиннур. Юлда килгәндә үзен борчыган сораулар да бер тәртипкә тезелеп, ачыклана төшкән кебек булдылар. Ул зур өметләр белән китап кибете ишеген ачты, ләкин гозерен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, эшсезлектән интегеп, ни эшләргә белмәгән юантык хатын кып-кызыл иреннәрен бөреп:

---

[1]Тора—шәһәр.

[2]Эт юасы кадәр—бик күп.

—Уку елы күптән башланды лабаса, хәзергәчә нишләп яттын сон?—дип аны кисәк кенә бүлдереп тә куйды.—Бетте дәреслекләр, бет-те-е-е.

Зиннур да тиз генә бирешергә теләмәде:

—Безгә татарча китаплар кирәк, бәлки берәр почмакта мина дигәннәре посып ятадыр, карагыз әле,—дип дәвам итте ул,—эшегезне буш итмәм, бездә кәреш[1] тә шәп каба.

Дүрт ел Төмән каласында студент шулпасын юкка гына чөмермәде егет, майламаган табадан коймак купмавын бик әйбәт белә иде.

—Булышсагыз, мен рәхмәтләр укыр идем,—диде ул бөтен тел осталыгын җигеп, җаен туры китереп, сатучынын буын аралары күперел торган озын тырнаклы кулына биш сум акча төртте. Сатучынын бөрелгән иреннәре ничектер җәелеп китте, күзләрен уйнаклатып:

—Әгәр бик теләсән, егеткәй, складка үзен кереп актарынып кара. Анда әллә нинди китаплар аунап ята,—диде һәм, арт санын уйнатып, үзе үк склад ишеген ачты. Кирәк китаплар табыла калса дип, ике капчык та суздьг.

Шатлыгыннан сулышы капкандай булды егетнен: алдында таудай өелеп сатудан төшерелгән татарча дәреслекләр, матур әдәбият китаплары ята иде. «Менә бит ничек эшләр, анда, мәктәптә, бер китапка тилмереп утыралар, ә монда бер өем китап чүплеккә чыгарып ташларга чират көтеп ята». Казына торгач, Зиннур мәктәп бик мохтаҗланган, ин кирәкле дигән китапларны аерып алды. Алары да ике капчыкка дынгычлап тутырырлык булды.

—Әллә эзләгәненне таптын инде?—дип каршы алды аны әлеге мимылдык абыстай, егетнен бәхет кошы тоткандай балкыган йөзенә карап. Һәр китапнын бәясен исәпләп, алыш-бирешне төгәлләгәч:—Ерак кайтасынмы сон, ат-фәләнен дә күренми?—дип кызыксынды.

—И, апа-җаным, бу китаплар өчен җир читенә барырга да риза, ничек булса да кайтып җитәрмен әле.

Сарычәч, бөтен йөзе белән елмаеп, озатып калды.

Октябрь аенын сонгы көннәре иде. Көмешлесу мәктәбенен яшь завучы авызлары бер-берсенә ныклап бәйләнгән капчыкларнын берсен алдан, икенчесен арттан инбашына асып, тирләп-пешеп пристаньга килеп җиткәндә, хан заманыннан калган «Туринец» исемле кечкенә генә иске пароход арык карт сыер мөгрәгәндәй итеп бу сезонда сонгы тапкыр юлга чыгасын белдереп, хәбәр салды. Йөгерә-атлый манма суга төшсә дә, пароходка кереп утырганда Зиннурнын күнеле шат иде. Шулай булмый ни, китаплар да табыштырды, пароходка да өлгерде! Күк капусы ачылгандай тойды егет, ун-унбиш минутлап кына сонласа да, ярда басып калачак иде бит. Зиннур иртәгә укытучыларына яна китаплар таратып шатландырасын күз алдына китереп, елмаеп куйды.

Пароход «ух-ух» килеп көчәнеп кузгалып киткәндә, көн кичкә авышкан, кояш баерга тәртә буе гына калган иде. Тимер айгыр бик гайрәтләнеп пошкырып торды да, парларын чыгарып, тәгәрмәч калакларын шапылдатып, кузгалып китте. Ләкин бик тиздән иске тагарактай сабырланып калды, ташбакадай акрын гына үрмәли башлады.

Палубадан суга карап уйга талган Зиннур тәненә җинелчә генә суык үтә башлаганын тойды, юка плащынын якасын күтәреп, җилгә аркасы белән басарга тырышты. Елга агымына каршы акрын гына барган пароход Иртеш белән Тубыл суын бергә куша, болгата иде.

Галәмәт бу табигать: сазлыклардан агып чыккангадыр Тубыл елгасы карасу-саргылт төстә, ә Иртеш суы исә зәнгәрсу-ак иде. Ин гаҗәбе дә шул: Сатыйхан авылы янында ук очрашкан елга сулары, араларын сызып куйгандай, бер-берсенә кушылмыйча агалар, Тубылны узганнан сон да әле байтак өзгәләшеп-тарткалашып баралар. Ахырда гына, тынлаусыз бала атасы сүзенә баш игәндәй, Тубыл да Иртешкә буйсынырга мәҗбүр

[1]Кәреш—чөгә балыгы, стерлядь.

була—су бер төстәге тоташ җәймәгә әверелә.

Пароход эчне пошырырлык дәрәҗәдә акрын кыймылдый иде, торанын кремле дә күздән югалырга өлгермәде, күзгә төртсән күренмәслек карангы салкын төн башланды. Иртеш буендагы тал-тирәкләр, мәнге яшел эрбетләр, нарат-чыршылар карангылык эченә кереп чумдылар. Прожектор тасмасы гына, юлчыларны тынычландырырга тырышкандай, бу карангылык базыннан чыгу юлын күрсәтә, тышкы дөнья белән тоташтыра иде.

Кузгалып китү ыгы-зыгысыннан соң урнашкан тынычлык озакка сузылмады, пароход командасы урнашкан каютадан яшелле-күкле җыр тавышлары, кычкырып көлешкән, тагын әллә нинди авазлар чыга башлады. Пароход та исерек кеше кебек чалышаеп-кыйшаеп китә, алпан-тилпән килеп йөргән матрослар да палубага балласт өчен ком тутырып куелган мичкәләрне бер ягыннан икенче ягына тәгәрәткәндә абынып егылып төшәләр, әче итеп сүгенеп куялар. Төнге сәгать икеләрдә пароходнын үз авылларын үтеп баруын шәйләп, Зиннур төшерүләрен үтенде. Исереп кызып алган рулевой үзен бик белдекле итеп тоя башлаган иде күрәсең:

—Вакыты җиткәч, туктатырбыз, без беләбезме, синме?—дип кенә җибәрде. Бераздан, Зиннур исәпләвенчә авылны узып ике-өч чакрым киткәч, «Туринец» борынын сайга китереп терәде.—Давай, не задерживай!—дип кычкырды гөбедән чыккандай калын тавыш.

Әлеге алпан-тилпән килеп йөргән ике матрос бозланып каткан трапны салдылар. Бер тактадан гына торган бу трапка басарга да куркыныч иде. Капчыкларын төшерешергә ярдәм сораган Зиннур җавапка ихахайлап көлгәннәрен генә ишетте.

Егетнен трапка басарга икеләнебрәк торганын күргән капитан да югарыдан торып кына акыллы киңәш бирүне кирәк дип тапты күрәсен, карлыккан тавыш белән.

—Шүрләмә бер дә, тирән түгел, батмассың!—дип кычкырды.

Крысов фамилияле кыска буйлы, төптән койгандай юантык гәүдәле бу кеше чыннан да әллә нинди бер ерткыч җанварга охшый иде. Бу минутта башына мондый урынсыз уй килүенә үзе үк сәерсенгән Зиннур акрын гына трапка басты. Аякларын тактадан аермаска тырышып, шуытып-шуытып кына атласа да, дулкын белән чайкалып торган басмада тигезлекне саклап кала алмады, ике-өч адым атлауга ук, шапылдап боздай салкын суга барып та төште. Йөрәге «жу» итеп китте егетнен. Бозлы суга төшсә дә, тәннәре чымырдап, аркасы тирләп чыккандай булды. Бәхетенә яр кырые чыннан да тирән түгел икән, су бил тиңентен генә булыр.

Ул исенә килеп, ярга үрмәли башлаганда, пароходтагылар, ямьсез көлешеп, бераз карап тордылар да, прожекторны Иртешкә борып, китеп тә бардылар. Дөм-карангыда япа-ялгызы, өсте-башы манма су булган Зиннур көч-хәл белән ярга чыгып ауды. Прожектор яктысыннан соң күзләре тәмам сукырайгандай булды. Ул корт чаккандай сикереп торды да, капшанып китапларын эзли башлады. Ни гаҗәп: капчыклары ярдан ерак та түгел тәгәрәшеп ята һәм алар коп-коры иде. Китапларны саклау теләге шулкадәр зур булгангадыр, суга егылганда нишләгәнен үзе дә аңламастан, капчыкларны ярга ыргытырга өлгергән икән бит яшь укытучы! Йөрәгенә жылы үткәндәй булды егетнен. Болай булгач, хәле үкенерлек үк түгел икән, танга кадәр ышыклану әмәлен тапса, тан аткач, авылга кайтып җиту озак булмас...

Якты уйлар анын йөген җиңеләйтте, җанын җылытты. Шул хәлдә атлаганда, текә ярга килеп бәрелеп, мангаен сыдыртты. Ике капчыкны иненә аскан көе, сыйпаланып-капшанып бара торгач, өскә күтәрелергә җайлырак урын тапты. Ә өстә болан үтмәслек куе чытырманлык иде. Үзе буйлык үләннәрне аралап, шүрәле бармакларыдай ботаклардан капчыкларын көчкә ычкындырып бара торгач, такыр печәнлеккә килеп чыкты. Бу кайсы төш: Кызылкашмы, Какмы? Ай ахырындагы болытлы төндә хәтта ачыграк урында да бернәрсә шәйләрлек түгел. Бер-бер нәрсәгә

килеп бәрелмәс өчен, буш кулын алга сузып, аякларын шудырып кына атлый башлады. Озак та үтмәде, бәхете булып, печән кибәненә килеп төртелде. Капчыкларын иненнән төшереп, печәнне йолкырга, аю өнедәй куыш ясарга кереште. Берәр кочак печән йолкынгач, кибән астына яшереп калдырган чиләк, кружкалар килеп чыкты. «Кибән хуҗасының әле җыелып бетмәгән чабынтысы бар икән»,—дип уйлап алды Зиннур. Маташа торгач, үзе сыярлык өн ясалды, капчыкларын өннең авызына ук тартып китерде, печәнгә чумып, күзләрен йомды. Аяк-кулы җылына төшкәч, изрәп йокыга талды.

Азмы-күпме вакыт үткәндер, Зиннур бала елагандай тавышка уянып китте. Аяк-кулларын селкеткәләп, күзләрен көчкә ачып караганда, таң аткан иде инде. Йоклаган куышын каплап торган капчыклары өстеннән иртәнге кояш нурлары саркып кергәне сизелә. Оеп калган аякларын язырга тырышып, урыныннан кузгалса, тораташтай катып калды. Ул йоклаган кибәннән биш-ун адым гына читтәрәк, муеннарын югарыга сузып, ике бүре улап утыра. Егетнең йөрәге дулап тибә башлады. «Инде нишләргә, бу явызлардан ничек котылырга?»—дигән уй чигәсен кысты. Булдыра алган кадәр кыштырдамаска, бүреләрнең игътибарын үзенә тартмаска тырышып, акрын гына аякларын сузгаларга кереште. Печән астында яткан чиләк-кружкалар шаңгырдашып үзләрен сиздереп куйдылар. Бүреләр дә, як-якларына карангалап, улауларыннан туктадылар. Утырып эш чыкмаячак, нәрсәдер эшләргә кирәк. Капчык читен кыйшайтып, Зиннур үзе төн үткәргән урынның кайсы печәнлек булуын чамаларга тырышты. Әйе, ул ялгышмаган, Көмешлесу ике чакрымлап артта калган булырга тиеш. «Көне буе утырсаң да, сине моннан килеп эзләүче булмас, ә бүреләрнең китәргә исәбендә дә юк. Тәвәккәлләргә кирәк». Әбисенең мискәне буш чиләккә янчегәнче суккалап, ач бүреләрне качыруын исенә төшерде. Пинҗәге астындагы ау пычагының кынында булуын тикшереп карады, сузылып аяк астындагы буш чиләкне һәм алюмин кружкаларны алды. Эченнән генә әнкәсе бала чакта ук өйрәткән догаларны укып, кружкаларны буш чиләккә китереп орды. Колакларны тондырып чиркәү чаңы кебек тавыш яңгырады. Тынлыкны ярып үткән бу тавышка ерткычлар сискәнеп куйды, бер-ике адым артка чигенде. Бүреләрнең чигенүе ана көч өстәгәндәй булды, ул тагын да ярсыбрак суга башлады, кыюланып, алга таба ике-өч адым ясады. Моны көтмәгән ерткычлар читкә тайпылдылар һәм чытырманлыкка кереп яшеренделәр. Тавышка иртә таңнан балык тотарга төшеп килүче авылдашлары килеп чыкты. Зиннурның буыннары йомшарып төште, тирән сулап, капчыклары янына килеп чүкте. Яңа гына күзен ачкандай, тирә-ягына карады егет: Иртеш өстеннән томан күтәрелә, саргая башлаган үләннәрдә салкын чык җемелди: табигать уянып килә иде.

Ул өйгә кайтып кергәндә, әнкәсе тимер мичне ягып, иртәнге ашны әзерли, күмер самавыры инде күнелле генә гөрләп утыра иде. Әнисе, таң белән кайтып кергән улының лычма су булган киемнәрен күреп, ни дип тә әйтергә белмәде, сораулы күз карашын улына төбәде. Шуны гына көткәндәй, капчык авызлары чишелеп китеп, китаплар шапылдап идәнгә сибелделәр.

—Шөкер, чыланмаганнар икән.

—Суга төшкән тавыкка охшап калгансың бит, нәрсәң чыланмаган? Суга баттыңмы әллә, балакаем? Ни булды сиңа?

—Миңа бернәрсә дә булмас, әнкәй, әнә китаплар коры калган!

Улының бу сүзләреннән бернәрсә аңламаса да, Ниязбикә карчык тиз арада коры-җылы киемнәр китереп бирде:

—Ярый, калганын соңыннан аңлатырсың, суык үткәргәнче киен тизрәк,—дип, улын олы якка озатты.

Мал-туар яныннан әткәсе дә керде. Чәй эчәргә утыргач, Зиннур картларны хафага салмаслык итеп кенә булган хәлләрне сөйләп бирде. Әнкәсенең җылынып мунча кереп чыгарга үгетләвенә карамастан,

китапларын күтәреп, мәктәп ягына юл алды. Тизрәк барып, укытучыларны сөендерәсе килде.

Чынлап та куанычның чиге булмады, әйтерсең лә завуч мәктәпкә энҗе-җәүһәрләр алып кайткан! Күтәренке күңел белән дәресләр башланды, Зиннур да башы-аягы белән эшкә чумды. Көн кичкә таба авышканда гына, әнкәсе яккан мунча исенә төшеп, ашыга-ашыга кайтырга чыкты.

Мәктәп тормышы көндәлек мәшәкатьләр белән үтә торды. Балаларның укуга омтылыш-теләкләре күп вакытта укытучының үзеннән дә тора бит. Институтта фотога төшерү эшенә өйрәнүе дә ярап куйды, әнә бит югары сыйныф укучыларының бөтенесе диярлек фототүгәрәккә йөри башлады. Баштарак оялып кына килгән кызлар да тиз арада эшкә өйрәнеп киттеләр. Укучылар төшергән фотолар стена газеталарында, төрле стендларда урын алды. Үз фәне белән укучыларның да кызыксына баруын тою Зиннурга чиксез горурлык та китерде.

Шулай җан атып эшләп йөргәндә аны, һич уйламаганда, райисполкомга чакыртып алдылар. Сәбәбен белмәсә дә, артык пошаманга төшмәде Зиннур, куркырлык сәбәбе юк ич. Китәргә җыенганда Нуриянең аны аулак урында көтеп торып әйткән сүзләре генә сагаерга мәҗбүр итте.

—Хәйрүш: «Мин аны төрмәдә черетәм», дип мактана икән, авылга «колхозның печәнен урлады» дигән хәбәр тараткан. Зинһар, саграк булыгыз.

Бригадир Хәйрүшнең ни өчен аларга каныгуын икесе дә аңлыйлар, шуна күрә эчтән тындылар. Сугышып йөреп берни булдыра алмаган Кәрбек икенче юл белән алардан үч алырга уйлаган, ахрысы. Дөрес сүз—таш яра, диләр, бу юлы да берни булдыра алмас Хәйрүш. Райисполкомда да аның ялганнарына ышанып утырмаслар. Нурия Зиннурны чын мәгънәсендә ут йотып озатып калды.

... Тубылда эш чынлап та зурга китте. РИК рәисе кабинетына барлык исполком әгъзалары җыйналган иде. Түрәләрнең кәттәләре барысы да монда, түрдән райисполком рәисе Бальчук үзе урын алган, аннан түбәнрәк райком вәкиле Кызылбаев, икенче ягында корсагы кара кителен төртеп чыккан прокурор Медведев мышнап утыра. Болардан тыш бүлек мөдирләре, тагын әллә кемнәр бар. Сәркәтип кыз Зиннур Абдуллинның чакырылуын хәбәр иткәч, ул кабинетка атлады. Зур бүлмәдә бик әһәмиятле мәсьәләне хәл итәргә җыенгандай, житди йөз белән утырган бу агайларның барысын бергә күрүдән Зиннур бермәлгә югалып калгандай булды, күзләре белән үзенә терәк булырлык ышанычлы кешене эзләде. РайОНО мөдире Гостеванын да монда утыруы аны тынычланырга, үз-үзен кулга алырга ярдәм итте. Икенче мизгелдә үк ул Кәрбек Хәйрүш белән күзгә-күз очрашты. Үзенең өстенлеген тоеп, мыскыллы елмаеп утырган авылдашын күрү белән, аның йөрәге кысылып куйгандай булды. «Нуриянең сүзләре дөрес булган, ахры,—дип уйлап алды ул.—Шулкадәр дә түбән җанлы, пычрак бәндә булыр икән!» Житәкчеләр эшне озакка сузып маташмаска булдылар ахры, сорауны кабыргасы белән куйдылар.

—Абдуллин, сине дәүләтебез социализм төзүче намуслы балаларны тәрбияләргә дип укытып чыгарды,—дип башлады сүзен рәис, урыныннан кымшанмыйча да.—Дүрт ел буе халык жилкәсен кимереп, стипендия алып яттың. Инде кеше булып кайткач, пычрак эшкә тотындыңмы? Син «Урак-чүкеч» колхозының печәнен урлауда гаепләнәсең!»

Зур дәрәжәле кеше авызыннан мондый гаепләү сүзе ишетү Зиннурга коточкыч бер хәбәр кебек тәэсир итте. Бу сүзләр сорау булудан бигрәк кире какмаслык дәлил булып яңгырадылар.

—Телеңне йоттыңмы әллә, әйт, социалистик милеккә кул сузуның иң зур җинаять икәнен ВУЗда өйрәтмәделәрмени?

Зиннурны иң ачындырганы исполком рәисенең аны тыңлауны кирәккә дә санамыйча, алдан ук эшнең нәтиҗәсе ни белән тәгәлләнәсенә ышанып сөйләве булды. Ул күкрәк киереп, бу юлы инде үзенең җинәсенә нык ышанган кешедәй кәперәеп утырган Кәрбеккә күз ташлап алды һәм ачуыннан, бу хәлдән чыгар юлны тапмау гарьлегеннән буылып

китте. Үзенең гаепле түгеллегенә нык ышанса да, сүзне нидән башларга белмәде: нәрсә әйтсә дә, барыбер ана ышанмаслар кебек иде. РайОНО мөдиренең сораулы күз карашы ана фикерләрен җыярга булышты:

—Эшне тикшерми торып кешегә гаеп тагу кирәкмәс иде,—дип башлады ул сүзен кызып китмәскә, күңелендә дулаган ачуны басарга тырышып,—минем бер чеметем дә колхоз печәнен алганым юк. Сез әнә теге эче кара бәндәнең җырын җырлыйсыз булыр, чеп-чи ялган бит бу!—Зиннур үтерердәй булып Хәйрүш ягына күз ташлады.

—Син, манка малай, авызыңнан нинди сүз чыкканын уйлап сөйлә.—Рәис ап-ак кульяулыгы белән маңгай тирен сөртеп алды.—Хәйбуллов иптәш, сез шулай юкны язып безнең башны катырып йөрисезме?

Бар да борылып бригадирга карады. Мондый борылышны көтмәгән күрәсең, Хәйрүш бермәлгә чүгеп куйды, бик житди булырга тырышып, як-ягына карап алды. Ул бүген кунакка баргандай чиста-пөхтә киенгән, муенына чуар галстук тагып җибәргән. Болай киенеп күнекмәгәнлектән булыр, аның кыяфәте әллә ничек сәеррәк иде. Торып баскач та, ул кулы белән пинжәген сыйпаштырып, галстугын төзәтеп алды. Ялтыратып артка таба тарап куйган чәчләре астыннан, тырпайган зур колаклары гадәттәгедән дә җәенкерәк булып күренде. Бик зур нотык сөйләргә җыенгандай, тирән сулыш алып, сүзен башлады:

—Иптәшләр,—тавышы бик сыек чыккач, Хәйрүш тамак кырып алды,—кхым-кхым, иптәшләр. Тикшергәч, безнең Уба астында бер кибән колхоз печәне тулмады. Мин азык әзерләүгә җавап бирүче фуражир Сәбәркәне йорт саен кереп, кем печән кайтарганын тикшерергә чыгардым. Ул печәнне Зиннур Абдуллинның сарай төбәсендә тапкан. Шул югалган кибәннең биркәсен ул миңа китереп тапшырды. Мин Абдуллиннан печәнне колхоз фермасына төяп китерүен үтендем, ул миңа кукиш күрсәтте.

—Менә сиңа укытучы!—дип куйды Кызылбаев.

Хәйрүш өстәл артындагыларга печән биркәсен китереп бирде. Таякка кадаклаган такта кисәгенә «17 номерлы кибән. 12 центнер, 1 сорт» дип язылган иде. Биркәне кулдан-кулга йөртеп карап чыктылар. Бирелгән сорауларга Зиннурның җавабы бер булды:

—Печәнне атам белән казна җирендә эшләдек, лесхозның рөхсәт кәгазе бар.

—Кайда, күрсәт булса?

—Мин монда нинди сорау буенча килгәнемне дә белмәдем, үзе бик әзерләнгән булса да, Кәрбек колак мине кисәтеп куймады шул.

—Син әле карак кына түгел, ялганларга, кеше кимсетергә дә бик оста икәнсең.

Шулчак прокурор авыр гәүдәсен хәрәкәтләндереп куйды.

—Мин исполкомны ярты сәгатькә өзеп торырга тәкъдим итәм, Абдуллин чыгып ишек төбендә көтеп торсын,—диде ул мышнап. Эшнең болай озакка китүенә кәефе кырылуы аның йөзенә үк чыккан иде.

Зиннур чыккач, прокурор сүзен дәвам иттерде:

—Районда колхоз милкен урлау күбәеп китте. Монда Абдуллинның печәнне урлавы көн кебек ачык. Башкаларга сабак булсын өчен, аны каты җәзага тартырга тәкъдим итәм. Хәзер үк телефон аша милиция начальнигын һәм бер милиционерны чакыртып, Абдуллинны кулга алырга кирәк, арестка ордерны хәзер үк үзем бирәм.

Прокурорның сүзен Бальчук белән Кызылбаев та хупладылар, бүлек мөдирләре сүзгә кушылмыйча гына кул күтәрделәр. Марфа Ивановна гына мәктәпләрдә югары белемле кадрлар җитмәвен, Абдуллинның әле яшь белгеч булуын, выговор-мазар гына бирергә кирәктер бәлки, дип әйтеп карады. Ләкин аны тыңлап торучы да булмады, киресенчә, кызып китеп, каракларны яклауда РайОНО мөдиренең үзен үк гаепли башладылар.

—Каракка киләчәк буын социализм төзүчеләребезне тоттырганчы андый специалистларның булмавы хәерле,—дип сүзне төгәлләделәр.

Яшь укытучы Зиннур Абдуллинның эше шулай хәл ителде. Шул

арада милиция начальнигы да килеп житте, тиз генә исполкомның карарын ана да аңлаттылар. Ул да, мәсьәләгә төшенүен белдереп, баш какты.

Сөйләшү, киңәш итешүне беткәнгә санап, янадан Зиннурны чакырдылар. Шушы биш-ун минут эчендә Зиннурның башыннан әллә нинди уйлар үтеп өлгерде. Әгәр аны чыннан да гаепле дип тапсалар? Юк, болай гына хәл итмәсләр, авылларына барырлар, ышанычлырак кешеләрдән сорарлар. Зиннурның намуслы кеше, тырыш укытучы икәнен авылдашлары, укытучылар әйтми калмас. Бер Кәрбек Хәйрүш сүзенә карап кына кешегә шундый яла якмаслар...

—Зиннур Абдуллин,—диде Бальчук, аңа бик үк туры карамаска тырышып,—исполком жыелышы сине «Урак-чүкеч» колхозының 12 центнер печәнен урлаган өчен шушы минуттан башлап кулга алырга һәм төрмәгә озатырга дигән карар чыгарды. Иптәш милиционер, арестованныйны хәзер үк алып китегез, менә прокурорның ордеры.

Теләсә нинди шелтә сүзе ишетергә дә әзер булып, мондый карар чыгарырлар, дип башына да китермәгән иде Зиннур. Һич көтмәгәндә тукмак белән тондыргандай хис итте ул үзен.

—Туктагыз әле, ничек кулга алырга, ни өчен? Ичмаса атам-анам белән саубуллашырга, эшне аңлатырга рөхсәт итегез.

Ул арада милиционер аның янына ук килеп баскан, кулын артка куеп чыгуын көтә иде.

—Алайса мина эшнең асылын аңлатырга рөхсәт бирегез, бу барысы да бригадир ялганнары... Аның сүзен рәиснең кискен тавышы бүлдерде:

—Без болай да син каракка бер сәгать тә биш минут вакытыбызны әрәм иттек. Сәгатьләр буенча синең белән гәп сатарга безне кем дип беләсең? Эш кешеләре без. Әле исполкомның көн тәртибендә тикшерәсе мөһимрәк мәсьәләләребез эт юасы. Сүз бетте, марш моннан!

Милиционер Зиннурны эткәләп-төрткәләп алып чыгып китте, бригадир Кәрбек бер башка үсеп, җиңүче кыяфәте белән ишеккә юнәлде.

## 8

«Колхоз печәнен урлаганы өчен Зиннур Абдуллинны төрмәгә яптылар» дигән хәбәрне авылга Хәйрүш үзе алып кайтты. Аның уенча, Нурия хәзер карак укытучының исемен дә ишетергә теләмәс, мәктәпкә дә йөрмәс, тиз арада Хәйрүш корган тозакка да килеп кабар. Күзге ямьсез көн, берөзлексез яуган янгырдан юллар боламыкка әйләнеп калган. Хәйләсенең барып чыгуыннан үзе үк ләззәтләнеп, рәхәт уйга-хыялга талып барган Кәрбек арбасы авып китеп, тәгәрәп төшүен сизми дә калды. Пычрак, сикәлтә юлдан бара-бара арбасының тәгәрмәче төшеп киткән икән. Бите-башы кубакка[1] буялып, озак маташа торгач, тәгәрмәчне авылга кадәр кайтып житәрлек итеп кенә әмәлләп куйды. Эченнән ачуына буылып, сүгенеп кайтса да, жиңү тантанасы барыбер үзенекен итте. Тизрәк авылга кайтып, эчен тырнап торган хәбәрне башкаларга да житкерергә ашкынды.

Усал хәбәр йөгерек була. Зиннурның таш капчыкка ябылуы башта мәктәпне урап чыкты, аннан бик күпләрне гажәпләндереп бөтен авылга, эти-әнисенә дә ишетелде. Алар, ни уйларга да белмичә, аһ-ваһ килделәр. Зиннур абыйсы урынына мондый усал хәбәрнең кайтуын көтмәгән Нурия утка төшкәндәй булды, сүзләрен бүлешер, эч серләрен чишәрдәй кеше тапмыйча изаланды. «Ничек булды соң әле бу?—дип өзгәләнде кыз.— Шул Кәрбекнең сүзенә ышанып кына эш йөрткәч, кемнәр утыра соң анда житәкче булып? Фәтхулла бабайлар ни эшли икән?» Эссе көндә ярга ташланган балыктай бәргәләнде кыз бала. Туктабикә, Камиләләр белән очрашкач кына, бераз тынычлангандай булды. «Эшне болай калдырмаслар әле, берәр юлын табарлар»,—дип юатты аны дуслары.

---
[1]Кубак—пычрак.

Берәү дә чакырмастан, укытучылар дәресләрдән соң директор кабинетына җыелдылар. Даут абый юаш, гадел кеше:

—Ул бит печәнне үзе чапты. Әйе, казна җиреннән. Нишләп урласын ди! Бер-бер аңлашылмаучылык чыккандыр, барып бригадир белән аңлашу кирәк, кул кушырып утырып булмас,—дип, чыгып китте. Укытучылар, ни уйларга да белмичә, аны көтеп калдылар. Үз хәбәренә үзе шатланып күкрәк киереп йөргән бригадирны табуы читен булмаган, күрәсен, директор тиз арада әйләнеп тә кайтты. Аны укытучылар, югары сыйныф укучылары уратып алды.

—Йә, нәрсә булган, нинди сүз ул?—дип каршылады аны дистәләгән пар күз.

—Ул печәнне казна җиренә чиктәш колхоз җиреннән чапкан, диде Хәйрүш иптәш. Алар кибәнне биркәләп тә куйган булганнар. Фәтхулла әкә «Печән эчендә бу нинди язулы таяк?» дип фуражир Сәбәркәгә биргән, анысы язуны Хәйрүшкә тоттырган. Әнә шул биркәне прокурор да күргән. Нәтиҗәсен үзегез дә беләсез,—дип тәгәлләде сүзен директор.

—Дөм ялган сүз бит бу,—дип, як-ягына карады Нурия.—Печәнне Зиннур абый әтисе белән казна җиреннән чапты. Мин Камилә белән бергә аларга кибән башы очларга, чүмәлә төбен тырнарга да булыштым. Моны Мифтах абый да, көтүче Чамакә әкә дә белә. Аңлашылмаган законсызлык бу.—Нурия үзен якларга кеше эзләп, укытучы абый-апаларына, дусларына күз йөртеп чыкты. Барысынын да башы каткан, барысының да күз карашлары сораулы иде.

—Эш тә шунда шул: барысы да законлы эшләнгән. Район советының карары прокурорның ризалыгы белән чыккан, кулга алуга рөхсәт кәгазе дә язылган.

—Даут абый, судка язу кирәк, эшне аңлатырбыз, әнә шаһитлар да бар икән,—диде өлкән яшьтәге укытучыларның берсе.

Бу сүзләр Нурияне дә канатландырып җибәрде. Олылар Хәйрүшнең ни сәбәпле Зиннур абыйсына каныгуын белеп бетермиләр, бу эшне чыннан да берәр аңлашылмаучылык кына дип кабул итәләр, шулай да аларның үз мәктәпләренә җанлылык кертеп җибәргән яшь коллегаларын яклаулары көн кебек ачык иде. Явыз Кәрбекнең кубызына биеп, дәшмичә калсалар, ул тагын да азына төшәр. Кайберәүләр эшнең уңышлы чыгуына ышанмауларын белдереп, икеләнүле тавыш белән:

—Нәрсә генә кыла алырбыз икән соң без, әнә утыз сигезенче елда да бер гөнаһсызга биш кешене юк иттеләр ич, нишли алдык соң ул чакта?—дип бер-берләренә карандылар.

Шулчак мәктәпкә, чарасызлыктан интегеп, Фәтхулла әкә килеп керде, сүлпән генә сәлам бирде.

—Бөтен өметем сездә генә, балакайлар. Югыйсә, Зиннурымның башын төрмәдә черетерләр. «Дөреслек таш яра» дигән картлар, бәлки берәр чарасы бардыр? Тугры-дөрес кешеләр кырылып бетмәгәндер бит әле җир йөзендә? Газиз баламның башын әрәм итмик, оланнар,—диде, укытучыларның әле берсенә, әле икенчесенә өмет белән карап алды.

Иртәгесен Даут абыйлары РайОНОга, райисполкомга барып карамакчы булды, аны дүрт күз белән көтеп калдылар. Мәктәп директоры алып кайткан хәбәрләр дә тынычландырырлык, өмет өстәрлек булмады.

—Прокурорга язып карарга киңәш бирделәр. Лесхозның печән чабарга рөхсәт биргән кәгазен алып килергә дигәннәр иде, аны белешергә дип кайтыр юлда Фәтхулла абзый йортына сугылдым. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, ул каһәр төшкән кәгазь Зиннурның чалбар кесәсендә булган икән. Улым кайтуга дип, Ниязбикә апа ул чалбарны юып куйган. Кесәдәге кәгазь теткәләнеп беткән, укырлык, берәр нәрсә аңларлык түгел. Тагын шул: Зиннурның кибәне колхоз җирендә булуын кибәнне биркәләүче Сәбәркә белән Локманнар язма рәвештә раслаганнар.

—Ул кибән аяклымы әллә? Без бит аны үзебез казна җирендәге кушкаен янына утырттык лабаса. Кәрбек, мәлгунь, монда да бер явызлык

эшләгәндер, мөгаен. Үзенең җинәсенә ышанмаса, райисполкомга кадәр барып йөрмәс иде ул куркак җан.—Даут абыйларын ут йотып көтеп алган кызлар ни уйларга да белмәде.

Бу көннәрдә авыл өстендә бер генә хәбәр йөрде. Күпләр Зиннурның хаксызга рәнҗетелүен аңлап, аны якладылар. Хатын-кызлар Фәтхулла карт белән Ниязбикә корткаякны тынычландырырга тырышты: «Ходай насыйп итсә, аңлашылмаучылык бетәр, балагыз исән-имин котылып кайтыр»,—дип юаттылар.

Мәктәп директоры, авыл советы рәисе Зиннәт абыйлары кызлардан Зиннурлар печән чапкан урынны күрсәтүләрен сорадылар. Кызлар исә ышанычлырак булсын өчен Мифтах абыйларын да алып барырга булдылар. Суыклар төшеп, җирләр туңган булса да, болар бәхетенә, әле кар яумаган, печәнлектә бөтен эзләр аермачык күренеп тора иде. Менә алар утырып ял иткән пар каен, бераз гына читтәрәк алар куйган кибән урыны. Ләкин бу ни хәл соң? Трактор белән печәнне тартып кайткан эзләр авыл ягына түгел, ә юлның икенче ягына—колхоз җиренә таба бара. Бу эзләр җир туңганчыга кадәр салынган булган күрәсең, куәтле ЧТЗ тракторының эзләре бик тирән баткан. Печәнне авылга суыклар төшеп, җир туңгач кына атлар белән сөйрәтеп кайтканнар: ат эзләре күренми диярлек, кибән эзе дә, кырпак кына кар яуса да, күмелеп калачак. Бу хәл чын табышмак булды. Бу башваткыч йомгакның җеп очын табарга әлеге дә баягы көтүче Чамакә ярдәмгә килде. Ул килеп, әлегә кадәр үзе игътибар да бирмәгән бер вакыйганы сөйләп бирде. Сентябрь урталарындагы көзге вак яңгырлар тукталып, әбиләр чуагы башланган чак була бу. Көтү йөртүләрнең соңгы атналары. Төшлеккә хайваннарны Сөенчәл чишмәсе янына туплый көтүче. Ерак та түгел МТСтан килгән ЧТЗ тракторлары дистә еллык карт каеннарны төпләп йөри. «Председатель чәчүлек җирләрен киңәйтә икән,—дип уйлый Чамакә.—Киләсе язга көтүне икенче җирдәрәк йөртү мәслихәт булыр», ди. Озак та үтми, трактор тавышлары ул ял итәргә утырган якка якынлаша. Менә трактор үзе дә агач араларыннан килеп чыгып, җәй көнне улы белән Фәтхулла карт җыйган кибән төбенә килеп туктый. Килә-килешкә Локман белән бригадир Хәйрүш сикереп төшә. Тиз арада кибәнне тимер трос белән уратып алып, юлның икенче ягына сөйрәтеп тә куялар. Эш шуның белән төгәлләнә.

—Мин ул чакта, Зиннурның кибәне агачларны төпләргә комачаулый торгандыр, дип кенә уйлаган идем, чынында исә кешенең башын катыр җибәрергә теләгән икән ул эт җан,—дип төгәлләде сүзен көтүче.

Инде җепнең очы күренә башлагач, тракторчыны һәм Зиннур соравы буенча печәнне өйгә сөйрәтеп кайткан егетләрне табып сөйләшергә булдылар. Үзен бер төркем авылдашлары урап, сорау ала башлагач, тракторчы Мәтвәй чыннан да, бригадир кушуы буенча, кибәнне икенче урынга тартып утыртуын әйтте. Моның өчен Хәйрүш аңа ярты да алып килгән, аны шунда ук эчеп тә куйганнар икән. «Миңа нәрсә, мин гаепсез, мин бригадир кушканны гына эшләдем,—дип аклана башлады ул, эшнең кай якка таба барганын аңлап алгач.—Зиннур абыйга зыян китерәсен белсәмме, гомеремдә моны эшләмәс идем! Яртысы-фәләне дә кирәк түгел иде, мин бит белмәдем, мин Кәрбек сүзен генә тыңладым... Мин бригадир сүзен тыңларга тиеш бит...—дип кабатлады ул берөзлексез, үзен әйләндереп алучыларның әле берсенә, әле икенчесенә мөрәҗәгать итеп. Кулларын бутап, яргаланган иреннәрен ялап, чуалган чәчле башын селеккәләп, үзенең гаепсезлеген расларга тырышкан бу бәндәнең ярты литр аракыга җир читенә барырга риза булуы тыңлаучыларның һәрберсенә дә мәгълүм иде.

Шулай итеп, печәннең ничек биркәләнүе, колхоз печәне исемлегенә ни рәвешле кертелүе тәмам аңлашылды. Боларның барысы да ачыклангач, авыл советы рәисе үзе акт язып, кирәк кешеләрдән кул куйдырып, торага юл алды.

Бер айдан соң Тубылда булачак судка бу эшкә бәйләнеше булган

авылдашларының барысы да чакырылды. Авыл советы рәисен, мәктәп директорын, Чамакә әкәне, Нурия, Камилә белән Туктабикәләрне, дусты Мифтахны күргәч, Зиннурның күзләре дымланды. Бу бер ай аны нык үзгәрткән, ул суырылып калгандай күренә. Сакал-мыек баскан йөзе егетне олыгайтып җибәргән иде. Эшнең ничек булуын аңламаудан, язмышы кай якка хәл ителәсен күз алдына да китерә алмаган укытучыны билгесезлек нык изгән күрәсең, суд залына керә-керешкә, сорау тулы күзләрен дусларына төбәде. Бәхетенә, эш аның файдасына хәл ителде. Судка килүчеләр бар да үз чиратларында белгәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләп, аңлатып бирделәр, Зиннур исә күзләрен зур итеп ачып, үз колакларына үзе ышанмыйча, аларны тыңлап утырды. Булса да булыр икән кешедә явызлык! Хәйрүшнең канатлары сынган, башын аска иеп утырган. Ләкин аның хакында эшләгәннәренә үкенәдер дип уйлап ялгышырга кирәкмәстер, күзләре бездәй кадала егетнең, бусыннан котылса, моннан да яманрак эшләр планлаштыра булыр әле хәерсез бәндә.

Зиннурны суд залыннан ук азат иттеләр. Соңгы сүз итеп судья яла якканы өчен гариза язып, Хәйрүш Хәйбулловны җавапка тарттырырга хакы булуын әйтте.

Авылдашлары Зиннурны уратып алганнар, барысы да шат, бәхетле иделәр. Ул аларның һәрберсенә рәхмәтләр әйтеп, кулларын кысты. Даут абыйсы белән Зиннәт әкәләре аны кочып, аркасыннан кагып куйдылар. Кызларның күзләрендә куаныч яшьләре иде. Берсен-берсе бүлә-бүлә, алар ничек итеп эшнең очына чыгуларын сөйлиләр, дөресрәге Камилә белән Туктабикә сөйли, Ә Нурия күзләрен тутырып Зиннур абыйсына карап тора иде.

Бер ай кешелек дөньясы өчен озак вакыт түгел, тик менә Зиннур өчен аның һәр көне генә түгел, һәр сәгате ел исәбендә булды. Нәрсәләр генә уйлап бетермәде егет шул вакыт эчендә! Әти-әнисе ни эшли, укытучылар, укучылары, авыл халкы ни уйлый? Ниһаять, Нурия ни эшләп йөри, аны уйлыймы? Аның гаепсез түгеллеген, Хәйрүш белән аның арасындагы каршылыкларның сәбәбен тулысы белән Нурия генә белә бит. Ләкин ул унсигез яше дә тулмаган кыз бала гына бит, ачыктан-ачык аны якларга, кеше сүзенә керүдән курыкмыйча судка килергә көче җитәрме аның? Суд булып та, котыла алмаса... Уйлары бу якка борылса, чәчләре үрә тора егетнең. Моннан чыгасына ышанычы какшаган вакытлары күбәйде Зиннурның: бер гаепсезгә китереп тыктылар бит әле менә, аңа ышанмадылар, аны тыңлыйсылары да килмәде хәтта. Шулай булгач, суд була калса да, авылдашларына ышанырлар дип кем өметләнә ала? Суд беткәнче шул уйлар мең төрле кыяфәткә кереп, укытучының фикерен чуалттылар. Хәзер дә әле менә Зиннур үзенең иректә булуына, яңадан пычрак, суык камерага кайтырга кирәк булмавына ышана алмагандай, үзен уратып алган кызларны тыңлый, әле берсенә, әле икенчесенә елмая иде.

Әзрәк тынычлангач, урамга, саф һавага чыктылар. Җәяүләп үзләре торага килгәндә атларны ял итәргә калдырган йортка таба атладылар. Нуриянең бәхетле йөзенә карап елмаеп, кызлар Даут абыйларын куып җитәргә дип адымнарын кызулаттылар.

Эшнең нәтиҗәсенә иң нык куанган кеше Нурия булгандыр, мөгаен. Судта авылдашларының барысына берьюлы рәхмәтле булган Зиннур, хәзер генә аңа аерым игътибар итә алды.

—Бик зур рәхмәт сиңа, Нурия, бөтен ышанычым синдә иде, мәңге онытмам миңа эшләгән изгелегеңне,—диде ул, кызны күкрәгенә кысып. Әле кибеп тә бетмәгән күз яшьләре яңадан Нуриянең керфекләренә элэнделәр. Дерелдәп торган тамчыларны Зиннур кулы белән сөртеп, дымлы бармакларын иреннәренә тидерде, аннан күпереп торган чәчләреннән йомшак кына сыйпап, кызны тынычландырырга тырышты. Бу минутларда алар икесе дә чын-чынлап бәхетле мизгелләрне кичерә иделәр.

Бу вакыйга Зиннурны олыгайтып, Нурия белән араларын тагын да якынайтып җибәрде, аларның саф дуслыклары олы мәхәббәткә әверелә

баруын икесе дә аңлый, тоя иделәр. Әмма бу хисләрне ачарга, тышка чыгарырга иртәрәк иде: Зиннур—укытучы, Нурия—аның укучысы бит әле. Илдә ала да бар, кола да бар, исемең гайбәтчеләр теленә эләксә, кызның яман атын чыгарырга да күп сорамаслар. Хисләрен эчтәрәк саклаулары хәерлерәк.

Зиннур янадан мәктәп эшенә кайтты. Әмма шактый вакыт элеккегечә онытылып эшкә чума алмады. Нindидер нәрсә күңеленә һаман тынгы бирмәде. Көзге болытлардай караңгы уйлар бер-бер артлы өстенә ябырылды. Гүя аның язмышында кискен үзгәреш булып алды. Нәрсәдер гүя шартлап өзелде. Моңарчы ул гамьсез генә яшәгән имин һәм тыныч тормыш инде кире кайтмаячак иде. Хәвефтән, бәла-казадан ул бервакытта да ансат кына котылмаячак иде. Гомумән алганда, гомер буена да арына алмаячак иде...

Ниязбикә карчык белән Фәтхулла карт та улларындагы бу үзгәрешне сизми калмадылар, ләкин сораулары белән аны бимазаламаска, бу хәлне кабат-кабат яңартмаска тырыштылар. Зиннур өчен иң газаплысы—җитәкчеләрнең аңа ышанмаулары булды. «Югары белемле укытучы, җаның балаларга ярып бирердәй эшләп йөргән кешегә ышанмадылар бит, ә менә ялганчы, башы аракыдан чыкмаган, инде әлләничә кызны кан елатырга өлгергән адәм актыгына ышандылар. Болай булгач, теләсә кем синең өстеңнән кәгазь язып, намусыңны таптый, чиста исемеңне пычрата ала дигән сүз бит бу. Әгәр дуслары, укытучылар артыннан йөрмәсә, берәү дә эшнең чыны ничек булуы белән кызыксынмаячак, авылга килеп, тикшерү үткәрмәячәк иде бит. Ышанычсыз ничек яшәргә соң?» Яшь укытучыны уйланырга этәргән төп сәбәп тә менә шул булды. Авыр минутларда сынала дуслык: дуслары чын дуслар икән—шуны да белде Зиннур.

Хәйрүш бу юлы җиңелчә шелтәләү белән калды. Хакы булса да Зиннур гариза язып, аның белән судлашып йөрмәде, бу да аның файдасына гына булды. Судтан исән-имин котылды ул, ә Нурия белән Зиннур арасын бозарга дигән уйларыннан котыла алмады. Әнә бит, Хәйрүшне котырткандай, судта да күзләрен күздән ала алмый утырдылар. «Шул укытучы кисәге комачауламаса, кыз әллә кайчан минеке буласы иде ләбаса. Тансылуы да әнә, ул укырга китеп ике-өч атна үтмәгәндер, куеныма үзе килеп керде. Бусы да тыпырчыныр-тыпырчыныр иде дә, барыбер килми калмас иде. Нуриясен дә әйтер идем инде! Кайта-кайтышына ук сагыз булып ябышты укытучы-фотографка, нәрсәсен тапкандыр шуның. Хатын-кызларның күңелен күрә беләмени ул молокосос?!» Янгын вакытында яман сүзләр таратырга тырышып карады—ышанмадылар, аю сөйрәтеп кайтып, колхоз атын яндырып үтерде, шунда да яклап калдылар. Йолкыш көтүче димә син аны, ул үлгән ат өчен икеләтә хакын түләтергә дип торганда, әтрәк-әләм Чамакә сикереп торып: «Ул аюны атмаса, көтүдән колак кага идек»,—дип әйтмәсенме. Шыр Шәкүре дә бит, күкрәген кагып: «Колхозга әле мин хуҗа, Зиннурны бүләкләргә боерам!»—дип аңа каршы төште. Колхоз председателе шундый булырга тиешмени? Килер бер көн, Кәрбек Хәйрүш баш булыр колхозга, аңа баш иясе көннәрегез алда әле. Хәйрүш диләр аны!..

Зиннур укырга китеп, Тансылу кибетче булып эшли башлаган заман. Гадәтенчә, шешә алырга дип кенә кергән иде кибеткә Хәйрүш. Тансылу чыннан да сылу иде шул, кызның кылларын тартып карарга булды. Әлегә кадәр үзеннән олырак егетләрдән игътибар күрмәгән кызга аның сүзләре серле дә, дулкынландыргыч та булып тоелды. Кичке уеннарда янында бөтерелде егет, жаен туры китереп кенә биленнән алгалады, күкрәгенә үрелде. Үзенә булган мондый игътибардан кызның башы әйләнде, үзен күкнең әллә ничәнче катында итеп сизде. Саубуллашканда Зиннурның бит очыннан гына үбүе сабыйлык булып кына калды. Әнә бит Хәйрүш ничек итеп үбә аны, аяк астында җирләр убылгандай була. Егетнең оятсыз күзләрен, көннән-көн тартынусызрак үрмәләгән кулларын якын күрде, үз итте кыз. Тансылу шашкан хисләрдән, егет белән якын

булудан исерде. «Үтә кызыл—тиз уна», Хәйрүшнең дә кыздан күнеле бик тиз кайтты. Егетнең авызына карап, нәрсә әйтсә дә үтәргә торган кыз кирәкми иде инде ана хәзер. Әнә бит аннан сылурак кызлар үсеп килә. Тансылу гына төннәр буе өзгәләнде, мендәр читләрен тешләп, күз яшьләрен түкте. Ләкин буласы эш булган, ә егетнең ана өйләнергә исәбендә дә юк икән. Ялгышты Тансылу, ә бит Зиннурны көтеп торса, хәзер тынычлап йоклар, дуслары белән күңел ачар иде. Тамак төбенә утырган төерне аракы белән юып төшерергә тырышты кыз. Чыннан да, күңелгә жинелрәк була, хәсрәтләр онытылып тора кебек иде. Каникулларга кайткан горур егет аның белән исәнләшмәде дә...

### 9

Сәнәйчек[1] Өннәш Даутын хатын-кызның күләгәсеннән дә көнли иде. Зиннурның котылып кайткан көннәрендә аның телендә бер генә исем булды:

—Карт көнендә инде яшь кызларга майландыра башладыңмы күзенне, оятсыз! Әйтәм аны көн-төн Фәтхулла картның улы артыннан чаптың, ять-яшь кызлар янында булганга икән. Бөтен авыл сезне генә сөйли, судка да шул сөйрәлчекләр белән баргансың икән. Шунда үзем булсаммы, битегезне ерта идем, адәм актыклары!..

—Инде сөттәй саф кызларны пычратырга керештеңме, ичмасам ике кулына бер эш тә таба алмадың.

—Мин көне-төне эшләп, син кызлар белән кәеф ачып йөрисе икән. Әйт алайса, кичә кабинетына бикләнеп Нурия белән нишләдегез? Инде мәктәптә ачыктан-ачык сөйрәлә башладыгызмы?

—Уф, Ходаем, бар икән күрәселәрем. Беренчедән, мин анда үзем генә түгел идем. Икенчедән, Нуриягә пионервожатый эшен тапшыру хакында гына барды сүз.

Белә иде Өннәш бу турыда, шуңа күрә сүзне дә шуннан башлады. Ләкин ирен беренче кабат күргәндәй, тагын да йөрәкләнебрәк дәвам иттерде сүзен:

—Әйтәм бит юкка түгел дип, күнелем сизде аны, укып торган килеш кемне вожатый иттергәннәре бар? Түләүле эш бит әле житмәсә. Оятсызлыкның чигенә чыгып, аякларыгызны салындырып утыргансыз икән. Тегесе дә бит, бернәрсә булмагандай, минем белән исәнләшеп йөргән була. Менә бит эшегез кайдан килеп тәртеп чыкты. Үзең түрә булып, аны вожатый кылып, сиңа шул чибәркәйне куеныңа алу кирәк. Менә нәрсә синең уеңда. Шулай гына булса бер хәл әле, үзем күреп тордым, Тансылу янына кибеткә дә өч тапкыр кереп чыктың, юкка йөрмисең син.

—Мәктәп буфетына кирәк азык-төлек хакында сөйләштек,—дип башлаган иде сүзне Даут, хатыны тагын аны бүлдереп китте:

—Тансылу куенындамы?

—Йа Ходаем, башымны кайларга гына алып качыйм икән синнән?—дип, кул селтәп, чыгып китте директор.

—Менә-менә, күптән шулай диясең калган, яшь кызлар белән рәхәтрәк, синнән аерылам, диясең калган, карт эт. Алары да, әйтмәсәм әйтим, артларын чайкап, синең туймас нәфесеңне кузгатып йөриләр. Кушылганда бетле Даут идең, инде мин ярамый башладым. Әйт дөресен, мин кемнән ким?..—дип тезеп, ишектән башын тыгып, кычкырып калды.

Тиз генә тынычлана алмады Сәнәйчек. Тоныкланган көзгедә бүртенеп кызарып чыккан йөзен, сынык тешләрен күреп, ачуы тагын да кабара гына төште. Кулындагы сөлгесен көзгегә ташлап, кая туктарга, нәрсәгә барып тотынырга белмичә, бәргәләнеп, ишекле-түрле йөрде. Нуриянең коеп куйгандай буй-сыны күз алдына килеп, үчекләгәндәй

[1]Сәнәйчек—азгын, сөйрәлчек.

тоелды. «Көмешлесуда тагын бер сәйрәлчек үсеп чыккан икән»,—дип уйлады бозык хатын, ире чыгып киткән якка капланып. Ачулы кеше агу белән тулы була бит, аны да кем беләндер бүлешәсе, кемгәдер түгәсе килә. Бу хәбәрләр дә Өннәшнең эчендә озак тормастыр ахры, тыңлаучысы гына булсын...

Директор абыйсы белән мәктәптә сөйләшкәннән соң Нурия өйгә дулкынланып кайтты. Әнисенә сөйләп, киңәшләшеп тә алды. Балалар белән эшләүне ярата кыз, түбән сыйныф укучылары белән уртак тел таба алуына ышана. Төрле уеннар, кичәләр үткәрәсен, балалар алдына чыгып басуын күз алдына китереп, елмаеп көзгегә күз төшерде. Үз кыяфәтеннән үзе канәгать калды кыз. Классташ кызларының чәчләрен кисеп, йә бөдрәләтеп, кашларын йолыккалап, алай да үз-үзләреннән риза булмауларын аңламый иде. Табигать биргән матурлыгы күпләрне сокландырырлык, яшьтәшләрен көнләштерерлек иде шул аның. Үзе болай уйламаса да, ахирәтләре төрттереп куялар, кайсыберләре соклануларын яшермичә:

—Эх, миндә булса икән мондый сап-сары толым, карлыгач канатыдай кара каш. Бер килмәгән җиреӊ юк шул синеӊ!—дип куялар. Чыннан да, авылларында кызлар бөтенесе диярлек каты кап-кара чәчле, төймәдәй кара күзле. Үзенеӊ зәңгәр күзләрен, йомшак чәчләрен көзгедә күреп, өннәсеннән[1] сораганы да бар аның бу хакта. Сигез-тугыз яшьлек нәбәрәсен алдына утыртып, өннәсе түбәндәгеләрне сөйләгән иде ул чакта.

... Күптән булган бу хәл. Көмешлесудан ерак түгел бер авыл булган, имеш. Тыныч яшәгән халык, үз көнен үзе күргән. Көтмәгәндә ул якларга илбасарлар өере килеп чыккан, авылны камап алып, икенче дингә өнди башлаганнар. Авыл халкы аксакаллар тирәсенә җыелып, киңәш иткәч, кискен карарга килгәннәр: динеңне, иманыңны югалтканчы, үзеңне югалту артык дип, соңгы кеше калганчы каршы торырга булганнар. Ерак җирләрдән килгән яулар көчле булган, ир-егетләрне үтереп, күлгә батырганнар, хатын-кыз, бала-чагаларны тере килеш күл буендагы чокырга күмгәннәр. Урманга ауга дип чыгып киткән ике егет, кайткач, бу фаҗигане күреп, тетрәнеп калганнар. Күл буена утырып, күз яшьләрен түккәннәр дә янадан урманга кереп киткәннәр. Җирне казып, яшәр урын ясаганнар егетләр, торнакүз, эрбет чикләвеге, гөмбә җыеп, кышка азык әзерләгәннәр. Кайда кыр тавыгы аулаганнар, кайда куянны тозакка төшереп алганнар. Шулай итеп, салкын кышны үткәргәннәр.

Менә бер заман, җәй башында, күлдә балык тотып йөргән егетләр чылтырап көлгән тавыш ишеткәннәр. Борылып карасалар, ни күрсеннәр— бөреләнеп утырган каен кәүсәсен кочаклап ике кыз боларга карап тора, ди. Өсләренә кигән күлмәкләре яшел укадан икән боларның, кояш яктысында җем-җем килеп тора. Кычкырып көлгән дә кызлар, әллә ничек кенә юкка да чыкканнар. Пәри кызларымы әллә бу, дип, куркуга төшкән егетләр. Атна-ун көннән ауда тагын теге туташларга тап булганнар. Бу юлы алар сылуларны өркетмичә генә сүз катканнар. Үзләренеӊ кайсы авылдан булуын әйткән егетләр, кайгыларын сөйләгәннәр, кызларны үз яннарына чакырганнар. Яшел күлмәкле кызлар, куркыныч килгәндә очып китәргә җыенган кошчыклардай, әкрен генә егетләргә якынлашканнар. Айсылу белән Гөлчәчәк дип исем биргән егетләр аларга. Шуннан болар парлашып көн күрә, учак яга башлаганнар.

Ул заманнан бирле күп еллар узган, чиксез сулар аккан. Нурияләрнеӊ токымы әнә шул урман кызларыннан башлана, имеш. Күзләренеӊ күкчәчәктәй, чәчләренеӊ сары ефәктәй булуы да әнә шуннан килә, ди. Әсәрләнеп тыңлаган иде Нурия өннәсен. Сөйләп бетергәч кенә, игътибар итте: өннәсенеӊ хәйләле-серле күзләрендә дә зәңгәр күк йөзе чагыла икән ләбаса, ап-ак чәчләре дә йомшак, нәфис.

Ә чыннан да кемнәр булды икән ул яшел күлмәкле, зәңгәр күзле урман кызлары, серле кызлар? Әнә бит халык телендә урман кызлары,

[1]Ө н н ә с е —әбисе.

еш кызлары[1] турында күпме әкият, риваять бар. Бу яклардагы Ешаер авылына, имештер, нәкъ әнә шул ике пар нигез салган[2], дип сөйли картлар. Халыкның мажаралы вакыйгалар, әкият-риваятьләр ятратуына сокланып, Нурия озак уйланып утырды.

## 10

Тавыш-гаугадан соң ике-өч көн үтүгә, Даут агага тагын эштә тоткарланырга, партия утырышында булырга туры килде. Шуны чамалагандай, өйгә бригадир Хәйрүш килеп керде. Сәнәйчек[3] әбәсе янына беренче генә керүе түгел егетнең, Даут абыйсының чыннан да өйдә юк икәнен тикшергәч, иркенләп түргә үк узды. Ары-бире каранды да, сүз башлады:

—Ничек яшәп ятасың, Өннәш әбә?

—Абыеңда берәр йомышың бар идеме?—дип сораган булды Өннәш кыланчыкланып, гәрчә Хәйрүшнең үз янына кергәнен белсә дә. Даутның бригадир белән сөйләшер сүзе, бүлешер малы юк. Ә менә Өннәш әбәсе белән эшләрне пешерә белә егет. Нәфесенне дә бастыра хатын, сөйләгән гайбәтләренне дә берен биш итеп кешегә тарата. Авызында жил тормый хатынның, оча да чыга. Белә Хәйрүш, кеше турында яман хәбәр чыгарасың килсә, Өннәшкә генә кереп сөйлә, иртәгә үк авылның иң азгын телләрендә шул хәбәр булыр. Үз ялганнарына үзенне ышандырырлык итеп сөйли белә ул гайбәтне. Бүгенге керүе дә юкка түгел егетнең, боргалап-нитеп тормыйча, турыдан башлады ул сүзне:

—Иренне әйтәм әле, гел яшь кызларны жыя үз тирәсенә. Әнә, теге Нурияне укуын да бетермичә эшкә алган икән. Әле кичә генә тезне-тезгә терәп, бик күнелле серләшеп утырганнарын күргәннәр. Әллә мин әйтәм, яшь кызның тамырын тотып карамакчы буламы? Нурияне бик кыйшан[4] диләр, аның өстенә сылулыгы да бар, теләсә кемнең башын әйләндерерлек. Күпләр аның артыннан чабалар. Сина гына якын итеп әйтүем, Өннәш әбә, ул әле бер кунак егете белән кунып та чыккан, диләр. Шуңа күрә бер елын укымый тордымы икән әллә? Даут абый да аны үзенә эшкә юкка гына алмагандыр, араларында нидер бар булыр...

Беркөнне вакыйгалардан ярсуы басылмаган хатынның көнләшү өянәге тагын да куәтлерәк булып кузгалды. Хәйрүшнең сүзләре аңа корт чаккандай тәэсир итте. Кәрбек хәйләкәр белеп эш итте, инде болай булса, теләгенә дә ирешер: бу сүзләр иртәгә үк үзе кебек гайбәтчеләр авызына керәчәк иде. Аннан туктатам димә инде син аны, бик тиз үрмәли, үрчи бит ул яман-ялган хәбәр. Кабаттан үзенә әйләнеп кайтканчы, чүпрәгә баскан камырдай арта, күперә ул.

—Юкка гына хафаланмаганмын, борын төбемдә генә типтереп ятарга уйлаганнар икән. Рәхмәт, Хәйрүш энем, син кереп күземне ачмасаң, мәңге, сукыр кеше кебек, борын төбемдәге хәлләрне дә күрмичә ятасы икәнмен... Нуриясе дә оялчан-тыйнак булып кыланган була, инде атасыдай кешене азындыруга керешкән икән!—Хатын мәктәпкә караган тәрәзәгә барып капланды.

Күргәннәре аны чыгырыннан чыгарды: мәктәп ишегеннән йөгереп Нурия килеп чыкты, капка янында куып житеп, Даут абыйсына ниндидер кәгазь кисәге сузды, куллары белән мәктәп ягына ишарәләп, нәрсәдер аңлата башлады...

Тәненә сыеша алмаган хатын ишеккә ташланды. Ике аратаны бер

---

[1]Е ш  к ы з л а р ы—пәри кызлары.

[2]Риваять Р. Абдеев, В. Софроновның «Тобольский хронограф» (1993) китабының «Зеленые девушки Сибири» дигән бүлегеннән алынып, Ә. Ниязов тарафыннан язылган. *(Автор искәрмәсе.)*

[3]Ә б ә—апа.

[4]К ы й ш а н—азгын.

генә сикерде Өннәш, ике-өч минут та үтмәгәндер, мәктәпнең янкапкасыннан директор хатынының тузгыган башы күренде. Борылып карарга гына өлгерде Даут, котырынган хатыны биш бармагын батырып, аның битен умырып алды. Бу хәлне аңышмыйча, директор әчеттереп кызышкан битен каплап алды, ә хатыны аларга карап катып калган Нуриягә ташланды.

—Инде абыең белән сөйрәләсеңме, оятсыз кәнтәй?!—дип, кызның ефәктәй чәчләренә килеп ябышты.

Эш ни белән очланган булыр иде, бәхеткә, Зиннур килеп җитеп, хатынның кулларын каерып атты.

—Котырган эт тешләдеме әллә сине, Өннәш әбә, акылыңа кил,—дип, хатынны иңнәреннән тотып селеккәләп алды.

Хатын ачу-ярсуыннан буылып, чүгеп төште, ләкин бирешергә исәбе юк иде. Ыңгыраша-ыңгыраша аягына басып, яңадан Нурия ягына атлый башлады.

—Син миңа кагылма, әнә үз сөяркәңне тый, аздырмасын минем картны, таркатмасын тату гаиләне!—дип ысылдады.

Бу вакыйгадан бернәрсә дә аңламыйча, исе китеп, аларга карап торган кыз, битен каплап, мәктәпкә йөгерде.

Нишләргә белмәде Зиннур, йодрыкларын йомарлап:

—Өннәш әбә, Нуриягә тагын тел тидерсәң, билләһи дип әйтәм, җаныңны алырмын, ышан сүзләремә!—дип, ныклы адымнар белән мәктәп ягына таба атлады.

Тузгак баш исә аның артыннан кулын болгап, ике бармак арасыннан кәҗә тоягы күрсәтеп калды. Хатынының кыланышына гарьләнгән директор исә бер төкерде дә, кулын селтәп, өенә юлланды.

Атна-ун көн мәктәптә күренмәде директор, битендәге җәрәхәтләр төзәлгәч, Зиннурны кабинетына чакырып, озак кына сөйләшеп утырды. Мәктәп коллективы моңа аерым игътибар да итмәде. Янә ике көннән РайОНОга барып кайткач кына, директор белән завучның ни турында сөйләшүе мәгълүм булды. Районда Даут үзен директорлыктан азат итүләрен сораган, берочтан бу урынга Зиннур Абдуллинның билгеләнүе хакындагы приказны да алып кайткан иде.

Шул көннән башлап Зиннур Көмешлесу урта мәктәбенең директоры булып калды.

*Дәвамы бар*





## Илдар Юзеев

### «ТАТАР ЯШИ!» ДИГӘН ӨЙДӘН МИН

**Гасыр кичкән чакта...**

Гасыр кичкән чакта уйга калдым
Күңелемне бер җыр тартты да...
Көем минем «Кара урман» сыман,
Кайгы-хәсрәтле дә, дәртле дә.
Бабамнардан калган мең батырлык,
Бабамнардан калган мең хата
Бер җырлата мине, бер елата.
Алда—мең бормалы юл ята.
Балачакта, үсмер яшьлегемдә
Ялган аллаларга табынып,
Мин үзем дә юлдан чыккаладым...
Буш хыялдан киләм арынып.
Күңелләрдә янган мең еллык Моң
Җиңеләйтә атлап барышны.
Килер елларым да булыр димен
«Туган тел»ле, «Сәйдәш марш»лы!
Егерменче гасыр күкрәгендә
Хәсрәт көен күбрәк җырладым.
«Тиран, җәлладларны Җир йөзенә
Ник тудырдың?» диеп сорадым.

---

Илдар ЮЗЕЕВ (1933)—*Татарстанның халык шагыйре(1993), РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1979, 1983). Кырыкка якын китап («Таныш моңнар», «Карурман», «Мәхәббәт китабы», «Калдыр, аккош, каурыеңны» һ.б.) авторы; драматург (пьесалары татар (Казан) һәм башкорт (Уфа) театрларында куелды), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1980). Балалар әдәбияты һәм тәнкыйть өлкәсендә дә актив эшли. Казанда яши.*

Сугыш утларында янган-көйгән,
Туфрак булган ирләр, балалар:
«Тыныч яшәр көннәр туармы?» дип,
Көйләремә иярөп баралар.
Чәчләремне сыйпап юат әле,
Дәвер җиле, гасыр кояшы.
Кырыслана, усаллана барам,
Булсам да бер Җирнең юашы.
«Син каян?» дип сорый Киләчәгем.
«Татар яши!» дигән өйдән мин.
Ниләр күреп, ниләр кичерсәм дә,
Аерылмам шушы көйдән мин.

... Гасыр кичкән чакта уйга калдым
Күңелемне бер җыр тартты да..
Көем минем Сәйдәш җыры сыман,
Кайгы-сагышлы да, дәртле дә...

## Бу базарда...

Базарларда яңа байлар йөри.
Кемнәр алар: еллар ачыклар.
Пенсиянең соңгы тиеннәрен
Санап тора картлар-карчыклар.
Янда гына, янәшәдә генә
Күтәрелә затлы сарайлар.
Күзләремә карап хәер сорый
Апуш яшендәге малайлар.
Мин шуларның җырын тыңлап йөрим,
Күбәйделәр бу ай, бу кышны...
Асрамага берсе алыр микән
Бу базарда «Тукай-Апушны?»

## Тукай бер генә!

*«Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да...»*
Г. Тукай.

Туры Тукайның яшь килеш
«Бөкрәйгәнен» аңладым.
Мин картайгач бөкрәйдем,
Тукай була алмадым.
Мин дә Тукайча ютәллим,—
Охшашлык бар бигрәк тә.
Үпкә генә түгел, мине
Якынайта йөрәк тә.
Яшьне санасаң, үземнән
Почти өч Тукай чыгар.
Әйтсәләр ярар иде дә:
«Болар, дип, Тукайчылар».
Тукайча даһи булырга
Хыялланмый кем генә!
Туры да, бөкре дә—миллион.
Тукай бары бер генә!

## Кайраучы

Пычак кайрыйм!
Яшь егетләр
Чәчәк кисеп алсыннар,
Саф хисләрен аңлатырга
Сөйгәненә барсыннар!
Чалгы кайрыйм!
Болыннарда
Җырлап печән чапсыннар!
Чалгы кайравын ишетеп,
Кызлар шунда чапсыннар!
Кайчы кайрыйм!
Сеңел-кызлар
Туй күлмәге кисеннәр,
Бу күлмәкне иң бәхетле
Ярлар—парлар кисеннәр!

Балта кайрыйм!
Өйләнешеп,
Өй нигезе корсыннар,
Бу йортларда сөеп-сөелеп,
Гел сөенеп торсыннар!
Көрәк кайрыйм!
Хыялларым
Шат йөзләрдә күренсен,
Мәкерле явыз ниятләр
Яшәмәсен, күмелсен!
Аһ, нигә аз бу базарда
Уемны аңлаучылар?!
...Теш кайрыйдыр—ниятемә
Ханҗәр-ук кадаучылар...

## Торналар төшкән җирдә

*Мөхәммәт Мәһдиев истәлегенә*

«Торрыйк-торрыйк» тавышлары
Йөрәккә күчкән җирдә
Каршылаган идек язны
«Торналар төшкән җирдә».
Карыйм ерак зәңгәрлеккә
Күзгә җил искән җирдә.
Үзең дә юк, кошларың да
Торналар төшкән җирдә.
Әллә китеп югалдыңмы
Кошларың очкан җиргә?
Көтәм таныш авазларны
Торналар төшкән җирдә.

## Илһамсыз чакларда

Күптән инде гармун тотканым юк,
Әллә нишләгәннәр җиз телләр:
Уйналмыйча озак яткангадыр,
Элеккечә көйле түгелләр.

Күптән инде каләм тотканым юк,
Аламын да... туктап каламын.
Хис коесы әллә саектымы,
Тутыктымы әллә каләмем?

Гамьсез һәм мәнсезләр арасында
Бу дөньяда бармын шикелле.
Их, ятмаска иде тузан йотып,
Уйналмаган гармун шикелле.

И Илаһым, Син бит мине Җиргә
Шигъри җанлы итеп яраткан.
Аермачы Күкләр кодрәтеннән,
Могҗизалы серле халәттән...

## Очты, очты

Очты, очты... ул еллар очты,
Бергә уйнаган уеннар очты,

Очты, очты чәчәкләр очты,
Бала вакытлар, яшь чаклар очты,

Очты, очты—кошларым очты,
Бергә очынган дусларым очты,

Очты, очты... барсы да очты...
Ярым бар иде, ансы да очты...

Очты, очты күмерләр очты,
Көл булып җилдә гомерләр очты...

Очты, очты... нишләргә кала?
Инде үземә очарга кала...

«Очтым! Очтым!» дип, соңгы талпынып,
Җиргә егылып төшәргә кала.

Әйтерләр, бәлки, «ул очты!» диеп,
Зәңгәр хыялын ул кочты!»—диеп...

## Өнме, төшме?

«Безнең белән бергә бул!» дип,
Әллә кемнәр кул кыса.
Яшәү авыр сезнең белән,—
Һава җитми, тын кыса.
Тарайганнан тараядыр
Бožра сыман шул кыса,
Ычкынасы иде шуннан,—
Һава җитми, тын кыса.
«Ваз кич Ирек хыялыннан!»
Җанбасарлар юл кисә.
Алтын тешләр елмаялар,—
Һава җитми, тын кыса.
«Алтын-көмеш—ун кесә!» дип,
Мәкер, хәйлә күз кыса.
Мохитегез—элмәк миңа,—
Һава җитми, тын кыса.
«Ник барасың авыр юлдан,
Яшәп кал бер, кем куша?!»
Үрмәлимен әсирлектән,—
Һава җитми, тын кыса.

Котылдың! дип, әллә Хаклык,
Әллә Вөҗдан кул кыса...

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Галимҗан Гыйльманов

# АЛБАСТЫЛАР

ХЫЯЛЫЙ КЫЙССА

### Беренче бүлек

I

Июль ахыры.
Челлә күзе.
Олы юл.

Урман аланнарына керә-керә бормаланып сузылган бу таш юл, очы-кырые булмаган мари урманнарын урталай кисеп, алга йөгерә дә йөгерә. Барасы жир күп калмадымы әле, дигән кебек, ул ара-тирә үр калкулыкларга килеп менә, биегрәк таулар очраса, хәл-егәрлеген юкка сарыф итмәс өчен, иренмичә әйләнеп уза. Мари урманнарының шомлы көе дә һич куркытмый аны. Хәтта юл белән урман бер-берсенә шулкадәр береккән, бәйләнгән кебек, юлны урман "биленнән" чишеп ташласаң, мәһабәт имәннәр, озын, төз чыршы-наратлар, шау-шулы усаклар авып, имгәнеп, төрле якка таралып бетәрләр кебек тоела.

Шул юлдан аркасына биштәр аскан бер кеше бара. Житез-өлгер атлавына, нык адымнарына карап, аның бер сугуда бүрәнә өзәрдәй әзмәвер егет икәнен чамаларга мөмкин. Йөзе кояшта янган. Карашы туры, тирән... Ә күзләре, күзләре—күк төсендә, ачык зәңгәр! Халыкта мондый күзләрне изгелеккә, илаһилыкка юрыйлар. Йөз-битенә кунган сакал-мыек төкләренә караганда, ул егерме яшьләр чамасында булыр. Шулайдыр. Атлаганда кулларын солдатларча як-якка сузып жибәрүе дә шуңа ишәрә итә.

---

Галимжан ГЫЙЛЬМАНОВ (1957)—*прозаик, тәнкыйтьче, шагыйрь. «Тозлы яңгыр» һәм «Гөрләвек», «Йөгерек гөрләвек», «Әбием сихерче бугай» исемле балалар өчен шигырь китаплары, «Көмеш кыңгырау» пьесалар жыентыгы авторы. Казанда яши.*

Өч сәгать бара инде ул. Ара-тирә артына борылып, юл очын күзләп ала. Тик юкка. Мондый челлә көнне бөтен тереклек, җан иясе ышыкка, күләгәгә качып беткән. Юлчы егет килгән юлына озак кына төбәлеп карап тора да, сарымай кыздырылган табага охшаган кояшка күтәрелеп бага... Ә ул һаман бер урында. Кузгалырга исәбе дә юк. Ичмаса, аз гына кешелеклерәк, миһербанлырак булса, түбәнгәрәк төшәр иде дә берәр чыршы канаты астына посыбрак торыр иде... Юк шул, аның үз мәшәкатьләре, үз шөгыле: салкын көзгә кадәр, дөньяга, тереклеккә күпме булдыра ала шулкадәр җылы биреп калдырырга тиеш ул...

Юлчы, утлы табага чагылган карашларын читкә алып, авыр итеп сулый да ары кузгала. Кояшның сихри балкышы бермәлгә аның бар дөньясын томалап куя, ихтыярсыздан, күзләрен бармак очлары белән уып ала, аннары биштәренең бауларын җайлап куя да адымын кызулата.

Кем ул? Шомлы мари урманнары уртасында калган бу җан иясе— кем ул? Каян килә? Кая бара? Алда аны нәрсә көтә? Исән-имин чыга алырмы ул бу табигать дөньясыннан, урман ихтыярыннан? Әле бу хакта беркем дә белми. Белсә дә, шушы тыныч, әмма үтә дә шомлы юл һәм миләрне кайнатырлык кызган июль кояшы гына беләдер.

## II

Районда юлы унды Хәлимнең. Сирәк була торган хәл: теләгән кибетенә кереп, теләгән әйберләренең барысын да җыеп алды ул. Күптән чыкканы юк иде бу якларга. Нәкыйп абыйларга кайткан кала кунагының машинасында бер урын булу ярап куйды. Хәлим шунда ук ризалашты. Әмма кайту ягын уйлап бетермәгән икән ул. Берәр машина туры килер әле дип чыгып китсә дә, әнә бит, юлда бер бөртек тә җан иясе күренми. Кояш, баш очына күтәрелгән килеш, ике-өч сәгать бер чөйдә эленеп тора. Вакыт тукталып калган диярсең, билләһи.

Юлына да түзәр иде, ару-талуына да аптырамас иде Хәлим, әмма мондый да хәтәр кызулыкка түзәр әмәлне каян табарга? Башына әрекмән яфрагы каплап та карады, хәрби полигонда йөргәндәге кебек, аркасындагы юл капчыгына агач ботаклары кадап та барып карады, барыбер челләнең утлы сулышыннан котыла алмады. Бара-бара аяклары кызып-шешеп чыкты, тәненнән шыбыр тир акты.

Ник бер җан әсәре булсын?! Ник бер үлән камылы, бер агач яфрагы селкенеп яисә аз гына җил исеп куйсын. Бу урманга кара инде, йә? Кысага алынган сурәт-рәсем кебек, бер тынсыз-сулышсыз килеш каткан да калган.

Берәр аланлыкка якынлашкач кына табигатькә җан керә: кошлар чыркылдашуы, чикерткәләр җыры ишетелеп куя. Әмма бу озакка бармый. Юл тагын урман куелыгына кереп китә. Аны ике якта стена булып баскан төз, мәһабәт, ләкин үтә шомлы нарат-чыршы рәте үзенә суырып ала. Тагын тын дөньяда пәйда буласың... Тән, җан сәер бер халәткә юлыга. Мондый тынлыкта йөрәк тибеше дә, тамырлардагы кан агышы да, ми күзәнәкләренең җитез хәрәкәте дә ап-ачык беленеп, ишетелеп тора...

Хәлим шуны искәрде: юл үзе болай әллә ни озын кебек тә түгел. Әнә күз күремендә генә, сандугач тавышы арасы гына. Ул бара-бара да, кинәт җир астына төшеп киткәндәй, юкка чыга. Юлның шул урында кинәт борылып китүен белә Хәлим. Әмма ничек инде үз күзенә ышанмыйсың ди. Әнә бит, юл кырт итеп киселә дә төшә... Күнелгә шом керә. Шул урында юл бетсә? Юл бетү бит ул тормыш бетү, гомер өзелү дигән сүз. Чынлап та, урманның иң караңгы, кеше аяк басмаган бер төпкелендә яшәүче берәр явыз хәшәрәт, аждаһа яисә албасты килеп чыгып, юлны кертләп өзеп атса, кабып йотса? Юк, тагын да хәтәррәк булуы да мөмкин әле. Әйтик, менә шушы юл буйлап барасың-барасың да, үзең дә сизмичә, әлеге албасты тамагына кереп китәсең...

Балаларча уйланып баруын тоеп, Хәлим үзеннән үзе унайсызланып куйды. Юл гына өзелмәсен шул. Юлдан гына аермасын кешене. Әнисе шулай ди торган иде. Хәлим үзе дә бик кечкенәдән юлда йөрергә яратты. Әбисенең әйтүенә караганда, Хәлимне әнисе юлда тапкан. Нигәдер әнисе генә аңа бу хакта сөйләми. Нәрсәсе бардыр инде анын—юлда тапса ни, башка җирдә ни... Шулай да, әбисенең әйткәләгәне бар иде: "Саниянең баласын Тәңребез үзе кабул итеп алган, югыйсә, берьялгызы урман юлында бала китерә алыр идеме ул? Кендеген өзә алыр идеме? Монда Тәңре кулы кергән, Тәңре кулы кагылган,"—ди торган иде.

Нигә алай дигәндер әбисе, Хәлим анык кына әйтә алмый. Әмма ул бик яхшы сизенә: нинди дер сер бар монда. Нидер яшерәләр анардан. Тагын шунысы да җанга тынгылык бирми: Хәлимнең әтисе дә бик сәер югалган. Сания авырлы калгач, туачак балага бишек ясау өчен, карама ботаклары сайларга дип урманга кереп киткән җиреннән чыкмаган. Төрлечә юрап карыйлар. Шүрәле, Убыр, Албасты хакында искә төшерәләр хәтта. Күрше Вәсимә карчык, кеше анын алучы исерткеч үлән-куаклар хакында сөйләп, кешеләрне тагын бер шомга сала. Сихер-хорафатка бик ышанмый торганнар: "Аю-бүре талагандыр",—дию белән чикләнәләр. Ничек кенә булмасын, авыл халкы өчен Кушйөрәкле Чәнтинең үлеме мәңгелек бер сер булып кала. Кушйөрәк тә, Чәнти дә, әлбәттә, кушамат кына. Үз исеме Рәхмәт анын. Кушаматынын тарихы болайрак. Рәхмәт тирә-юньдә үтә дә тәвәккәллеге, кыюлыгы, алып йөрәкле кеше булуы белән дан казанган. Шушы дуамал тәвәккәллеге өчен ана "Кушйөрәк" дигән кушамат биргәннәр дә инде. "Чәнти"нең үз тарихы. Рәхмәт яшь чагында авылның бер диванасы белән бәхәскә кергән. "Әгәр фәлән-фәлән кызны алмасам, чәнти бармагымны кисәм дә ташлыйм", —дигән. Теге кыз авылның бер чибәре була, әлбәттә. Егетләр анын артыннан өерелеп йөри, ди. Рәхмәт тә төшеп калганнардан түгел. Көндәшләре арасында үзенең уңганлыгы-булганлыгы белән аерылып та тора әле. Кыз да һушлы. Рәхмәтне шунда ук күреп кала. Әмма бик сер бирми. Башкаларның ябышып йөрүләренә дә күнеле кытыкланып тора имеш. Шуна күрә, Рәхмәткә вәгъдә биреп куйса да, ул булмаганда, башка егетләргә ияреп киткәли икән.

Бердәнбер көнне Рәхмәт, Зәлиләсен озатып, татлы хыялларга чумып кайтып килгәндә, авыл читендә урнашкан умартачы йортында торган Ак бабайның хәлен белеп чыкмакчы була. Шактый утыралар болар. Кайту юлында Кирәмәт күле буендагы ике шәүләне бик тиз шәйләп ала Рәхмәт. Берсе—сөйгәне Зәлилә! Ничек сыенышып утыралар диген, ә!

Шул көннән Рәхмәт Зәлилә янына адым да атламый. Елап та карый кыз, ялварып та, гафу сорап та карый... Рәхмәт аны якын җибәрми. Әлбәттә, үз сүзендә тора ул. Ишегалдында торган каен кискәгә бармакларын җәеп сала да үткен балта белән чәнти бармагын чаба да өзә...

Анасы Хәлимне ялгызы үстерә. Баштарак күрше-күлән алардан читләшебрәк яши. Саниянең баласын бик сәер рәвештә табуы шикләндерә кешеләрне. Нәрсә булган соң ул вакытта урман юлында? Беркем дә белми. Шайтан кулы уйнамаганмы, янәсе.

Бала табуга, Сания, терекөмеш кебек житез, дәртле хатын, кинәт кенә сүрелеп-сүлпәнләнеп кала. Баланын күк-зәңгәр күзле булып тууы, маңгай уртасындагы кечкенә миң бөртеге шик-шөбһәләрне көчәйтә генә.

Һәр нәрсәгә күнегәсең бит. Тора-бара Рәхмәт-Сания-Хәлим тарихына да әллә ни игътибар итми башлыйлар. Киресенчә, һәрьяклап ярдәм күрсәтәләр, булышалар, теләктәш булырга тырышалар. Ятимлектә, мохтаҗлыкта калган бу ике Ходай бәндәсен рәнҗетергә бирмиләр...

Кая ул! Мәкерле, кара эчле җаннар барыбер Саниянең бәгырен телгәләү юлларын таба. Берәүләр: "Баласын урыстан тапкан", —дип сөйләсә, икенчеләр: "Тапкан чакта баласын урман буенда җен-албасты алмаштырган",—дип сафсата сата. Мондый вакытларда Сания күкрәк баласын тиз-тиз генә төрә дә, куенына кысып, авыл читенә чыгып китә.

Сәгатьләр буе урман юлында, аланлыкларда йөри, күңеле тынычланганчы, тәмам бушанганчы, жаны аяз күк кебек чистарынып калганчы үксеп елый... Кем белә, Хәлимгә юл шаукымы, бәлки, шул вакытлардан ук күчеп калгандыр? Ул, хәтта, әнә шул чактагы юл чатларын, эреле-ваклы сукмаклар китеп югалган тау, үр төпкелләрен, урман, әрәмәлек буйларын да хәтерли кебек.

Әлбәттә, моның булуы мөмкин түгел. Бер яшьлек кул баласы нәрсә хәтерләсен инде?!. Әмма шул аңсыз чагында, күз карашлары аша ятланып, күңеленә салып куелган табигать мизгелләре гөлт-гөлт итеп, янып-балкып китә кебек.

Сания башка кияүгә чыкмады. Күп ир-егетләр димләп карады аны. Кайсысын тукмаклап, кайсысын юмалап, үгетләп чыгарды. Ялгызы калды. Хәлименә бөтен гомерен багышлады. Хәзер дә ул җәһәннәмдәге район үзәгенә киткән малаен көтеп утырадыр. Тәрәзәдән тәрәзәгә йөридер. Юлның кара урман аша үтәсен белә бит ул. Бүген дә шомланып: "Урманга кереп йөрмә, юлдан чыкма",—дип калган иде... Һаман сабый күрә ул улын. Хәлиме инде хәрби хезмәттә йөреп кайтты. Анда нинди генә афәтләр аша үтәргә, әкәмәт хәлләр кичерергә туры килмәде бит. Ул хакта сөйләсәң, бу урман сөйләкләре бер әкият булып кына калырдыр, мөгаен.

Хабаровск тайгасында булган бер вакыйга әлегә кадәр аның жан бәгырен өшетеп тора. Кара урман эченә урнашкан бер хәрби частьтә хезмәт итә иде ул. Бервакыт азык-төлек келәтләренә аю ияләште. Килә дә туздырып китә, килә дә туздырып китә. Постта торган солдатлар сизми дә калалар. Иң кызыгы шул—күренмичә йөри ул. Күктән төшкән кебек пәйда була да, алдындагы бар нәрсәне җимереп, ашханәгә кереп китә, солдатлар исә, аның гипнозына эләгеп, тораташ булып катып калалар, имеш. Аю чыгып киткәч кенә аңнарына килеп, мылтыкларына ябышалар икән.

Беркөнне каравылга Хәлимнәр взводын куйдылар. Чиратлашып ял итә-итә төн уздырдылар. Инде таң атарга да күп калмады. Менә-менә ерак тайга сопкалары артыннан беренче кояш нурлары бәреп чыгар төсле.

Шулвакыт урман буенда чыбык-чабык шартлап сынган тавышлар ишетелде. "Килде",—дип уйлады Хәлим. Автоматларын корып, келәт почмагына чүгәләделәр. Менә хикмәт: аю исә бөтенләй башка яктан килеп чыкты. Мәһабәт бу җан иясе келәт ышыгыннан килеп чыкты да автомат тотып торган егетләр өстенә ябырылды. Берничә егет як-якка очты. Аю ике сикерүдә Хәлим янына килеп тә житте. Хәлим аюның өскә күтәрелгән тәпиен генә шәйләп калды. Хәрби күнегүләрдә өйрәнгәнчә, ул башын бер читкә тайпылдырмакчы булды. Шул вакыт аның күзләре аю күзләре белән очрашты. Прожектор уты яктысы ургылып, суырылып керә кебек иде бу күзләргә. Күк-зәңгәр төстә булгангамы, чиксез тирән иде алар. Хәлим башын читкә алу түгел, керфеген дә йома алмый тора иде бу вакытта. Аю да бик сәер тотты үзен. Өскә күтәрелгән көрәк тәпие шул килеш асылынып калгандай булды, юеш борыны ешрак сулыш ала башлады... Менә аның тәпие аска таба хәрәкәтләнде. Хәлим чытырдатып күзләрен йомды. Шулай да: "Беттем... Бетерде бу мине... Башымны чәрдәкләде..."—дип уйлап өлгерде. Әмма сугучы булмады. Хәлим күзләрен ачарга кыймады. Әлегә исән-сау булуы күзләрен йомып торуы белән турыдан-туры бәйләнгән төсле тоелды аңа.

Кинәт... Кинәт аның маңгаена кагылдылар. Юк, тимәделәр, маңгай турысына салкын су тамыздылар ахры... Хәлим башкача түзеп тора алмады, күзләрен ачты. Һәм... йөрәге ярыла язды! Аның күз алдында үлән чыгына чыланган килбәтсез аю тәпие тора иде. Аю юеш тәпие белән Хәлим маңгаендагы борчак кадәрле миңгә тиеп-тиеп карый иде... Шулай күпме торгандыр, бераздан артына утырды да, борылып тиз-тиз генә китеп барды бу әзмәвер жан иясе. Төрле жирдә төрлечә егылып яткан солдатлар, бер аюга, бер Хәлимгә карап, телсез калганнар иде.

Шул көннән башлап частьтә Хәлимгә мөнәсәбәт үзгәрде. Хөрмәт

артты. Аю да башка килмәде. Тик шунысы гына: Хәлим кайтып киткәч, тагын аю бимазалый башлаган частьне. Бу хакта ана дуслары шундук хәбәр жибәрделәр.

Менә нинди хикмәтле хәлләр була бит тормышта. Очраклы бер мәзәк хәлме бу, әллә Тәңре ихтыярымы—анысын беркем дә төгәл генә әйтә алмыйдыр, мөгаен.

...Бу юлның берәр очы-кырые булыр микән? Юлның очы булмый, ди халык. Инде олы бер гомер барган кебек Хәлим. Вакытның чамасы оныттылды. Дөресрәге, Вакыт тәгәрмәче бөтенләй туктап калгандай булды. Кояш һаман шунда—бер урында. Коймага менгәч, күлмәге кадакка эләгеп, асылынып калган авыл малае кебек, ул һаман бер ноктасында тора.

Хәлим үзенең кайда икәнен дә чамалап бетерми инде. Әллә көн кызулыгыннан, әллә зиһен казанында кайнаган уйлардан аның башы әйләнеп киткәндәй булды. Юк, туктарга ярамый. Берәр аланга чыккач хәл алыр әле. Мондый караңгы урында туктап, жиргә утырсаң, урман зәхмәте авызына керер дә, тилелек галәмәте булып, гомерлеккә эчендә калыр...

Хәлимнең шул хакта уйлап куюы булды, юл очында бер яктылык күренде. Барган саен ул зурайды, киңәйде. Тагын да якынлашкач, гаҗәеп манзара пәйда булды. Хәлим телсез калды. Телсез генә түгел, аңсыз калдыра язды аны алдында ачылган табигать дөньясы. Кояшта яныпкаралган кеше тәнендәге алтын тәңкә кебек, түрдә, өлгергән ашлыклары белән күзнең явын алып, кечкенә басу жәелеп ята. Матур рәсем кысасына охшап, аны һәр яктан куе агачлык, тыгыз куаклык уратып алган.

Иң гаҗәбе шул: юл басуны урталай бүлеп, хәтта, сындырып үтә. Таш юл буйлап әлеге "сынык дөнья" эченә килеп керүгә, тагын бер сәер һәм шомлы тойгы кичерәсең—камылларда тулышып, башларын асылындырып утыручы иген басуы әле генә күзләрне әрнетерлек дәрәҗәдә ялкыткан урман яшеллеген каплап-томалап куя. Гүя: "И кеше, әйдә, бераз гына шушы урманнан ял ит, минем гарәбә төсле тәнемә кагылып уз, сихри дөньяма кереп чык",—ди иде.

Чынлап та, ачыклыкка килеп чыгу белән, Хәлим үз күңелендә ниндидер бер үзгәреш тойды. Нинди үзгәреш икәнен төгәл генә әйтә алмый, әмма ниндидер әйбәт, күңелгә көрлек, сулышка иркенлек, аңга уяулык бирә торган үзгәреш тойды ул бу минутта. Хәлим шунда ук юл читенә утыртылган ялгыз баганaны күреп алды. Ниндидер сәер багана иде ул. Юл эшчеләре утырткан дисәң, бернинди язу да, билге-тамга да күзгә бәрелеп тормый. Тукталыш баганасы дисәң, нинди тукталыш булсын инде кара урман уртасында? Расписание тактасы да юк. Аннары, шунысы да гаҗәп тоелды Хәлимгә: бу баганага ниндидер сырлар уелган иде. Күпме-күпме?.. Нәкъ уникe сыр! Кызык, нинди Робинзон Крузо сырлады икән боларны? Хәлим тыелып кала алмады, кесәсенә тыгылды. Үзе белән хәрби хезмәттә йөртеп кайткан сөяк саплы пәкесен тартып чыгарды, аның үткенлеген карап алды да, баганадагы уникe сыр янына унөченчесен уеп куйды. Ике мәртәбә "керт" иткән тавыш кына ишетелеп калды.

Үзенең бу гамәленнән разый булып, Хәлим багана төбенә чүгәләде. Чирәмнең үтә дә калынлыгы, куелыгы, жетелеге ошады аңа, жәелеп үк утырды, аякларын алга сузып жибәрде...

Ул бу мизгелдә ниндидер бер рәхәтлек кичерә иде. Көне буе юлның ике ягы буйлап озата килгән яшел дивар таралып юкка чыккан. Аның баш очында да, тирә-ягында да тоташ алтынсу-сары дөнья хасил булган. Өстә—шундый ук Кояш...

Хәлим, капчыгын салып, юлда ашарга дип тыккан вак бәлешен, шешәдәге катыгын алды. Ничек кенә ачыккан кебек тоелса да, тамагына бармады. Капкалаштырып утырды да ризык-тәгамнәрен кире капчыгына салып куйды. Оетып жибәргәндәй итте. Ул башын әлеге рәхмәт төшкере баганага терәде, аннары барасы юл очына күзләрен текәп, уйга калды. Уйлары бик серле иде аның.

Кая алып бара бу юл аны? Бәхеткәме? Бәхетсезлеккәме? Ни көтә аны бу юл очында? Һи, юләр, юлның очы була димени...

Их, менә хәзер, менә шушы минутта ут өстендәге табадай кызган юл буйлап аңа табан дөньяның гүзәл бер кызы килеп чыксын иде... Килеп чыксын иде дә Хәлимне бәхетле итсен иде... Ул кыз Нәфисәсенә охшаган булсын иде...

Шулай дип уйлавы булды, Хәлим төбәлеп карап торган юл башында бер нокта пәйда булды. Егет сискәнеп китте. Нәрсә бу? Кем бу? Кемнең газиз улы яки кызы? Аның кебек тагын бер тиле кеше бар икән әле бу якты дөньяда. Әнә бит килә! Килә... Юк, киләләр. Берәү генә түгел, икәү булып чыктылар хәтта! Бигрәк әйбәт. Бер сөйләшеп-гәпләшеп алырлар, ичмасам. Ничек сагындырды Хәлимне шушы ярты көн эчендә кеше тавышы!

Юлчылар һаман якынлаштылар. Хәлимнең үткен күзләре ерактан ук шәйләп алды: әби карчыклар. Киемнәре бик сәер: гел карадан. Хәтта ачы чиллә дип тә тормаганнар: башларына бераз кояшта унган иске шәл бәйләгәннәр. Аркаларында биштәрләр. Йөкләре бик авыр ахры, алга иелеп-бөкрәеп баралар. Кулларында юан, әмма бик матур шомартылган таяклар. Йөзләрен генә ап-ачык итеп күреп бетереп булмый. Чит-читләре катлап бәйләнгән шәл-яулык эчендә —икешәр пыяла кисәге. Күзләр! Әмма йөзләрен күрү һаман әле мөмкин түгел. Әһә! Кайчакта алга очлаебрак чыгып торган ияклəрен чамаларга була икән...

Хәлим юлчылар белән үзе башлап исәнләшмәкче булган иде дә, карчыкларның берсе алданрак сүз әйтеп өлгерде:

—Нихәл, балакай! Берәрсен көтәсеңме? Бу вакытта беркем дә йөрми шул. Бик озын юлга чыккансың, югалтырлар бит. Өйдә хатының, балаларың бардыр?..

—Исәнмесез-саумысез, әбиләр. Юк, өемдә зарыгып көтеп торган хатыным да, балаларым да юк. Өйләнмәгән әле мин. Әни карчык кына. Ә ул минем китеп йөрүгә күнеккән инде. Көтә белә ул ...

—Улым, кайсы авылдан соң син?

—Кампәрледән мин, әбекәй.

—Кампәрледән? Кем улы буласың соң?

—Белмисез сез безне. Сания белән Рәхмәт улы мин.

Әбиләр дәшмәс булдылар. Бер-берсенә карашып, ым белән генә сөйләшеп алгандай иттеләр. Хәлим аларның бу гамәл-тәртибенә зур мәгънә бирмәде.

—И-и, балакай.. Күзләрең бик арган синең. —Карлыккан тавышлысы әңгәмәне дәвам итте.—Әйдә, безнең белән бергә ял итеп ал. Йоклап ал. Күзләреңә дә ял кирәктер...

Шулай сөйләнә-сөйләнә карчык чирәмгә сырмасын түшәде. Икәүләп шул түшәккә жәелеп утырдылар. Төс-битләре ошап бетмәсә дә, Хәлим әллә ни шомланмады. Бик итәгатьле әбиләргә охшаганнар. Әнә бит, бик яхшы итеп, теләктәш булып сөйләшәләр. Тавышларындагы шомлы бер аваз гына жанны сискәндереп куя: карчыкларның икесе дә "р" авазын үзгәрәк, "гыр" кебегрәк әйтәләр иде. Ниндидер шомлы бер аһәң, дөресрәге, козгын тавышы ишетелеп кала иде бу аваз яңгырашында...

Хәлим сер бирмичә:

—Юк-юк, армадым. Армиядә болай гына йөрми идек без,—дип караса да, бераздан, алдагы юлның озынлыгын уйлап, ризалашты, башын багана күләгәсенә куеп, бераз черем итеп алырга булды. Биш минутлар чамасы шулай оеп утырды ул. Шунда гына искәрде: әле генә медер-медер килүче әбиләрнең тавышы ишетелми башлаган икән. Әллә китеп барганнармы? Хәлим күзләрен ачты. Китмәгәннәр икән. Әмма бик сәер күренешкә тап булды ул: әбиләрнең берсе, аның янында утырганы, башын аска игән, маңгаен тезләренә терәгән, күзләрен йомып уйга калган. Әллә йоклаганмы? Юк икән, әнә иреннәре калтыранып ала. Догаларын пышылдый ахры. Икенчесе дә шунда гына. Ул да, мәрткә

киткән кеше кебек, оеп китеп дога укый: "медер-медер, медер-медер..."
Кинәт Хәлимнең күзләре яшел чирәм өстендә аркылы-торкылы яткан таякларга төште. Әбиләр кулындагы таяклар бит болар! Таяклар үзләре генә ятса, әллә ни сәер дә тоелмас иде, Хәлим аларны искәрмәс тә иде. Гаҗәп: бу ике таяк бер-берсенә тәре рәвешендә куелган, ә урта бер жиргә, таяклар кисешкән урынга, бер карыш чамасындагы чөй кагылган иде. Иң гаҗәбе дә бу түгел әле. Иң гаҗәбе: аркылы-торкылы яткан таяклар юл комы белән божраланып алынган иде. Ә үзәккә кагылган чөй башында—әллә үзле балчыктан изеп, әллә таштан кыеп ясалган сын, кечкенә балбал кисәге. Бу кеше сынының түбәсе очлаеп киткән, гәүдәсе кинәйгән, аскы өлеше тагын очлаебрак тора.
Хәлимнең зиһенен кыеп үткән беренче уй шул булды: "Нәрсә эшлиләр бу карчыклар? Кемнәр алар?" Чынлап та, нәрсә белдерә бу билге — тәре, божра, сын?
Шунда Хәлимнең йөрәге "жу" итеп китте. Кысылып-кысылып куйды. Ул ике-өч ел элек булган бер вакыйганы исенә төшерде. Армиягә алынырга күп калмаган иде инде. Клубка чыгарга әзерләнеп йөргән вакыты. Кинәт капкадан хәле бетеп күрше Васимә карчык килеп керде. Керү белән, капканың тәртәсен тартты, келәсен төшереп куйды.
—Беләсенме, Саниякәем, авылга сихерчеләр килгән. Сак була күрегез, бер-бер хәл кылып куймасыннар дип керүем. Тавыш-тыныгызны чыгарасы булмагыз!.. Аллаһы шомлыгы, берәр кайгы алып килмәсәләр генә ярар иде инде, әстәгъфирулла, тфү—тфү!..
Әлбәттә, Хәлим ышанмады мона. Нинди сихерче булсын ди бу космос заманында?! Карт-коры әкияте! Ул киенде-ясанды да капка-ишекләрне шалтыратып ача-ача урамга чыгып китте. Клуб ягына борылды. Шунда аның күзе капка баганасындагы бер тамгага төште. Божра эченә тәре сызылган иде. Божра үзәгендә, ике сызык кисешкән урында кечкенә түгәрәк... Ак таш белән төшерелгән бу тамгага әллә ни игътибар итеп тормаган иде Хәлим. Менә хәзер шул рәсем аның исенә килт итеп килеп төште. Әлеге ачышыннан йөрәге шартлап ярылырдай булып, ярсып-ярсып тибә башлады. Әмма аяклары, куллары, тәне ана буйсынмады.
...Шул вакытта тирә-якта сәер хәлләр башланды. Хәлим үзе утырган жирнең селкенеп куюын тойды. Башын терәп куйган багана да калтыранып торган кебек иде. Үзе дә торараташ кебек катып калгандай булды. Нинди хәл бу: ми эшли, зиһен бар, кан йөгерә, йөрәк суга, күзләр күрә, колак ишетә, әмма кузгалыр егәрлек юк. Үтереп йокы килә. Баса... өскә тегермән ташы бастырып куйганнармыни... Элек әбиләр "Албасты басты" дип сөйләшәләр иде. Бу да нәкъ шуның кебек. Әллә?.. Әллә бу карчыклар албастыларның үзләре микән?
Жир тетрәпме-тетри. Хәлим арыш башакларына игътибар итте: алар да әллә каян гына килеп чыккан жил уңаена әле бер якка, әле икенче якка дулкынланып утыралар. Хәлим төш күрәм бугай, дип уйлап өлгермәде, кинәт жил көчәеп китте, ә дигәнче давыл гарасатка әверелде, басу өстендә "жен туе" күтәрелде, көн караңгыланды, озакламый кояш та, кызгылт шар кебек, төссезләнеп, тоныкланып калды...
Нииндидер көч Хәлимне күк катына алып менеп китте... Ул авыр итеп ыңгырашып куйды да, хәлсез керфекләрен йомып, һушын югалтты...

## III

Хәлим дертләп уянып киткәндә һаман шул күренеш иде: күз күреме жирдә басу, басу артында яшел тасма сузылган — аңысы урман; күк аяз, көн якты, чиллә... Юл да, юл буен сырып үскән үләннәр дә шул ук. Хәтта, аркасын терәп утырган багана да урынында...
Хәлим үз аңында иде, әмма бөтен һушын, аң-зиһенен жыеп алырлык дәрәҗәдә уянып житмәгән әле. Келт итеп, моннан берничә минут элек кенә пәйда булган ике карчык хәтеренә килеп төште. Кайда алар, кемнәр

алар? Нәрсә булды соң аның белән? Ниндидер гарасат—давыл чыгып, җир тетрәгәндәй итте —моны Хәлим ап-ачык хәтерли... Ә хәзер, әнә — бөтен дөнья тып-тын калган. Ниндидер сәер, үлем тынлыгы...

Хәлим кузгалмакчы булды. Аркасы белән баганадан этенеп, бер омтылуда торып басарга уйлаган иде дә... Кая, алай тиз генә басып булмый икән әле. Хәлимнең тән-гәүдәсе, аяк-куллары егәрлеген югалткан иде. Ми зеңләп тора, тамырлардан шыбыр-шыбыр кан йөгерә, әмма тән әгъзалары, җансыз кебек, бер чарасыз калганнар иде бу минутта. Гүя өстенә бер йөк агач бастырып куйганнар. Бөтен тәне, гәүдәсе сыкрап-сыкрап сызлый...

Хәлим кулларына таянып басарга тырышып карады. Бармакларын очлары эссе чиләдә көеп өлгергән үләнлек өстенә җәеп җибәрде. Шунда анын йөрәге "жу" итеп китте, тәненә салкын йөгерде. Кулларына, чалбар ертыгыннан күренеп торган аякларына карарлык түгел иде аның. Шулкадәр дә каралып, майланып, корымланып каткан, әйтерсең лә, гомер буе су-мазар күрмәгән. Хәлим шунда ук киемнәрен караштыра башлады. Чалбар балаклары пычранып, тузып, чукланып беткән, күлмәгенең нинди төстә булуын да әйтеп булмый. Әле районга барыр алдыннан гына сандыктан алып кигән иде бит. Хәлим айнып киткәндәй булды. Нәрсә бу? Нинди сихер? Ул ничек торып басканын да сизми калды. Торып басты да куллары белән үз тәнен капшап-капшап карый башлады. Менә аның кул-бармаклары йөзенә менеп житте... Тагын бер ах итте Хәлим. Аның йөз-битен сакал-мыек баскан иде...

Хәлим нишләргә дә белмәде. Хәтта, төш күрмим микән дип, үзен чеметкәләп тә карады. Баш житәрлек хәл түгел бит: биш минут элек кенә бөтенләй башка дөнья иде... ә хәзер... сәләмә бер дәрвиш хәлендә басып тора !.. "Акылдан язаммы әллә?" —дигән уй йөгереп үтте ми жепселләреннән. Унга кадәр санап та карады, аннары кабат бергә кадәр санап төште... Юк, үз акылында...

Хәлимнең аяк буыннары тотмас хәлдә иде, ул аркасы белән баганага ышкылып, кабат җиргә шуып төште... Тагын бер мәртәбә, керләнүдән, күпсанлы җәрәхәтләрдән гайрәтне чигәрерлек хәлгә килгән кулларына карап алды да чирәмгә капланып ятты...

Ниндидер башка бер дөньяга кереп чыккандай хис итте ул үзен. Ул дөньяда, гүя, вакыт бөтенләй башка тизлектә ага... Бер мизгелдә бер сәгатьлек, бер сәгатьтә бер еллык вакыт уза анда. Тик... нинди дөнья соң ул? Сәер дөнья... Ниндидер бер тавыш чыңлап тора...Тукталып ала да тагын сузып-сузып кычкырта... Нинди сәер тавыш соң бу?

Хәлим башын күтәреп юлга карады. Бераз узыбрак машина туктаган, аның кабинасыннан бер баш калкынып тора. Шул яктан килә икән тавыш. Машина сигналы. Тукта, бу бит күрше урамда яшәүче Зөфәр! "Кага-бога" Зөфәре. Бала чакта малайлар аны шулай дип үртиләр иде. Чөнки ул "р" авазын әйтә алмый иза чикте. "Кара карга очып бара" дигәнне ул: "Кага кага гоп бага",—ди иде.

—Син кая? Котымны алдың, мәет ята дип торам. Әйдә, утыр...—дип кычкырды Зөфәр. Әмма үзе машинасыннан төшмәде. Бераз шикләнә иде ахры. Хәлим башын тагын да калкыта төшеп:

—Зөфәр, бу мин—Хәлим... Ташлама мине. Зинһар... Ниндидер афәткә юлыктым ахры. Калдырма, ал мине үзең белән. Хәзер торам!.. Бераз хәл генә алам да...

Шунда Зөфәргә әллә нәрсә булды.

—Хәли-и-м?—дип сузды ул. Аннары:—Син каян? Син исәнмени? Юктыр, шайтандыр син? Тфү-тфү! Кит моннан, гыйфрит!—дип сөйләнә-сөйләнә, тиз генә кабинасына кереп утырды да газга басты. Эчтән генә сыкранып, сулкылдап эшләп утырган йөк машинасы үкерә-үкерә алга ыргылды.

Хәлим, бөтен көченә сикереп торып гәүдәсен юлга ташлады. Әмма машина, аның белән бергә таныш дөнья—авыл, әнкәйләр, күршедәге

Васимә әбиләр, Ак бабайлар, Нәфисәләр, Зөфәрләр һаман ерагая барды. Хәлим үзенен шушы ике дөнья арасында калуын һәм шул аралыктан чыгып булмаслык ниндидер тирән упкынга очуын тойды. Ул кинәт аяк астында яткан бер ботакка абынып, мәтәлчек ата-ата, юл читендәге эссе тузан эченә барып төште... Аннары, тән сыкравы белән жан сыкравын бергә кушып, "Аh" дип куйды да тынып калды.

## IV

Хәлим кайтып кергәндә авылга энгер-менгер төшкән иде инде. Көтү күптән кайткан, урам тузаны басылган, авылның әле бер очыннан, әле икенче очыннан, адашып чит-ят утарга кергән бәрәннәрнең ара-тирә кычкырып куюы гына ишетелеп кала. Аларга капка төпләрендәге яшел чирәм өстендә түшәлеп яткан каз-үрдәкләрнең мыгырданып сөйләшүе өстәлә. Сирәк-мирәк кенә эт өреп куя. Кайсыдыр йортта чиләк колагы чынлап төшә—сыер савалар... Кичке авыл исе, борын тишекләренә кереп, кытыклап йөри. Яна сөт исе! Авыл исе дигәнең әнә шул сөт исе инде ул.

Кояшның кызуы басылган. Әмма ул әле офык артына кереп китәргә ашыкмый. Күңелдә шомлы халәт: кояш дип йөртелгән бу кызыл шар бераздан жиргә кагылыр да, ташка төшеп чәлпәрәмә килгән кабак кебек, шартлап ярылыр сыман.

Хәлим авылга якынлашканчы шул ут йомгагына карап килде. Әллә күңел тынгысызлыгыннан, әллә хәлсезлектән, ничек кенә адымын тизләтергә тырышса да, ул авылга якынлаша алмый интекте. Гүя авыл анардан качарга тырыша иде. Хәтта вакыт тукталып калган кебек — күк читендә сәгать буе эленеп торган болыт тасмасы шуңа ишарә итә. Вакыт кына түгел, гомер, тормыш тукталып калган диярсен. Хәлимнең йөрәге дә, туктаргамы-юкмы дигән кебек, теләр-теләмәс кенә тибә иде бу минутта...

Ындыр артыннан кермәкче булды Хәлим. Ул бик яхшы аңлый: нәрсәдер булган. Юл буенда утырган азмы-күпме вакыт эчендә бу дөньяда ниндидер хикмәтле хәл булган. Ниндидер бер галәмәт, зәхмәт суккан аны... Шуңа күрә, бу хакта иң элек әнисеннән сорарга уйлады Хәлим. Бәлки ул беләдер?

Арткы бакча капкасына килеп тотыну белән, Хәлимнең йөрәге "жу" итеп китте: капканың келәсе башка иде. Ул иртә белән арткы яланга бозау илткәндә бөтенләй башка бик, башка келә иде бит! Әнә, койма такталары да сирәкләнеп калган, —кеше чыгып-кереп йөрерлек ярыклар барлыкка килгән!

Хәлим як-ягына карана-карана ишегалдына килеп керде. Килеп керде дә багана кебек катып калды. Аптырарсың да шул: ишегалды тулы кеше. Күршедәге бөтен карт-коры, әз-мәз генә дога белгән һәркем шунда —кем жиргә чүккән, кем койма буендагы бүрәнәгә кунаклаган... Хәлимнең әнисе ялгызы гына өйалды баскычында утыра.

Хәлим, керү уңаеннан, абзар диварына елышып, үрә катты. Ярый әле күрмәделәр, дип уйлады ул. Бер мизгелдән кызыксынуы жиңде — башын чыгарыбрак, үрелеп карады. Әһә! Дога укып утыралар бит болар! Һәрберсе кулын алга жәеп салган. Әнә бит—үзләренең уч төпләренә төбәлеп, ниндидер илаһи бер халәткә кергәннәр, тик, алмашлап, ара-тирә генә иреннәрен "медер-медер" китереп алалар яисә, серле бер ритмга буйсынып, гәүдәләрен әле алга, әле артка ташлыйлар...

Хәлим ачык торган жил капка баганасына сөялгән Зөфәрне күреп алды. Нишләп тора ул монда —гомергә аяк басканы юк иде бит аның Хәлимнәр ихатасына? Житмәсә, дога укыган булып, кулларын алга сузган. Көндез юлда ташлап китүен аның бер исенә төшерәчәк әле Хәлим...

Әмма Хәлимнең уйлары Зөфәрдә озак тукталып тора алмады, үз ихаталарындагы сәер күренешкә әйләнеп кайтты. Хәлим бу күренешне һичничек аңлатырлык хәлдә түгел иде. Нәрсә бу? Үлем-китем булганмы?

Каян килгән монда “мәет җыены”? Ак бабай нишләп тора? Нигә аның йөзе караңгы, боек? Әнисе дә, иң якын, иң газиз кешесен югалткан кебек, башын аска иеп, кайгылы чакта гына бәйли торган шәленә уралып утыра... Хәлимнең кайтуын көтмәгәннәр, ахры, болар...

Шунда ихата җанланып алды. Догаларын укып бетергән картлар: “Амин!”—дип куйдылар да, битләрен сыпыра-сыпыра урам капкасына таба юнәлделәр. Берничәсе Сания янында калды. Ак бабайның тавышын беркем белән дә бутарга мөмкин түгел: шундый да ягымлы, йомшак, моңлы тавыш булыр икән:

—Ярый, Сания, догаларыбыз кирәкле урынына барып ирешсен. Барысы да әйбәт булыр, Аллаһы боерса. Күңеленне тынычландыр, бәгыреңне телгәләмә... Бүген бит Хәлимең югалуына нәкъ бер ел. Бер елдан соң Коръән чыгарга кирәк булган. Дога сораган ул. Урман буенда өрәк булып кайгырып йөргән Хәлимең дә, тынычланып, үз урынына кереп яткандыр инде... Бар, син дә кер, алай нык кайгырма, була андый хәлләр, үз елларында мәрхүмнәр үлгән җирләренә килүчән булалар...

Хәлим башкача түзеп тора алмый иде инде. Тагын бераз шулай торса, йә, гөрселдәп җиргә егылыр, йә меӊ-миллион кузәнәккә таралып, шартлар кебек иде. Ул абзар коймасыннан көч-хәл белән аерылып, ихатага табан ике адым атлады да, бар булган егәрлеген җыеп, үпкәсеннән берничә сүз кысып чыгарды:

—Ак бабай... Әнкәй... Нишләп мин үлим ди... Менә бит мин— исән...

Әмма Хәлимнең көч-егәрлеге тәнен, буыннарын ташлап киткән иде инде. Ул, әйтергә теләгән сүзен дә әйтеп бетерә алмыйча, ике кулын алга сузган килеш, башта тезенә төште, аннары акрын гына янтая барып, җиргә чүкте, тагын бер мизгелдән аһылдап койма буендагы кычыткanlык өстенә ауды... Ындыр ягыннан кинәт пәйда булган сакаллы карачкыны күреп төрле якка тайпылган авылдашларын да, кулларын учлап, ашыга-ашыга дога укырга керешкән Ак бабайны да, “Улым!”— дип, ике кулын сузып аңа таба омтылган әнисен дә күрмәде Хәлим... Күрмәве хәерлерәктер дә. Бу хәлне күргән булса, йөрәк-бәгыре түзмәс иде, шартлап ярылыр иде дә бөтен дөньяны аһ-зарга тутырыр иде...

## V

Кеше кайчакта үзенең туган мизгеленә кайта, аны ачыктан-ачык күрә, тоя, диләр. Менә ул якты дөньяга килә, беренче мәртәбә көн яктысы, кояш нурлары белән очраша. Аннары арлы-бирле йөрүче шәүләләрне чамалап ала, күз карашы белән шул шәүләләргә ияреп йөри башлый. Тоныкк кына, ниндидер үтә күренмәле пәрдә аша кеше йөзләре күренгәләп ала. Кайбер йөзләр, ерактан карап торуга гына риза булмыйча, якын ук киләләр, иелеп-иелеп, йотардай булып, комсызланып карыйлар... Бераздан бу тын дөньяга җан керә, тавыш инә һәм баштарак саңгырау гына бер чың, аннары бертуктаусыз көчәя барган дөнья шавы ишетелә башлый... Тиздән бу шау күптөрле төсмерләргә, аһәңнәргә таркала, әле бер мизгел элек кенә якты дөньяга килгән сабый колагына әнисенең, әтисенең, әби-бабаларының тавышлары аермачык булып килеп ирешә. Сабый өчен бигрәк тә үз анасының тавышы якын. Газиз, илаһи бер көй кебек...

—И-и, балакаем... Үлепләр терелдеңмени соң син? Кайларда гына йөреп кайтты икән бу башларың? Кайларда гына йоклап, нинди генә ризыклар кабып үтте икән синең бу елың?.. Йа Илаһым, башыңны исән-сау йөртеп алып кайтканыңа мең-мең рәхмәтләр сиңа. Гомерем буе догадан ташламам, и Раббем!

Ана яшьле күзләрен сөртә-сөртә түшәктә ак юрганга чорналып яткан малаеның җиту чәченнән, сакал-мыек баскан йөз-битләреннән

сыйпый, бармак очлары белән генә куе кашларыннан йөгереп үтә, мангаендагы миненә тиеп карамакчы була да, инде кагылдым дигәндә генә кулын кабат тартып ала...

Хәлим уянып, дөресрәге, янадан туып ята. Ул әлегә анасының шәүләсен, җылысын, исен, карашын, тавышын аермый, бары тик тоя гына...

—И-и, балакаем... Бер ел буе, көне-төне түккән күз яшьләрем кайтарды бит сине... Ходай тәгалә, гомер буе интектердем, инде бер сөенсен, дигәндер, мең рәхмәтләр ана... Менә бит минем балам кайткан... Улыкаем минем!..

Анасының авыр эш эшләп кытыршыланган кулларын Хәлим күптән тоеп ята. Аның сөйләнүен дә ишетә. Әмма һаман да уянып, туып җитә алмый. Дөресрәге, аның җаны, рухы инде күптән уянган, хәтта, бераз өскә күтәрелеп, өй эчендәге Ана белән Балага карап тора, ә менә тәне, җисеме уянып җитмәгән, мәрткә киткән килеш ята бирә.

Шул мәлдә Хәлим үзенең ирен читендә бер дым сизде. Ниндидер тозлы бер тамчы, каяндыр килеп тамды да, ирен читенә төшеп югалды... Бу кечкенә тамчы шулкадәр көчле-куәтле иде, Хәлим шундук күзләрен шар ачып җибәрде һәм... түшәк читендә елап утырган әнисен күреп, аһ итте... Аның янында ап-ак чәчле, йөзләрен кат-кат җыерчык баскан, күп елаудан күзләре шешенеп беткән, күзе коесының төбенә үк төшеп киткән, йөзенең һәр күзәнәгеннән ниндидер олы авыртыну бәреп торган бер карчык утыра иде...

Шулай да, аның күзләрендә сызылып яткан гаҗәеп матур, сихри бер яктылыкны, нур бөртеген күрми мөмкин түгел. Бу—баласының табылу сөенеченнән әле яңа гына кабынган күңел яктылыгы, бәхет нуры иде.

—Әнкәй... —дип пышылдады Хәлим. —Ник елыйсың, әнкәй? Ул инде тәмам уянып җиткән, аң-зиһенен җыеп өлгергән иде бу вакытта.

—Балакаем... —бу юлы инде Сания өзгәләнде. Иң кадерле, газиз әйберен табып куанган кебек, Хәлимнең башын күкрәгенә кысып, көйләп сөйләвен дәвам итте.

—Ник еламыйм ди... Менә бит—син кайттың, бердәнберем минем... Кайларда гына йөргәндер бу башкайларың...

—Әнкәй...

—Юк-юк, сорамыйм. Кайларда булганыңны, кемнәр белән ничек гомер кичергәнеңне сорамыйм. Кирәк тапсаң, үзең сөйләрсең әле. Кайтуың гына хак булсын. Өметемне өзгән идем бит инде. Өметсез яшәү бигрәкләр дә кыен шул, балам...

—Әнкәй, мин бит бер нәрсә дә белмим... Ак бабай бер ел ди әнә... Берни дә аңламыйм. Бүген генә районга киткән идем... Ә сез бер ел дисез... Кайда булганмын соң мин бу вакытта, әнкәй, ә?

—И улым, сиңа ял итәргә кирәк. Әнә бит нинди хәлгә төшкәнсең – тәнең, бөтен сөяк тә тире, йон баскан, тәнеңдәге җәрәхәтләрнең исәбе-хисабы юк. Менә ял итеп алырсың да... барысын да исеңә төшерерсең. Ходай боерган булса.

—Әнкәй! Мин бит дивана түгел! Хәзер үк ни дә булса искә төшергән булыр идем... Юк, әнкәй, ниндидер галәмәт бар монда. Нәрсә соң бу, ә, әнкәй, белсәң, яшермә, әйт!..

—И- и, белсәм аны... Әтиең дә шулай китеп югалды. Инде син дә китеп юк булгач, мин үзем дә әллә нәрсәләр уйлый башлаган идем. Җен-албастылар ияләштеме әллә безнең нигезгә, дип тә шикләндем. Менә син кайткач, күңелемдәге таш шунда ук эрегән кебек булды...

—Әнкәй, ничек алай булырга мөмкин соң ул? Һичбернәрсә аңламыйм. Авылга кайткан җиремнән утырып кына торган идем бит. Хәл алырга дип юл читенә чүгәләгән генә идем... Әле анда ике карчык та бар иде...

—Ә? Ике карчык? Кемнәр алар? Сораштыңмы соң?

—Әллә инде... Ниндидер кара карчыклар. Йөзләре күренми иде...

Хәлим, бөтен хәтер егәрлеген бер төенгә җыеп, йөзләрен чытып, нидер исенә төшермәкче булды. Әмма моннан берни дә барып чыкмады, ул, ыңгырашып, мендәргә капланды:

—Ыһ-һ!..

Анын күнеле тулды, рәхәтләнеп, ауный-тәгәри бер елыйсы килде. Рәхәтләнеп еласа, бу чарасызлыктан берни дә калмас, ә хәтере кабат кайтыр кебек тоелды. Әмма ул елый алмый иде шул...

Сания инде барысын да аңлап алган иде. Күп еллар буе нәселнигезләрен эзәрлекләп торган зәхмәт аның Хәлименә дә килеп кагылган булып чыкты... Шуңа күрә улына ул башка сүз катмады. Капланып яткан Хәлимнең башыннан сыйпый-сыйпый, ишетелер-ишетелмәс кенә җыр башлады:

Түзәр кебек идем, булмас ахры,
Гомер итүләре кыенга.
Юатмасмы, үз итмәсме диеп,
Каерылып карыйм каенга...

Бу җырда барысы да бар иде: Хәлимнең нәкъ бер ел элек районга чыгып киткән җиреннән кайтмый калуы да, керфек тә какмый көннәр, төннәр буе зарыгып көтүе дә, районга барып, бөтен таныш-белешләреннән, туган-тумачаларыннан сорашып йөрүе дә, бертуктаусыз милиция, военкомат, прокуратура тупсаларын таптавы да, эзләү бригадаларына кушылып, юл буе мари урманнарында ничәмә-ничә төннәр кунуы да, ниһаять, ярты елдан соң урман буенда бер мәет табып, аны Хәлимгә юрап, бөтен авыл белән җыелып, елый-елый күмүләре дә, шул кайгылы вакытлардан соң, зиратка килеп, сәгатьләр буе улы белән сөйләшеп утырулар да бар иде...

Бу башыма төшкән кайгылардан
Менеп качып булмый айга да.
Кеше түгел, каен түзмәс иде
Миндәге бу ачы кайгыга...

Әйе, Саниянең бу ел эчендә күргәннәре кайбер кешеләрнең озынозын гомерләре буе күргәннәренә торырлыктыр шул. Башта ук аның Хәлимне районга җибәрәсе килмәгән иде. Күңеле сизенә икән ана кешенең. Авыл аша ике сихерченең узуы да күңелдәге шомны арттырган иде. Тикмәгә генә түгел бу; ике карчык кыяфәтенә кереп йөргән җеналбастылар хакында сүзләр мари авылларында күптән йөри бит. Менә хәзер алар татар авылларында да күренә башлаганнар...Тик ул вакытта Хәлим әнисенең сүзен колакка элмәде шул.

—Мине ике дәрвиш карчык түгел, өй чаклы аю да куркыта алмый, әнкәй, борчылма,—дип уенга алып куйды да юлга чыгып китте. Үз башына җилкенгән икән, үз башына...

—Тәүбә диген, балам урман юлында ниләр булмас. Доганны әйтеп, җен-шайтаннардан сакланып йөр, Зәңге баба юлдаш булсын, Чупан баба кулдаш булсын,—дип кул болгап калган иде ул Хәлимнең артыннан. Хәлим исә, авылга кайткан кунакларга ияреп китте дә барды. Артына борылып та карамады, ичмаса. "Артына борылып карамады, тиз кайтыр",—дип юрады Сания, күрше Мәрьям әби сүзе белән.

Әмма кайтмады да кайтмады Хәлим. Кичкә дә, икенче көнне дә, бер атнадан, бер елдан да... Сания телдән калды, аяктан калды, арынды, бетеште. Әмма Хәлимне көтүен, өзгәләнүен ташламады, очраган бер кешегә ияреп районга йөрде, бөтен милицияне, танышларын, туганнарын аякка бастырды.

Саниянең җанын көне-төне бер уй телгеләде: "Урман йотты, урман тартып алды аның баласын. Атасын алган кебек, улын да урман үзенеке итте..." Яшь чакларында ук башыннан кичкән төрле вакыйгаларны уйлап бетерде. Гомерендә очраган бөтен сәер хәлләрне дә Хәлимнең югалуына китереп бәйләде...

Беренче галәмәт Хәлимне тапканда булды.

Сания төгәл белә: бала килергә ике-өч атна вакыт бар иде әле. Шуна күрә дә ул бер икеләнмичә урманга җиләккә чыгып китте. Менә шушындый җәй көне иде. Җиләкнен түшәлеп унган чагы. Урман аланын яланаяк аркылы үтсән, балтырдан җиләк сутына буялып чыгасын... Яфрак зурлыгындагы җиләкләрне сыдырып кына аласын да ярты сәгатьтә чиләкне тутырасын да куясын... Сания дә күп булса ярты сәгать эчендә чиләген чүмәкәй итеп тутырып куйды. Иелеп йөреп, корсагына көч килдеме, әллә ерак юлдан арыбрак киттеме,—кинәт хәлсезләнүен тойды ул. Башы әйләнеп жиргә чүгәләде, аннары, аякларын як-якка ташлап, алан уртасына сузылып утырды... Тамагы кибүен тойды, сусаудан иреннәре бөрешеп-бөрешеп килгән кебек тоелды. Якында гына чишмә бар барын... Ничекләр генә барып житәсе ана? Юк, басып булмый. Үрмәләргә корсак комачаулый. Әнә бит ул таллык, инкүлек. Чишмә тавышы да ишетелеп киткәндәй була, хәтта.

Сания юка тукымадан тегелгән пәрдә аша караган кебек, тырышып-тырышып, чишмә ягын карый. Су астындагы дөньямыни?! Нәрсә бу? Көн кызудан рәшә тирбәлүеме, әллә берәр сихерме?

Тукта! Чишмә буенда кешеләр йөри түгелме сон?.. Кемнәр алар? Кычкырыр иде дә—сынар аваз чыгарырлык та егәрлеге калмаган анын... Үзләре монда килә түгелме? Ике кара шәүлә... Урман женнәреме әллә? Бәй, әбиләр бит болар. Кулларында чүлмәк-чуен ише нәрсә дә бар. Сания ачык күрә—алар атлап килгән унайга, чүлмәктәге су чайпалып-чайпалып китә...

Шул вакытта Саниянен карынына жан кергәндәй булды. Тугыз ай буе бәгыре янында йөрткән баласы, дөньяга чыгаруны сорап, тыпырчына башлады. Йөрәген урталай телделәрмени —Сания, жан ачысы белән, инрәп кычкырып куйды. Ул инде бу минутта тирәсендә кайнашкан әбиләрне күрерлек хәлдә түгел иде. Ярый әле күрми. Учак әмәлләп йөргән, бөркет томшыклы карчыкны яки якты дөньяга чыгарга ашыккан, шунын өчен дау куптарган баланы каршы алырга хәзерләнгән шадра йөзле сихерчене күз чите белән генә күрсә дә, шундук йөрәге ярылыр иде, туып яткан баласын якты дөньяга китмәс борын ятим итәр иде, билләһи...

Сания озак, бик озак жәфаланды. Ул моны яхшы белә. Бала тавышы иксез-чиксез урманны сискәндергәндә мәһабәт наратлар башына шәфәкъ тиер-тимәс тора иде инде.

Сания бер мизгелгә генә айнып киткәндәй булды. Анын күзенә ин элек дөрләп янып яткан учак чагылды. Аннары... Аннары теге таныш ике карчык... Каяндыр шыбыр-шыбыр су акканы ишетелә. Колак төбендә янгырап торган чынга түзәр әмәл юк. Бөтен тәне кыйналган, ватылган, жимерелгән кебек... Кисеп ташланган диярсен, үтереп күкрәкләре сызлый... Бераздан бу сызлау аны ташлап китә. Авырту басыла, яктылык югала, бөтен тирәлекне карангылык һәм тынычлык баса... Сания тагын мәрткә оча...

Икенче мәртәбә уянуын төгәл белә инде ул. Тан атып килә... Кошлар тавышына түзәр хәл юк. Бигрәк тә чишмә ягындагы таллыктан үзәк өзгеч бер кош тавышы килә. Парын югалткан сандугач булыр бу. Ул гына шулай күнелне ялкынсытырлык итеп сайрый ала...

Саниянен уй-зиһене уянса да, тәне йоклый иде әле. Ләкин ул шунда ук тоеп алды: күкрәк турысында жанлылык бар. Ниндидер бер тереклек иясе селкенепме-селкенә...

Ныклабрак караса — бала! Яна туган бала. Әйбәтләп төреп, авызын Саниянен күкрәге турысына китереп, имү өчен жайлап куйганнар...

Саниягә бик тиз хәл керде. Ул баласынын исән-сау булуына куанды, төш пәрдәсе аша гына күзенә чагылып калган карчыкларга рәхмәт укып бетерә алмады...

Саниянен урманда бала табып кайтуын төрлечә юрадылар. Ире Рәхмәтнен сәер хәлләрдә югалуыннан сон авылны шаккаттырып булмас

кебек иде. Ә! Була икән шул. Моның өчен урманга барып бала табу гына кирәк икән. Әйтерсең лә бүген әбиләребезнең басуда, уракта вакытта бала табулары бөтенләй булмаган да, моны бер кеше дә күрмәгән, беркем дә ишетмәгән... Баштарак бераз сүз куерттылар да, тындылар тагы. Әмма Саниядән бөтенләй читләштеләр. Аның йортына айлар буе йомыш белән дә керүче юк иде. Күршедә яшәүче Васимә әби белән Ак бабай гына онытмады аны. Алар булмаса, ничек үстерер иде икән ул Хәлимен. Юктыр, үстерә алмас иде. Бер-бер хәл булыр иде яисә бөтенләй дә юлдан язар иде аның баласы.

Әле дә хәтерендә: Хәлимгә дүрт-биш яшьләр булгандыр. Ул инде ихатадан чыгып йөри, якындагы наратлык буеннан күкеләр җыеп кайта яисә Ак бабай янына —ат абзарына барып, картның ат чистартканын карап тора.

Шулай бер көнне Хәлим Ак бабай янына йөгереп чыгып китте. Әмма кайта торган вакытында кайтмады. Тагын бераз көтте дә, малаен үзе барып алмакчы булды Сания. Ак бабайны урынында күрмәгәч, Саниянең күңеленә шом керде: кайда булырлар соң алар? Ак бабайны әйтер идең инде—яшен яшәгән кеше бит үзе. Бала кешене әллә кая алып йөрмәсә...

Ак бабай һаман кайтмады да кайтмады. Сания урман буена, атлар көтүе йөри торган иңкүлеккә юнәлде. Шунда йөрмиләрме? Юк, анда да юк...

Шунда урман авызына кереп китә торган юл очында бер җигүле ат пәйда булды. Шул, үзе — Ак бабай! Ә Хәлим кайда? Сания әллә нишләп китте. Ул үз-үзен белештермичә, атка каршы йөгерде. Барып җитәрәк кенә арба эченә бөгәрләнеп яткан улын танып алды.

Ак бабай, кайта-кайта, менә нәрсәләр сөйләде аңа. Ул ат карарга кереп киткәндә Хәлим утарда уйнап калган булган. Атларга бер-ике сәнәк печән ташлап чыгуга Хәлимнән җилләр искән имеш... Тиз-тиз генә абзарны әйләнеп чыга карт, күрше урам-тыкрыкларга күз сала. Җир астына төшеп киткәнмени—юк Хәлим! Шунда карт урманга таба китеп баручы өч кешене күреп кала һәм, җигүле атын куа-куа, шулар артыннан чаба, тегеләрне урман эченә кереп барган җирдән куып тота. Куып җитә дә, ике карчык белән җитәкләшеп барган Хәлимне, тартып алып, арбасына менгереп тә утырта. Тege карчыклар һушларына килгәнче җан-фәрманга атын куа да башлый...

Малайны өч көн исенә китерә алмый интектерәләр. Авыл очында ялгызы яшәүче Мәймүнә карчык кына аны, өшкереп, аягына бастыра. Өч көн буе сөйләшмичә, көлмичә-елмаймыйча йөргән Хәлимгә җан керә, ул элеккедән дә шаянрак балага әверелә... Мәймүнә карчык, малайны сакларга кушып, Саниягә әллә нинди тылсымнар төяп чыгара: алар арасында аю тырнаклары, җәнлек тешләре, кош каурыйлары, тагын әллә нәрсәләр бар. Акрынлып барсын да югалтып бетерә Хәлим. Иң соңгы ябалак йонын Хәлим, кызык итеп, армиядән бер хатына салып җибәрде. Хатында исә: "Әни, үзеңне сакласын, бу бик тылсымлы әйбер..."—дип язган.

И—и, бигрәкләр дә әкәмәт-сәер хәлләр булды шул аның Хәлиме белән. Адым саен бер "мөгез чыгара" иде ул. Мангаендагы миңе белән булган хәлләр дисеңме... Нигә—нәрсәгә генә юрамадылар бу миңне?! Сихергә дә, тылсымга да, илаһи пәйгамбәрлеккә дә... Хәлимнең аны кисеп ташлар чаклары еш була иде. "Ярамый, миңне киссән, гомерең кыскара, үзеңә бәла чакырырсың, балам, тынычлан, көләрләр дә бетәр..." —дигәч кенә тынычлангандай була иде Хәлим.

Әнә бит—мангаендагы миңе бер үзгәрмәгән. Сания, тирән йокыга китеп, мышный-мышный йоклаучы Хәлимгә текәлеп карап тора. Аратирә, бөтен тәне белән калтыранып, дертләп куйган баласына карап, аны сөеп алмакчы була, әмма уятудан куркып, кулын тартып ала, шулай да бераз аскарак шуган юрганын улы өстенә тартып куярга кыюлыгы җитә.

Сания тышта әтәч кычкыруына сискәнеп китте. Кискен борылып,

тәрәзәгә күз салды—таң атып килә иде инде. Беренче әтәчкә башкалары кушылды, кайдадыр эт өреп куйды, кайтмый калган ялгыз бәрән еламсырады. Авылга жанлылык инде. Әмма көтүгә әле иртәрәк. Шулай уяныр-уянмас хәлдә авыл әле берәр сәгать чамасы иләсләнеп ятачак.

Хәлим изрәп йоклый. Карап тора-тора да, тагын аптырап куя Сания: шулкадәр үзгәрсә дә үзгәрер икән кеше! Әтисенең йөзеннән алып "каплаган" күз-каш тирәләре булмаса, иң мөһиме, маңгаенда миңе булмаса, аны Хәлим дип кем уйлар иде икән?!

Сания иртән иртүк мунча ягарга карар кылды. Юып, чистартып, кырындырып кеше рәтенә кертергә кирәк бу дәрвиш малайны. Юлда очрасаң, чирмеш диванасы дип, таш атып китәрсең, билләһи. Әле ярый кеше күзенә күренеп йөрмәде... Шулай да кичәге "өрәк куу" жыенына әләкте анын Хәлиме. Әләкмәс иде дә, Зөфәр кайтып бөтен дөньяны аякка бастырып өлгергән иде шул.

Ичмасам, туры Сания апасы янына да кермәгән. Очраган бер кешегә такылдап йөргән. "Урман юлында Хәлимнең өрәген күрдем, арттан иярә язды",—дип сөйләнгән. Васимә түти кереп әйтмәсә, Сания бу хакта белми дә калыр иде, мөгаен. Йөгерә-атлый Зөфәрләргә барып кергәч, аның үзен дә сәер генә, син үзең дә өрәк түгел микән, дигән кебек каршы алдылар. Шулай да, Зөфәр үзенең күргәннәрен инде йөзенче тапкыр сөйләп бирергә иренмәде. Сания кат-кат сорашты: Хәлим идеме соң ул? Бер-бер хәл булмаганмы? Нәрсә кигән иде?.. Зөфәр тәфсилләп жавап биреп барды. Ахырдан: "Сания апа, менә икмәк тотып ант итәм, бер дә өрәк-әрвахка охшамаган иде ул, чып-чын кеше кебек иде... Билләһи газыйм дип әйтәм!"

Шушы сүз Саниянең күңеленә корт булып урнашты. Бәлки?.. Юк-юк, ничек исән булсын ди ул. Бер ел бит. Бер ел эчендә урманда кеше исән каламы? Бигрәкләр дә ышандырып, чын кеше күргән кебек сөйли тагын Зөфәре дә...

Ак бабай киңәше белән, күрше күләнне дәшеп, "өрәкне бәхилләү жыены" жыйгач та Саниянең күңеленнән теге "корт" китмәде. Бәлки исәндер? Берәр каян кайтып килешедер?

Картлар, ишегалдында тезелешеп, дога кылып утырганда да Сания Алла сүзе пышылдамады, улының исән булуын теләп, исән булса, үз нигезенә тизрәк кайтуын теләп, эченнән генә өзгәләнеп утырды...

Күңел ай-һай серле дөнья бит ул. Ул бер ым бирсә, шул раска килә дә куя. Шушы ымны гына вакытында тоеп, сизеп калырга кирәк. Тик торганда гына күңелнең бер үзәк тамыры тартылып куя, йөрәкне авырттырып ала, ан-зиһен исә сынын турайтып, калкытып жибәрә; нинди бер илаһи халәткә юлыгып, кеше барысын да ап-ачык итеп күрә, күрмәсә, тоя, тоймаса, юрый башлый. Бу юлы Сания белән нәкъ шулай булды да. Ул берданбер улының исән-имин булуына бик үк ышанып житми иде. Әмма бу хакта төгәл белә иде инде. Тик әлеге белү-инануына зиһене генә барып ирешмәгән, нинди бер уй томаны аның аңын томалабрак тора кебек...

Икенче әтәч тә, өченче әтәч тә кычкырды. Сания, белгән догаларын укып, Хәлимнең түшәген өстән берничә мәртәбә сыпырып алгандай итте. Мәймүнә карчык шулай куша. "Сихер кайтару" дип атый ул бу ишарәләрне. Ягъни, төне буе кеше тирәсенә жыелган жен-пәриләрне куу йоласы була бу. Икенче, өченче әтәчләрдән соң төн рухларының көче бетә икән бетүен. Әмма, Аллаһы тәгалә сакланганны гына саклар, диләр бит. Әтәч тавышы яңгыраугa, өй-кураны ташлап киткән бу зәхмәт иярәләренең канат-каурыйлары төшеп калучан, имеш. Ал, кызгылт төстәге бу канатлар кешегә чир, үлем китерәләр икән.

Сания, шул хакта исенә төшереп, Хәлимнең баш очын тагын бер сыпырып куйды. Шуннан соң гына тынычланып, өстенә мал карарга кия торган халатын салды да чыгып китте.

Хәлим боларның берсен дә күрмәде. Хәтта, сизмәде дә. Ул бер ел

йокламаган татлы йокысын йоклый, бер ел күрмәгән бәхетле төшләрен күреп ята. Гаҗәп хәлләр: тәрәзәнең пәрдә белән капланмаган өске өлгеләреннән сузылып килеп кергән беренче кояш нурлары аның ярым ачык күк-зәңгәр күзләренә килеп кагылдылар да, икеләтә, өчләтә көчәеп, өй эчендә ниндидер сихри, илаһи бер балкыш барлыкка китерделәр. Берничә нур, Хәлимнең күзләрендә чагылып, стенадагы фотосурәтләр рамына барып сыенды, аңдагы кеше сурәтләрен аерымачык күрерлек итте. Бигрәк тә бер сурәт җем-җем килеп тора башлады. Хәлим йокы аралаш күзләрен ачты. Ул әтисенең бердән-бер, һәм югалырына бер ай кала төшкән фотосын шунда ук танып алды. Урман юлында, сабан туеннан кайтып барганда төшкән. Әнә ничек елмаеп тора ул. Бәхетнең югары катында диярсең. Аны анларга була: әле кичә генә Саниясе балага узды, бала көтүе хакында әйтеп сөендергән иде. Баласы булачак бит аның! Малае! Шул шатлыктан бераз төшереп тә алган, ахрысы. Аннан арттарак, урман читендәрәк ниндидер ике шәүлә тора. Сәер, баштанаяк карадан киенгәннәр. Ниндидер чит-ят карчыклар. Әллә? Теге таныш карчыклармы болар?

Шунда Хәлимнең күзләрендә чагылып, фотосурәтләрдә балкып торган кояш нуры, кырт сынып киткәндәй булды да, җилдә сүнгән лампа яктысы кебек, тынлык тарафыннан тәмам йотылып бетте. Өй эче караңгыланып калгандай булды, анасының йомшак түшәгендә изрәп йоклап яткан Хәлимнең ирен читенә кунган елмаю да юл тузанына каткан сакал араларына төшеп юкка чыкты...

## VI

Мунча өлгерүгә, Сания, өйгә кереп, Хәлимгә дәште. Вакыт төшлеккә җитеп килә иде инде. Чиллә үзенекен итә: кояш астында озак йөрергә иркенлек бирми, бөтен кош-кортны, бозаубәрәннәрне шундук куләгәгә куып кертә.

Өй ишекләре шар ачык. Тәрәзәләр дә кысып ачып куелган. Ап-ак пәрдәләр, күбәләк канаты кебек, җил унаеннан җилфер-җилфер килеп торалар. Шул пәрдә арасыннан кысыла-кысыла үткән җил түр түшәктә яткан Хәлимнең житү чәчләренә, сакал-мыекларына килеп урала, аннары, шул тозактан чыга алмыйча шактый тарткалаша, тыпырчына... Ниһаять, ул ычкынып китә һәм шул шәпкә ишек катындагы чаршау итәгенә барып бәрелә. Соныннан, бу өйдә рәт булмасын аңлап, бәласеннән башаяк дигән кебек, ишек яңакларына бәрелә-сугыла, ишегалдына чыгып чаба...

Очраклы гына килеп кергән җил малае Хәлимнең уянуына сәбәпче булды да. Хәлим инде уянган, әмма әле күзен ачмаган. Бик ачар иде дә, куркыта шул: күзләрен ачса, бу илаһи халәт кинәт юкка чыгар да, ул кабат ниндидер афәткә юлыгыр кебек. Шул ярымтерек хәлдә кичәге дулкынландыргыч мизгелләргә әйләнеп кайта, булган хәлләрне башыннан кичереп ята Хәлим. Районга бару, басу чите, әбиләр, Зөфәр, ишегалдындагы халык, әнкәсенең җылы түшәге... Барысы да ап-ачык. Әмма... берни дә ачык түгел. Бер еллык гомер ачык түгел. Бер көн түгел бит ул, бер ел!

Хәлим бөтенләй аңсыз түгел лә. Бик яхшы төшенә: ниндидер сихергә тарыган ул. Бу афәтнең теге ике карчык белән бәйләнгән булуын да чамалый. Кемнәр соң алар? Нинди серле, сихерле затлар? Ә! Теге чакта клубка чыкканда очраган ике карчыкка да бик охшаганнар бит алар! Шулар түгелме? Барыбер ачыклаячак моны Хәлим! Үз аңына кайтачак әле ул, хәтерен яңартачак!

...Тыштан чиләкләрен шылтырата-шылтырата әнкәсе кереп ята иде. Керә-керешкә үк ул Хәлимгә дәште:

—Улы-ы-м, улым дим, торасыңмы инде, мунчаны ябып кайттым, бераздан әзер була. Йә, тор инде, тор, әйдә, юын, ашап ал, озакламый кеше килә башлар... Ак бабаң көтү куганда ук кермәкче иде дә, тыйдым әле. Йөрмәгез әле, мәйтәм, малаемны үзем дә күреп туйганым юк,

мәйтәм. Ике ел әрмиядә йөрде, кайткач тагын бер елга китеп югалды, үзем карыйм әле башта, мәйтәм... Төштән соң керә башларлар, насыйп итсә. Бик тә сорашасылары килә үзеңнән. Кайда булуың хакында сорашасылары килә...

Сания сөйләнә-сөйләнә түргә узды. Улы янына килеп утырды. Салкын суда озак торудан күшеккән кулларын Хәлимнең мангаена, яңакларына куеп карады.

—Менә бит, әйбәтләнгәнсең. Әйдә, балакаем, тор инде. Мунчага бар, юын, кырын, тырнакларыңны кис, бу бабай сакалларыңны төбе-тамыры белән йолкып ат. Әйдә, кешеләр килә башлар. Би-и-к тә беләселәре килә...

—Әнкәй,—дип башлады сүзен Хәлим. Сак кына күзләрен ачты, тирә-ягына каранды.—Хакмы бу? Мин өйдәме? Исәнме мин?..

—Исән-исән, балам...

—Исән лә ул, тик мин бер нәрсә дә белмим бит, әнкәй. Берни белмим...—Аның соңгы сүзләре калтыранып чыкты.

—Юкны сөйләмә, балам, ничек инде белмисен ди? Бер ел йөреп, берни дә хәтерләмисенме? Ай Аллам, менә нинди бәлаләр төште башыбызга...

—Ике әби карчыктан башка беркемне дә күрмәдем. Менә кичә кебек... Хәл алырга гына утырган идем бит...

Кинәт Саниягә әллә нәрсә булды. Ул учлары белән авызын каплап, караватка утырды.

—Ике карчык дисеңме, улым? Ай, хараплар гына булдык ласа... Шул, шул карчыклар инде. Сине бала чакта да урлый язганнар иде. Әнкәем!.. Бәй, теге вакытта, мин бала тапканда да ике кара хатын булышкан иде... Ай, Аллам, шулар гына харап итте микәнни сине, балам? Алар бит ел саен эссе чилләдә авыллар аша узалар. Син әрмиядән кайткан чорда да килгәннәр иде, хәтереңдәме... Чын сихерче диләр бит аларны. Бер тотырып карасалар, кеше соңгы тавышын үзе чыгарып бирә, ди, аларга... Шулар гына сихерләгәннәрдер димен шул. Атаңны да шулар харап иткәндер әле, мәрхүмкәемне. Кайларда гына рәнҗеп-сыкрап ятадыр инде аның сөякләре. И, Аллам, күрәселәребез булган икән. Нишләп безнең нәсел-нәсәпкә генә каныктылар икән соң бу җен карчыклары, шайтан коткылары...

—Әнкәй, ярый, тынычлан инде. Исән-сау булгач, кайтып кердем бит. Елама, борчылма. Менә дигән иттереп яшәп китәрбез әле.

—Ходай кушса, дип әйт, балам.

—Ходай кушса...

Ана белән бала, гәпләшеп, озак юандылар. Бераздан мунчасы исенә төшеп, Сания тыз-быз килә башлады. Өстәленә ризык-нигъмәтләрен иртән иртүк чыгарып тезгән иде ул. Капланган ашъяулыкны ачып ташлады да самавырын җылытырга куйды. Аннары үзалдына төрле догаларын укый-укый тышка чыгып китте.

Хәлимгә боларның барысы да кызык иде. Гаҗәеп хәл бит, әле кичә генә шушы өстәл артында утырып ашаган иде, әле кичә генә мунча кереп, өр-яңа киемнәрен киеп алган иде, әле кичә генә... Баксаң, бер ел үткән дә киткән. Әле һаман да ышанасы килми, билләһи.

Хәлим торып утырды. Әнкәсе тышкы киемнәрен салдырган икән. Кылкаланып беткән эчке ыштанга карарлык та түгел. Ул ишек төбендәрәк урнашкан кием шкафына юнәлде. Бөтенесе дә үз урынында! Кичәге кебек! Бөтенесе чиста, пөхтә, күзнең явын алып тора.

Хәлим үзенә кирәк киемнәрне сайлап куйды, юынгыч шүрлегендә яткан көзге-пәкеләрен җайлап кына сөлгегә төрде, аннары, өстәлдәге ризыкларга карап, тукталып калды. Әнисе әзерләгән бу ашларга чистарынмаган, сихер-зәхмәтләрдән арынмаган килеш кагыласы килмәде аның.

Тыштан: "Хәлим улым, чык, мунчаны юып чыгардым, миллекне пешердем, чык..."—дигән тавышы ишетелде. Шуны гына көткән Хәлим, дәррәү кузгалып, ишегалдына чыкты, әле кичә генә аның рухына Коръән

чыгылган чирәмлек аша үтеп, пар бөркеп торган мунчага кереп чумды.

Төшке ашны бергә ашадылар. Юынып, кырынып алган Хәлимне танырлык түгел иде. Сания улына сокланып бетә алмады. Күзенә генә карап торды. Халыкта болай текәлеп карауччыга "Күзенә керердәй булып карый" диләр. Яратып, сөеп, үтә дә үз итеп, газиз итеп каравы иде Саниянең. Ул әле дә булса айнып җитә алмый. Нинди бәхеткә тарганын белә белүен, әмма бу шатлык-сөенечен аң-зиһене аша үткәреп бетерә алмый иде әле.

Саниянең сөйләшер сүзләре күп җыелган икән. Улына авыз ачарга да ирек бирмичә, сөйләде дә сөйләде. Хәлим күбрәк тыңлап торды. Нәрсә сөйләсен инде ул?! Ул бит кичә генә чыгып киткән кеше. Сания исә түкми-чәчми авыл хәлләрен сөйләде, кемнәр үлгән, кемнәр туган, кем йорт салган, кем читкә киткән, кем кияүгә чыккан, өйләнгән—берсе дә калмады. Шулай тәтелдәп сөйләгән җиреннән нәрсәдер исенә төшеп, кинәт туктап калды ул. Авыр сулап алды да теләр-теләмәс кенә әйтеп куйды:

—Сине әрмиядән көтеп алган Нәфисә кияүгә чыкты бит, балам...

Хәлим, чәйни торган ризыгын йота алмыйча, күзле бүкән кебек катып калды. Кулындагы кашыгын шулкадәр каты кысты, беләкләрендәге кан тамырлары бүртеп, шартлар дәрәҗәгә житте.

Улының иң авырткан җиренә кагылуын чамалап алган ана ике арадагы кискенлекне йомшартырга керешге:

—Нишләсен инде, улым... Башта гел көтте. Минем белән бергә көтте. Сине көтеп, сөйләшә-сөйләшә кичләр, төннәр уздырдык... Мәетеңне алып кайтып күмгәч, иң беренче сорап килгән кешегә чыкты да китте...

Өстәл артында тагын тынлык урнашты. Сания тагын чыдамады. Ана кеше түземсезлеге белән, ул Хәлимгә карамый гына әйтеп куйды:

—Нәфисәне әйтәм... Бик ярата иде сине. Ишеткән, синең кайтуыңны кичә үк ишеткән. Көтү чыгарганда йөгереп килде дә, күкрәгемә капланып үксеп-үксеп елады... "Сания апа, Хәлим алса, бер көн тормыйм, хәзер чыгып китәм,—ди.—Иремнән бер уйламыйча китәм,—ди.—Алсын әле,—ди... Үзе үкереп елый...—Көтә идем мин аны, мәет таптылар бит,—ди...

Тагын тынлык. Дәшми-нитми генә чәй эчтеләр. Әмма Саниянең соңгы сүзе Хәлимнең колагына ныклап кереп калган иде инде. Тукта, нинди мәет ул? Хәлим исән булгач, кемне күмгәннәр соң авыл зиратына? Кайсы ананың газиз баласы ята салкын туфрак кочагында?

—Әнкәй, нинди мәет соң ул?—Сания сискәнеп китте. Күрәсең ул үзе дә шул мәет хакында уйланып утыргандыр. Хәлим кабатлап сорады:

—Каян, ничек таптыгыз сез аны? Таный алмадыгыз мыни?

—И-и, белсәң иде, улым... Кичәдән бирле җанымны кимерә инде ул мәет. Кемнеке булсын соң, берәр мәхлук бәндәнеке, качкынныкы яки берәр ерак җирдән килгән юлчыныкыдыр. Йөзе-бите танырлык булмаган, диделәр, күлмәкләрен карадым, нәкъ синеке иде, ә йөзенә карый алмадым... Хәлимнең йөз чыраена охшаган, диделәр дә, шуның белән эш бетте... Ашык-пошык күмеп тә куйдылар...

—Ну бит, һәр кешенең башкалардан аерылып торган җире була. Сөяк, кан, тире күзәнәге, тагын... чәче, мине...

—Нindидер врачлар да килде, кәгазьләр тутырдылар, миннән куллар куйдырттылар... Чак аягына басып торган хатынны көйләү-чөйләү әллә ни авыр булмагандыр шул. Аннары... эзли-эзли арып та беткән булганнардыр инде. Бөтен район милициясен, солдатларны аякка бастырдым бит мин. Этләр белән дә эзләп карадылар. Урман юлын аркылыга-буйга айкадылар...

Шул вакыт шыгырдап урам капкасы ачылды. Сания белән Хәлим дәррәү капка янындагы тәрәзә янына килделәр. Кирәргәме-юкмы дип икеләнделәр бугай—капка яртылаш ачылган килеш шактый торды әле. Бераздан капка арасыннан Ак бабайның башы килеп чыкты, аның артыннан күмәк хуҗалык рәисе Фәнил Рәхмәтуллин күренде. Келт итеп

Хәлимнең Фәнил Гыйниятовичка биргән вәгъдәсе исенә төште. Ул кичә... юк ла, былтыр җәй, МТМ дагы ватык комбайнны караштырып, ашлык сугарга төшәргә сүз биргән иде. Ә менә ничек килеп чыкты... Ничек итеп аның күзенә карар ул...

Кунаклар бик озак керделәр. Сания, әллә кире чыгып киттеләр инде, дип уйларга да өлгермәде, әчке өй ишеге ачылып китте, чолан карангылыгыннан Ак бабайның ап-ак кәҗә сакалы суырылып чыкты... Бераздан пеләшләнә башлаган башның кульяулыгы белән туктаусыз сыпыра-сыпыра Фәнил Гыйниятович килеп керде:

—Эһ-һе-һей, кеше куркытып йөргән картлач син булдыңмыни әле, ә? Зөфәр барыбызның да башын бутап куйды. Һи-и... Бөтенләй өлгереп, ир-егет булып кайткансың, димме... Бераз ябыккансың икән...

Шулай сөйләнә-сөйләнә башта Ак бабай килеп күреште. Аннары күмәк хуҗалык рәисе кулларын сузды. Карт һаман сөйләнүендә булды:

—Аллага шөкер, исән-сау кайткансың. Ананның күз яшьләре өчен килеп ирешкәндер сиңа Ходайның бу мәрхәмәтләре... Әмма бик зур шелтәм дә бар сиңа, олан. Еракка, күпкә китәсе булгач, әнкәңә генә булса да хәбәр итәргә кирәк иде. Монда дөньяның өсте аска килде... Җитмәсә, икенче бер Хода бәндәсенең салкын гәүдәсен синә дип әзерләнгән кабергә салдык... Ул нишләп, ничекләр генә түзеп ятадыр инде анда. Вупшем, әйтмичә китеп әйбәт эшләмәдең син, олан. Хет әнкәңне кызганырга иде...

Каушап калган Хәлимнең хәленә кереп, Сания сүзне үзенә алды:

—Һи-и, Сабир абзый. Бер ел кайда яшәгәнен үзе дә белми бит ул... Бер еллык гомеренең бер бөртек мизгелен дә хәтерләми... Ялгыштырганнар аны, бутаганнар, алай тиз генә ябышма әле син.

—Ничек инде—югалган?

—Менә шулай. Урман юлы буйлап кайтып килгәндә ике карчык зиһенен алган балакаемның. Шуннан берни дә белми...

—Әнкәй, ярар инде. Үзем дә сөйли алам бит...—әнкәсенең сүзен бүлеп, үртәлебрәк әйтеп куйды Хәлим.

—Да... хәлләр... А то без әллә нәрсәләр уйлап бетердек ,—дип сүзгә кушылды Фәнил Гыйниятович.—Нишләргә җыенасың соң? Иртәгә идарәгә кил. Сөйләшербез.

Хәлим һаман дәшмичә тора иде. Аны кыен хәлдән бу юлы да әнкәсе коткарды:

—Юк әле, юк, Фәнил балам. Җибәрмим әле мин аны колхоз эшенә. Чак аягында басып тора—күрмисеңмени. Бераз хәл алгач, тәненә ит кундыргач барыр. Ачуланма-нитмә, бераз өйдә торсын...

—Ярар, ярар, Сания апа, бер сүзем дә юк. Бер дә борчылмасын, эш булачак, диюем генә ...

Сүз сүзгә ябышмады. Моны Ак бабай да, Фәнил Гыйниятович та, Сания белән Хәлим дә бик яхшы беләләр иде. Шуңа күрә дә кунаклар озакламады. Ничек кергән булсалар, шулай ук тиз генә чыгып та киттеләр. Хәлимнең күңелендә авыр тойгы калды. Югыйсә бөтенесе дә тәртиптә бит... Тик элекке җан тынычлыгы каядыр юкка чыккан. Хәлим, хәтта, аерым минутларда, нигә кайттым икән мин монда, дип тә уйлап куя иде. Бер еллык тормышының гомер баскычыннан өзелеп төшүе, Нәфисәнең кияүгә чыгуы, аның исеме белән күмелгән мәет, ике сихерче карчыкның авылда йөрүе—боларның барысы да Хәлимнең күңелендә кабат кабынып киткән өмет, сөенеч, хыял, яшәү утын өреп сүндерергә маташалар иде...

## VII

Кичен Хәлим абзар артындагы утыргычка чыгып утырды. Аларның йорты калкулыккарак урнашкан. Шуңа күрә бөтен авыл аерымачык булып күренеп тора.

Хәлим кичке авыл утларына карап озак утырды. Көтү инде күптән

кайткан. Шуна күрә авыл урамнарында җанлылык сизелми диярлек. Уйларны барларга, хис-тойгыларны чарларга, фикерне бер ноктага тупларга иң кулай вакыт бу. Ә бит уйлап баксаң, уйланырга уйлар бар икән. Юк әле, соңгы сәер хәлләр хакында гына уйламый Хәлим. Анысы хакында уйлап бетерергә гомер дә җитмәс, мөгаен. Гомумән, Хәлимнең үз гомерендә бер генә тапкыр да тормыш хакында, яшәү гаме, котылгысыз язмыш, үткән һәм киләчәк хакында, тукталып, үз күңеле белән бергә-бер калып, уйланып торганы булмаган икән.

Менә бүген шундый уңайлы чак. Беркем дә борчымый. Бер бөртек мәшәкать калмаган. Хәтта... хәтта кечкенәдән үк күңеленә кереп, бертуктаусыз рәхәт борчып, җан-бәгырен иркәләп тә, телгәләп тә торган мәхәббәте—Нәфисә дә юк инде... Ул үзе дә юк. Юк. Бетте-китте... Аны инде күмеп куйганнар. Иртәгә эшкә барасы юк, кич сөйгән яры белән очрашырга чыгасы юк...

Хәлим ындыр артында аунап яткан каен агачлары өстенә менеп кунаклады. Өч тау, дөресрәге, дүрт тау арасында урнашкан авылга күз салды. Бер дә болай утырганы булмаган икән шул аның. Әнә нинди матур урынга урнашкан Кампәрле авылы. Дүрт уйсулык тоташкан урынга, кечкенә үзәнлеккә генә сыеп бетә алмыйча, кайбер йортлар, чат булып, янәшәдәге тау битләренә үк менеп киткәннәр. Аларның кайберләре тау башларында шаулап утыручы мәһабәт чыршы-нарат урманнарының янына ук килеп тез чүккән. Хәлимгә авылның ике очы гына күренә. Өченче очы күренми. Дүртенче очның иң соңгы йорты—аларныкы. Әнә, ындыр тыкырыгыннан борылу белән, ферма йортларын узасың да урман авызына кереп китәсең... Кечкенәдән калган тойгы (Хәлимнең күп мәртәбәләр күзәткәне бар): авылдан чыгып киткән кешеләрне бу кара урман шомлы, ерткыч авызы белән кабып йотар кебек иде...

Кампәрле авылы хакында әллә ниләр сөйлиләр. Сөйләрлек тә шул. Тайга урманының иң ерак эченә кергән авыл ул. Аннан да ерак авыл юктыр. Юньле-башлы юл да юк. Бердәнбер юл кирегә—Кампәрледән кырык биш чакрым ераклыкта урнашкан район үзәгенә алып чыга. Бу юл буена тезелеп утырган авылларның күбесе—мари авыллары. Аларның Кампәрлегә иң якыны—унбиш чакрымда.

Кара урман йоткан бу татар авылының тарихы хакында Хәлимнең күптөрле мәзәк, гыйбрәтле риваятьләр ишеткәне бар. Иң хәтердә калганы—сихерчеләр хакындагысы.

Имеш, хәзерге Кампәрле авылы урынында, тайга үзәгендәге бер кечкенә үзәнлектә, сихерче карчыклар гаиләсе яшәгән. Бу урынны аучылар читләтеп узган, ә сихерчеләр үзләре кешеләргә зыян салмаганнар. Әмма начарлык кылырга тырышкан бәндәләргә бик мәрхәмәтсез булганнар. Бер ырым белән кешеләрнең һушларын алганнар, кул-аякларын буынсыз, хәлсез иткәннәр. Иң хәтәре—аларны аңсыз, хәтерсез калдырган-нар...

Тукта-тукта, Хәлим белән булган хәл бит бу! Аңсыз, хәтерсез, һушсыз... Әллә? Әллә шул сихерчеләр килеп чыкканмы? Нишләп инде? Авыл кайда да, теге сихерче карчыклар кайда! Ә бит бабасы кайчакта сөйли торган иде. "Авылга безнең нәсел нигез салды",—дип әйтә иде. Аюлар нәселе! Әйе. Хәлимнең бик борынгы бабалары көч-гайрәтләре белән аюдан ким булмаганнар. Беләк юанлыгындагы агач-куакларны җирдән суырып чыгарып, ун адым читкә ыргыта алганнар.

Авылның тарихында фаҗигале хәлләр еш булып торган. Бу тирәдә яшәп яткан сихерчеләрнең тынычлыгын бәхет һәм әйбәт җир-урын эзләп килеп чыккан берничә татар гаиләсе боза. Татарлар башта, берничә йорт салып, әлеге сихерчеләр янәшәсенә урнашалар. Алар һәртөрле авыруны, күңелсезлекне шул сихерчеләрдән күрә башлыйлар. Ике арада ызгыш-талаш чыга. Бер гаиләгә икенчесе, өченчесе өстәлеп, шактый ишәйгән авыл сихерчеләргә каршы чын-чынлап көрәш ача. Ниһаять, аларны куып җибәрәләр, ә гаилә башлыкларын, тотып алып, агачка бәйлиләр дә ут төртәләр.

Ин гажәбе шунда ки, сонынннан тирә-якта Кампәрле авылы кешеләренен үзләрен дә "сихерчеләр" дип атап йөртә башлыйлар. Кампәрле атамасы да шуннан килә—Кам-пәриле, ягъни сихерче-пәриле... Ә бит иң беренче кешеләр авылны Чуриле дип атамакчы булганнар. Әмма бу исем авылга ябышып калмаган.

Хәлим, әлбәттә, аңлый. Аның үз гомер тарихында да ниндидер сихер катнашкан. Тик нинди сихер, нинди зәхмәт аның язмышы белән шаяртмакчы булган соң? Бу хакта ул әлегә белми. Кайчандыр ерак бабалары эшләгән хилаф эшләре өчен урманга качкан сихерчеләрнең үч алуымы? Алар бик озак—берничә йөз ел да яши алалар, ди бит. Сихерчеләрнең балалары, оныклары да исән булырга мөмкин...

...Уйлый-уйлый Хәлимнең баш тубалы шартлар дәрәҗәгә житте. Аның зиһененнән "Бу сихер белән бөтенләй акылдан шашмасам ярар иде" дигән уй йөгереп үтте. Әйе, ана бу хакта күп уйларга ярамый. Бу галәмәтләргә барыбер акыл ирешерлек түгел. Бөтен булганны-күргәнне калдырып, тормышка кайтырга, жиргә төшәргә, бөтен шик– шөбһәләрне оныттырырлык берәр хезмәткә керешергә кирәк! Иртәгә үк идарәгә барып, иң авыр эшне сорап алачак Хәлим. Тормышны жайларга күптән вакыт инде. Өйне яңартырга, абзар-кураны рәтләргә, малны ишәйтергә, өйләнеп жибәрергә...

"Нәфисә! Их, Нәфисә... Бер ел да көтмәгәнсең бит... Мәет дип инде... Күңелең, жан-бәгырең сизмәдемени соң? Ә нинди вәгъдә-антлар бирешкән идек! Туйлар, алдагы тормышлыр хакында да сөйләшә башлаган идек бит..."

Уйлаган әйберең алдыңа килер, дигәннәр бит. Хәлим Нәфисә хакындагы уйларын төйнәп тә бетерә алмады, ихата ягыннан үтә дә таныш, газиз тавыш ишетелде:

—Сания апа, Хәлимне күрергә буламы?

Хәлим бу тавышны мең, миллион тавыш арасыннан танып алыр иде! Жанны эретеп жибәрә торган, йөрәкне төпсез чоңгылга ата торган сихри тавыш иде бу.

—И-и, Нәфисә икән әле... Белмим шул. Ярый микән соң... Син бит ир хатыны. Иртә белән әйттем бит инде, кермә дидем...

—Беләм дә соң, күз чите белән генә карыйм әле үзенә. Әллә ул түгелдер?.. Күмдек бит без аны кара жир куенына, Сания апа. Үзем күрдем бит... Ләхеттә ята иде... Менә шушы учларым белән балчык эшереп күмдем... Хәлим түгелдер ул!..

—Әстәгъфирулла... Тәүбә диген, Нәфисә кызым... Нишләп мин үз улымны танымыйча торыйм ди... Бөтен жире дә үзенеке. Түшәккә салганда да бөтен тән жирен карап чыктым. Күзләре дә күм-күк... Миңе дә нәкъ үз урынында...

—Ачуланма, Сания апа, аптыраганнан әйтәм инде. Бик яратам бит мин аны, оныта алмыйм... Төшләремдә күрәм. Кочагын жәеп килә. Көлә-көлә килә. Инде кочаклаштык дигәндә генә аюга әверелә дә куя...

—Абау, бигрәк сәер төшләр күрәсең икән син, Нәфисә кызым. Мәймүнә әбиенә барып, өшкертеп карамыйсыңмы соң?

—Өшкерә алса, Хәлимгә булган сөюемне алдырыр идем мин, Сания апакаем. Жәзаланам бит. Ирем дә сизенә бугай инде. Шулай да, барып карадым. Мәймүнә әби дә берни эшләтә алмады. Йөрәккә, жан-бәгырьгә кагыла алмыйм, дивана итәрмен дип куркам, ди...

—Шулай шул, йөрәккә кагылма, өрәк итәрсең, дигәннәр бит борынгылар.

Тынлык. Хәлим ышыккарак керде, посып тыңлавын дәвам итте.

—Әле кайда соң ул, Сания апа?

—Белмим шул, кызым. Йөри инде шунда. Башына жинеллек килмәсен дип куркам. Үзенең бер ел югалып йөрүенә һаман ышанып житә алмый, бәгърем минем...

—Бик үзгәргәнме, Сания апа?

—И-и, Нәфисә кызым, бик күрәсең киләмени соң? Өзгәләнүеңә аптырап әйтәм. Гөнаһысына кереп булса да әйтим инде—ындыр ягында, бакча тирәсендә йөри ул. Бар, тиз генә кереп күрешеп чык. Озак торма, кеше-мазар күрсә, язгы миңа була, белеп тор. Бар, кызым, син аны барыбер бер күрергә тиешсең. Юкса сезнең икегезгә дә тормыш булмаячак... Аннары... бик үтенеп сорыйм: күңелен җилкендермә. Сезнең арада буласы булган инде. Синең үз тормышың, аның үз язмышы, шуңа күрә күңелен авырттырып, өметләндереп йөрмә...

—Юк, юк, Сания апа...

—Бар, тиз бул... Мин кире уйлаганчы...

—Рәхмәт, Сания апа... Мәңге онытмам бу яхшылыгыңны...

Ындыр якка чыга торган капканың киләсе күтәрелүгә, Хәлим утынга кайтартылган бүрәнә өеме артына чүгәләде...

Нәфисә түргә узды. Бакчаның әле бер башына, әле икенче башына йөгерде, койма аша үрелеп, күрше бакчаларны, үр куенында челтерәп яткан чишмә буйларын карады.

—Хәлим! Хәлим!..

Нәфисә, бер тын йотылып тынлап торды да Хәлим качып торган бүрәнәләр янына килде. Йөрәге нидер сизенә иде аның. Хәлимнең янда, якында булуын ул тоеп белә ахры, әмма күзләре томана сукыр иде шул.

Нәфисәгә шунда әллә нәрсә булды. Ул утын өеменә якын ук килде дә, күзләрне камаштырырлык ак төстәге каен агачын сыйпап, үзалдына:

—Хәлим, Хәлимкәем!.. Кайда соң син?—дип үрсәләнеп эндәште. Аннары йөзен куллары белән каплап, кычкырып елап җибәрде. Терсәкләренә капланып, сулкылдап басып торган Нәфисәнең калтыранган тәнен Хәлим телсез-аңсыз калып карап торды. Ул бу минутта сулу алудан да туктап калды, ахры. Йөрәге, күкрәгеннән калкынып, дөп-дөп итеп, бүрәнәгә бәрелеп тибә кебек... Нәфисә өзгәләнде:

—Хәлим... Агачка әверелдеңме әллә син?

Үзенең моннан соңгы тәртибен Хәлим берничек тә аңлый да, анлата да алмас иде. Төштәге кебек кенә. Менә ул каен әрдәнәләре артында багана кебек катып торган җиреннән чыкты да чарасызлыктан нишләргә белмәгән Нәфисә янына килде. Куллары белән сак кына аның иңбашларына кагылды. Үксеп-үксеп сулкылдаган Нәфисә Хәлимнең кулларын башта тоймады. Әмма, тоеп алгач, сискәнеп читкә тайпылмакчы булды. Хәлим аны көчле куллары белән кочып алды, бер мыскал читкә тайпылырга да ирек бирмәде.

—Нәфисә!..

—Ә?! Хәлим?

—Әйе, бу мин, Нәфисә. Юк, белмим, белмим... Бәлки, минем өрәк кенәдер...

—Ай Хәлим! Син бу, син! Юкны сөйләмә! Мин синең кулны әйбәт беләм. Көчле, куәтле, шул ук вакытта йомшак-назлы куллар...

—Нәфисә...

—Дәшмә, Хәлим, беләм мин синең нәрсә хакында сорасыңны... Әйе, мин кияүдә, сине югалтуга, ялгызлыгыма, сагынуыма, кара кайгыма түзә алмыйча чыктым, Хәлим...

—Мин барысын да беләм, Нәфисә, тынлап тордым...

—Син кая югалдың, Хәлим?

—Белмим, Нәфисә, белсәм иде ул!

—Алай булмый, Хәлим?

—Була икән шул...

—Кемнең бәддогасы төште икән соң безгә, йа Ходай?

—Ходайныкы да, Иблиснеке дә түгел, ике албасты карчыгының сихеренә эләктем мин, Нәфисә. Менә, гомерем бетмәгән булгач, тагын сезгә кайттым...

Хәлим Нәфисәне үз итеп, бөтен назын, җылысын биреп кочаклады, аның башын үз күкрәгенә салды. Нәфисәгә бу гына аз тоелды, ул

ялкынлы сулышы, утлы иреннәре белән Хәлимнең иреннәренә үрелде... Хәлим ана каршы омтылды, әмма, өзелеп сагынган, сөю ләззәтенә сусаган иреннәр бер-берсенә кушылды дигәндә генә, башын читкә борып, Нәфисәнең дерелдәвек тәнен читкә этәрде:

—Юк, Нәфисә, син хәзер башка кеше хатыны. Кирәкми, күнелләрне ымсындырмыйк, жанны талкымыйк...

—Нигә мине читкә этәсең, Хәлим, нигә рәнжетәсең?..

—Безнең язмышлар аерылган, Нәфисә. Күзенне ач—тормыш бу, ачы хакыйкать бу... Тик белеп кенә бетермим әлегә... Үзең әйтмешли: нәрсә булды соң? Ходай каргадымы, әллә Иблис шаярттымы?

—Их, Хәлим... Хәлимкәем минем... Мин бит сине һаман өзелеп-өзелеп яратам. Синең белән ятам, синең белән торам, син дип яшим, син дип үләчәкмен дә...

—Үлмә әле,Нәфисә, яшә. Матур-матур балалар үстерерсез...

—Бала дисең син, Хәлим!.. Юньләп йоклаганым да юк бит ирем белән... Сине сагынам мин. Башка тәнгә орынасым да килми. Чирканам...

Кинәт Нәфисәнең аң-зиһенен бер уй сызып үтте. Ул сикереп торды да Хәлимнең башын, назлап, ике учына куйды.

—Хәлим... Минем синнән бала табасым килә! Синең баланы үстерәсем килә! Әйдә, йоклыйк әле, сөешә-сөешә, яратыша-яратыша бер йоклыйк әле!..

—Нәрсә сөйлисең син, Нәфисә?!

—Мин сине назга күмәчәкмен, Хәлим. Бөтен жан, тән күзәнәкләреңне үбеп чыгачакмын... Ахырдан бер матур малай табып бирәчәкмен. Хәлим, ишетәсеңме, минем бала табасым килә!.. Синең баланы табасым килә...

Нәфисә кинәт жиргә тезләнде, Хәлимнең аякларын кочаклап алды, үрсәләнеп-ялварып анардан бала сорый башлады...

Хәлим каушап калды. Кичәге көннән бирле мингерәүләнеп торган башы тәмам акылдан шашар дәрәжәгә житте...

Ул шулай аптырап карап торган арада ихата ягыннан әнкәсе килеп чыкты да, Хәлимнең аякларын кочаклап елап яткан Нәфисәне торгызып, балаларча үгетли-үгетли ишегалдына алып чыгып китте.

—И-и, балакаем. Бетеренмә ул кадәр. Кеше көлдереп тавышланып йөрмә... Бар, кайт, ирең көтәдер. Башка килеп йөрмә, яме. Нишләтәсең инде, Ходай тәгаләгә шулай кирәк булгандыр...

Әнкәсе Нәфисәне алып чыгып киткәч тә Хәлим бераз вакыт һушын жыя алмыйча торды. Нәфисәдән аерылуга анын күнелендә, күнелендә генә түгел, бөтен тормышында бик мөһим бер кыл шартлап өзелгәндәй булды.

## VIII

Хәлим тормышка авыр кайтты. Үткәндәге гомеренең һәр шаһиты белән очрашу күнелен тетрәндереп куя, жан-бәгыренә көтелмәгән жәрәхәтләр сала иде. Читтә йөреп кайту гына түгел шул, үлеп, күмелеп, кабат якты дөньяга туып кайту белән бер анын бу язмышы. Иң аянычлысы шул: ул үзенең бер еллык гомере хакында берни дә белми. Бер бөртек хатирә, бер мизгел гомер, гөлт итеп кенә булса да кабынып алган берәр күренеш, мажара булсын иде дә бит...

Баштарак Хәлимнең кайтуына сөенгән кебекләр иде. Өйләренә килеп хәлен белүче авылдашларының исәбе-хисабы булмады. Кайтканының икенче көнендә үк Ак бабай белән Васимә карчык бер түгел, мең кергәннәрдер...

Ак бабай, сиксән яшькә якынлашып килүенә карамастан, хужалыкта умартачы булып эшли. Авылның иң мөгътәбәр, хөрмәтле кешеләреннән. Берничә ел элек кенә тергезелгән мәчеттә имам булып та тора. Әмма карагруһ динче дә түгел ул. Һәр төрле дару үләннәре жыеп, аларны

киптереп, кайнатмалар эшләп, халыкны дәвалый, җае килгәндә өшкереп-төчкереп куярга да күп сорамый. Ялгызы яши. Кампәрленен икенче башында торучы кызы килеп, картнын өй-тирәсен, өс-башын караштырып китә. Вакыт булган саен Сания дә кереп йөри, үзләрендә камыр әйберләре пешкән көннәрдә, табынга утырыр алдыннан, Ак бабайга күчтәнәч кертеп, ризыкка фатиха алып чыга.

Бу юлы да, Хәлим кайту шатлыгыннан, Сания әллә күпме тәм-том пешереп куйган. Хәлим сынап торды: менә хәзер әнисе табында өелеп торган кабартма-бәлешләрнен иң матурларын гына сайлап алачак та, ап-ак сөлгегә төреп, күршедәге Ак бабайга йөгерәчәк...

Әмма бүген Хәлим ялгышты. Әнисе беркая да чыгып йөгермәде. Стенадагы сәгатькә күз сала-сала табын хәзерли башлады.

Өй буенча тыз-быз йөрүче әнкәсенә карап бер куанды, бер борчылды Хәлим. Куанды, сөенде, чөнки әнкәсенең кызлар кебек өлгерлеге, житезлеге, унганлыгы бөтен өйгә ниндидер сихри бер дәрт һәм көрлек йоктырып тора иде. Әмма бу тышкы тәэсир генә. Улынын кайту шатлыгыннан гына шулай очынып, юк, очып йөри ул. Чынлыкта исә анын күнел түрендәге, җан-бәгырендәге сагышын үлчәп тә, аңлап та бетерү мөмкин түгелдер. Яшьтән үк ирен югалтып, гомер буе авылдашларынын битәрен ашап яшәгән бу хатынга Ходай тәгалә тагын бер сынау җибәргән—улын тартып алган, ул гына да түгел, аны кабат кайтарып, күнелен тагын мен-миллион кисәкләргә телгәләгән... Ничек кенә куанса да, ничек кенә бәхетенә сөенсә дә, йөзендәге тирән җыерчыклар, күп еллар сөременнән эчкә баткан, кара бөҗра эчендә калган монсу күзләр, агарып битә язган кыл чәчләр—барысы да Саниянең гадәти Җир кешесе булмыйча, Күк тарафыннан сынау өчен җибәрелгән Хода бәндәсе булуы хакында сөйлиләр иде.

Ниһаять, табын әзерләнеп бетте. Ишек артында гына көтеп торган кебек, кинәт тупсада Ак бабай пәйда булды. Әһә! Менә кем өчен әзерләнә икән бу кунак табыны!

—Әссәламәгаләйкем, балакайлар, исәннәрмесез-саулармысез...

—Исәнме-саумы, Ак бабай.

—Ничек, күнегеп беттегезме әле бер-берегезгә?

—Күнегеп дип... Без бит чит кешеләр түгел, Ак бабай. Безгә күнегәсе дә, нитәсе дә юк...

—Алай димә, Сания кызым. Бер атна читтә йөргән кешегә дә кабат күнегәсен ул. Кайчакта бер көн дә кешене үзгәртеп куя...

—Ә миңа бөтенләй дә күнегәсе юк, киткәнемә дә ике генә көн бит әле,—дип шаяртмакчы булды Хәлим. Әмма шаяртуы барып чыкмады, Ак бабай белән әнкәсе бер-берсенә карашып алдылар да, Хәлимнен сүзен бөтенләй дә ишетмәгән кебек, әнгәмәне дәвам иттеләр.

—Менә, кызым, сезгә өр-яңа бал. Бүген иртән генә аертып алдым. Җып-җылы килеш. Мә, табынына куй, сыйла улынны. Яна бал җанга китә, ди ул...

—Ай-й, рәхмәтләр генә яусын үзенә, Ак бабакай... Иртәннән үк иреннәремә тәм төшкән иде. Балга булган икән...

Хәлим шуны искәрде: әнкәсе өстәлгә ике генә чынаяк куйды, димәк, табынны ике кеше өчен генә әзерли... Моны ул Ак бабай белән икесе арасында булачак җитди сүзгә юрады. "Ниндидер заговор коралар болар",—дип уйлады Хәлим, малайларча фикер йөртеп.

Сания күп көттермәде, ниндидер сәбәпләр табып, чыгу ягына юнәлде.

—Хәлим улым, бабана чәй ясарсын, яме. Әйдә, бер гәпләшеп утырыгыз әле... Гомергә бер ярый ул. Үзем дә озакламам...

Хәлимнен Ак бабай белән күп мәртәбәләр бергә-бер сөйләшеп утырганы бар барын. Әмма бүген бөтенләй башка очрак. Ниндидер унайсызлык сизде Хәлим. Күнеле тыныч түгел иде анын. Йөрәк җилкенүе диләр моны. Шуңа күрә дә, әнкәсе чыгып китү белән, гаепле кеше

сыман, өстәл артына бөрешебрәк утырды да тынып калды.

Ак бабай Сания ясап киткән чәйне мактый-мактый сүз башлады.

—Һай, бигрәкләр дә тәмле итеп пешерә инде чәйне Сания. Мәрхүмә карчыгым чәенен тәмнәре бар анын чәендә.

Хәлим дәшмәде.

—Әйдә, олан, балыннан житеш. Быел бал күп булыр, мөгаен. Чәчәк күп, урман әйбәт...

Хәлим һаман дәшмичә утыра бирде.

—Безнен тормыш урманнан тора шул. Ул бирсә—яшибез, бирмәсә—иза чигәбез...

—Әйе шул...

—Урман дигәннән, Хәлим олан, ул сине дә шактый изалаган, ахры... Әнә бит—как сөяккә калгансын.

Хәлим сүзнен кирәкле эзгә төшеп барганын сизде. Димәк, Ак бабай Хәлимнен үткәннәрен ачыклау өчен, һич югы, бу хакта күнел кылларын тарткалап карау өчен юлланган. Әлегә ул ачылып китмәскә булды. Ак бабайнын үз сүзе.

—Хәлим олан, киемнәренә, йөз-чыраена караганда, бу елда син урманда гомер сөргәнсен. Ничегрәк булды сон ул? Кайда, кем белән яшәден, диюем...

—Их, Ак бабай, белсәм иде мин...

—Алай булмый ул, олан. Күз, караш, тән, тәненнен күзәнәкләре ни дә булса ятлап алып кала. Син бит үз акылындагы кеше, күзен күрә, колагын ишетә, тәнен-жанын сырхау түгел...

—Юк, Ак бабай, бу сүзне шушында башлыйк та шушы урында бетерик. Юл читендә ярты сәгать черем итеп кенә алдым, шуннан башка берни дә хәтерләмим. Уянып китсәм—дөнья кыяматкә әверелгән, кеше күзенә карарлык та түгел, билләһи!..

—Кызма, олан, кызма, әйдә, баштан ук сөйлә әле.

—Районнан кайтып киләм. Бер ачыклыкны сайлап, жәелеп утырдым, ашап алдым, аннары... Аннары каршы юлдан ике әби килеп чыкты...

—Ашыкма, олан, сабыр гына сөйлә: кемнәр иде алар, ничек киенгәннәр?

—Кап-карадан киенгән ике карчык. Таяклары, төенчекләре бар... Бик әйбәт сөйләштеләр...

—Берәр сәерлек сизмәденме?

—Әллә инде...

—Ни дә булса гажәпләндермәдеме сине бу вакытта?

—Юк, ахры... Ә! Алар чирәмгә бик сәер бер тамга сыздылар. Түгәрәк, анын уртасында аркылы-торкылы куелган таяклар... Үзәккә кагылган чөйдә—уенчык кеше сыны, курчак. Үзләре туктаусыз дога укыйлар. Жилдавыл чыкты, жир тетри башлады...

Хәлим үзе сөйли, үзе шул мажараны кабат күз алдына китерә. Күз алдына китереп кенә калмый, үткәненә кабат кайтып, сәер бер халәткә юлыга... Менә ул таганда атынган кебек, әле бер якка, әле икенче якка тайпылып хәрәкәтләнә башлый. Ана рәхәт. Нindидер салкын жил, сулыш алгандагы кебек, аны суырып ала да өскә алып менеп китә... Хәлим мәтәлә-мәтәлә күк катындагы ястык болытлар өстенә килеп төшә...

...Хәлим күзләрен ачканда Ак бабай аны түшәккә сузып салган, изүләрен бушатып азаплана иде. Үзе бертуктаусыз дога пышылдый.

Хәлим бик тиз айныды. Ана Ак бабай алдында бик тә унайсыз иде.

—Әллә нәрсә генә булды шунда, ачуланма инде, Ак бабай, яме. Әле һаман да буыннарымнын егәрлеге-көче юк...

—Буыннар дисен дә... Сине сихерләп, бозып жибәргәннәр, олан. Һушынны, ан-зиһененне, хәтеренне алганнар. Нәсел үчен кайтаручылар эше бу. Мин моны шундук анладым. Бик авыр сихер, бик әшәке зәхмәт бу... Белмим, аны кем генә жинә алыр икән?!

—Нигә, нәрсә өчен миңа шулай үчләнәләр соң, ә, Ак бабай? Минем бит беркемгә дә начарлык кылганым юк...

—Алай димә, олан. Кеше жиде буын бабасына кадәр бөтен хилафлыклар, гонаһлар өчен жавап бирергә тиеш.

—Миңа нишләргә соң хәзер, ә? Ничек яшәргә бу килеш? Мин бит бу якты дөньяда бар да, юк та...

—Бик алай ук бетеренмә, олан, берәр жае чыгар, Ходай теләсә... Кара әле, бая син ниндидер тамга-билге телгә алдың...

—Әйе-әйе, яшел чирәм өстенә ком чәчеп сызылган божра. Аның эчендә тәре рәвешендә салынган ике таяк. Уртада—чөй, чөйдә курчак, шул гына.

—Шул гына түгел шул. Бу бик шомлы фал, олан. —Ак бабайның тавышы калтыраныбрак чыкты.—Бу билге—бик борынгы дәверләрдә шушы урманда яшәгән сихерчеләр тамгасы...

—Ничек инде?

—И олан, бу бик ерак тарих. Менә син, кошка әверелеп, күккә очып менә алсаң, астагы жир дөньясына күз ташласаң, күрер идең: безнең авыл — нәкъ шул тамга рәвешендә утырган. Дүрт оч, дүрт урам... Авылны, билбау кебек, нарат-чыршы урманы чорнап-урап алган.

—Ә курчак?

—Курчагы хикмәтлерәк, күрәсең... Авылның нәкъ урта бер жирендә сер булырга тиеш. Курчак шуңа искәртә...

—Ак бабай, бу урын Нәфисәләр йорты каршында үсеп утыручы тупыл агачына туры килә бит...

—Шулай икән шул...

Бераз сөйләшмичә тордылар. Хәлим бу авыр хәлдән чыгу юлын бик тиз тапты:

—Ак бабай, әйт әле, зиратка күмелгән мәет белән нишләргә соң инде? Мин бит исән...

—Ул хакта уйларга да куркып торам. Бу бик житди эш. Аллаһы тәгаләне үчекләгән кебек була бит; кабердән мәетне кабат казып алу—мактана торган эш түгел... Афәт чакыру белән бер ул.

—Алмыйча булмыймы соң? Ятсын шунда тыныч кына...

—Булмый диләр шул. Ул да кемнеңдер газиз улыдыр. Эзлиләрдер. Менә сине эзләгән кебек... Авыл Советына хәбәр килгән инде: алдагы атнада казып алачаклар... Мескен... Үлгәч тә тынгылык таба алмый иза чигә, мәрхүмкәй...

—Беләсеңме, Ак бабай, кайчакта шул хакта уйлыйм: минем гүя жисми тәнем кабердә ята, ә жан-йөрәгем жир өстендә йөри... Менә хәзер синең белән минем өрәгем сөйләшеп утыра кебек...

—Юк, кирәкмәс, Хәлим олан. Алла исемен кушып тәүбә ит. Нинди өрәк инде син?! Өрәкнең тәне ал, күзе ут була бит. Син күбрәк бакча түренә утыртып куелган колга-карачкыга охшагансың... Хи-хи-хи...

Кеткелдәп көлеп торган Ак бабайга кушылып, Хәлим үзе дә шаркылдап көлеп жибәрде. Бу—аның билгесез сәфәрдән кайткач беренче көлүе иде.

## IX

Беркөнне күршедәге Васимә әби "имче" дип даны чыккан Мәймүнә карчыкны алып килде. Бу карчыктан Хәлим кечкенә чактан куркып үсте. Кампәрледә аналар, тәртипсез балаларын куркытканда, гел Мәймүнә исемен искә төшерәләр иде. "Сихерче Мәймүнә алып китәр!" яки: "Мәймүнәгә бирәм!"—дип орышучы хатыннарны авылда әле дә адым саен ишетергә була.

Менә шул Мәймүнәне Хәлимнең аң-хәтерен дәвалау өчен алып килделәр дә инде.

Әнкәсенең соңгы көннәрдә Мәймүнә исемен еш кабатлавын хәзер

генә аңлады Хәлим. Имеш, ул кырык бер ногыт борчагы белән фал ача, имеш, ул малларның арка сөяге белән имли...

Мәймүнә бик сәер карчык булып чыкты. Күп сөйләшми. Сөйләшкәндә һәр сүзен, әйтергәме инде, юкмы, дигән кебек, тешләре арасыннан кысып чыгара.

Хәлимгә күз ташлау белән, имче Мәймүнә Васимә карчыкның колагына нидер пышылдап өлгерде. Күрше әби, гаҗәпләнү кыяфәте чыгарып, башын чайкап куйды.

Хәлимгә боларның барысы да кызык тоелды. Ул ясаган чәен эчеп бетерде дә чыгып китмәкче булды. Аның юлын әнкәсе бүлде:

—Чыкмый тор әле, улым. Менә Васимә әбиең белән Мәймүнә абыстай сине өшкереп алмакчы булалар. Бездән калмасын... Ачуланма да, битәрләмә дә, яме, улым. Әйдә үзләре теләгәнчә булсын. Бәлки, чынлап та яхшырып китәрсең, аң-зиһен тәрәзәң ачылыр, хәтерең кайтыр...

—Мин бит бер сүз дә әйтмим, әнкәй. Әйдә, өшкерсеннәр лә...

Мәймүнә карчык кулындагы кечкенә янчыгын түр түшәккә җәелгән япма өстенә чишеп ташлады. Нәрсәләр генә юк иде бу сәер төргәктә. Ногыт борчаклары, артыш ботакларыннан телеп ясалган шакмаклар, җәнлек теш-тырнаклары, каурыйлар... Болар арасыннан озынча, әмма яссы ике сөяк шапылдап төште. Хәлимнең йөрәге "жу" итеп китте... Тәненә салкынлык йөгерде, кул-беләкләрендә каз йоннары кабарып чыкты.

Хәлим бала чактан ук сөяктән курка. Урманда йөргәндә янгырдан ышыкланам дип бер кечкенә тау куышына кергәч, кеше скелетына тап булган иде ул. Сөяккә калган бу бәндәнең өстенә ертык-йортык чүпрәк каплаганнар диярсең,—баксаң, кибеп каткан тире кисәкләре шундый тәэсир калдыра икән...

Хәлим, шул вакыйганы күз алдына китереп, чирканып, калтыранып куйды.

Мәймүнә карчык үз эшен яхшы белә. Ул ниндидер кипкән үлән бәйләменә ут төртеп, өйне ыслата башлады, чебен куган кебек, тәрәзәгә, ишеккә табан хәрәкәтләр ясады. Өй эче әчкелтем төтен исе белән тулды. Бу төтен сулыш алганда укшыта язып үпкәгә кереп тула да, шулай ук укшыта язып кире чыга...

Хәлимне бүлмә уртасындагы артсыз урындыкка утыртып куйдылар. Тәрәзәләрне томаладылар. Сания кай арададыр күршедән тагын ике карчык алып кергән. Хәят әби, Мөршидә түти һәм Васимә карчыклар, аларга кушылып Сания үзе дә өй почмакларына таралып утырдылар. Дүртесе дүрт якта белгән догаларын укый башладылар.

Хәлимнең ишеткәне бар. Кара рухлар, шайтан сыңарлары почмакларда булучан икән. Өшкергәндә аяк тыгып, койрык болгап тормасыннар өчен, һәр почмакка сакчы беркетәләр.

Тәрәзәләрне каплап куйгач, бүлмәгә шомлы караңгылык инде. Тәрәзә япмалары читеннән эчкә сузылган яктылык—бернинди кояш нурлары да түгел, гүя әллә нинди әкияти затлар, озын, төз бармаклары белән, бура араларындагы сүс толымнарына ябышып торалар төсле... Ара-тирә бу бармак-нурлар уйнап-кыймылдап китәләр... Менә алар очлы тырнакларын сүсләрдән тартып алырлар да, бүлмә уртасына җыелып килеп, Хәлимнең бугазына ябышырлар кебек...

Хәлим үз уйларыннан үзе куркып китте. Бөтен көчен җыеп, игътибарын имче карчыкка юнәлтте.

Мәймүнә әби иң элек теге җәлпәк сөякләрне кулына алды. Аларны бер-берсенә аркылы куеп, бармаклары арасына кысты да Хәлим каршында, сәгать әйләнеше буенча, кул хәрәкәтләре ясый башлады. Шундый ук хәрәкәтләрне Хәлимнең баш түбәсендә, арка ягында башкарды.

Шул мәлдә Хәлим Мәймүнә карчыкның йөзенә игътибар итте. Күзләре йомык иде аның. Үзе бертуктаусыз нидер көйли. Көй дә түгел ул, ниндидер ыжылдавык тавыш, иске курай кебек!

Менә ул кулындагы сөякләрне Хәлим алдына—идәнгә куйды. Куйды

да бер-берсенә аркылы яткан сөякләр өстеннән кулларын йөртеп, өшкергәндәй итте. Аннары түшәк өстендә чәчелеп яткан бер куш уч ногыт борчагын барып алды. Тезләнеп, аларны сөякләр өстенә койды. Борчаклар сөяккә бәрелә-бәрелә төрле якка тәгәрәде, кайберләре сөякләрнең үзләренә килеп сыенды. Берничәсе ишек төбенә үк китеп барды... Ә берсе... Берсе бөтенләй дә гаҗәпкә калдырды: идәндә сикергәләп торды да өстә яткан яссы сөякнең нәкъ астагысы белән кисешкән урта бер өлешенә сикереп менде һәм ике-өч мәртәбә селкенеп куйганнан соң тынып калды... Ул—Мәймүнә карчык кулыннан аска төшеп киткән иң соңгы борчак иде. Нигәдер имче аңа бик озак карап торды. Әмма Хәлим, бүлмә караңгылыгында кеше йөзен ачык күрү мөмкин булмаганлыктан, аның көенүен яисә сөенүен ачык кына белә алмый калды.

Хәлим үзенең манма тиргә батуын тойды. Сулышы кысылды. Ниндидер бер көчкә буйсынып, күзләрен йомды. Әмма егылмады. Селкенергә дә ирек бирмичә, шул ук сихри көч дүрт ягыннан да терәп тора кебек иде. Шулай ярым һушсыз күпме утыргандыр, бервакыт аның колагына Мәймүнә карчыкның басынкы тавышы килеп иреште:

...Төтәс-төтәс хатыннан,
Кыздан—кара күздән,
Зәңгәр күздән, яшел күздән,
Коңгырт күздән, усал күздән,
Картлардан, яшьләрдән,
Ятлардан, дуслардан...

Бу җыр һаман якыная барып, ниһаять, колак, төбендә үк яңгырый башлады. Аның белән бергә Хәлим дә кабат тормышка кайткандай булды. Мәймүнә карчык көйләп укыган мәҗүси доганың соңгы сүзләре яңгыраганда Хәлим өй эчендәге "шылт!" иткән тавышны да ишетерлек дәрәҗәдә айнып җиткән, аңына кайтып өлгергән иде инде.

...Тфү, тфү, бетсен-китсен
Җитмеш агач башына,
Азганга, тузганга,
Тигәнәккә, туфракка,
Җилгә очкан яфракка,
Тфү, тфү, үтсен-китсен!

Кемдер тәрәзәләрдәге япмаларны ачып җибәрде. Өйгә ургылып көн яктысы кереп тулды. Бу яктылык, өйгә керү белән генә чикләнеп калмыйча, ниндидер үҗәтлек белән, андагы кешеләргә ябырылды, ник мине кертми тордыгыз, дигән кебек, әле берсенә, әле икенчесенә укталды. Көн яктылыгыннан Хәлимнең дә күзләре камашып тора иде. Әмма бу халәт бик тиз үтте. Чөнки адәм баласы яктылыкка бик тиз күнегә. Төнгә, караңгылыкка гына күнегә алмый интегә ул. Ә менә Көн, Кояш хасиятләре аның табигатенә ягылган. Чөнки ул—Кояш иярчене. Табигать баласы, тереклек иясе булган кеше гомере дә шифалы Илаһи Нур, Кояш белән турыдан-туры бәйләнгән...

Мәймүнә карчык бер-берсенә аркылы яткан сөяк сыныклары янында булаша, калганнар кайда нинди борчак ятуын әйтеп торалар. Әмма үзләре бер бөртегенә дә кагылмыйлар. Бу борчакларга имче Мәймүнә карчык кына кагыла ала, күрәсең...

Шулай ногыт борчакларының кырык берен дә табып, билгеләп куйдылар. Бу эшне үтәп чыккач, карчыклар, ниндидер мөһим сүз көткән кебек, Мәймүнә карчыкка төбәлеп, тынып калдылар. Имче озак көттермәде, борчакларны тотып карый-карый тезеп китте:

—Хәлим улым, гомерең озын булачак. Әмма син аны юлда каңгырып үткәрәчәксең... Әмма ахыры әйбәт, көн ягына яткан... Ишек төбенә тәгәрәгән гомер ташын шул хакта сөйли... Атаң-анаң исән-сау... Менә —анаң, ә менә бусы —атаң... Әмма аларның икесе ике якка тәгәрәгән...

Ир-ат ташы капланып төшкән. Нәрсә бу? Үзе тере, үзе үлек?.. Анламыйм... Юлдашын хакында ни-нәрсә беләләр сон ташлар? Ә, менә монда икән... Әстәгъфирулла... Сөйгән ярын кара көчләр, түбән рухлар белән бәйләнгән... Менә бит —мәхәббәт ташы почмакка, шайтанның койрык астына кереп яткан... Сине шулар сихерләгәннәр дә. Әмма... сөйгән кешеннең бер гаебе дә юк. Ул ал ягы белән өскә карап төшкән. Ул яшәгән дөнья гына бәла чыганагы. Менә күрәсенме—мәхәббәт ташыннан туп-туры булып сина таба ташлар тезмәсе китә... Барысы да кара... Алар сина бәла алып киләләр, кайгы сорыйлар...

Ә менә монысы—бәхет ташы. Бәхетсезлек ташы белән чагыштырып карасаң... Әһә, менә ул таш... Бәхетең бәхетсезлеккә караганда арырак шул, улым. Тик борчылма—бәхетең олы синең, мәңгелек һәм ихлас... Ул сине гомерең буе озатып барачак, менә күрәсенме—гомер ташына янәшә яткан...

Сихер иясен дә тоям, күрәм, таныйм... Алар икәү. Ике кара зат. Явызлык фәрештәләре... Аларның юлы шушы нигезгә килә. Юк, шушы нигездән чыгып китә...

Мәймүнә карчык сөйли дә сөйли. Өйдәге карчыклар аның сөйләменә "Сөбханалла!", "Тәүбә-тәүбә!", "Ходаем сакласын!" кебек сүзләр кыстырып, үз мөнәсәбәтләрен белдереп баралар. Әмма ныклап бүлеп сорарга яисә кушылып китәргә кыймыйлар. Ярамыйдыр күрәсең...

Хәлим өчен кызык болар. Аны зурдан кубып беренче мәртәбә өшкерәләр бит. Өшкерүче-сихерчеләрне әллә нинди убырлы карчыклар кебек күреп нык ялгышкан икән Хәлим. Әнә нинди итагатьле, мөлаем, ягымлы һәм теләктәш икән алар... Баштарак ногыт борчакларына бик сәерсенеп караса да, Мәймүнә карчыкны тыңлаган вакытта, аларда ниндидер Тылсымның, Илаһи Көчнең булуына тәмам ышанып житә язды.

Хәлим бер нәрсәгә генә аптырап утырды. Беренче карашка берберсеннән һичничек аерылмый торган бу борчакларны Мәймүнә карчык ничек аера ала икән соң? Әле аларның ак һәм кара яклары да бар имеш.

Монысы—тышкы тәэсир генә. Хәлимнең жан-бәгыренә төшеп, серле әрнеш булып яткан уй-хәбәрләр дә бар иде имче, дөресрәге, фалчы сүзләрендә. Ничек инде аның әткәсе исән булсын ди? Хәлим туганчы ук үлгән ул. Югалган... Ә?!. Чынлап та, югалган гына бит. Аның үле гәүдәсен беркем дә күрмәгән... Бәлки, чынлап та исәндер, кайдадыр яшәп ятадыр? Фу, баш житмәслек хәлләр болар...Сихерчеләр диме? Ниндидер мәхәббәт борчагы сихерчеләр янында яшәүче кызга күрсәтә, диме? Монысына бөтенләй баш житми...

Бик сорар иде, фал ачканда, имләгәндә сорарга ярамый —йола бозыла, ди. Бу хакта әнкәсе дә, күрше карчыклары да белә, әлбәттә, әнә бит, сүзгә кушылмыйча бот чабып утыралар. Ә үзләренең бик тә, бик тә сорашасылары киләдер әле...

Мәймүнә карчык эшен төгәлләде, әмма йола моның белән генә бетмәгән иде. Ул учларын учка ышкып алды да кулларын күтәрде, уч ягын аска каратып, Хәлимнең баш очында "медер-медер" килеп, имләү сүзе пышылдады: "Жиде дингез артында, кара урман эчендә бер кара башлы елан бар. Бер мөгезе алтын, бер мөгезе көмеш. Ул еланны кайчан кеше житеп бозса, бу Хәлимне анда бозсын! Яман хаста кире кайта: ак атлы, ак булат кылычлы, ак ябынычлы, ак этле, ак ук-садаклы, ак күн кигән хаста кире кайта. Кызыл атлы, кызыл булат кылычлы, кызыл ябынычлы, кызыл этле, кызыл ук-садаклы, кызыл күн кигән хаста кире кайта! Яман хаста, кире кайт! Кире кайт! Тфү-тфү!"

Им-том такмагын онытылып тыңлап утырган Хәлим сизми дә калды: аның баш түбәсенә нәрсәдер чәчеп жибәрделәр, алар Хәлимнең кул башында, кушырып куелган кул-беләкләрендә аяк-тезләрендә сикереп уйныйуйный жиргә тәгәрәделәр. Хәлим аларның берничәсен генә шәйләп калды; бигрәк тә ниндидер жәнлек тешләре, кош тәпиләре, эт (әллә бүреме) тырнаклары... Иң чирканчыгы —елан кабыклары иде. Аны күргәч, Хәлимнең

тәненә салкын йөгерде, ул үзе дә сизмәстән читкә тайпылып куйды.

—Кабыгы гына ул, балам, ул синен мәнгелек фалын... Еланнар мәнгелеккә ирешкән тереклекияләре. Алар кабыкларын салалар да, яшәреп, кабат туып яшиләр. Без ул мөмкинлектән мәхрүм. Әмма еланнан бездә күп нәрсә бар. Шуна күрә курыкма син еланнан. Кешедән курык! Чага торган елан әллә каян чагам дип килә, ә чага торган кеше, сөю сулышы белән исертеп тә чагарга мөмкин...

Хәлим, Мәймүнә карчык сөйләгәннәрне аңлап бетермәсә дә, башын селкеп, риза булып утырды.

Бераз тынлыктан соң имче үз эшен дәвам итте. Ул, йөзләрен чытып, күзләрен ачулы кысып, Хәлимгә укталган кебек кыланып, кулбармакларын алга сузып, алпан-тилпән йөренә башлады:

—Бар кит, зәхмәт, юлында бул! Анымны бир, жанымны бир, санымны бир! Дөнья жәнлегенен сулышын өрәм: "Өф-ф-ф!". Дөнья жәнлегенен тырнагы белән тырныйм: "Р-р-р!".

Хәлим каршында йола башкаручы Мәймүнә карчык бу минутта әкиятләрдә генә була торган убырлы карчыклардан, ялмавызлардан бер дә ким түгел иде. Кеше шулкадәр дә үзгәрер икән! Әле генә мөлаем әби иде, хәзер әнә җен карчыгыннан бер жире белән дә аерылмый: артык та түгел, ким дә түгел. Тизрәк бетсен генә иде бу әкәмәт хәлләр...

Хәлим, нииндидер бер ярдәм сораган шикелле, әнкәсенә борылып карады. Сания дә шул хәлдә, тән-гәүдәсен катырган да, тын алырга да куркып, малаеның һәр күз карашын күзәтеп тора. Язмышы хәл ителә диярсең, күзләрендәге өмет нуры керфекләреннән тамам, тамам дип тора бит әнә...

Имче тагын нәрсәдер кыланды, сәер хәрәкәтләр ясады, Хәлим аңа әллә ни игътибар итмәде. Ул инде тоеп, сизеп белә иде: тиздән йола тәмамланачак, ниһаять, ул торып чыгып китә алачак, бу эссе, тынчу, сасы, ярымкараңгы һәм серле-сихерле бүлмәдән котылачак... Котылачак, чөнки Хәлим тиле түгел бит. Мәймүнә карчыкның йола сихере генә аның хәтерен кайтара алмаячагын ул белә.

Ниһаять, Мәймүнә карчык, соңгы әфсен-догасын әйтеп, идәндә чәчелеп яткан борчакларны, тырнак-тешләрне жыя башлады. Аңа башка карчыклар дәррәү кушылды. Сания самавырын янартырга керешге.

Шуны гына көткән Хәлим ашыгып урамга чыгып китте. Үпкәсен тутырып сулыш алды. Шундый халәт: аның тәне мамык кебек жиңеләеп калган, инбашын басып торган авырлык юкка чыккан, ә күңелендәге таш эреп беткән иде.

Өйдәгеләр әңгәмәләшергә калдылар. Хәлим, ындыр капкасын ачып, яраткан урынына—каен әрдәнәләре өелгән почмакка кереп китте. Шул каеннарны күргәч, тагын Нәфисәсе искә төште, бераз басыла башлаган йөрәк ярасы ачылып, сулкылдап-сулкылдап сызлый башлады. Әмма Хәлим өчен рәхәт газап иде бу. Каһәрле язмыш аның бер еллык гомерен урласа да, Нәфисә белән кичергән беренче мәхәббәт гомерен, назларын, бәхетле мизгелләрен юып ала алмаган бит!

Хәлимнең жырлыйсы килде. Юк, ул жырчы түгел. Юньләп жыр да белми ул. Ә менә хәзер түзеп булмаслык дәрәжәдә жырлыйсы килә иде аның! Жан-бәгыренә укмашып каткан кайгысы, аһ-зары, чарасызлык хисе жыр юллары белән очып китәр кебек идеме әллә? Ул гомерендә беренче мәртәбә авызын ачып жыр башлады:

Урман карамасы каралган,
Карамага үлән уралган...
Кара карамадан сорап йөрим:
"Язмышыма ниләр юралган?.."

Басылып кына, ярым пышылдап жырлады ул. Тыны житмәгән урыннарда сүз уртасында тизрәк сулышын алып, әмма жырның көен сакларга тырышып, чын күңеленнән бирелеп жырлады Хәлим. Әллә

жырлады, әллә жылады... Күзләреннән аккан яшь тамчыларының игечиге булмас кебек иде.

Урман карамасы каралган,
Урманнарда яфрак яралган...
Кара кайгым, карамалар булып,
Бөтен дөньясына таралган...

...Кинәт ишек алдыннан Саниянең тавышы ишетелде:

—Хәлим! Хәли-и-м... Балам, кер инде. Әбиләр китте, кер әйдә...

Хәлим, бер сүз дә әйтмичә, әрдәнәләр артында утыруында булды. Үзе дә аңлый алмый—ни өчен дәшми соң ул?

Ишегалдыннан эзләп таба алмаган Сания ындыр ягына чыкты. Тагын берничә мәртәбә Хәлимне чакырып карады. Хәлим дәшмәде. Кинәт Саниягә әллә нәрсә булды. Ул: "Ай, аллам"!—диде дә ындырның аргы башыннан бу якка табан йөгерә башлады. Үзе бертуктаусыз:

—Урладылар! Тагын алып киттеләр баламны! Ай, Аллам, Хәлимкәемне алдылар!..—дип такмаклый иде. Яшь аралаш инрәп кычкыручы Сания тиле кешене хәтерләтә иде бу минутта. Менә ул, Хәлим качып торган утын өемен узып китеп, капкага барып тотынды...

Шунда Хәлим:

—Әнкәй!—дип әйткәнен сизми дә калды. Сания шып туктады. Хәлим үзе дә әнкәсенә омтылды. Менә алар—Ана белән Ул—очып диярлек килеп бергә кушылдылар, кочакка-кочак, тәнгә-тән беректеләр. Ике җан, бөтен аһ-зарлары, кара кайгылары, күңел ачыгысы белән берьюлы кычкырып елап җибәрделәр. Бер-берсеннән һич оялмыйча, бөтен гәүдәләре белән калтырана-калтырана, инри-инри, ыңгыраша-ыңгыраша елыйлар иде алар... Күңеленә кереп урнашкан кайгы ташы эресен өчен Аллаһы тәгалә кешегә елау сәләте биргән. Ярый әле биргән! Югыйсә бөтен җир өсте таш багана-балбаллар белән шыплап тулыр иде!..

## IX

Хәлим өчен иң кыены зираттагы кабердән ана нисбәт ителгән мәетне чыгару булды.

Ул көнне районнан өч кешелек комиссия килеп төште. Прокурордан, военкомат вәкиленнән һәм район шифаханәсенең баш табибыннан торган бу комиссия Хәлимнең кем булуын ачыкларга тиеш иде. Ялганчы түгелме, янәсе...

Әмма Хәлимнең Хәлим икәнлеген раслау кыен түгел иде. Бөтен авыл, бигрәк тә егетнең анасы, күршеләре, укытучылары аның кем булуын һәрьяклап дәлилләп бирделәр. Военкомат вәкиле өс-баш, аяк размерларын үзләрендәге кәгазьләр белән чагыштырды, табиб районда саклангaн медицина карточкаларын төяп алып килгән—алты яшендә Хәлимнең сукыр эчәген алганнар иде. Прокурор җентекләп беркетмә язды, ана ярты авылдан кул куйдырды, авыл советының мөһерен сукты, аннары, кабердәге «Хәлим»не казып алырга киләчәкләрен хәбәр итеп, шул ук көнне китеп тә барды... Прокурор "Волга" сы артыннан табиб белән хәрби кеше утырган "Москвич" кузгалды. Авыл очына китеп югалган машиналар артыннан купкан тузан болыты басылмас борын, Хәлим зиратка юл тотты. Аптырап барды: кайтуына ничә көн узган, ә ул зиратка барып кайту хакында уйлап та карамаган икән! Аның кабердә кем ята? Нинди кеше? Каян? Ни өчен аның җаны бу хакта борчылып, кыймшанып та карамаган? Ә бит анда кемнеңдер газизе ята. Кемнеңдер Хәлиме ята!

Зират авылдан ерак түгел. Пөхтә итеп койма белән уратып алынган түбәтәй-таулыкка урнашкан каберстанга ялгыз керү көндезен дә шомландыра. Ә көн кичкә авышып бара иде. Хәлим адымын кызулатты, кояш офыкка килеп кагылганчы каберне карап чыгарга кирәк! Тиздән зиратка "җеннәр вакыты" керәчәк...

Хәлим үз каберен бик тиз таныды. Бераз ишелә башлаган кызыл балчык өемен, аның алдына кадаклап куелган такта кисәген, андагы язуны, үзенең фотосурәтен ул төштә күргән кебек кенә кабул итте. Мондый хәлнең өндә булуы мөмкин түгеллеген тиле-миле кеше дә һич икеләнүсез әйтеп бирер иде.

Шулай да, бу өн иде. Менә бит аның кабере. Кабер тактасына кагылу белән, Хәлимнең йөрәге кысылып куйды, тәне ток йөгергәндәге кебек, чымырдап китте...Аның фотосурәтеннән өстәрәк—ярым ай рәвешендә уелган гөмбәзнең тап уртасында, шар ачык күзләр кебек, бик тә таныш бер тамга тора иде. Божра-түгәрәк, аның эченә тәре рәвешендә киртләтеп, аркылы чөй сызганнар... Бу бит албастылар тамгасы!.. Түгәрәк уртасында—ике сызык кисешкән урында—тирән уентык...Хәлим артына егылып китә язды. Мондый тамга очраган һәр җирдә аны һәлакәт көткәнен белә ул. Әмма һушын тиз җыеп алды.Күптән уелган тамга ласа бу! Әнә бит—кар-янгыр тиеп, сызыклары карая башлаган, ә уртадагы уентыкка төкерек кадәр генә урман мәшкәсе кунган...

Шулай да, бу билге—шомлы фал иде. Хәлим тиз-тиз җыенды да, зират капкасын сикереп чыгып, йөгерә-атлый авылга таба китте. Артына борылып карамады. Борылып караса, албастылар аны кабат үз сихерләренә буйсындырып, кире тартып алырлар да кабат әллә нинди җисми һәм рухи газапларга дучар итәрләр, иң аянычлысы, тагын әнкәсеннән, авылыннан, кешелек дөньясыннан аерырлар кебек иде...

Хәлим кабер тактасындагы тамга хакында беркемгә дә әйтмәде. Беленер-беленмәс кенә торган бу сызыкларны районнан килгән кешеләр дә, аларга булышучы авыл картлары да күрмәде.

Комиссия биш кешедән тора иде. Элгәреге өч кешегә тагын шәһәрдән килгән эксперт һәм милиция кешесе өстәлгән. Алар авылда озак юанып тормадылар, авыл советы рәисендә чәй эчеп чыктылар да, урамда көтеп торган бер төркем картны ияртеп, зиратка менеп киттеләр.

Иң арттан Ак бабай белән Хәлим иярде. Хәлимнең барасы килмәгән иде. Ак бабай: "Алай ярамас, олан, әйдә барыйк, бергәләп дога укырбыз, бу ялгышлык өчен Ходай тәгаләдән бәхиллек сорарбыз",—дигәч, барырга булды. Хәлимнең үзенә дә кызык иде. Хәлим үзе булмагач, кем ята соң анда?

Урамда кеше юк. Пәрдә читен күтәреп, тәрәзәдән карап калучылар колонна булып сузылган төркемне озатып калганда кояш төшкелеккә күтәрелеп килә иде инде.

Бер тәрәзәдә Нәфисәнең йөзе чагылып китте. Хәлимгә ток бәргән кебек булды. Басыла башлаган йөрәк әрнүе кузгалып куйды, буыннары йомшап, Ак бабайдан да арткарак кала башлады. Аның болай да тынычлыгын югалткан күңел дөньясына ургылып өр-яңа хатирәләр өермәсе килеп керде...

... Ул җәйне Нәфисәләр йортына кара кайгы керде. Аның әтисе—колхозның алдынгы тракторчысы Фәнил абый кинәт кенә куллары, аяклары тыртышып үлеп китте. "Гомер буе авыр эштә булгангадыр",—дип юрасалар да, әзмәвердәй ирне алып киткән авыруны төгәл генә билгели алмадылар.

Авылда бик яраталар иде мәрхүмне. Аның җеназасы артыннан бөтен авыл ияреп барды. Кызы Нәфисә генә зиратка бармады. Әтисен күмәсе көнне кинәт кенә юкка чыкты. Әнисенең үз хәле хәл иде. Күршеләре моны нәрсәгә дә юрарга белмәделәр. Эзләп, чакырып карадылар да башкалар артыннан иярделәр.

Хәлим Нәфисәне эзләп калды. Кайда гына булмады ул—абзар-куралар, ындыр артлары, чокыр-чакыр... Якындагы урман буйларын күзләп килде. Аннары, бераз вакыт аптырап басып торганнан соң, зиратка таба китте.

Халык кайтырга чыккан иде инде. Хәлим аларга каршы барырга кыенсынды. Юлдан тайпылып, әрәмәлек аша туры гына китте. Болай зиратка ерак калмый. Ул каберстанга бик тиз барып җитте. Койма аша

керергә кыймады. Алан уртасындагы кара балчык өеменә коймa аша озак карап торды, күнеленнән генә мәрхүм белән саубуллашты, аннары, авыр гына кузгалып, шомырт куаклары арасына кереп китте. Әмма бик эчкә кермәде, берничә адым атлау белән, туктап калды, бер карт шомыртны сайлап, аның кәүсә төбенә төшәлгән яшел чирәмгә утырды. Хәлимгә бик тә ямансу иде бу минутта... Бөтен дөньяга ачуы килгән чагы иде. Нәфисәсенең юкка чыгуы да, Фәнил абыйсының үлеме дә, аны озатырга бара алмавы да, барысы бер ноктага төйнәлеп, җан-бәгырен әрнетеп бораулыйлар иде. Хәлим башын тезләренә куеп, күзләрен йомды. Бераздан, әллә арудан, әллә күнел төшенкелегеннән, онытылып оеп китте, аны әкиятләрдәге алыпларга гына төшә торган авыр йокы басты...

Менә бервакыт Хәлим сәер тавышка сискәнеп уянды. Ниндидер кош тавышына. Тыныч кына, басылып кына сайраучы кош иде ул. Әмма... кош та түгел...

Хәлим шомланып, сагаеп калды. Хәтта сикереп үк торды. Көн кичкә авышкан. Зират ягына барасы килмәсә дә, шул яктан килүче сәер тавыш, көчле магнит белән тарткан кебек, аны үзенә суырып алды. Хәлим ничек зират капкасы янында пәйда булуын сизми дә калды.

Эчтән—Фәнил абыйсының кабере ягыннан килә иде әлеге тавыш. Бу тавыш бераздан сыктауны, сулкылдап елауны хәтерләтә башлады. Шунда гына әтисе кабере янында утырган Нәфисәне күреп алды Хәлим. Ул бик сәер, хәтта куркыныч мажарага тап булды: Нәфисә әтисе кабере каршына тезләнгән дә, елый-елый, яна балчык өемен ике якка эшерә. Ике якка таба хәрәкәтләнгән куллар, талпынып-талпынып очарга әзерләнүче кош канатларын хәтерләтәләр иде...

"Тукта! Үз әтисенең кабeрен чокып маташа түгелме соң бу кызый?"—дип уйларга да өлгермәде, кемдер, арттан килеп, Хәлимнең башына капчык кидертте, авызын томалады... Икенче берәү, тез астына сугып, аны җиргә екты. Ул шуннан башка берни дә хәтерләми. Уянып киткәндә таң атып килә иде инде. Гаҗәп, шулай зират коймасына арка терәп утырган килеш төн чыккан микән ул? Янында беркем дә юк. Кулаяклары да исән-сау, йөз-башы да таза, аңы-һушы да үзенеке.

Хәлимнең исенә, "келт" итеп, кичәге хәлләр килеп төште. Ул, үзен-үзе белештермичә, зират эченә күтәрелеп карады. Фәнил абыйсының кабере үз урынында, янында беркем дә күренми иде. "Нәфисә кая? Нишләткәннәр аны?" дигән уй Хәлимнең күнелен әрнетеп узды. Ул, сикереп торып, бәрелә-сугыла зират эченә барып керде. Анда бакты, монда бакты, әмма Нәфисәне таба алмады.

Хәлим авылга кайтып белешергә булды. Бәлки өйдәдер инде ул? Җан ачысы булып төшкән кайгысын әнкәсе белән бүлешеп утырадыр?..

Чынлап та шулай булып чыкты. Тыны-сулышы бетеп кайтып кергән Хәлимне Нәфисә белән Тәскирә апа бераз гаҗәпләнебрәк каршы алдылар. Бу төнне алар аяк өстендә үткәргәннәр ахры, әнә бит—йөзләре шешенгән, күз алмаларына кызыл пәрәвез эленгән...

Хәлим артык сорашып тормады, кайгыларын уртаклашып, хәләхвәл белеште дә өйләренә кайтып китте. Бераздан бу хакта бөтенләй дә онытты. Нәфисәдән бик сорашасы килсә дә, зиратта булган хәлләр хакында сүз кузгатырга батырчылык итмәде. Шулай да аны буынсыз итеп, һушсыз калдырып җиргә егып ташлаган бәндәләр, серле затлар (ә бәлки—җеннәрдер) кайчакта хәтеренә килеп төшәләр дә, күнеленең иң нечкә бер җиреннән әрнетеп-чеметеп алалар иде. Җитмәсә:"Без әле тагын килербез, онытма безне..."—дип әйтәләр кебек.

Шул вакыттан бирле Хәлимнең зиратка тыныч күңел белән кергәне булмады. Бер ел югалып торып кайтканнан соң, "үз кaберен" карарга дип зиратка баргач та өч көн буе башы авыртып, шаулап йөргән иде... Бүген дә—аның исеме астында кабергә куелган бәндәви җанны казырга барганда да ныклап беркетеп куйды ул: зиратка кермәячәк, керсә дә, казу эшләрендә катнашмаячак, читтән генә карап торачак. Хәлим инде

тәгаен белә: ниндидер көч аны зиратка якын җибәрмәскә тырыша, афәттәнме, әллә берәр бик мөһим серләнме сакларга, якларга омтыла иде... Бәлки, киресенчәдер?.. Кара рухлар, аның ан-зиһенен алып, үзләренеке итмәкчеләрдер, Хәлим генә баш бирмидер, буйсынмыйдыр...

Иң гаҗәбе шул булды: мәет мангаендагы миң каядыр юкка чыккан иде. Юып-күмеп йөргән Вафа карт кат-кат килеп караган, имеш. Үз күзе белән күргән, үз куллары белән тотып капшап караган минне таба алмаган ул... Ах иткән дә, башын чайкый-чайкый китеп барган, диләр.

...Казып алынган мәетне, дөресрәге, аның калдыкларын, районга алып киттеләр. Авылда шом артты, имеш-мимеш күбәйде. Сания белән Хәлимнән тагын да ныграк читләштеләр. Әмма, менә хикмәт, Сания дә, Хәлим дә моңа сөенделәр генә. Алар бер-берсенә бик җиткәннәр иде. Кеше теленә кермичә, кешегә кагылмыйча гына тормышларын җайга салырга, күнелләрен утыртырга кирәк иде аларга...

## X

Күмәк хуҗалык рәисе үз сүзендә торды: Хәлимгә, искерәк кенә булса да, комбайн бирде. Бер-ике атна МТМ түрендә майга батып ятканнан соң, Хәлим кырга чыгып китте. Иң алдынгысы булмаса да, ун-унбиш ел буе комбайн штурвалы тотып шомарган абзыйлардан әллә ни калышмады ул.

Эш Хәлимне авыр уйлардан арындырды. Сәер сәфәр хакында да, Нәфисә хакында да ул элекке кебек әрнеп уйланмый инде. Бөтен борчуы—бу басудагы икмәкне ничек тә тизрәк егып бетерергә, тизрәк сугып алырга... Бер басу бетсә, ул борчуын башка басуга күчерә иде, аннан өченчесенә, дүртенчесенә...

Басу игеннәрдән арынгач, Хәлим "зәб"кә чыкты. Көн дими, төн дими җир сөрде. Сания аңа карап бер сөенде, бер көенде. Сөенде, чөнки аның улы тәмам тормышка кайтты, аның күзләренә нур кунды, сүзенә элекке җорлык керде... Көенде, чөнки Хәлим һаман да кешеләрдән читләшебрәк яши, кичләрен чыгып йөрми, элекке дуслары белән аралашмый...

Әйе, Хәлим бөтен буш вакытын өй тирәсендә уздырды. Абзар-кураларын рәтләде, койма-капкаларын торгызды, мичләрен яңартты... Бер көнне, эш кораллары тутырылган әрҗәсен күтәреп кергән унайга әйтеп куйды:

—Әнкәй, болай яшәп булмый, өйне яңартырга кирәк. Быел ук урманда агач юнәтеп, бура бурап куярга туры килер...

"Урман" дигән сүзне ишетү белән, Сания дертләп китте. Әмма эчке халәтен улына сиздермәде.

—Көзге эшләрдән дә бик арыдың, балам, әллә киләсе кышка калдырасыңмы соң?—дию белән чикләнде.

Хәлим:

—Юк, әнкәй, быел эшләп булганны нигә киләсе елга калдырырга, җир туңып беренче кар яту белән, урманга чыгып, агач хәстәрли башлыйм. Марилар белән сөйләштем инде...—дип кырт кискәч, Сания дәшмәс булды. Әмма шул минутта ул күңел тынычлыгын югалтты, аның тормышына тагын шом, борчу килеп керде...

Хәлим, бер ният кылса, үз ниятен тормышка ашыра торганнардан иде. Бу яктан ул әтисенә тарткан. Нечкә күңелле, кешелекле булуы әнисеннән килсә, дуамалрак холкы, эшкә зарурлыгы—әтисеннән. Бу юлы да аның канында әтисенең холкы-табигате баш калкытты—әнисенең айваена карамыйча, ялан-кырга беренче кар яту белән, урманга чыгып китте. Урман төпкеллегендә урнашкан кечкенә генә мари авылында куна-төнә ятып, булачак йорт өчен агач әзерләде. Авылдан бер кеше дә алмады. Көзге эшләрдән соң Хәлим үзенә тигән бер машина ашлыкны мариларга илтеп бушатты да, шуның бәрабәренә мариларны яллап агач кистерде.

Кар калынайганчы, киселгән бүрәнәләрне авылга кайтару хәстәрлеген

күрергә кирәк иде. Хәлим, кайтачак агачны бушатырга урын юнәтү өчен авылга кайтты. Әнисен сөендереп, кунып ук китте. Мунчада юынып алганнан соң, гадәттәгечә, Ак бабайны чакырдылар. Өчәүләп үлән чәе эчтеләр, авылдагы, тирә-яктагы яңалыклар хакында сөйләштеләр. Соңыннан Ак бабай йомшак кына әйтеп куйды:

—Сак була күр, олан, агачлар белән, диюем... Әллә нинди төшләр керә соңгы вакытта. Урман киселгән агач өчен әҗер сораучан була. Ягъни, түләү сорый... Догаларыңны укып, урман иясен бәхилләтеп йөр... Бөтиләрең янында булсын...

Ак бабайга Сания кушылды:

—Әллә, балам, монда гына каласыңмы? Агачларың киселгән, өеп куелган, мари Митри үзе төяп җибәрер әле, ул бит рәтен белә... Күңелем тыныч түгел...

Хәлим әнкәсенең күзләренә тутырып карады, әмма дәшмәде. Ак бабайга кайсы агачны кайда бушатырга кирәклеген аңлата башлады.

Иртән Хәлим тагын марилар янына китеп барды. Сания бөтен борчылулары белән берьялгызы торып калды.

Икенче көнне агач кайта башлады. Башта берьюлы ике машина кайтты. Аннары өченчесе күренде... Ярты урамны буйлап ятучы төз, юан нарат бүрәнәләр бөтен авылга тәмле ис таратты. Ак бабай, мөһим кыяфәт чыгарып, өйрәтеп йөрде. Өмәгә чакырып куелган урам ирләре, ах-ух килеп, кар өстендә таралып яткан бүрәнәләрне койма буена аркылы салынган каен киртәләр өстенә тәгәрәтеп менгерә башладылар.

Төшкә кадәр эшне тәмамлап та куйдылар. Машиналар кире китте. Күрше ирләре, Саниянең тәмле ризыкларын мактый-мактый, тартырга чыктылар. Шунда кемдер, шаяртырга теләп булса кирәк, әйтеп ташламасмы:

—Анысы-монысы, керүен-кердек тә, сихер йогып калмасын тагын...

Барысы да, дәррәү борылып, тавыш килгән якка карадылар. Әмма җавап кайтаручы да, бу сүзне шаян-көлкегә алучы да булмады. Тәмәке төпчекләрен сүндереп, бер-берсе белән ашык-пошык саубуллаштылар да Сания-Хәлимнәр йорты яныннан тизрәк китү ягын карадылар. Саф гәрәбә төсендә балкып-янып ятучы агач өеменә карап алар: "Авылыбызга тагын нинди генә афәт-борчулар кайтты икән инде?"—дип уйладылар булса кирәк.

Ак бабай белән Сания һаман өйдә иде әле. Алар, агач кайту сөенечен бер-берсе белән уртаклаша-уртаклаша, тынычлап кына чәй эчтеләр. Әммә бу вакытта икесенең күңелендә дә, кара елан кебек, нindидер зәһәр шом шуышып йөри башлаган иде.

Әйе, Хәлим дүрт машина хакында сөйләгән иде. "Дүртенче машинада киртә-җепсәләр булыр",—дигән иде. Көн кичкә якка авышса да, Хәлим күренмәде. Нидер сизенгән кебек, Ак бабай да кузгалмады, юк сүзне бар итеп утыра бирде.

Бервакыт сөйләшер сүзләре дә бетте. Сания ут кабызды, пәрдәләрен тартып куйды. Өйне тынлык басты.

Ниһаять, авыл башында машина тавышы ишетелде. Тонык кына гүләү, көчәя барып, ыңгырашу-үкерү авазлары белән алышынды, күңелләрне шомландырып якыная башлады... Машина фарасы караңгы урамны телгәләп, айкап килде-килде дә, өй каршында туктап, катып калды. Машина гудогы күңелдәге шомны арттырды гына. Нинди хәл бу: Ак бабай да, Сания дә Хәлим белән нидер булганын өйдә утырган килеш тә тәмам төшенеп җиткәннәр иде. Аларга, йөгереп чыгып, шофер егетнең: "Хәлимне агач басты, районга алып киттеләр..." —дигән сүзен ишетәсе генә калды.

## XI

Хәлимнең мари якларында беренче булуы түгел. Байлыкка, ялтыравык уенчыкларга кызыкмыйча, табигать белән кушылып, аның белән бер тында, бер сулышта яшәүче мари халкы аны

сокландыра. Урман дөньясын бик беләләр алар. Аның холкын, йоласын, ымын-ырымын яхшы беләләр. Иң гаҗәбе шул: урман бавырына беркеп яшәсәләр дә, үзләренең йортлары кечкенә, кысан. Аны бик тиз янартырга да җыенмыйлар. Аларча, ике буынга бер йорт салынса—шул җитә. Чөнки утыртылган агач кешеләрнең ике буын гомере кадәрле вакыт эчендә үсә икән.

Бу гади, самими тормышта яшәүче, ризыкка, тереклек итүгә талымсыз халык урманны илаһи бер көч итеп, аңа табынып яши. Марилар-ның күбесе әле дә мәҗүси. Һәр мари гаиләсендә, түрдә торган шкафтагы агач савытта кечкенә, тулы битле, йомры гәүдәле, корсагы алга бүлтәеп чыккан, тәнен, йөзен җыерчык баскан урман рухы яши. Аны мәҗүси шаманнар агачтан юналар. Мондый сын, буыннан-буынга күчеп, нигезләр-нең тынычлыгын саклый, урманны кешеләргә игелекле иттерә, имеш.

Хәлимнең бу урман рухы хакында күп мәртәбәләр сорашканы бар. Аның исеме үк бик аптыраткан иде. Нәкъ татардагыча, "Орман" дип атыйлар икән бу урман иясен. Менә кайда ул хикмәтле хәлләр!

Юк, Хәлим әллә ни аптырамый. Анынча, бу яктагы бөтен халыклар да бер атадан тамырланып киткән. Шуңа күрә, телдәге уртак сүзләргә, күңелдәге уртак ышануларга нигә аптырарга?

Хәлим, Митри исемле марида ун көн ятып, көндезен урманчылар, ялланган марилар белән мәш-мәшә килеп, кич кайтып егыла иде. Митринең телне йотарлык гөмбә ашларын да, ачы көмешкәсен дә татып карады Хәлим. Мунчасын да яратты.

Иң кызыгы, Митриның хатыны Нәстә түтәй һәр иртәдә, урманга кузгалыр алдыннан, аның өстенә артыш куагының киптереп тартырылган тылсымлы онын сибеп җибәрә иде. Хәлим моның серен сорап-нитеп тормый, Нәстә түтәйнең күңеле булсын дип, елмаеп тора бирә, аннары, шул тузанлы чәченә эт бүреген кия дә чыгып йөгерә.

Соңгы көнне, әллә нишләп, Нәстә түтәй чолан тирәсендә буталып калды. Хәлим, тышта машина гудоклары ишетү белән, иртәнге йола хакында да онытып, тунын эләктерде дә урманга чыгып йөгерде. Хуҗабикә чоланнан киптереп җепкә тезелгән гөмбә "төймәләре" тотып кергәндә, Хәлимнән җилләр искән иде инде. Нәстә түтәй, буш өй күреп, "ай-вай" килә башлады, төрле мәҗүси догалар пышылдап, түргә узды, кечкенә агач сандыктан Орман потын алды, ике уч арасына куеп, ышкый башлады...

Догаларын укып бетереп, потны урынына салып куйгач та ул бик озак сөйләнде әле. Аннары урман як тәрәзәгә карап баш иде дә үз эшләре белән чыгып китте.

Бу вакытта Хәлимнәр тау кадәрле "Урал" машинасына агач төяп яталар иде. Эш җинел барды. Шаян сүз, мәзәк сөйләү бер минутка да тукталмады. Ике машинаны төяп җибәргәч, утырып ашап алдылар, көмешкә кабып куйдылар. Урманчыларның йомшый башлаган буыннарына хәл керде, йөзләре алсуланды, телләре тагын да тугарылып-чишелеп китте...

—Буранны үзебез бурап бирербез, башка беркемне дә чакырма, — дип сүз башлады Митри. Ана Никол дигән мари кушылды:

—Бер кадак кертмичә, агач чөйләргә утыртып өярбез, эчен-тышын агартып куярбыз...

—Аннары туй туйлыйсы гына кала инде... Хәлим, ә, Хәлим! Безне чакырмыйча гына кара! Икенче көнне үк өең ишелеп төшәчәк...

Шулай сөйләшә-сөйләшә өченче машинаны төяделәр. Дүртенчесенә керештеләр. Бу соңгысына бәпкәлекләр, җепсәлекләр, башка вак-төяк агачлар төялде.

Инде эш бетеп килә иде. Башкалар төяп калды, Хәлим урман куелыгы эчендә калган коралларны алырга кереп китте. Баштарак берни дә сизмәде, тоймады ул. Коралларны җыеп бетереп, урманчылар төркеме ягына омтылган гына иде, кинәт башы әйләнеп китте. Миенә корт чокып кергән диярсең, чигә турында гына нидер безелдәп, чынлап тора башлады. Шунда тирә-яктагы биек наратлар аның өстенә ауган кебек

тоелды. Бигрәк тә берсе—араларында иң юаны, иң шомлысы—якынайганнан якыная барып, нәкъ аның өстенә ава... Хәлим, агач астында калмас өчен, читкә тайпылырга кирәген белә, әмма, һушын җыеп, гәүдәсен һәлакәт астыннан ала алмый иза чигә иде.

Мәһабәт агач якынайды ды якынайды. Кузгала алмыйча бер урында катып калган Хәлим үз һәлакәтен көтеп тора башлады. Агач кәүсәсе авып төшкән мизгел эчендә бөтен гомерен хәтереннән кичереп өлгерде ул... Ап-ак җаймә өстендә яткан бала, атка атланып китеп баручы малай... Янәшәдә генә бәхетле әтисе атлый... Ап-ак чәчәккә күмелгән алмагач төбендә сагышка чумып әнисе басып тора... Нәфисә... Ул туй күлмәгеннән. Нәрсә бу? Аның йөзен тирән җыерчыклар баскан... Менә ул тагын үзен күрә... Янында тагын кемдер бар... Кап-кара, озын чәчле, зәп-зәңгәр күзле кыз көлеп тора. Кем соң ул?..

Хәлим уйлый башлаган уен төйнәп бетерә алмый калды, нарат агачы аның өстенә килеп тә төште. Моны күреп, тайга урманы "аһ!" итте, ыңгырашып-иңрәп куйды.

Хәлимнең агач астында калуын башкалар да күреп өлгерделәр. Йөгереп килеп, аны нарат астыннан сөйрәп чыгардылар. Бәхеткә, Аллаһы тәгалә Хәлимне афәттән саклап калган булып чыкты: мәңгелек нарат агачы Хәлимне басмаган, бары тик җиргә кыскан икән. Әмма егетнең башы нык бәрелгән, хәтта баш түбәсеннән ун колак артына кан агып төшкән, ул инде суыкта куерып, катып та өлгергән...

Хәлим аңын югалткан иде. Йөрәк тибеше, кан басымы куркыныч түгел, җәрәхәтләнгән, сынган җирләре дә юк кебек. Шулай да, Хәлимнең аңсыз ятуы бик куркыта иде, аны ничек тә районга—шифаханәгә җибәрергә кирәк икәнен дә беләләр. Кемдер машина эзләп йөгерде, кемдер шәһәрдән авылга кайтып тора башлаган карт табиб артыннан чапты. Әмма, Хәлим белән булашып, ун адымнар читтә генә агачлар арасыннан ашыгып урман куелыгына кереп баручы ике шәүләне беркем дә күрмәде. Хәлимне баскан, тигез итеп алдан ук кисеп куелган нарат төбенә сызылган сихерчеләр тамгасы хакында да беркем белми калды...

## XII

Кайчандыр җир өстендә кошлар гына булгандыр... Чөнки иң элек Күк туган бит. Кояш, Ай, йолдызлар, аннары Дәрья, аннары Җир, аннары тереклек, аннары гына кешеләр барлыкка килгән... Әмма бөтен дөньяга баш булып һәрвакыт Күк Тәңре калган. Галәм яшәеше шушы Күк, аның Тәңресе карамагында һәм ихтыярында булган.

Димәк, кайчандыр Күк кенә булган, кошлар гына булган... Шуңа күрә Җир йөзендә гомере бетеп үлгән һәр тереклек иясе кабат Күккә — йолдызларга оча. Әйе-әйе, Җан кошы булып оча да китә...

Башта ул агачлар очына кадәр генә күтәрелә, аннары кошлар оча торган биеклеккә менә, болытларга җитә, җир йөзенә соңгы тапкыр күз сала да йолдызларга оча...

Хәлимнең җаны да иң элек авыллары өстендә пәйда булды. Ул, салмак кына канат җилпеп, һаман өскәрәк күтәрелә барды. Бераздан Кампәрле авылы уч төбендәге кебек кенә күренә иде. Әнә —дүрт тарафка дүрт урман китә, уртада берничә йорт... Алар арасында Нәфисәләрнең йорты да бар. Иң үзәктә —мәһабәт тупыл үсеп утыра. Аның башында козгын, карга оялары караеп күренә. Менә Хәлимнәрнең үз өйләре. Өй каршында өр-яңа бура тора. Гәрәбә төсендә балкып торган бура янында—әнкәсе. Ул Күккә очып киткән Хәлимгә ак яулыгын болгый. Хәлимнең җаны авыл өстендә бер очып әйләнә дә урманга таба шуыша башлый. Аста—бормалы юл тасмасы. Ул, кара урманны урталай бүлеп, читкә йөгерә. Хәлимнең җан кошы аның артыннан чак-чак кына өлгереп бара. Менә ул юл өстендә яткан алтын тәңкәне күреп кала; бу алтынсу таба аны үзенә суырып, тартып ала. Хәлимнең җаны, яшен ташы кебек, шул

урынга атылып төшә башлый; җиргә якынайган саен, күзенә якты аландагы һәр агач, куак, арыш басуы, юл буендагы багана, багана тирәсендәге өч кеше ачыграк шәйләнә бара.. Җан кошы озак уйлап тормый, төшкән унайга, баганага аркасын терәп утырган егетнең күкрәгенә барып куна һәм, шул ук мизгелдә, аның җан-бәгыре булып кабат уяна, ул адәм баласын яшәүгә дәртләндерә, аның күңеленә өмет бөртеге сала... Егет башын калкыта, күзләрен ача һәм салмак кына хәрәкәтләр белән торып баса. Янындагы ике карчык аны ике кулыннан җитәкләп, урман эченә алып кереп китә...

Хәлим ап-ачык күрә: үзе бит бу! Теге вакытта нәкъ шундый ике карчыкка тап булган иде. Хәзер алар аны кая алып баралар? Кемнәр алар? Ник Хәлим аларга ияреп бара? Ник каршы бер сүз дә әйтми? "Минем бит авылда әнкәм бар, җибәрегез, мин аның янына кайтырга тиеш",—дими? Башын аска иеп, ярым йокылы, ярым уяу хәлендә бара да бара... Каршысына чыккан куак ботаклары аның тәнен йолкый, тарткалап алып калмакчы була, беләкләрен, йөзләрен тырный... Әмма шул ботак-чатакларны читкә этәреп куярга аның көче, егәре юк. Ул кемнендер ихтыяры буенча бара. Аның аңы томаланган, теле юк... Тагын шул сорау: кемнәр алар—кара киемдәге бөкре карчыклар.? Кеше рәвешендә йөрүче җен-пәриләрме, албастылармы, әллә... Тәмугъ сакчыларымы? Бәлки, Хәлим инде теге дөньядадыр? Анда да җирдәге кебектер, урман да, юллар да, авыллар да, хәтта кешеләр дә...

Хәлим күпме барганнарын белми. Акрын гына, мыштым гына гына бардылар да бардылар алар. Көн кичкә авышты. Урман өстендә күк яктылыгы чагылып калгаласа да, аста инде эңгер-меңгер хакимлек итә. Хәлим берничә мәртәбә абынып та егылды, алдыннан һәм артыннан баручы ике шәүлә исә, бер адым да читкә тайпылмыйча, үзләре генә белгән сукмак буйлап һаман алга баралар...

Менә бервакыт алда яктылык пәйда булды. Җыйнак кына урман аланы иде бу. Менә хикмәт! Беренче карашка гына ачык, буш, ялангач алан булып күренгән икән ул. Ныклабрак карагач, күз алдында гаҗәеп кызык манзара барлыкка килде: әнә, алан читендә, куе, мәһабәт нарат ышыгында, яртылаш җиргә иңгән алачык тора, аның янында икенчесе, кечерәге. Арырак—абзар утары, ул киртәләп бүлеп алынган, эчендә берничә бозау күренә, аланның аргы башында караеп торган кыр шәйләнә, чәчү җире булырга тиеш. Анда нindидер бер ир китмән белән җир эшкәртеп йөри. Күлмәксез-нисез кояш астында йөреп, аның тәне кара-көрән төскә кергән.

Каян килеп чыктылар соң алар? Авыл дисәң авыл түгел... Ә бит ярты көн буе йөриләр инде. Димәк, бу утар Хәлим белгән авыллардан бик ерак урнашкан. Бәлки, Хәлим—бу якларга килеп чыккан беренче кешедер? Ә болар... болар—урман җеннәре генәдер?

Хәлим, ике карчыкка ияреп, зуррак алачыкка таба китте. Анда барып җиткәч, алдагы карчык, ымлап, керергә кушты. Алачык берничә кысан бүлмәгә бүленгән иде. Хәлим үтешли генә искә алып барды: бүлмәләрнең ике як стеналарына сәкеләр беркетелгән, түрдә такта өстәл, кечкенә генә тәрәзә уентыклары, алар арасында шүрлекләр, нindидер чүлмәкләр, тиреләр, киптерелгән үләннәр, яфраклар, җиләк-җимеш...

Хәлимне түр бүлмәләрнең берсенә кертеп яптылар. Ул, кая килеп эләккәнен анларга тырышып, бөтен зиһенен эшкә җикте, әмма әллә ни кыра алмады. Бөтен нәрсә төштәге кебек кенә. Юк, аңлый-төшенә Хәлим: нindидер сәер, сихри, хәтта, зәхмәтле бер дөньяга эләкте ул, әммә, нигәдер, бу аны борчымый, күңеленә тими... Хәлим үзе ябылган бүлмәне өйрәнә башлады. Җир идән. Почмакта агач кисмәк белән су тора. Түрдә сәке, озынча агач өстәл. Кеше гәүдәсе сыя алмый торган стена тишеге алачыкта тәрәзә хезмәтен үти булса кирәк.

Хәлим, торып, шул тәрәзә янына барды. Тышка күз салды. Аланда җанлылык сизелмәде. Әһә! Әнә ул! Аланнын аргы башында эшләп йөрүче

ир кешене тагын күреп алды Хәлим. Жансыз машина кебек, һаман бер рәвештә селкенә дә селкенә бу адәм заты. Кергәндә күрмәгән икән, алачык каршында гына буралы кое тора. Аның торна борыны өскә каратылып, астан үзәк кәүсәгә бәйләп куелган...

Кинәт бүлмә ишеге шыгырдап ачылып китте. Хәлим сискәнеп борылып карады. Ишек төбендә балчык касә тотып бер кыз басып тора иде... Ул, Хәлимне гаҗәпкә калдырып, аңа исеме белән дәште:

—Хәлим...

Хәлим нишләргә дә белмәде, каккан багана кебек катып торуында булды. Исем кабатланды:

—Хәлим...

## XIII

—Хәлим! Хәли-и-м...

—Ә?..

—Хәлим балам! Уян инде, мин бу—әниең...

"Әнкәй..."

Хәлимгә күз кабакларын күтәрү искиткеч авыр булды. Бер пот атланмай бастырып куйганнармыни!

—Хәлим!

Ниһаять, Хәлимнең күз кабаклары калтыранып алдылар да киң ачылып киттеләр. Аның аңына гөлт итеп дөнья яктылыгы кереп тулды. Бу мизгелдә Хәлимнең күз аллары гына түгел, күңел дөньясы, хәтер чоңгыллары, аң-зиһене дә яктырып, балкып алгандай булды.

Күзенә иң элек әнкәсе чагылды. Елап-шешенеп беткән йөзләрен яулыгы белән каплап утыра иде ул. Ак халаттан. Хәлимнең бер дә күргәне юк иде аны халаттан. Ак чәченә ак халат бик килешеп тора икән... Гомумән, бөтен дөнья ак монда. Стеналар, кешеләр, хәтта, аларның йөзләре дә ап-ак...

—Әнкәй, мин кайда?

—И-и, улым, уяндыңмыни?.. Әйттем бит, хәзер тора ул, дип... Больниста син, балам, больниста. Агач басты сине... Агач астында калдың. Хәтерләмисеңмени, балам?

Әлбәттә, Хәлим барысын да хәтерли. Өстенә төшеп килүче юан нарат агачын да ап-ачык хәтерли ул. Нарат астында калгач та берниндн авырту сизмәде, бары тик, аягы таеп ниндидер караңгы, төпсез бер чоңгылга очуын гына тойды... Шул очуыннан ул авыл өстендә пәйда булды, күз алдына урман юлы, ике карчык, ниндидер аланлык, алачык, таныш түгел кыз килеп басты...

Ә?! Кинәт, гөлт итеп, Хәлимнең зиһененә хатирәләр ташкыны ургылып керде. Ул барысын да искә төшерде! Үткәндәге бер еллык гомере, ап-ачык булып, аның күз алдына килеп басты.

Әйе, агач бәрелүдәнме, әллә ниндидер башка бер сихердәнме—аның хәтере кабат кайткан, аң-зиһене кабат уянган, терелгән иде...

Агач бәрелүдән миңгерәүләнебрәк калган башына ишелеп төшкән бер еллык гомер хатирәләреннән Хәлимнең башы әйләнеп китте. Бихисап күп вакыт гомер, маҗаралар, таныш түгел йөзләр аның хәтер тезмәсендә әле алга таба, әле артка таба йөгерешә башладылар... Иске, тавышсыз кинолардагы кебек, кешеләрнең хәрәкәте гайре табигый, ә дөнья йөзенә бары тик ике төс—ак белән кара төсләр генә ягылган иде...

Хәлим тагын мәрткә китте. Аның күз алдында тагын баягы күренеш янарды. Ниндидер балчык, саман өй эче, кечкенә тишектән сузылып кергән көн яктылыгы ишек төбендә басып торган зифа гәүдәне яктырта. Биленә кадәр төшкән куе, кара чәчле, ай кашлы, төз, матур борынлы, бик калын да бик юка да булмаган, сөешеп-үбешеп торырга гына яратылган иренле, иң гаҗәбе—томраеп карап торган зәп-зәңгәр күзле, йөз-бите, кояшта янып, караңгы гәрәбә төсенә кергән бер яшүсмер кыз,

кызыксынулы, сынаулы карашын яшерә алмыйча, Хәлимгә эндәшә иде:

—Хәлим?..

Көтелмәгән хәлдән телсез калган Хәлим, ниһаять, үзендә баш селкерлек егәрлек тапты. Моның белән генә чикләнмичә, "әйе" димәкче булды. Әмма телен әйләндереп әйтә алмады... Тотлыккан кеше кебек, авызын ачып-ябып торды да, тагын бер мәртәбә баш ию белән чикләнде.

Кыз ике куллап тоткан касәсен сузды. Хәлимнең үтереп тамагы кипкән иде. Агу бирсәләр дә эчәр иде бу минутта. Ул, кыздан күрмәкче, касәне ике куллап алды да шыбырдатып эчеп тә куйды. Су түгел иде бу. Ниндидер әчкелтем шулпа. Бераз ит, бәрәңге тәмен тойды Хәлим. Әмма ниндидер үлән кайнатмасы булуын да чамалады. Әчкелтем-тәмсез үлән...

Хәлим касәне кире кызга сузды. Кыз, карашларын егет күзләреннән өзмичә генә, касәне үрелеп алды да, кинәт нәрсәдер исенә төшкәндәй, дәррәү чыгып йөгерде.

Хәлим, әллә капыл килеп кергән кыз белән очрашудан, әллә әчкелтем шулпадан, тәнендә, буыннарында сәер бер хәлсезләнү тойды. Ул, сынын җыя алмыйча, стена буендагы сәкегә утырды, аннары, янтая барып, саламмы, печәнме тутырылган киндер капчык өстенә ауды... Аның тән әгъзаларын гына түгел, чәчелеп, таралып яткан уйларын җыеп алырга да хәле юк иде бу минутта.

## XIV

Хәлим ачыргаланып кычкырган әтәч тавышына уянып китте. Иң беренче күргәне кап-кара канатлар рәте булды. Түшәмгә аркылы яткан матчаның ике ягына кыстырып куелган бу канатларны күрүгә үк дертләп китте ул. Тигез итеп ике якка тезелгән карга канатлары менә хәзер, шушы минутта ук, ниндидер сихри ым булу белән, очып китәрләр кебек иде...

Әтәч тавышы кабатланды. Хәлим сискәнеп тирә-ягына каранды. Шунда гына аның хәтеренә кичәге сәер хәлләр, урман сәяхәте килеп төште. Тик... ни хәл бу?—Ул шуннан башка берни дә хәтерләми иде. Урманны хәтерли... Урман сукмаклары, әрәмәлекләр, ниндидер шомлы сазлык... пар-бу бөркеп торган афәт дәрьясы... Аннары тагын урман. Кара урман... Кара шәүләләр... Бер пар шәүлә, юк, кешеләр, таякка таянган карчыклар... Кая алып баралар соң аны?

Тукта! Ә теге кыз?.. Ниндидер сыеклык эчертте бу кыз Хәлимгә... Шул сыеклыкны эчкәч мәрткә китте дә инде ул. Анысы тагын нинди пәри заты?

Хәлим, баш миен каезлаган сорауларны сыгып чыгарырга теләгән кебек, ике кулы белән башын кысып тотты... Чынлап та, аның кан йөреше бераз тынычлангандай итте, уң як чигә турында чынлап торган кыңгырау тавышы да тукталгандай булды. Бераздан ул башын күтәреп, өй эченә караш ташлар хәлгә килде. Кичке эңгердә томанланып кына күренгән стеналар, өстәл-шүрлекләр, кечкенә тишектән өй эченә сузылып кергән яктылык дулкынында коенып, соңгы күзәнәкләренә кадәр балкып, күзгә кереп торалар. Тигез, пөхтә итеп кызыл балчык белән сыланган алачык стенасына берничә имән чөй кагылган; аларга юкә баулар, чыбыркы-камчылар, чыршы күркәләреннән тезелгән "төймәлекләр", гөлҗимеш дисбеләре эленгән...

Хәлим, сәкедән торып, өй эчен якты дөнья белән тоташтыручы бердәнбер тишек янына килде. Үрелебрәк тышкы якка күз салды. Ул үзе килеп эләккән дөньяны аңлауга ачкыч булырдай берәр тавыш ишетелмәсме дип, колагын тишеккә куеп тыңлый башлады. Баягы зәһәр тавышлы әтәчтән һәм аның тирәсендә "кыт-кыт" килеп йөрүче тавыклардан бышка беркем дә юк иде бу сәер дөньяда. Ниһаять, кайдадыр якында гына кеше сөйләшкән тавышлар ишетелде. "Медер-медер" килгән авазлар

якыная барып, өй катына ук килеп җиттеләр. Берсе өйгә керде, ахры, ыңгырашып ишек ачылды. Хәлим, сагаеп, кабат сәкегә утырды, бүлмә ишегеннән килеп керәсе кешене көтә башлады. Күп көттермәде, ишектә кичәге кыз пәйда булды. Ул бүген тагын да чибәррәк күренә. Бите дә алай ук кара түгел икән, чәчләре дә тигез итеп таралган, озын күлмәге дә, искерәк булса да, пөхтә һәм таза...

Кыз, тагын бер мәртәбә гаҗәпкә калдырып, салмак кына атлап килде дә Хәлимнең кулыннан тотты, аннары сак кына тышка сөйри башлады...

Егет карышмады. Бу минутта аның каршылык күрсәтерлек көчегәрлеге дә, ният-теләге дә юк иде.

Алар аланга килеп чыктылар. Үпкәләргә кереп тулган саф урман һавасына тончыга язып калды Хәлим. Бераздан тәненә ниндидер рәхәтлек, җиңеллек иңә башлады. Мәрт йокысыннан уяныргa теләгәндәй, кискен генә башын чайкап куйды. Әмма ул уяна алмады, каршысындагы манзара, стенага эленгән картина кебек, шул килеш бер үзгәрешсез калды... Шулай да, бер үзгәреш бар иде бу картинада: ике алачык арасын-дагы корылма каршына озынча өстәл куелган. Анда төрледән-төрле татлы ризыклар, кайнар ашлар, сөт чүлмәкләре тезелеп киткән. Иң мөһиме, озынча өстәлне ике яклап ниндидер кешеләр утырган... Әнә—бер-берсенә капма-каршы ике әби урнашкан. Кичәге сәер җаннар... Шунда ук ике ир кеше күзгә чалына. Алар алларына куелган балчык савыттан агач кашыклар белән тыныч кына аш-шулпа чөмерәләр. Ара-тирә өстәлгә җәеп салынган яшел суган кыякларын учлап алып, умырып ашый башлыйлар. Каткан ипи кисәкләрен шулпада җебетеп кабалар—бу да сәер тоелды Хәлимгә.

"Кемнәр болар? Мин кайда?"—дип уйлап өлгермәде, Хәлимне әлеге өстәлнең бер башына китереп тә утырттылар. Аның ашы әзер иде инде. Хәлимне алып чыккан кыз үзе өстәлнең аргы башына барып утырды.

Әллә тамагы ачканга, әллә урман, табигать һавасы тәэсир итте, Хәлимгә аш тәмле тоелды. Беренче тәлинкәне шыбырдатып чөмереп куйды, икенчесен сорап алмакчы булды. Әмма телен әйләндереп сүз әйтә алмады. Хәлим тагын бер инанды: ул телсез калган иде.

Аны аңладылар. Кыз, сикереп торып, Хәлимнең тәлинкәсен алды, бераздан пар-бу бөркеп торган кабыклы бәрәңге алып килде.

Хәлим тәмам туйды. Әмма, бу урман "пәриләрен" рәнҗетмәскә теләп, бәрәңгене соңгы тамчысына кадәр ашап бетерде. Аннары алдында торган балчык касәдәге җылымса сөтне эчеп куйды.

Өстәл артындагылар авызларына капкан ризыкларын тыныч кына чәйнәүләрендә булдылар. Хәлим мондагы кануннарны белми иде әле. Киләчәктә: "Күпме тизрәк ашасаң, көчең шулкадәр тизрәк бетә",—дигән сүзне карчыклар теленнән күп мәртәбәләр ишетәчәк ул.

Иртәнге аштан соң ике ир кеше, ишарәләп, Хәлимне алан эчендәге басуга чакырдылар. Аның "албастылар" тоткынлыгындагы тормышы әнә шулай башланып китте.

Бу тормышны "тоткынлык" дип әйтеп булмыйдыр. Хәлимне беркем дә тыймады, сакламады. Әллә шулай тоелды гына микән? Хикмәт шунда: аның күңелендә сагыну хисе, аң-зиһенендә качу уе бөтенләй юк иде. Ул бу тормышын бик табигый дип таба, салмак кына агып ятучы гомер яшәешен шулай булырга тиешле итеп кабул итә. Үткән белән иң мөһим җеп-тамырлары өзелгән, рухы бастырылган, теле алынган хәлдә яшәде дә яшәде ул. Ә көннәр бер берсенә үтә дә охшаган иде: иртән кояш белән торасың, кое суында бит чылаткач, ашап аласың да кыр янсә урман эшенә китәсең. Кичләрен соң гына кайтасың, кайткач та утар тирәсендә эш табылып тора... Кичке караңгылык биек чыршы түбәләренә кагылу белән, кереп ятасың... Беркем белән сөйләшү, аңлашу, аралашу юк... Теләк тә юк...

Хезмәт авыр түгел. Арттан куучы, аз эшлисең, аз күтәрәсең, диюче юк. Күпме булдыра аласың—эшлисең, күпме күтәрә аласың—күтәрәсең.

Хәлимнен тәненнән ташып торган көче ярап куйды. Бергә эшләүче ирләр шактый арыклар, хәлсезләр иде. Алар ярты көн эшләгән эшне бер сәгатьтә эшләп куя иде Хәлим. Башта ана тексә генә, хәтта, шикләнебрәк карап йөргән ирләр бераздан Хәлимне үз иттеләр. Хәлим моны күнеле белән тоеп, кайчакта күзләренә карап белә иде... Баштарак томанлы, жансыз-иясез күренгән күзләргә ниндидер мәгънә кергәндәй булды, беленер-беленмәс кенә нур кунды: Хәлимгә алар менә-менә сөйләшеп китәр кебек тоела иде.

Ул чакта Хәлим үзенең кол хәлендә калганын аңлап житмәгән иде шул; хәзер генә ул, аккыллыланып, барысын да күздән кичереп утыра. Ә ул вакытта... Шулай да, Хәлимнең урман эчендәге яшерен утарда үткәргән көннәре бөтенләй үк мәгънәсез булмаган икән. Ул төгәл белә: утардагы теге сәер кыз белән алар арасында нидер булды... Тик нәрсә булганын Хәлим тиз генә хәтеренә төшерә алмады...

...Шифаханә түшәгендә яткан Хәлимнең башы, тимер кыршау белән кыскан кебек, әрнеп авырта башлады. Ул, аң-зиһененә берьюлы ишелеп төшкән хатирә-истәлекләрдән арып, башын мендәр астына тыкты да изрәп йоклап китте.

Ләкин ул бу урман тормышыннан төшенә качып та котыла алмады. Анда да шул ук кол ирләр, яртылаш жиргә ингән шыксыз алачыклар, кычкырып арттан ияреп йөргән сарык бәрәннәре, арык атка аркан белән тагылган терке ботаклары... Тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр, кино тасмасында алышынып торган кадрлар кебек, Хәлимнең күз алдыннан үтеп тордылар.

Шунда... бер кызык хәл булып алды. Кино күрсәтү аппаратына лента тыгылып калганда экранда калтыранган бердәнбер кадр кебек, Хәлимнең хәтер лентасында ниндидер бер мөһим күренеш катып калды, дөресрәге, менә өзеләм, менә өзеләм дигән кебек, дерелдәп, калтырап тора башлады. Бу дерелдәвектән Хәлим кемнеңдер йөзен шәйләп калды. Ул—теге вакытта урманда аны каршы алган озын кара чәчле, шундый ук кара, ай кашлы, күк-зәңгәр күзле, яшь, сылу кыз иде. Кызның сурәте бераз жансыз килеш, өянәк тоткандагы кебек калтыранып торганнан соң, тагын кузгалып китте, йөри, йөгерә, сикерә, уйный-көлә, жырлый-бии башлады...

Шунда Хәлим барысын да кабат исенә төшерде: аның күнелендә ниндидер бик газиз, бик кадерле бер хис янарды, ул, хәтере кайтканнан соң беренче мәртәбә үзенең йөрәге барлыгын тойды...

## XV

Көннәрдән бер көнне албасты карчыклар юкка чыктылар, бер атна чамасы утарда күренмәделәр. Карчыклар утарда яшәгәндә дә Хәлим аларны бик сирәк күрә иде. Ул үзе өчен башта ук ачыклап куйды: шушы урман затларының кара сихеренә эләккән ул. Тик төгәл генә аныклап та, хәтерләп тә бетерә алмый: Каян килгән ул? Кайчаннан бирле монда яши? Бу карчыкларга, кара урман эчендә югалган бу шомлы алан-утарга аның язмыш йомгагы ничек килеп бәйләнгән?

Карчыклар үзләрен бик сәер тоттылар. Хәлим белән аралашмадылар. Ул тулысынча утарда яшәүче ике телсез-әпә ир карамагында калды. Иртәнге һәм кичке аш өстәлен карчыклар янында яшәүче үсмер кыз әзерли. Өй-алачык тирәсендәге хужалык эшләре дә шул кыз өстендә.

Хәлим башта ук игътибар итте: утарда беркем дә сөйләшми. Мал-туар, кош-корт тавышы гына һәм әллә нигә бер күренеп ала торган ниндидер йолкыш этнең ялкау өреп куюы гына бу жәһәннәм тишегендә жан иярләре яшәвен белдереп тора. Юк ла, сөйләшәләр икән. Теге яшь кыз еш кына үзалдына сөйләшеп йөри. Кайчакта урмандагы агачлар, куаклар, чәчәкләр яисә бозау-бәрәннәр белән сөйләшеп, әвәрә килә ул...

Карчыкларның тәртип-гамәлләре Хәлимне шундук шикләндерде. Кара сихер белән өртелгән бу урман дөньясының өрәкләре итеп күрде ул аларны. Карчыклар белән очрашмаска тырышты, юл-сукмаклары туры килсә дә, читкә тайпылып, урау юлдан китә торган булды.

Бу ике сихерче җәйге бер төндә урман уртасында кара мәче яндырдылар. Очлары киртләнгән озын таякның бер башын җиргә кадап куйдылар да очына тере мәче элделәр. Мәченең өзгәләнеп кычкыруына бөтен урман сискәнеп тын калды, хәтта, кичкә табан тавыш чарларга яратучы чикерткәләр дә җырларын җырламас булдылар.

Сонынның карчыклар, янып-көеп беткән мәче сөякләрен селки-селки, төн уртасына кадәр утар аланын төтәсләп йөрделәр, бу зәхмәтле урынга кара сихер индерделәр.

Ул төнне утарда беркем дә йокламады. Алачык-өйләргә, абзар-кураларга, агач-куакларга уралып калган сасы истәнме, карчыклар башкарган шомлы-сихерле йоладанмы, әпәләр дә төн буе ыңгырашып, ухылдап чыктылар, карчыклар ягыннан да "медер-медер" сөйләшкән тавышлар ишетелеп торды...

Иртән торып чыккан һәркемнең күзенә алан уртасында үсеп утыручы ялгыз тупыл агачына эленгән мәче үләксәсе чалынды. Теге ике әпә дә, урманга эшкә китәр алдыннан, озак кына шул якка карап тордылар, карчыклар янында яшәүче кыз да, шул якка карый-карый су алганда, чиләген аягына төшереп, берничә көн аксаклап йөрде...

...Бердәнбер көнне урман албастылары тагын китеп югалдылар. Шуннан файдаланып, Хәлим утарны урап чыкмакчы булды. Үзенең сәер хәл-халәтенә җавап табар кебек иде ул бу кечкенә сәяхәтеннән.

Иң элек ул үзләре яшәгән алачыкны урап, әйләнеп чыкты. Саман диварлар эченә яшерелгән тар, караңгы бүлмәләрдән салкынча шом бәреп тора. Тәрәзәләр урынындагы тишекләр йотам-йотам дип торган дию авызын хәтерләтәләр. Карчыклар ягындагы ишек төбендә матур-матур чәчәкләр, куаклар үсеп утыра, җир-сукмак та пөхтә, чиста итеп себерелгән. Һәр җирдә кызлар кулы тигәне сизелеп тора. Агачтан-агачка эленгән бауларга юылган керләр эленгән. Җепләргә тезелгән гөмбәләр, балыклар да бихисап күп, алар үзләре нииндидер бәйрәм күренеше тудыралар.

Күршедә генә кечерәк алачык. Анда беркем дә тормый. Һәрчак бикле ул, тәрәзәләре дә күренми. Бу алачыкка ике карчыктан башка беркемнең дә кергәне юк. Хәтта яшь кызның да. Хәлим алачык ишегенә колагын куеп тыңлап карады: әллә нинди шомлы тавышлар, ырылдау, улау, чинау, чыелдау авазлары ишетелгәндәй булды. Алачык ишегенә ниндидер тамга тырналган. Бу билге бик сәер—түгәрәк-бөҗра уртасында тәре, тәре үзегендә чөй кагылган... Нәрсәне белдерә ул тамга? Хәлим бу хакта белми, белә дә алмый, белергә теләми дә. Чөнки аның хәтере—бер атналык кына...

Урман эчендәрәк берничә җир өй. Берсендә ике телсез, әпә ир тора, икенчесендә ашлык, азык-төлек саклана. Аның җир идәне астына олы баз төшеп китә. Әпәләрнең өе тар, тынчу, сасы. Анда Хәлим озак кала алмады, ике катлы сәке белән тар гына өстәлгә, берничә бүкәнгә күз йөгертеп узды да, ашыгып кире чыгып китте. Суган-сарымсак исе катыш тирләгән аяк сасысыннан аның күнеле болгана башлаган иде инде. Өченче җир өйдә—кара мунча. Хәлим ул мунчаны шунда ук үз итте. Җәйге ару-талчыгудан, кышкы салкыннан саклап торган бердәнбер оҗмах почмагы иде ул утардагылар өчен.

Абзар-куралар тирәсендә дә шактый юанды Хәлим. Лапас эчендә өчме-дүртме бозау ябулы ята. Сыерлар урман буенда, көтүдә, ахры. Аранда арык кына бер ат тора, шунда ук арба-чаналар, утын кискәләре, арыраk—салам, печән чүмәләләре. Боларның барысы да ике рәт киртә белән әйләндереп алынган.

Хәлим бозаулардан учын ялатып торган арада каяндыр йөнтәс эт килеп чыкты. Килеп тә чыкты Хәлимнең солдаттан киеп кайткан

ботинкасыннан тарткалый да башлады. Хәлим аны чак-чак кына куып җибәрә алды.

Эт аны алан уртасындагы тупыл агачына табан чакырган кебек кылана иде.

Хәлим, үзе дә сизмәстән, әлеге эт артыннан шул якка табан атлады. Кырга чыкканда тирән чокырга эләгеп егыла язды. Ул шунда гына аңлады: әлеге тигез чокыр аланны урталай бүлеп тора икән. Якынрак барган саен Хәлим ныграк төшенде—бу чокыр-канауны тупыл турысында урталай бүлеп, алан аркылы тагын бер тирән, тар чокыр үтә. Хыял кошына атланып өскә, болытлар катына менгән очракта бу алан бик мәзәк күренер иде. Карчыкларның сихер алачыгы ишегенә тырнап сызылган тамганың зурайтылган сурәте төшерелгән бит бу аланга! Түгәрәк эчендә тәре, уртада... агач! Хәлим хәтер ташы астында чак-чак сулыш алып яткан аң-зиһене белән тоеп белә: бу—зәхмәти тамга һәм бу зәхмәткә аның үзенең дә турыдан-туры катнашы булырга тиеш.

Әнә ул—мәһабәт тупыл агачы. Хәлим әллә каян гына аңыша: тупыл—шул ук Туба агачы, оҗмах үзәгендә үсеп утыручы Мәңгелек Агач, Дөнья Кәүсәсе, Яшәү умырткасы... Каян белә соң ул бу хакта? Күрәсең, Изге Китап белән кергән иман шартларын, Коръән образларын сихер-зәхмәт тә йолып, юып бетерә алмагандыр...

Тупыл ботагына эленгән кара мәче үләксәсе җилдә талгын гына тирбәнеп тора. Аның янәшәсендә башка үләксәләр: каргалар, чыпчыклар, елан кабыклары, бүре тиресеннән тегеп эшләнгән курчаклар... Шунда ук төсле тасмалар, бау-җепләр... Тупыл янында баткак саз бар икән. Ныклабрак караган кеше күзенә чалынмый калмый—җир астыннан, тупыл төбеннән, тамырлары калкынып-тырпаеп торган урыннан чишмә саркып тора. Шул урынны казып, балчык чүлмәк куйганнар...

Чишмә үзенә ничек кенә тартып торса да, Хәлим тупыл яныннан китәргә ашыкты. Мондагы кара сихер аны тотып калыр, әллә нинди афәтләргә дучар итәр кебек тоелды аңа...

Шул китүдән ул аланның аргы башында тотып алынган бакча-ындырларга барып чыкты. Алар уртасында тагын бер кое, аның төбендә су чиләкләре тора. Шунда ук маллар өчен ялгашлар, ниндидер таш тәрбәләр, азык-төлек сарайлары, базлар, вак-төяк келәтләр... Төп алачык-абзарлардан аерымрак урнашкан бу төбәктә беркем дә тормый. Тик ара-тирә, бигрәк тә көзге эшләрнең кызу вакытында әпәләр кунып калгалыйлар. Бу вакытта алар ризыкларын да үзләре хәстәрли. Ашауга талымсыз бу ирләр. Бервакыт Хәлим аларның елан ите ашап утырганнарын күрде. Кайчакта, урманда эшләп йөргәндә яисә ау вакытында, бу әпәләр капкынга эләккән киекләрне чистартып, йолкып та тормыйча учак өстенә куялар иде.

...Хәлим үзенең сыек акылы белән аңларга, үз-үзенә төшендерергә тырышты. Бу—төш түгел, өн бу. Аңа менә шушы дөньяда яшәргә кирәк. Ул, кичә генә туган сабый бала кебек, берни дә белми. Ләкин ул тоя, сизә—мона кадәр ниндидер олы дөнья булган, ул күп нәрсә белгән, бик күп кешеләр белән аралашкан. Нинди дә булса эш башкарганда ул ачыктан-ачык тоя—бу эшне аның эшләгәне бар иде инде... Ләкин берни дә кыла алмый. Аның хәтере югалган, теле алынган, күңеле шыр ялангач калган. Хәлим үзенең йөрәк тибешен сизә, аның кан тамырларында кызгылт, җылы кан тибә, аяклары җир катысын тоя, куллары сизгер, күзләре үткен... Хәлим тагын шуны төгәл белә: ул—Кеше! Ул—адәм баласы! Әнә теге әпәләр кебек, әнә теге кызый кебек, ниһаять, теге карчыклар кебек... Юк ла! Бу карчыклар кеше түгелдер, ниндидер башка төрле рухи затлардыр, кара сихер ияләредер... Шушы берничә атна эчендә дә Хәлимнең сынап торганы булды, бу карчыклар янында аның башы әйләнә, күңеле болгана, болай да зәгыйфьләнеп калган аң-зиһене бутала башлый...

Хәлим кайтып кергәндә көндезге табын җыештырылган, өстәл өстендә аның өчен махсус калдырылган, өсте каплаулы итле шулпа белән өстенә калын итеп киселгән ипи телеме куелган сөт чүлмәге генә тора

иде. Күп йөрүдән, күп уйланудан Хәлимнең тамагы бик ачкан иде, ул өстәлдәге ризыкларны ялт иттереп куйды. Рәхмәт йөзеннән, баш селкеп булса да куяр өчен, утар тирәсеннән хуҗабикә кызны күзләп карады, әмма, таба алмыйча, салмак кына торды да абзарга кереп китте. Тынгысызланып пошкырына башлаган арык атны су эчәргә алып барасы бар иде аның...

## XVI

Ул көнне Хәлим гадәттәгечә иртә торды. Кош сайравы басыла башлаган вакыт. Анда-монда гына чыркылдап куйган ялгызак кош тавышына игътибар итеп тә тормыйча, Хәлим тиз-тиз генә җиенеп, тышка чыкты. Урман арасына көн яктылыгы соңрак инә. Күк йөзе яктырып беткән инде, ә урман куелыгындагы алачык тирәсе һаман әле төн пәрдәсеннән арына алмый җәфалана. Җәй уртасында гына була торган хәл: һавага салкынлык керә, үләнгә чык мул төшә...

Хәлим бер мизгелгә генә тукталып, күк йөзенә карап алды да коега табан китте. Әмма, берничә адым атлауга ук, баскан урынында катып калды. Аның әле уянып та, ачылып та бетмәгән күзләре кое янындагы шәрә кыз гәүдәсенә тап булып, шар ачылган килеш хәрәкәтсез калдылар. Күзләрдән күрә, гәүдә әгъзалары да кыймшанмас булды.

Хәлим, утарда пәйда булган көнне үлән кайнатмасы кертеп биргән кыз кое бурасына беркетелгән ялгашта юынып тора иде. Аның хәрәкәтләре шулкадәр салмак, нәзберек иде ки, зифа тәненнән, учларыннан, бармак араларыннан агып төшкән су тавышсыз-тынсыз гына яшел чирәм өстенә тамып тора. Кыз шулкадәр мавыгып юына, ул, башын артка чөеп, учларындагы суны йөзенә коя, аннары шул су агымына ияреп, кулларын бөтен тәне буйлап шудырып төшерә. Бу куллар башта йөзләрен сыпырып үтә, аннары кызның зифа, озын муены буйлап аска төшә башлый, калку, тулы күкрәкләре тирәсендә бераз иркәләнгәннән соң, биленә юнәлә һәм... ике бот аралыгына кереп югала...

Хәлимнең кызны, күп булса, дүртенче-бишенче мәртәбә генә күрүе иде. Кайчан күрсен ди ул! Иртә таңнан эшкә—урманга, кышкылыкка утын әзерләргә чыгып китәләр. Көндезгә ашны—ике сынык ипи белән берничә бәрәңге яисә какланган ит телемен, өстәп бер шешә сөтле үлән чәен—үзләре белән алалар. Кич тагын соң кайтыла. Кичке ашны караңгыда гына капкалыйлар да түшәкләренә кереп егылалар.

Хәлимгә кадәр яшәгән ике ир аерым торалар. Хәлим әлегә кадәр аңлый алмый: нигә аны алачыкта тоттылар икән? Шул ук алачыкта Хәлимне урманга алып кергән карчыклар белән әлеге кыз да яши. Аларга керү ишеге генә башка... Хәлим айнып киткәндәй булды: әйе, шушы урман дөньясында менә инде берничә атна яшәвенә карамастан, ул бу кызны бик сирәк күрә иде.

Кыз юынды да юынды. Хәлим, тычкан сагалаган мәче кебек, һаман да бер халәттә, бер мыскал да кузгалмый тора бирде. Аның йокысы тәмам ачылып бетте. Ул үз хәленнән кыенсына да башлаган иде инде. Менә ул, кире борылып алачыкка кереп китәргә уйлады. Әмма... атлау өчен аякларын алыштырып куюы булды, сукмакта яткан коры ботакның шартлап сынуы булды. Иртәнге таң балкышы яктылыгында суда коенучы кызның куллары асылынып калды, учындагы су, зифа тәненә килеп житә алмыйча, үлән өстенә агып бетте... Кое янында торган сихри сын салмак кына алачык ягына борылды. Хәлим дә алачыкка таба борылып беткән иде. Әмма шул килеш тә кызның карашын тоеп алды; тоймаслык та түгел: бу караш учакта кызган ук очы кебек, аның аркасын яндырып-көйдереп керә иде...

Хәлим алачыкка ничек барып житкәнен, ничек кергәнен сизми дә калды. Бераз һуш җыйганнан соң, аланга чыга торган түгәрәк ишек янына килде, тышка күз салды. Әлбәттә, аны бу мизгелдә бары тик теге

кыз гына кызыксындыра иде. Тик бу юлы кое буе буш иде, бары тик аның тирәсендә җәелеп яткан яшел келәмдә су тамчыларының иртәнге кояш нурларында җем-җем килеп елмаешуы гына күңелгә ниндидер җанлылык, күтәренкелек биреп тора. Шушы көннән башлап Хәлим кызны оныта алмады.Нәрсә генә эшләсә дә, кая гына барса да һаман шул кыз турында уйлады. Үтә күренмәле зифа гәүдәсе, кояш нурлары кагылуга да калтыранып куя торган нечкә биле, калку нәфис күкрәкләре, биленә җитеп үскән куе кара чәчләре күз алдына килә дә баса... Хәзер аңлый Хәлим: аның бит гомер тактасы, язмыш кенәгәсе буп-буш булган ул вакытта. Үткәне убылып әллә кая киткән, киләчәге... Ә менә, яшәеш көнендә аның өчен бердәнбер матурлык шушы сихри урман кызы булган.

Ләкин ничек кенә тырышса да, Хәлим кызны бик сирәк күрә иде. Кайчакта иртәләрен бергә ашыйлар, кайчакта кичен кайтмаган сыерларны куарга чыгалар. Шулай бердәнбер көнне сыерлар кайтмый калды. Карчыкларның шомлы пышылдашуын, ирләрнең озаклап урман авызына карап торуларын күргәч, Хәлим уйлап куйды: нәрсәдер булган сыерларга. Гадәттә, маллар күршедәге калку аланлыкта йөриләр, урман эченә бик кермиләр. Бу юлы аларны ни дә булса куркыткан ахры, әле генә күз алдында йөреп яткан ике сыер кинәт кенә юкка чыкты да куйды.

Карчыкларның калкурагы ишарәләп кенә кызны чакырып китерде. Ана, кулындагы таягы белән сыерлар аланына төртеп күрсәтә-күрсәтә, ашыгып нидер сөйләргә кереште. Кыз дәшмичә генә тыңлап торды да, аңладым дигән кебек, башын кагып алды, аннары Хәлим янына юнәлде. Хәлимнең йөрәге ешрак тибә башлады, тәнендә каны котырынды, уч төпләре тирләп чыкты. Шулай да ул читкә тайпылмады, каушавын сиздермәде.

Кыз Хәлим янына килеп җитте, уң кулын сузып, үзенең нәзек бармаклары белән Хәлимнең көрәктәй кулыннан тотты, аны урманга таба тартты...

—Әйдә киттек... Хәлим...

Хәлим, ниндидер көчле гипнозга эләккән кеше кебек, теләсә-теләмәсә дә, кыз артыннан кузгалды. Бераз баргач, кыз кулын ычкындырды, аннары, күз ачып йомганчы, урман куелыгында юк та булды...

Кызның житезлегенә, елгырлыгына сокланып, гаҗәпләнеп торырга Хәлимнең вакыты юк иде. Ул да йөгерә-атлый урман эченә барып керде, агач араларыннан кыргый җәнлек кебек "шуышучы" кызны күреп алды. Әйе, кыз бу минутта шуышып барган чын киек кебек иде. Ник бер "шарт" иткән тавыш чыксын! Әнә Хәлимнең аяк астында тәмугъ кисәүләре янган тавышлар чыгып кала. Аның авыр солдат ботинкаларына юан агач кәүсәләре дә түзми—баскан саен шапылдап яисә ухылдап калалар...

Кызның аягында куныччы тезгә кадәр күтәрелгән җинелчә тире итек, бу итек табанына юка агач кагылган. Озын күлмәк итәкләре һава кебек җинел, аның чабулары, куакларга эләгеп, ачылып-ачылып китә, шул вакыт аның матур, зифа аяклары балкып күренеп кала. Хәлим барган уңайга һич алдына карамый, кызның әнә шул аяк-ботларына карап бара, бу күренештән үзенчә тәм таба, күңелендәге шомлы бушлыкны тутырырга тырыша иде...

Иелә-баса, мәче кебек кача-поса, урман эченә кереп барган кыздан ничек тә калмаска кирәк иде. Ә кыз "эһ" та итми бара... Җендер бу... Хәлим тәмам арыды, бераздан аны инде кызның шәрә ботлары да кызыксындырмый иде.

Ниһаять, кыз туктады... Бармагын иренenә куйды.

—Тс-с!..—Алдагы яктылыкка ымлады. Үзе, алдындагы балан куагын ике якка аерып, алга карарга кушты. Хәлим, аланга бер күз салу белән ах итте.

Кечкенә аланлык уртасында бер сыер тора. Икенчесе яткан. Ятканы, ыңгырашкан кебек, мөгрәп куя...

Кыз икенче бер якка төртеп күрсәтте. Хәлим күпме караса да,

берни күрмәде. Берни күрмим дигән кебек, жилкәсен сикертеп куйды. Кыз тагын күрсәтте. Хәлим, нишләсен, тагы башын сузып карады. Бөтен аланны жентекләп күздән кичереп чыкты. Ниһаять, әнә анда берничә әрем башы селкенеп куйды. Юк ла, нинди әрем башы булсын, ниндидер жәнлекләр бит болар... Бүреләр? Бүреләр!

Хәлим үз ачышыннан үзе куркып, сискәнеп китте. Хәтта, читкәрәк тайпылгандай булды. Кыз моны шундук сизде. Матур иреннәрен жәеп, елмаеп куйды. Әмма бу елмаю озакка бармады, кызның йөзе кискен тартылып, ул тагын алга—алан уртасында мөгрәп торган сыерларга төбәлде.

Менә ул алга омтылды. Хәлимгә, ишарә белән, урынында калырга кушты. Шулай да, якында гына яткан калын күсәккә ымлап күрсәтте. Ал, янәсе, кирәк булуы бар... Үзе әллә каян гына кин пычак тартып чыгарды, аны авызына кабып, аланга табан үрмәләп китте. Хәлим берүзе ут йотып калды.

Кыз үрмәләде дә үрмәләде. Менә ул сыерларга якынлашты. Сыерлар моны сизенде, ахры. Кыймылдаша, тынгысызлана башладылар, жирдә ятканы бигрәк тә ачыргаланып мөгри, бер-бер зыянга тарган, ахры...

Сыерлардан ун-унбиш адым читтә утырган бүреләр дә нидер сизенде; алар, берәм-берәм, чиратлашып, утырган урыннарын алыштырдылар.

Ниһаять, кыз сыерлар янына барып житте. Барып та житте, торып та басты. Хәлимнең жаны табанына төшеп тә китте. "Ник күренде инде ул, хәзер башын ашыйлар бит моның!" дип уйлап бетермәде, бүреләр читләтеп-читләтеп алга кузгалдылар. Үзе дә сизмәстән, күсәген күкрәгенә кысып, Хәлим дә алгарак омтылды. Ул, "ә" дигәнче аланга чыгып, үлән арасына ятты. Бүреләр кызга ташланса, биш-алты сикерүдә барып житәчәк ул...

Кыз үзен бик сәер тотты. "Менә мине күрегез", дигән кебек арлы-бирле узды да, үзе бүреләргә каршы килә башлады. Тешләрендә—ике яклы пычак, түшенә күтәрелгән кул бармаклары киереп ачылган...

Бүреләр ана каршы ике яклап киләләр иде. Кыз әле берсенә, әле икенчесенә карап ала. Менә ул иелә башлады, тәмам жиргә чүгәләп бетте, аннары, дүрт аяклап йөреп китте. Шулай кул-аягында торган килеш бүреләр каршында пәйда булды ул.

Хәлим нишләргә дә белмәде. Ары-бире каранды. Кулындагы таякны тагы да жайлабрак тотты. Әмма алгарак барырга батырчылык итмәде.

Тешләренә пычак кыстырган килеш, кыз бервакыт әллә нинди ямьсез тавышлар чыгарып ырылдый башламасынмы! Бүреләр моны көтмәгәннәр иде, ахры, туктап калдылар, әмма бик азга гына туктаган булып чыктылар, әле уннан, әле сулдан урап, кызга табан шуыштылар...

Кыз тагы да хәтәррәк ырылдады, күзләрен чекерәйтеп, мангаен теге бүреләрнең мангайларына терәп диярлек, шыншый-шыншый ырылдады ул. Алар арасында ике-өч адым гына ара калган иде инде. Башын боргалый-боргалый, чәчләрен тузгытып, куллары белән үлән йолкый-йолкый бәргәләнгән кызга карап, бүреләр дә каушабрак калдылар, ахры, бераз арткарак чигенделәр, ничек килгән булсалар, шулай ук шуышып элекке урыннарына барып утырдылар...

Кыз да тынычланды, әмма урыныннан кузгалмады. Тыныч кына ырылдап тора бирде. Бераздан күзләрен бүреләрдән алмыйча гына Хәлимгә дәште:

—Китмиләр... Әзер булып тор... Хәзер башлана...

Шулвакыт Хәлимнең күз карашы ияреп өлгерә алмый калган бер хәл булды. Кыз, ияген алга чөеп, күккә карап, ачы итеп улап жибәрде:

—У-у-у!.. А-а-а!..Ау-у-у!..

Аннары сикереп торды да бүреләр өстенә ташланды. Бүреләр моны көтмәгәннәр иде, ахры. Кыз ике-өч сикерүгә, алгарак чыгып утырган баш бүре, тешләрен ыржайтып, ырылдап алды да, башын бер якка кискен тайпылдырып, куаклар арасына кереп чумды. Аның артыннан икенчесе иярде. Кыз, бер улап, бер кычкырып, бүреләр басып торган

урынга барып житкәндә, качып киткән ерткычларнын ырылдавык тавышлары басылган иде инде. Баш бүре таптанып торган жиргә барып житкән кыз, үкереп-улап шул урындагы үләннәрне, вак куак үсентеләрен йолкый башлады.

Хәлимнең күңеленә шом йөгерде: куркуыннан акылыннан шашканмы әллә бу кыз? Ялгызы бүре көтүенә каршы бармас иде, аз гына акылы булса... Хәлимнең шомы арткannан арта барды, чөнки кыз жир тырный-тырный, улавыннан туктарга жыенмый иде. Хәлим үзе дә сизмәстән кыз янына омтылды. Бүреләр кереп киткән ешлыкка тагын бер мәртәбә караш ташлады да, сак кына басып, аланга юнәлде. Хәлим барып житкәндә кыз бераз тынычланган, әмма һаман да шыншуыннан, ыңгырашуыннан, иңрәп елавыннан тукталмаган иде. Хәлим, тезенә чүгәләп, сак кына кызның иңбашына кагылды. Кыз аның кулын тоймады. Юк, тойган икән, сулкылдавын жинә алмыйча, дымлы йөзе белән Хәлимгә табан борылды. Хәлим сак кына аны үзенең куенына кысты. Кыз моны тойды. Жиргә таянып торган кулларын бушатып, Хәлимне кочаклап алды, аннары чын кешеләрчә, чын кызларча чыелдап елап жибәрде.

Хәлим нишләргә дә белмәде. Әмма ул бу вакытта кызны тынычландырырга кирәк түгеллеген белә иде. "Әйдә, еласын, яшь белән бергә бөтен куркуы, кара коты чыгып бетсен",-дип уйлады ул. Үзе йомшак кына кызның озын, куе чәченнән сыйпап торды.

Ниһаять, кыз тынычланды. Башын күтәреп, Хәлимнең күзләренә тутырып карады. Йолдызлы-айлы күк кебек тирән, чиксез иде бу күз карашлары. Гүя юеш күк йөзе читеннән якты кояш чыгып килә. Ул болытларны кысрыклый-кысрыклый күкнең икенче читенә узды, кара пәрдәне күтәреп, нурларын ирекккә чыгарды. Дөньяга ургылып яктылык килеп керде. Кызның шар ачык күзләре тарая башлады. Менә озын кара керфекләр калтыранып алдылар, ярым ай кебек кашлар дулкынланып киттеләр... Кыз, Хәлимнең күзләреннән күзен алмыйча, рәхәтләнеп елмаеп жибәрде...

Алар, бер-берсенә тотынышып, торып бастылар. Кыз салмак хәрәкәтләр белән Хәлимгә ишарәләп дәште:

—Хәлим...

Аннары уң кул очын күкрәгенә куеп, үз исемен әйтте:

—Май-йа...

Хәлим, төшенүен белдереп, кыз артыннан кабатлады:

--Май-йа...

...Сыерларга әллә ни зыян тимәгән иде. Берсенең муены ертылган, икенчесенең арт саны умырылып төшкән. Әмма сөяк-санаклары зыян күрмәгән, кан да егәрлек-хәл китәрлек күп акмаган. Хәлим белән Майя ятып торган сыерны "һай-һай"лап торгыздылар да кайтыр сукмакка төштеләр.

Хәлимнең йөрәге урынында түгел. Ул һаман-һаман артына борылып карый. Бүреләр иярмәгәнме, янәсе.

Кыз моны сизенде, ахры. Тыныч кына әйтеп куйды:

—Хәзер килмиләр инде алар. Ачлыкны курку жинде. Куркуны берни дә жинә алмый. Ул—урманда иң зур көч. Син дә курыкма. Курыкмасан—берни дә булмас...

Хәлим Майядан беренче урман "дәресе" алды. Соклануын яшерә алмыйча, ул юл буенча Майяны күзәтеп барды. Кечке энгер-меңгердә дә әнә ничек матур бит ул! Йөзендә кырыслык, горурлык катыш тәккәберлек бар-барын, әмма алар да матурайта гана бу урман кызын. Кай арада чәчләрен артка жыеп, бөтереп куйган, баш очына аклы-каралы буй тасма бәйләгән. Тасманың алгы өстенә ылыс кыстырган. Артыш ботыгы! Жен-пәриләрдән, зәхмәт-сихердән саклый торган артыш бит бу! Менә кызык...

Һич кенә дә Хәлимнең башына сыймый иде: ничек шушы яшь сылу кыз бүре өерен куркытып жибәрә алды сон? Ырылдап кына куркытып

кара син аларны!.. Нindiдер хикмәт бар монда... Сер бар, сихер бар...

Хәлим тагы уйланды: каян гына белеп бетерә икән бу кыз урмандагы бихисап күп сукмакларны? Әнә—сыерлары да белә тагын, кирәкле сукмакны үзләре сайлап, акрын гына атлыйлар да атлыйлар. Ара-тирә генә мөгрәп куялар. Савылмаган сыер гына шулай кычкыра.

Хәлимнең уйларын укып барган диярсең, Майя йөгереп барып, артта баручы сыерның имчәкләрен капшап карады. Аннары Хәлимгә борылып, алдагы сыерга төртеп күрсәтте:

—Сөтен эч. Үзенә дә хәл керер, сыерга да жиңеләер,—диде.

Хәлим аңламады. Ничек инде—эч... Кем савып бирә? Савыты да юк бит әле аның...

Ул икеләнеп, уйланып торган арада Майя арттагы сыер янына килеп, аның астына ятты, аннары, башын калкытып, жиленне учлап тотып, бер имчәкне авызына капты...

Хәлим, гажәпләнү катыш кызыксынуын жиңә алмыйча, Майя янына тизләнде. Кыз исә, имчәкне авызыннан аермыйча гына икенче сыер ягына ишарәләде. "Бар, им", —янәсе...

Хәлим үзенең тәнен үзе тоймыйча, аягына басты, алдарак туктап калган сыер янына барды. Йөзен чытып кына аның астына сузылып ятты һәм йөзенә тияр-тимәс торган кытыршы имчәкне авызына капты. Суырырга тырышып карады. Сөт килмәде.Көне буе ялансеберен йөргән имчәктән әчкелтем үлән исе килә иде. Хәлим куллары белән жиленне кыскалый башлады. Ниһаять, беренче сөт тамчысы аның теленә агып төште. Аннары икенчесе, өченчесе...

Бераздан Хәлим тәмам жайлашып житте. Ул бер ритмга төшеп, салмак кына имә башлады. Жылы сөт аның бөтен тәненә шифа биреп, агылды да агылды...

Әмма бу рәхәтлек озакка бармады. Кемдер аның иңбашына кагылды һәм:

—Йә, житте, әбиләргә дә калсын,—диде.

Хәлим, битләренә, муен-түш тирәләренә чәчрәгән сөт тамчыларын сөртә-сөртә торып басты.

Тагын кузгалдылар. Сыерларга жиңел булып китте, ахры. Адымнарын тизләттеләр. Үзләренә дә хәл керде. Шул кузгалудан башка тукталып тормадылар, кайтып та життеләр.

Утарга керә торган аланлык авызында аларны әбиләр көтеп тора иде. Кыз озак сөйләшеп тормады, Хәлимгә борылып та карамыйча, алачыкка кереп китте. Хәлим сыерларны лапаска ябарга булышты. Әбиләр йөгерә-йөгерә сыерларның жәрәхәтләрен дәвалый башладылар. Хәлим нидер сорашырлар дип көтсә дә, беркем бер авыз сүз чыгармады. Бераз таптанып торганнан соң, ул үз ятагына юнәлде. Яткач та озак йокыга китә алмады. Әбиләрнең сыер савып, өшкеренеп йөрүен тыңлап ятты. Майя хакында уйланды. Нинди кыз ул? Әбиләрнең кызы түгел ул... Бик яшь бит. Ә нинди чибәр... Күзләре ут-күмер... Иртәгә күрешерләрме? Тизрәк таң атып, иртә булып, тагын күрәсе иде аны!..

Хәлимнең күңеленә кара елан булып бер уй шуып керде:"Ә үзең кем соң син? Каян? Нигә монда яшисең? Ни өчен?"

Шулвакыт, бүлмәдә ут сүнгән кебек, аның хәтер-зиһенендә сыек кына янып торган яктылык гөлт итеп сүнде, Хәлим кеше күзенә күренми торган канатларын салмак кына кагып, мәрт йокысына очты...

## XVII

Беркөнне Хәлим утарда яшәүче ирләргә ияреп балыкка барды. Сәләмә кием кигән ирләрнең арка бөкресенә карап берничә сәгать баргач, дәшми булдыра алмады:

—Тук-тый-быз-мы?..

Хәлим арудан әйтмәде моны. Ирләр белән сөйләшәсе, якынрак танышасы килүдән әйтте. Ничә атна буе урманда утын кисеп тә бер авыз сүз сөйләмәгән кешеләр ич алар.

Ирләр, Хәлимнең әйткәнен генә көткән кебек, якындагы юан имән төбенә чүгәләделәр, аркаларындагы юл капчыгын салып, андагы ризыкларны берәм-берәм чыгара башладылар.

Хәлим дә үз капчыгын чиште. Анда берничә йомырка белән ярты ипи, көн кызуында җылына башлаган бер шешә чишмә суы бар иде.

Хәлим форсаттан файдаланып калырга ашыкты. Тотлыга-тотлыга:

—Сез кем-нәр? И-се-ме-гез ни-чек? Мин—Хә-лим, ә сез?—дип сорады.

Теге ирләр бер-берсенә карашып алдылар да, берни булмагандай, тагын ашарга тотындылар. Озак юанмадылар, итәкләренә төшкән ипи валчыкларын учларына җыеп, кабып җибәрделәр дә капчык авызын бәйли башладылар. Хәлим дә аларга иярергә мәҗбүр булды.

Бераздан нindidер күлгә килеп чыктылар. Ирләр өчен күнегелгән шөгыль булып чыкты—алар, килеп җитүгә үк, яшереп куелган җылымнарын алып, чишенеп тә тормыйча, суга кереп киттеләр. Җылымның итәкләрен тартып, як-якка казыклар кагып куйдылар. Шуннан соң гына ярга чыгып, чишенә башладылар. Чал кунган чәчләре асылынып төшкән, сакал-мыек баскан карт ирләр, өсләрендәге сәләмәләрне салгач, килбәтсез өрәкләргә охшап калдылар. Буйчан, чандыр, куе кашлы, күк-зәңгәр күзле ирнең озын җиннәре астында яшеренеп йөргән сул кулында бер бармагы юк икән. Чәнти бармагы... “Сәер,—дип уйлап куйды Хәлим, —эшләгәндә аның бу кимчелеге бер дә сизелми. Киресенчә, күп эшләгәне шулдыр әле. Аларның икесенең көчен бергә кушсаң да Хәлим егәрлеге кадәр булмас булуын, әмма бу чәнтисез бәндәнең кайчандыр әзмәвердәй ир-ат булуын чамалап белергә була иде”.

Бераз тын алгач, балыкчылар эшкә керешге. Ике әпә ян-яктагы казыкларга барып тотындылар, ә Хәлимне, ишарәләп, уртага кертеп җибәрделәр. Ул эчкә кереп, җылымның урта бауларына бәйләнгән элмәкне алга тартып барырга тиеш иде. Хәлим аңлады: эшнең иң авыры анарда. Әпәләр җәяүләп баралар, ә аңа гел йөзәргә туры киләчәк. Ул карышып-нитеп тормады, күл читендәге камышларны куллары белән ике якка аера-аера эчкә кереп тә китте.

Ярты чакрымнарга сузылган су тасмасы буйлап шактый бардылар. Хәлим арый башлады. Ярга чыгарга кушып, кулларын селки-селки кычкырып карады. Әмма әпәләр аңа игътибар итмәделәр, тездән ләмгә батып, ах-ух килеп, кулларындагы таякларын алга өстерәделәр.

Хәлимнең тәмам хәле бетте. Аяклары тыңламас, куллары күтәрелмәс булды. Ул әпәләрдән артка кала башлады. Җылым үрмәсенең аякларына уралуын тойды. Комсыз аждаһаның зур авызы Хәлимне һаман үзенә суыра, имеш, ә җылым аның кырык картасы кебек...

Хәлим, ярдәм өмет итеп, әле бер ярга, әле икенче ярга карады. Кычкыргандай итте. Аның күз карашы ярдагы бер сәер күренешне генә ятлап калырга өлгерде. Чәнтисез әпә бөтен көченә җылымның өске чабуын Хәлимнең өстенә капларга тырыша иде. Берничә тапкыр омтылып та теләгенә ирешә алмагач, ул каршы ярдагы иптәшенә ишарәләде. Хәлим үзе дә сизмәстән шул якка борылды. Анысы да, җылым селкенү ритмына ярашып, кулындагы таякны өскә чөя башлады. Җылым, судан калкына алмый торды-торды да, кинәт өскә атылып чыкты һәм, һавада бер-ике мәртәбә “канат җилпеп” алганнан соң, Хәлим өстенә килеп төште. Шул ук минутта аны бөтереп аска алып төшеп тә китте...

Шулай да Хәлим уйлап өлгерде: “Бу ике әпә аны үтерергә җыеналар бит... Кемнәр алар? Нигә аны үтерәләр... Ни өчен? Нәрсә эшләгән ул? Кемгә нинди зыяны тигән?”

Әллә күпме сораулар белән бергә Хәлимнең аң-зиһене дә, баш миеннән аерылып, читкә, каядыр өскә, күк катына очып менеп китте. Ә

ул һаман аска, күл төбенә төшүендә булды. Әмма көрәшүеннән туктамады Хәлим. Соңгы мәртәбә якты дөньяны күреп калырга теләгәндәй, бөтен булган һәм булмаган көчен жыеп өскә омтылды. Ләкин су өстенә кадәр күтәрелә алмады, бары тик уң кулы гына күл өстендә пәйда булды. Хәлим моны әллә ничек кенә тоеп алды һәм, үзе дә сизмәстән, бармакларын учына кысып, чәнтиен өскә күтәрде. Бу хакта ул үзе белмәде, моны зиһен төбендә йокымсырап яткан инстинкты эшләде. Ә инстинкт Хәлимнең балачак хатирәләре арасыннан нәсел кушаматын сөйрәп чыгарды—"Чәнти"! Малайлар Хәлимне шулай дип үртиләр, еш кына чәнти бармагы күрсәтеп жанга тияләр иде. Әнисенең сөйләгәне бар: чәнти күрсәтсәләр, әтисе дә чыгырыннан чыгып, женләнеп йөри торган булган.

...Хәлим күл буендагы чирәмдә аңына килде. Кемдер авыр йодрыгы белән аның күкрәгенә баскалап маташа иде. Кем икәнен башта аңламады ул. Бөтен дөнья әйләнә... Күк әйләнә, ярлар, куаклар, кешеләр әйләнә... Янындагы ике бәндәне Хәлим шундук танып алды: теге әпәләр бит болар! Аны үтерергә уйлаган әпәләр! Берсе, тезләнгән килеш, яр тулып чәчелеп яткан балыкларны жыя иде, икенчесе, Хәлимнең айныганын күреп, елмаеп куйгандай итте, нindидер рәхәт тойгы кичереп, егетнең үлем кыскычы белән кысылган йодрыгыннан тырпаеп торучы чәнтиен сыйпап алды, аннары үзенең чәнтисез кулларын Хәлим күзләренә якын ук китереп, әйләндереп-әйләндереп күрсәтә башлады.

Күлдә нәрсә булганын Хәлим барыбер аңлап житә алмады. Әллә батырдылар аны, әллә коткардылар... Дөресен генә әйткәндә, бу хакта аның уйлыйсы да килмәде. Исән калуына сөенеп бетә алмады ул. Шунда ук урмандагы утарда калган Майяны уйлап куйды. Күңелендәге иң матур хисләр шул урман кызы белән бәйләнгән шул.

Бераздан Хәлимгә тәмам хәл керде. Ул торып утырды, әпәләр белән бергә капкалап алды. Тотылган балыкларны ике ир үз капчыкларына тигез бүлеп салдылар. Хәлимгә авырлык китерергә теләмәделәр.

Бу сәяхәт Хәлимнең тормышын кискен үзгәртте. Хәлимгә битараф йөргән әпә ирләр аңа якынрак булырга, адым саен аңа ярдәм итәргә тырыша башладылар. Очрашканда да йөзләренә сизелер-сизелмәс кенә елмаю куна, Хәлим дә аларга елмаеп баш кага...

## XVIII

Агачларда яфраклар саргая башлаганчы, басулардагы игенне жыеп, сугып куйдылар. Бөтен эш кул эше белән башкарылды. Чалгы белән еккан игенне, бер-ике атна кояш астында тотканнан соң, урта бер жирдә ындыр табагы ясап, чүмәләләргә өйделәр дә, таяктәпәчләр белән тукмап, орлыкларын пыяла кебек тигез жиргә кактылар. Аннары, бер-ике кат жилгәргәч, капчыкларга салып, жир куенына кертебрәк төзелгән бура амбарга салдылар. Гөмбә, жиләк, шомырт, балан жыю да гөрләп барды. Майя бу эшләрнең остасы иде. Капчык-капчык кипкән жиләк-жимешне шулай ук амбарга кертеп өйделәр.

Хәлимгә һәр эшкә яңабаштан өйрәнергә туры килде. Хәтере каядыр убылып төшеп киткән иде аның. Күңелендә төпсез чоңгыл гына караеп ята... Зиһене саф, чиста булса да, аның артында нindидер салкын, шомлы бушлык иде...

Хәлим бик сәләтле, һушлы булып чыкты. Аңа нинди дә булса эшне бер күрсәтү дә житә, шундук бу эшне жиренә житкереп башкара иде. "Тән хәтере" дигән нәрсә дөрестер, күрәсең. Хәлим дә үтә сәер бер хәлгә тарган, ахры: аң-хәтере югалган, әмма тәне, куллары барысын да ятлап алып калган. Шуңа күрә дә, нindидер эшкә тотыну белән, ул аны бик тиз үзләштерә, шактый камил дәрәжәдә эшләп чыга иде.

Балык киптерү, тозлау белән дә, гөмбә әзерләү белән дә шулай булды, хәтта, кышка ит каклауны да тора-бара Хәлимгә ышанып тапшырдылар.

Хәлим килгәч, утарда бер тамакка артты. Кышка азыкны күбрәк әзерләргә кирәк иде. Утарда ит—төп ризык. Шуңа күрә, асраган мал-туар белән генә чикләнмичә, урманга вак-төяк җәнлек, кош-корт ауларга да чыккаладылар. Капкынга берничә кабан, хәтсез генә куян эләкте. Эткә дә өлеш тия иде—капкынга төлке эләккән көн—аның өчен бәйрәм көн. Кышкы кием, түшәк өчен тиресен салдырып алгач, төлкенең итен утарда яшәүче эткә ыргыталар.

Бу эт хакында аерым сөйләргә кирәктер. Аның үз исеме дә юк. Чакырганда да "Һау-һау" дип кенә җибәрәләр. Теге ике телсез-әпә авызыннан чыккан бердәнбер сүз дә шушы "Һау-һау" иде. Соңыннан Майя Хәлимгә бу эт хакында кеше ышанмастай әйберләр сөйләде. Имеш, бу эт башта эт булмаган, ә бер мәхлук кеше булган, шушы утарда карчыкларга хезмәтче булып гомер сөргән. Бервакыт бу кеше качып киткән. Кая чаклы кача алгандыр, беркем дә белми, әмма өч көн дигәндә утар ияләре—теге ике карчык аны каяндыр табып алып кайталар. Бераздан бу кеше тагын кача, тагын, тагын... Шуннан соң карчыклар аны кара сихер белән өшкереп эткә әверелдергәннәр, имеш.

Чынлап та, эткә охшамаган бу эт. Бервакыт карчыклар эт баласы алып кайттылар. Бу көчек "Һау-һау"дан курка иде, шул куркуыннан үлеп тә китте бугай ул. Берничә көн чинап ятты да җан тәслим кылды.

Менә шул "Һау-һауын" ияртеп ауга баргалады Хәлим. Капкын куярга өйрәнгән иде инде ул. Әмма аңа капкын кую ошамый. Аның тамырларында кыргый кан уянып китә дә, бераз баш күтәреп йөргәннән соң, берзаман каткан миен, ярым-зәгыйфь зиһенен дөмбәсли башлый:"Бабаңнар киек җәнлекне ничек аулаган булса, шулай аула, йөгер, чап, бәр, сук—артларыннан барып бастыр, тот, үтер!.."

Берәр җәнлек күренеп китсә, Хәлим үзе дә азартка керә, бөтен дөньясын онытып куа башлый, шушы эзәрләүдән тәм таба иде. Еш кына куган җәнлек тотылмый да, әмма ул моңа һич борчылмый, гүя бу ауда табыш үзе мөһим түгел, иң мөһиме—сунарчылык азарты, кан-сөлеккә үтеп кайнаган тиле кыргыйлык хисе...

Хәлим "Һау-һау"ның акылына шаклар ката; хуҗасының уен, ниятен белеп тора иде бу эт. Юри сынаганы булды. "Әнә анда барып бас",—дип уйлап кына бетерә, "Һау-һау" бара да баса. Ауда да килешеп киттеләр, сонга табарак куян-төлкене Хәлимнең алдына ук куып китерә иде "Һау-һау". Үрелеп сугасы гына кала.

Сугу дигәннән, утарда мылтык-мазар юк. Ау-сунар кораллары булып, таяк-тәпәч, тимер башлы сөнге яисә озын пычак хезмәт итә. Хәлим ук-җәя әмәлләп карады,әмма әллә ни кыра алмады—ялгыш атып, "Һау-һау"ның аягын яралагач, карама агачыннан бөгеп ясаган җәясен учакка тотып атты.

Утарда Хәлим тора башлагач, анда яшәүчеләрнең тамаклары туйды, өсләре бөтенәйде. Егетнең яшьлеге, житезлеге, унганлыгы аркасында кышны кышларлык утын, азык-төлек, тун-кием әзерләнде. Көзге яңгырлар башланганчы, бөтен уныш җир келәткә кереп бетте. Киртә белән тотып алынган бакчада мич чуены кебек мәһабәт, тыгыз кәбестә башлары гына агарып утыра бирделәр. Тагын чөгендер, кишер, шалкан кебек яшелчә азыгы калды әле. Хәлим ауга чыгып йөргән арада әпәләр бәрәңгене алып бетереп базга салганнар, алачык түбәләрен ябу, ныгыту чараларын күргәннәр иде.

Көзге яңгырлар ешайгач, карчыклар да утарда ешрак күренә башлады. Җәй көннәрендә Хәлим аларны биш-алты мәртәбә генә күреп калган иде. Иртәнге өстәл артында тавыш-тынсыз гына очрашуларны искә алмаганда, ул бу сәер карчыклар белән аралашмады. Шуны гына сизде: бу ике җан иясе, шәүлә кебек, әллә каян кайтып киләләр дә, бераз яшәгәч, шулай ук шәүлә кебек, тагын каядыр китеп юкка чыгалар. Алар юкта өй-хуҗалык эшләре, табын хезмәте Майя өстенә төшә, Хәлим исә булдыра алган кадәр кызга булышырга тырыша иде.

Гомумән, Майя аны бертуктаусыз үзенә тартып тора. Бу тарту кайчакта югалып-юылып бетә яза, кайчакта түзеп булмаслык дәрәҗәдә көчәя, Хәлим үзен кая куярга белми, кыз белән очрашу эзли, йоклый алмый иза чигә, газаплана... Менә хикмәт, Хәлимнең хәлен сизгән кебек, андый чакта Майя аны үзе эзләп таба иде.

...Ул көнне иртә таңнан алып кичке эңгер-меңгергә кадәр яңгыр койды. Көз башы үзен сиздерә—яңгырга ияреп салкынча җил килеп житкәч, ул алачык төбендә генә тукталып калмыйча, бөтен ярык-йорыктан кысылып булса да эчкә керергә азаплана, керә калса инде, чыгып китәргә җыенмый, шактый вакыт җаңга тиеп җәфалый иде.

Түшәктә уйланып яткан Хәлим ишек тавышын ишетмәде дә. Майя шулай тавышсыз-тынсыз йөри белә. Кайчакта Хәлим:"Стена аша да йөрми микән бу кыз?" дип тә уйлап куя.

Хәлимнең күзләре йомык. Маңгаена кагылган салкын кулны башта тоймады ул. Кулдан күчкән суык, дымлы маңгае аша ми шәрәфләрен өшетә башлагач кына күзләрен ачты. Шул ук сихри карашка, шар ачылган күк-зәңгәр күзләргә тап булды Хәлим. Кызның озын чәчләреннән тамчылар тама, өстендәге юка күлмәге манма су, беләкләре өшүдән ябыгып, бөрешеп калган...

Хәлимнең күзләре ирексездән Майяның калку күкрәкләренә төште. Юеш күлмәк аша бүртеп торган ике төймә аның күзләрен суырып алыр кебек иде.

Ни өчен шул урынга караганын Хәлим аңлата алмый. Әмма шушы калку күкрәкләрдәге бу төймәләрне тотып карау теләге аның канын кыздыра, ирлек дәртен көчәйтә иде.

Кыз да Хәлимнең карашын сизде. Хәлим ни дә булса уйлап өлгергәнче, кискен генә арты белән борылып, юеш күлмәген салып та атты, мич янындагы чыбыкка җәеп элеп тә куйды. Аннары, ауга чыккан кыргый җәнлек кебек, мыштым гына килеп, Хәлим янына менеп ятты. Яны белән борылып, Хәлимне кочаклап алды, тәненең һәр чокыры, һәр калкулыгы белән сыенып, тынып калды.

Кызның салкын тәне Хәлимне өшетеп җибәрде. Әллә кыз алдында каушау, уңайсызлану, курку аның җан түренә урамнан кергән салкын мәче булып йөгердеме? Хәлим һушын чак-чак җыеп, түшәк читендә яткан япманы тартып китерде дә кызның өстенә каплады. Нишләргә дә белмәде Хәлим. Ике айлык кына хәтер капчыгын күпме генә кармалап-капшап эзләнсә дә, ул моңа охшаган хәлне таба алмаячак иде.

Кыз тәненнән бөркелеп торган салкынлык Хәлимнең җанына үтеп керә башлады. Ул үзе дә сизмәстән читкә тайпылды. Әмма Майя аның беләгеннән нык кысып тоткан иде. Хәлим башкача тартышмады, кызның ихтыярына буйсына барып, ниндидер бер дәртле ымсыну хисе белән, үзе дә аның салкын, юеш тәнен кочаклап алды.

Хәтсез генә тын яттылар. Бер-берсенә сыенышып яткан ике яшь тән бер ритмда, бер көйдә яши башлаганнар иде бу минутта.

Хәлимнең уйлары яшен тизлегендә йөгерешә башлады. Хәзер нишләргә? Нигә керде бу кыз? Кем булып керде? Туган булыпмы? Дус булыпмы? Сөяркә булыпмы? Әллә ата-ана жылысын сагынып кергәнме ул? Кем булып юатырга, иркәләргә, назларга соң бу урман баласын? Менә бит—тәне баканыкы кебек—сап-салкын... Бөтен жан-бәгыре өшегән, ахры, бу табигать затының... Кем соң ул—урман кызы? Хәлим кебек үк бер мәхлукмы, үткәнен, хәтерен югалткан Хода бәндәсеме?

—Майя...—Хәлим авырлык белән генә сүз башлады. Урманда, утарда ул башкалар белән сөйләшми, дөресрәге, теләсә дә сөйләшә алмый. Ә менә Майя янында ул бераз бушана, аң-зиһене дә кызурак эшли, хәтер елгасындагы дулкыннар да чәп-чеп килеп дулкынлана, иң мөһиме, ул авырлык белән генә булса да сөйләшә башлый...

Бу юлы да шулай булды. Майя янында берничә минут ятуга аңа тавыш инде, аның теле ачылды:

—Майя...

—Хәлим...

—Майя, син—әйбәт кыз...

—Син дә әйбәт, Хәлим...

—Майя, син—кем, каян син?..

—Мин... мин—урманнан...

—Ничек инде—урманнан?..

—Әйе, минем әнкәм, әткәм—урман ияләре. Әбиләрем шулай диләр.

—Алай булмый, Майя... Ничек инде урманнан кеше тусын ди?..

—Була, Хәлим... Әбекәйләр мине сабый бала чагымда ук урманнан, бүре өненнән табып алганнар... Бүре имеп үскәнмен мин. Бүре балалары белән бергә. Ә бүре өненә мине урман ияләре салган...

—Майя, теге чакта бүреләр белән нәрсә булды соң? Ничек куркыта алдың син аларны?

—Алар миндә үз тиңнәрен таныдылар. Ул чакта мин алар каршына бүре булып чыктым. Миндә ике төрле кан ага—бүре каны белән адәм каны. Ул чакта бүре сөте белән кергән кан котыра иде, менә шул куркытты да ерткычларны. Мин бит бүреләрнең күзенә туры карый алам. Гадәти адәм баласы бүре күзенә карый алмый. Минем көчем дә шунда...

Хәлим башын күтәреп, кызның йөзенә карады... әмма йөрәге "жу" итеп китте. Аңа таба ике утлы күмер кисәге карап тора иде... Икенче мизгелдә бу куз-күмерләр жем-жем итеп алдылар да тоныкланып калдылар, күксел төскә кереп, ялтырап, балкып тора башладылар. Хәлим Майяның чәчләренә кулын тидерде. Бармак очлары белән генә кагылып, маңгай, кашлар өстеннән сыйпап үтте, бераздан аның көрәктәй учы кызның ябык, әмма күркәм йөз-битләренә төшеп ятты. Яшь, гөнаһсыз тәннәреннән бөркелеп торган дәрт-энергиядән тәмам җылынып, изрәп беткән ике гәүдә бер-берсенә тартылдылар...

Әмма шул вакытта "Һау-һау"ның тонык кына өргәне ишетелде.

—Әбиләр...—дип пышылдады Майя. Менә ул Хәлимне соңгы мәртәбә кысып кочты да, торып, күлмәген киеп куйды. Аннары сәкедә ятып калган Хәлимгә борылып карады. Кызның күзләре урынында берничә минут элек янып алган ике күмер кисәге кабат пәйда булды. Ләкин бу юлы Хәлим ул ут бөртекләреннән курыкмады, киресенчә, алар бу юлы нурлы йолдызлар кебек мөлаем жемелдәп күренәләр иде.

Майя чыгып киткәч тә Хәлим шактый уйланып ятты. Ул йортның икенче башында пышан-пышан сөйләшүче карчыкларны да, бер караңгы почмакка бәйләп ташланган, кыйналудан күгәреп беткән тәнен салам өеме астына яшереп елап ятучы Майяның әкрен ыңгырашуын да ишетмәде. Зиһен савытында бөтерелеп йөргән бер фикер аңа йокларга ирек бирми иде: "Үзе хакында ник сорамады ул Майядан. Аның тән кабыгында яшәп ятучы Хәлим—кем ул? Каян ул?" Майя беләдер. Ул белергә тиеш... Ул бит сихергә, тылсымга ия... Ул бит гадәти кеше түгел, ул—рух, урман рухы... урман рухы... урман..."

## XIX

Бер көнне утар аша аучылар узды. Иртән иртүк сәер башланды бу көн. Әле кояш кыздырып, әле салкынча янгыр явып торды. Кояш белән кара болытлар көрәшкән мәлдә зәһәр жил-давыл кузгалып, агачлар бертуктаусыз ыңгырашып, гүләп тордылар. Кояш күренүенә жил туктап кала, болытлар күк йөзен томалый башлауга кабат кузгала.

Бу көнне Хәлимнәр абзар-кура тирәсендә эшләп йөриләр иде. Төшке аш вакыты якынлашып килә. Жанга тигән янгыр да басыла башлады. Күк йөзе ачылып, яктырып китте. Нәкъ шул мәлдә Хәлим яшәгән алачыкның икенче ягында жанлану башланды: теге сихерче карчыкларның ашыгып-ашыгып сөйләшүе ишетелде, кереп-чыгып йөрүләре дә ешайды...

Менә алар Хәлимне алып кайтканда кигән кара япмаларын ябынып

чыктылар да йөгерә-атлый урман эченә кереп югалдылар. Абзар эченнән йөгереп чыккан ике әпә озак кына карчыклар киткән якка карап тордылар. Аларның йөзенә курку катыш шом кунган иде...

Ун минутлар чамасы вакыт узгандыр, урман эченнән тонык кына эт өргән тавышлар ишетелә башлады. Бу тавышлар көчәйгәннән көчәеп, аланлыкка һаман якыная бардылар. Менә бервакыт кара урман авызы этләр ияртхән ике аучыны аланлыкка чыгарып җибәрде. Зәһәр өрә-өрә алга ыргылган этләренә чак-чак кына өлгереп, йөгерә-атлый барган аучылар үзләрен бик сәер тоттылар. Гүя алар аланлыктагы алачыкларны, абзар-кураларны, ындыр-бакчаларны, сукмак буенда гына торган коены бөтенләй күрмиләр иде... Аучылар ничек тиз килеп кергән булсалар, аланлыкның аргы башына китеп, шулай ук юк та булдылар. Әмма алар күздән югалсалар да, этләр тавышы шактый вакыт утар өстен шомландырып торды әле.

Хәлим анлады: аучылар кеше торган утар аша үтүләрен белмәделәр дә, сизмәделәр дә. Димәк алар да сихер-зәхмәткә тап булдылар. Алар да алдандылар. Әлбәттә, бу да—теге карчыклар эше.

Урманда яшәгән гомер эчендә Хәлим башка чит-ят кеше күрмәде. Шулай да, эт ияртхән аучыларның бу якларга килеп чыгуы аның күнеленә корт кертте. Өмет корты. Хәлим бөтен зиһенен туплап уйланды: кайдадыр башка дөнья бар... Хәлим дә әнә шул билгесез дөньядан килеп чыккандыр бу Алла каргаган җиргә...

Өмет шундый нәрсә бит ул: күнелгә яшәү дәрте, яшәү мәгънәсе бирү белән бергә тормышны тынгысыз итә, бертуктаусыз җан-бәгырьне бимазалап, “кимереп” тора. Хәлим дә тынычлыгын югалтты. Әмма бу рәхәт тынгысызлык иде. Аның зиһене төбендә ачык бер максат барлыкка килде, Хәлим кешелек сыйфат-хасиятләренен янадан уянуын, терелүен сизде. Аның томалап алган сихернен кимүен, бушануын тойды. Аның хәтере кайтмаган әле, әмма ул инде үз акылында, һушында...

Хәлим качып китәргә карар кылды. Ләкин Майяны күрмичә, аның белән хушлашмыйча китәргә теләмәде ул. Нигәдер сонгы көннәрдә күренми башлады бу кыз... Авырып киттеме әллә?.. Әллә... Әллә теге көнне Хәлим белән бер түшәктә ятуыннан оялып йөриме? Табынны да карчыклар үзләре әзерли. Табак-савытны да карчыклар юа. Сыерларны да алар сава. Гүя мона кадәр Майя булмаган да...

Хәлимгә бу бик сәер тоелды. Ул карчыкларның берәр кая чыгып китүен көтеп йөри башлады. Әмма, үч иткәндәй, теге зәхмәтләр беркая да китәргә җыенмыйлар. Димәк, Майя янына ишек аша керү мөмкин түгел. Тәрәзә тишекләре дә эчтән томаланган. Нәрсәдер булган монда, ниндидер сер бар. Әнә бит—бер атнадан артык инде Майяның тышка чыкканы юк... Әллә аны да берәр сихергә юлыктырганнармы бу хәшәрәтләр?

Ниһаять, Хәлим уйлап тапты. Ул, карчыклар ягы белән бүлеп торган саман диварны тишәргә, шул тишек аша Майя белән элемтәгә керергә, бу сәер хәлне ачыкларга булды. Чалгы очыннан ясалган пычак белән бораулап, өч көн тиште ул саман кирпечне. Карчыклар көннен күпчелек вакытын алачыкта уздыралар, үч иткәндәй, бу көннәрне Хәлимне дә аланның аргы башындагы келәтләргә эшкә җибәрә башладылар. Аннан-моннан вакыт урлап булса да, Хәлим өч көн дигәндә ике карыш калынлыгындагы саман кирпечне тишеп чыкты. Тишеп үк бетермәде, шул тишек аша кеше сөйләшкән тавышлар ишетелә башлау белән, туктап калды. Карчыклар өйдә иде бу вакытта...

Карчыкларның козгын-карга каркылдавын хәтерләткән тавышлары ишетелми башлагач та Хәлим бераз көтеп торды әле. Әһә, Майя үзе генә калды ахры... Тукта, ул мондамы сон? Баягы сөйләшүдә кызлар тавышы ишетелмәде бит...

Менә ул йөзен тишеккә терәп диярлек куйды да, ярымпышылдап:

—Майя...—дип эндәште.

Әлбәттә, бу пышылдау авазын Майя ишетмәячәк иде. Хәлим, нәрсә

булса шул булыр дип, бөтен дөньясына кул селтәп, кычкырып дәште:

—Майя!

Дивар артындагы бүлмәдә нәрсәдер шыгырдады. Идән ахры... Нәрсәдер шыбыр-шыбыр килде, шуыша башлагандай итте... Салам шыбырдаган тавыш бугай...

Хәлим тагын дәште:

—Майя, син мондамы?

Ишек аша таныш тавыш ишетелде:

—Хәлим... Хәлим...

Кыз елый иде...

—Майя, син өйдәмени, ник чыкмыйсың?..

—Хәлим...—Майя сулкылдап-сулкылдап елый иде.

—Майя, нәрсә булды сиңа? Нигә юкка чыктың?.. Майя әйт инде...

Бераз дәшми торганнан соң, авыр сулап куйды да, кыз сүз башлады:

—Хәлим... Мине әбекәйләр бәйләп, ябып куйдылар. Синең белән бергә булуымны сизгәннәр... Теге көнне иснәделәр-иснәделәр дә, кыйнап, кертеп бикләделәр. Алар ис буенча да сизәләр бит... Эт кебек...

—Нигә миннән куркалар соң алар? Мин кем соң, Майя?

—Синең кем икәнлегеңне мин дә белмим. Синең сереӊ сихер тамгасында... Әмма минем белән аралашкан чакта сиңа йоккан сихер, зәхмәт кими башлый... Мин моны беләм.

—Майя, мин качам моннан...

—Ай-һай, кача алырсың микән, Хәлим?.. Әбекәйләр бик сизгер бит... Урман эчендәге сихер чиге дә куркыныч. Әбиләр булмаса да, бу сихер чиге кешенең ис-һушын ала, ди...

—Аны ничек белергә соң?

—Саргылт он тузаны сибелгән җир күрсәң, сихер читенә җиткән булырсың. Аңа кагылырга, хәтта якын барырга да ярамый.

—Майя... —Хәлим, әйтергә ниятләгән сүзен оныткан кеше кебек, төртелеп, тукталып калды.

—Нәрсә, Хәлим?

—Майя... Әйдә бергә качабыз. Ничек тә икәү яшәрбез әле... Майя, ә?

Майя бераз тын калып торды. Аның авыр итеп сулаганы, ара-тирә уфылдап куйганы ишетелә иде.

—Юк, Хәлим, моннан кача алмыйм... Мин бит бу әбиләргә гомерем белән бурычлы. Аннары... аннары, качсам, әбекәйләр мине бик тиз табачаклар, чөнки минем исне, җылыны алар бик яхшы беләләр. Минем аркада син дә бик тиз харап булырсың... Качсаң, үзең генә кач, Хәлим...

—Майя, мине онытма яме...

—Хәлим, син дә мине онытма... Бүре кызы Майя мин—онытма...

—Майя, ә нигә синең исемең шундый сәер?

—Май-Майя—Күк алласының, бөтен дөнья алласының хатыны... Кояш кызы... Мин шул алиһәнең исемен йөртәм. Минем бүлмәдә бу алиһәнең сыны да бар...

—Майя... мин сине алырга киләчәкмен. Көт син мине яме...

—Миңа нәрсә булсын... Үзеңне сакла, Хәлим...

—Мин киттем, Майя. Әбиләр өйдә юк чак, тизрәк урманга кереп китәргә кирәк. Сау бул, Майя. Мине онытма... Онытма...

Соңгы сүзләрен ярымпышылдап әйтте Хәлим. Ниндидер эчке мәгънә биреп, бөтен җанын салып әйтте... Үзе, Майяның җавабын да көтеп тормастан, ашыгып чыгып китте. Урманга керә торган сукмак буенда аңа "һау-һау" иярде. Хәлим куып та карады, таяк-мазар да атты, әмма эт калмады.

Хәлим йөгерә-атлый шактый барды. Бер-ике чакрым киткәч тынычланды, адымнарын акрынайтты. Утырып хәл алды. Шунда гына, фикерен бер ноктага туплап, уйлый башлады: "Кая бара ул? Бу урманның берәр чиге бармы? Эчәргә су да, ашарга бер телем ризык та алмады ласа... Эте дә, телен асылындырып, башын кырын салып, салкын карап тора Хәлимгә...

—Йә, нәрсә кирәк сиңа миннән? Ник иярдең? Әллә дөресме,

кайчандыр син дә качкан иденме? Син дә кеше иденме? Менә минем кебек... Ә?..

"Һау-һау" ыңгыраша-шыңша сузылып ятты, ике аягын алга сузып, башын аяклары өстенә салды, күзләрен йомып, тынып калды. Нәрсә әйтергә теләде эт—Хәлим аңламады...

Ул юлын дәвам итте. "Һау-һау" да, сикереп торып, аны чабып узып китте. Ул, хуҗасына тугры этләр кебек, бераз алга йөгереп китә дә, Хәлимнең килеп җиткәнен көтеп ала, тагын алга китә, тагын көтә. Ул шулай хуҗасына ачыграк урыннарны, йөрергә җиңелрәк сукмакларны сайлап күрсәтеп бара.

Менә бервакыт "Һау-һау" шыңшып куйды. Хәлимнең беренче уе елан хакында иде. Елан-мазар күренмәде. Әллә тәпие шырпыга яисә ике ботак арасына кысылганмы? Якынрак баргач, Хәлим гаҗәеп күренешкә тап булды. "Һау-һау" кечкенә ачыклык уртасында тырпаеп утырган агач төбе янына сузылган да, башын селки-селки, шыңшып-чинап, бәргәләнеп ята. Хәлимнең күзе төп өстенә төште: аның йөзлегенә саргылт он тузаны сибелгән. "Сихер чиге"нә җиттем, дип уйлап өлгерде Хәлим һәм... әллә ничек кенә башы әйләнеп китте. Әмма егылмады, якындагы кушкаенга тотынып калды. Бераздан ул айныды, баштагы авырту, зәһәр чынлау кимеде; аның өши башлаган күңеленә тагын ышаныч катыш өмет нуры кереп тулды. "Һау-һау" калдымы-юкмы, борылып карарга да кыймады Хәлим, барды да барды. Егәрлеге тәмам беткәч кенә утырып хәл алырга булды. Алда тын-сулышны кинәйтеп җибәрә алырлык ачыклык эзләде. Әһә! Әнә анда ак тап бар. Утырып торырга агач төбе дә тора... Хәлим шунда омтылды. Әмма караеп торган төпкә җитәргә ике-өч адым калгач, сөртенеп китте дә келәм кебек тигез, яшел үлән өстенә капланды. Башын калкытмакчы булды. Әмма бу вакытта аның буыннары йомшап калган, баш мие мәлҗерәгән, күзләре әйләнеп чыккан иде инде. Ул, хәтта, янында буыла-буыла мышнап яткан "Һау-һау"ны да, борын төбендәге төп өстендә саргаеп торган тузан өемен дә күрерлек хәлдә түгел иде.

Үзенең берничә чакрым урап, кабат шушы "зәхмәт чиге"нә килеп чыгуын да белми калды Хәлим. Белсә, аның белән берәр хәтәр хәл булыр иде, мөгаен. Хәтәр хәл булмый калды, чөнки бу—Ходай тәгалә Хәлим язмышына билгеләгән сынауның башы гына иде әле...

## XX

...Хәлим ниндидер су шыбырдавына уянды. Уянды, әмма күзен ача алмады. Аның бөтен аң-зиһенe бөтәшеп каткан, көчегәрә ташлап киткән. Шулай да, зиһен тәгәрмәче акрын гына әйләнә: "Кайда ул? Нинди су-чишмә буенда ята? Янда берәрсе бармы? Тукта, ул бит качып китеп бара иде... Кача алдымы соң? Әллә... Бу—бөтенләй яңа дөньямы?.."

Хәлим теләсә дә ачты күзләрен, теләмәсә дә ачты. Әмма соңыннан нигә ачканына үкенде. Ул сихерчеләр утарындагы алан уртасында үсеп утырган тупыл төбендә чалкан төшеп ята, имеш. Кул-аякларын як-якка җәеп ташлаган, аларны кыймылдатырга һич ирек юк...

Су дигәне шушы тупыл агачының җилдә шыбыр-шыбыр килеп утыруы икән. Җил көчәйгән саен шыбырдау көчәя, басылганда шыбырдау тынып кала. Тагын көчәя, тагын тына...

Тукта, тупылның яшел ябалдашлары эчендә нәрсә караеп тора соң анда? Ниндидер җәнлек, ахры... Юк, урман җәнлеге түгел бу. Бу... утар эте бит, "Һау-һау"ласа бу! Нигә аны асканнар, нигә элеп куйганнар соң? Нинди гаебе бар бу мәхлукның? Шунда ул үзенең качырга җыенуын, ана "Һау-һау"ның ияреп баруын исенә төшерде. Йөрәге "жу" итеп китте: "Димәк, кача алмаган... Тотылган икән... Тотып алып кайтканнар аны..." Шунда ул тагын аңын югалтуын тойды. Бөтен тәне-җаны белән убылып, ниндидер кысан, караңгы коега төшеп китте ул...

Бераздан кое очында ачыклык күренде. Якынайды, якынайды да күзләрне авырттырырлык итеп ачыла, яктыра башлады. Хәлимнең күз алдында тагын тупыл агачы пәйда булды. Тик бу юлы тупылны ак борчаклар төшерелгән кара җәймә чорнап алган иде. Юк ла, кара җәймә түгел икән, бу күк йөзе икән. Ак, җемелдәвек таплар—күктәге йолдызлар икән...

Хәлим кулын кузгатырга тырышып карады. Бармакларында җанлылык сизде, әмма кул-аякларын җыеп ала алмады. Алар дүрт якка кагылган чөй-казыкларга нык итеп бәйләп куелганнар иде. Бер карыш, хәтта бер илле дә кузгалырлык түгел.

Кайсыдыр яктан җылылык тойды Хәлим. Учак бит бу! Ниндидер зур учак, шартлап янган кисәүләрдән купкан очкыннар багана булып күккә күтәреләләр. Бераз күтәреләләр дә күктәге йолдызлар белән кушылалар, кара җәймәдәге ак бөтерчекләр санын күбәйтәләр.

Хәлим каяндыр тоньк кына ишетелгән барабан тавышларына игътибар итте. Башын күтәреп алачыкларга таба карады. Аннан шомлы-салмак кына шуышып, ике кара шәүлә килә иде. Берсенең кулындагы утлы кисәүдән йөзләренә яктылык төшә. Очлы, кәкре борыннары, алга бүлтәеп чыккан килбәтсез иякләре күзгә чалынып китә, төпсез күзләреннән ниндидер дымтөтен ургылып тора кебек ...

Берсенең кулында барабан кебек нәрсә бар. Ул барабан, карчык суккан саен, үләр алдыннан соңгы тапкыр калтыранып куйган мал-туар кебек, селкенеп-калтыранып ала. Карчык билгеле бер ритмга ярашып, барабанны сак кына кагып килә. Утлы кисәү тоткан икенче карчыкның кулында ниндидер үләннәр, ботаклар көлтәсе...

Хәлим ачык сизде: аны җәзага тартачаклар. Ниндидер сихри йола башкарылачак хәзер. Барабан тавышы һәм учак шул зәхмәт туенның иң беренче һәм иң шомлы хәбәрчеләре иде.

Әбиләр Хәлим яткан чирәмлеккә якын ук килделәр. Кулына үлән бәйләме тоткан карчык, учак өстенә килеп, бер кочак дымлы үләнне ут өстенә ташлады. Учакка бу ошамады, ахры, ул төн йөзенә саргылт-көрән төстәге төтен болыты атты... Бу төтен тирә-якка җәелә башлады, ул гына да түгел, тиз арада бөтен дөньяны сасытырга өлгерде.

Карчыкларның берсе әчкелтем, сасы төтенне Хәлим ягына куа башлады. Бу гына ярдәм итмәгәч, учактан янып-пыскып яткан бер-ике куак ботагы алып, корбанын төтәсләргә керешге. Икенче карчык барабан кагуында булды. Анысы, салмак кына атлап, җиргә казыклар белән шыплап беркетеп куелган Хәлимне урап-әйләнеп йөри. Урталыкта яшькелт-соры төтен бөркеп, зәхмәти йола башкаручы шаман карчык ара-тирә сәер тавышлар чыгарып куя—әллә көйли, әллә мәҗүси догалар укый...

Бу төтенгә Хәлим башта әллә ни игътибар итмәде. Бирешмәде. Әмма бераздан сәер халәткә керә баруын сизде. Ул бөтен барлыгы белән ниндидер җинеллек, рәхәтлек тойды. Һәр нәрсә матур булып күренә башлады: төн көнгә әверелде, агачлар жете яшел төскә керде, мәҗүси бию башкаручы сихерче карчыклар гүзәл кызлар кыяфәте алды...Кигән киемнәре дә ап-ак иде аларның, йөзләре дә, куллары да ап-ак. Гүзәл кызларның берсе якын ук килде дә, иелеп, Хәлимнең күзләренә бакты. Кышкы елга бозы астыннан якты дөньяга карап торган кебек халәт кичерә иде Хәлим.

—Уяна... Аңына килә...—диде теге кыз. "Кем уяна? Нигә уяна? Ничек аңына килә! Үз аңында ласа ул... Тик... теге карчыклар кая киткән соң? Учак кая киткән? Сихерчеләр утары кайда? Нигә бу кадәр дөнья ак соң әле?..

...Хәлим тәмам уянып житте. Тагын берничә мизгел төш белән өн арасында бәргәләнеп торды да фани дөньяга, шифаханәдәге ап-ак бүлмәгә, шундый ук халатлар кигән, ап-ак йөзле шәфкать туташлары янына, ниһаять... күрше караватта ап-ак мендәргә башын төртеп йоклап киткән әнисе янына кайтты...

## XI

Шифаханәдә бер атналап юангач, Хәлимне авылга озаттылар. Баш ярасы төзәлеп, ярым йокылы саташулар кимегәч тә, Хәлимгә бер айлап өй тирәсендә булырга, ятыбрак торырга куштылар. Баш мие кузгалып, ан-зиһененә зарар килмәсен тагын, дип шикләнделәр.

Хәлим төшендә Майяның исемен әйтеп саташкан, ахры. Ниндидер албастылар, сихерче карчыклар хакында сөйләнгән, хәтта, эт булып өреп тә күрсәткән ул. Хәлим боларның зиһен ялгышуы түгеллеген анлый, әмма бу хакта әйтергә кыймый; чөнки ул белә: урманда күргәннәрен сөйли башласа, аны ике дә уйлап тормыйча тиләләр йортына ябып куячаклар.

Авылга кайткач, Хәлим бераз тынычланды. Шулай да, уйлап-уйлап, тагын бер гажәпләнеп куйган чаклары еш була: менә бит нинди язмышка дучар булган ул! Ничек килеп чыкты соң әле бу? Нигә аны сайлаганнар бу ачы, шомлы, зәхмәтле сынау өчен?

Тагын аптыраш: чәнти бармаксыз кеше—кем ул? Әллә?.. Әллә әтисеме? Ни өчен әтисе аны үтермәкче булды соң, алайса? Ни өчен кабат коткарып калды? Кем ул—Майя? Кемнәр алар—албасты карчыклар?..

Төрле уйлар белән гөжләп торган тубал башын кая куярга белмичә, кайчакта Хәлим агач юна башлый... Төрле җәнлек, кош сыннары ясый... Кечкенәдән килгән гадәте иде ул аның. Армиядә чакта да бераз шөгыльләнде. Менә тагын җай чыкты.Бу вакыт дигәнен ничек тә уздырырга кирәк бит. Урман хакында уйларга курыкты Хәлим. Качып тотылган кöне белән өзде дә, хәтер йомгагының җеп очын чияләйләп бәйләп куйды ул. Уйлар урманга таба йөгерешә башлау белән, шул чияләнгән очны таба да тартә-тартә эчкә кертеп, күренмәслек итеп яшерә торган булды.

Кая алай гына яшереп бетереп булсын инде уйларны! Бер ел буе биктә яткан хәтер котырыпмы-котырына, нинди әмәл кылырга да белгән юк... Бигрәк тә Майя хакында уйлый Хәлим. Нәрсә хакында фикер кузгатса да, аның очы шул урман кызына алып чыга, Майяга булган иң газиз, иң матур хисләренә барып ялгана...

Бер көнне Хәлим үз-үзенә аптырады: кулындагы агач кисентесеннән ниндидер кыз сынын юнып ята ласа ул! Майя сынын! Менә нинди хикмәтләр була икән бу дөньяда...

Улының күнеле утыруын, зиһене яхшыруын, торып йөри башлавын күреп, Сания дә тынычланды. Ак бабай да еш керә. Башка күршеләр дә Хәлимнәр капкасына юлны онытып бетермиләр. Хәтта бер аулакта Нәфисә дә кереп чыкты. Хәлим белән күзгә-күз карашып тордылар да, саубуллаштылар. Бөтен очрашу-күрешү шул булды. Хәлимнен күнеленә Майя кереп утырган, ә Нәфисә, үз язмышына буйсынып, үз яшәеше белән тәмам килешкән иде...

Кыш үзенекен итте. Салкыннарын да, карын да, буранын да кызганмады. Кыш котырынган саен Хәлимнен уйлары да, буранга ияреп, кабат теге зәхмәтле урман аланлыгына, албастылар утарына исә башлый. Чөнки узган кыш та шулай ук бик салкын һәм көртле булган иде.

## XXII

...Хәлимне кара сихер белән өшкергән иртәдә беренче кар төште. Ул өшеп-калтыранып уянып киткәндә җир өсте агарып өлгергән иде инде. Яңа кар озак тормый, дымсу үләнгә куна бара, шунда ук эреп тә бетә. Эрегән кар бөртеге урынына икенчесе төшә, өченчесе, дүртенчесе. Шуларның кайсыдыр эреп өлгерә алмый кала, бу тере кар бөртеге өстенә төшкәннәр тагын да кыюланалар... Шул рәвешле кар япмасы калыная, көрәя...

Тирә-якта җан иясенең әсәре дә юк. Урманның аргы ягында күккә багып торган наратлар артыннан таң атып килә. Урман тынып калган.

Талгын гына төшеп килүче кар бөртекләре бу тынлыкка сихри ямь бирәләр.

Хәлим торып утырды. Учак урыныннан күккә таба нечкә генә төтен тасмасы сузыла. Хәлим юештә, пычракта җәелеп яткан гәүдәсен җыеп ала алмыйча озак кына интекте әле. Ниһаять, ул торды, өстен каккалады, аннары, берни булмагандай, алачыкларга таба китте. Ни хикмәт, бу мизгелдә аның башында бернинди кайгы да, борчу да юк иде. Хәлим өчен боларның барысы да табигый, шулай булырга тиеш кебек тоелды.

Кереп яткач та берни уйламады ул, өстендәге күлмәген җылымса мич буена салып элде дә түшәгенә менеп ятты. Тиз генә йокыга китә алмады. Әмма ул инде элекке кебек уйлау сәләтеннән дә мәхрүм иде. Хәлим бу хакта әле аңлап та, төшенеп тә бетми, әмма яхшы тоя: хәзер ул тулысынча кара сихер карамагында, албастылар ихтыярында...

...Кыш керде. Урман карга күмелде. Үтә дә ямансу, бертөрле тормыш башланды. Хәлим хәтерли: иртән тора, зур алачык эчендәге бер бүлмәдә иртәнге ашны ашый, абзарга чыга, анда эш беткәч, тагын кереп китә, кичке аштан соң түшәккә барып ята... Көн саен бер үк сукмак—алачыктан—абзарга, абзардан—алачыкка... Кайчакта гына мунчага су ташырга, кар көрәргә чакырып алалар. Чакырмасалар, Хәлим көннәр буе түшәгендә ята, йоклый, иң мөһиме, моңа ул һич кайгырмый, борчылмый, киресенчә, рәхәтләнеп, разый булып яши.

Карчыкларны ул сирәк күрә, иртәнге ашка да нишләптер аның ялгызын гына чакыралар, кайчакта гына ике әпә ир килеп кушыла. Кичке аш вакытында карчыклар бер үк өстәл артына утыралар, әмма Хәлим белән сөйләшмиләр.

Майя бөтенләй күренми. Кыз шулай кыш буе алачыктагы бүлмәсеннән чыкмыйча яшәде. Күрешсәләр дә берни булмас иде. Хәлимнең күңел савытлары шыплап ябылган, аның өстенә кырык потлы тегермән ташы бастырып куелган кебек...

Тегермән дигәннән, бер тапкыр алар икәүләп тегермән тартырга барганнар икән әле. Читтәге амбар-келәтләрнең берсендә иде ул кул тегермәне. Бер көнне Хәлимне шунда ашлык тарттырырга җибәрделәр.

Ул инде эшен бетереп килә иде, кинәт тыны бетеп Майя атылып керде. Кызны күреп, Хәлим сискәнеп китте, әмма артык игътибар бирмәде, өске тегермән ташына беркетелгән имән саптан тотып, әйләндерде дә әйләндерде...

Майя аңа булышырга килгән булып чыкты. Карчыклар утарда юклыктан файдаланып, качып килгән. Бу хакта Хәлимгә сөйләп, аны көлдермәкче булды. Әмма Хәлимнең битараф күзләренә, салкын карашына тап булып, тукталып-тотлыгып калды.. Шулай да егетнең киң түш күкрәгенә йөзен куйды, он кунган, озын, зифа бармаклары белән мангаендагы миңенә тиеп алды, аннары шул бармакларын Хәлимнең артка каратып таралган куе,озын чәчләренә батырды....

Хәлим дәшмәде. Бер урында катып торуында булды.

—Хәлим, нәрсә эшләттеләр сиңе? Ник дәшмисең? Әллә оныттыңмы мине? Бу мин—Майя...

Хәлим аның артыннан кабатлады:

—Май-йа...—Әмма, авызын ачып сүз ката алса да, аның карашлары "үле", күзләре исә, нинди дер мәрт караңгылыгына төбәлеп, тоныкланып калган иде...Майя барысын да аңлады. Һәм дәшми-нитми генә Хәлимгә он җыярга булыша башлады. Идәнгә җәелгән торпышадан онны себереп бетереп капчыкка тутырганнан соң, ашыгып чыгып китте, Хәлим тегермән ташы өстендә утырып калды. Бу минутта аның уйлары да, гамьнәре дә, күңеле дә, зиһене дә үзенеке түгел иде...

Хәлим бу кышта башкача Майяны күрмәде. Үзе дә тышка кирәккә генә чыга иде. Аю кебек, үз бүлмәсендә көннәр, төннәр буе йоклады да йоклады ул. Аларның нәселен аюлардан килә диюләре әллә чынлап та дөрес микән? Аю да кышын йоклап чыга бит. Әнисе бала чактан ук аны:"Кышка керсәң, башыңны мендәрдән алмыйсың",—дип тирги иде. Менә шул галәмәттән үскәндә дә, армиядә чакта да котыла алмады ул.

Хәзер Хәлим анлый инде. Эш "аю нәселе"ндә генә түгел. Анын "тирән йокы"сына иң элек теге сихерче карчыклар сәбәпче. Алар гипнозында яшәгән ул бу кышта. Майяны танымавы да шуннан килә. Әгәр чын акылында булса, танымас, күрмәс идемени аны?!

Күрмәде дисә дә, тагын бер мәртәбә күргән икән Хәлим ул кызны. Уйланып утырганда анын хәтеренә бер вакыйга килеп төште.

Кыш үз көченә кереп кенә барган бер мәлдә албастылар утарына аю килде. Килеп кенә калмады, хужалыкка, йорт-курага шактый зыян салды.

Хәлим башта аны сизмәде. Ярым төш кебек кенә хәтерли ул: баштарак тынгысызланган мал-туар тавышлары ишетелде. Аннары төнге күкне ниндидер үкерү авазы ярып җибәрде. Шунда гына Хәлим айнып китте. "Тагын аю килде!"—дип уйлады ул. Ни өчен шулай уйлаганын Хәлим хәзер дә анлап житә алмый. Аюнын башка бер вакытта да килгәне юк иде бит. Армиядә килеп интектергән аю хакында ул оныткан иде инде. Күрәсен, күнелендә яткан хәтер күзәнәге бер ел элек булган "аю вакыйгасын" өскә тартып чыгаргандыр.

...Аю үкерә-үкерә карчыклар белән Майя яшәгән алачык ягына юнәлде, бер төртүдә ишекне ватып ачты да эчкә кереп китте.

Хәлимнең эчендә дә "җанвар" уянды. Аюнын үкерү тавышы бу "җанвар"ны котырта иде, котыртып кына калмыйча, анын кыргый холкын үртәп, урамга чакыра иде.

Хәлим ике-өч сикерүдә тышка атылып чыкты, тагын берничә омтылуда алачыкнын аргы башына барып житте. Җимерелеп яткан ишекне атлап чыгып, эчкә кереп тә китте...

Яктырып килгән мәл. Эчтәге тәрәзә-тишекләр аша кергән тоныккына яктылыкта почмакка поскан Майяны шәйләп алды Хәлим. Аю бүлмә уртасында башын як-якка чайкап, нишләргә белмичәрәк тора иде. Карчыклар күренми. Хәзер дә Хәлим төшенә алмый: ничек юкка чыктылар икән бу карчыклар? Майянын: "Әбиләр кеше күзенә күренмичә дә йөри алалар",—дигән сүзләре дөрес булып чыга түгелме?

Хәлимнен килеп керүен аю шундук сизде. Ул Майяга карап үкереп торган жиреннән кинәт туктап калды, аннары, салмак кына биеп, артында торган Хәлимгә таба борылды. Менә алар—ике аю—бер-берсенә карашып торалар. Кем—кемне? Кайсы өстен чыгар—кеше аюмы, әллә кыргый урман хужасымы?

Юк, алыш булмый калды. Бүлмә уртасында басып торган аю, борынын күккә чөеп үкерде дә пыр тузып чыгып китте.Хәлим, ишеккә сылана язып, чак кына читкә тайпылып калды.

Ул, стена буена чүгәләп, ярым һушсыз торган Майяны кулларына күтәреп, түшәгенә илтеп салды. Аптырарлык хәл бит: кая киткәндер бу кызнын бүреләргә каршы торган көче, батырлыгы? Хәлим әлегә чаклы моны анлый алмый. Ничек кенә булмасын, аю Майяга да, башкаларга да зыян сала алмады. Каяндыр кинәт пәйда булган карчыклар Майя тирәсендә булашып калдылар, Хәлим тышка чыгып китте. Чыгуга шуны шәйләп алды: аюнын эзе, алачыктан чыгып, урманга таба киткән, шул яктан тоныккына агач сынган, үкергән тавышлар ишетелеп тора иде.

## XXIII

Хәлим бу кышта ике тормыш белән яшәде. Беренчесе анын өйдә иде—газиз әнисе янында, якын күршеләре, таныш-белешләре янында. Икенчесе хәтер урамнарында барды—үткән кыштагы урман вакыйгалары, гомумән, урман тормышы ана бер дә тынгылык бирмәде.

Яз иртә килде. Хәлим бик еш тышка чыгып, нарат бүрәнәләр өстендә утыра, үр астындарак яткан авылны күзәтә, үткән-сүткән белән күрешеп кала, кеше булмаганда, сәгатьләр буе ялгызы уйланып утыра, күнелендәге урман сәхифәләрен актара...

...Март кояшы карау белән, сыерларны утарга чыгардылар. Жылы-

лыкны тоеп вак маллар, кош-кортлар да тышка чыкты, хәтта, арык алаша да, язгы уянуны сизенеп, кирәккә-кирәкмәгәнгә пошкырына башлады.

Нарытта бөреләр бүртте, усак, чаганнарның кәүсәләре дымлана башлады. Кошлар тавышына да ниндидер яңа аһән, яңа мәгънә керде. Хәлимнең күңеле генә кышкы йокысында калды. Көздән карчыклар салып калдырган бозны эретерлек кояш чыкмаган иде әле аның түбәсендә.

Март та узып китте, апрель сулары акты. Урман аланы кардан тәмам ачылып житте. Агачларга яшеллек кунды. Көз очып киткән кошлар кайтты. Көннәр буе урман өстеннән кәккүк тавышы китмәде. Шушы кәккүк моңы белән уяна башлады, ахры, Хәлим... Күңеленең иң нечкә-нәзберек, иң изге кылына кагылды бу тавыш. Кәккүк түгел, бәйләп-кыйнап ташланган җаны кычкырган кебек иде аңа.

—Күк-күк...Күк-күк...

Тавышын да шуңа ишарә итә бит, ичмасам: "Күк... Күк..." Тәненнән кубарылып, Күк катына очып киткән җанының инрәү авазы ласа бу!

Чынлап та, кошлар тавышы аның ябык хәтер сандыгына тылсымлы ачкыч булды, ахры. Мәсәлән, шәүлегән тавышы аның күңеленә шом бирә иде. Төнге ябалак тавышына да аның елыйсы килә —шулкадәр дә бәгырьне әрнетеп яңгырый бу тавыш. Башын мендәр белән томалап куйган чаклары еш була иде Хәлимнең. Ә менә урман чыпчыгының тавышына куана иде ул. Күңелнең бик ерак почмагында калган ышаныч-өметне сакларга булышкан, ахры, бу кошның сайравы.

Аннары... төнге йолдызлар белән дә күңелен сыный иде Хәлим. Яз көннәрендә, утарда бөтен җан иясе йокларга кереп беткәч, ишек төбенә чыгып утыра да, җиту сакал-мыегын сыйпый-сыйпый, күк йөзенә бага. Йолдызлы күкне ул төрлечә күз алдына китерә: ап-ак борчаклар чәчелгән ындыр табагы итеп тә, караңгы мич көймәсе рәвешендә дә... Кайчакта Күк аңа елаган төсле тоела. Утлы сызыклар ясап йолдыз атылу—күз яшьләренен җиргә тамуы кебек...

Кайбер йолдыз тезмәләрен Хәлим әйберләргә охшата: әнә—кое буенда әйләнеп торган чүмеч, әнә—Майя ындыр табагыннан ашлык ташый торган канатлы көянтә... Шул көянтәнең ике очына яртышар капчык солы сала да ат абзарына кайта ул. Туры килгәндә булышкан була Хәлим. Әмма Майя аңа йөген бирми. Карчыклар күрүдән шикләнә ахры... Боларның барысы да—көз булган хәлләр.

Яз кояшы белән Майя да тышка чыкты. Әмма ул инде башка кыз иде. Көзге уенчак, тамырларында бүре каны кайнап торган дәртле кыз түгел. Ябыккан, күзләре, караңгы божра эченә ябылып, эчкә баткан, хәрәкәтләре дә салмакланган, күз карашлары да менә сүнәм дип тора...

Әлбәттә, Хәлим боларны күрерлек хәлдә түгел иде. Менә әле генә—авылына кайтып, кешелек асылына кабат ирешкәч кенә яңабаштан исенә төшереп, кичереп утыра ул боларны. Ул вакытта Хәлимнең үз хәле хәл иде. Бердәнбер тормыш мәшәкате—көндәлек эш. Ярый әле эш булган! Албасты сихереннән дивана булып калыр иде, билләһи!

Әйе, яз иртә килде, шуңа күрә чәчүгә иртә чыктылар. Көне-төне кырдан кайтып кермәделәр. Язын карчыклар тагын бер ат алып кайттылар. Басуда эш җинеләеп китте. Яшь бия белән Хәлим эшләде. Бик тиз ияләшеп киттеләр алар бер-берсенә. Хәлимнең күз карашыннан, ымыннан аңлый иде хайван. Атланып йөрергә дә өйрәнде Хәлим. Гомумән, аның тормышына ниндидер матурлык, ямь кергәндәй булды. Бу матурлык күңел түрендә таш булып катып калган Майяны алыштырырлык булмаса да, дөньяга, тормышка көр, якты караш белән карарлык күпмедер тыныч, гамьсез яшәрлек көч, мөмкинлек бирә иде.

Хәзер Хәлим аңлый, төшенә: сихер язгы яңарыш көннәрендә йомшый башлый икән. Кошларның дәртле сайравы да, агачларда бөре "тибенүе"дә, яландагы беренче үлән "керфекләре", чәчәк "күзләре"дә, күктә жем-жем килеп янган йолдызлар да, үзенә генә бер татлы исе булган яз җиле дә—боларның барысы да Хәлимдәге зәхмәт-сихер бауларын бушатып җибәрделәр,

ахры. Ара-тирә дертләп уянып киткәндәй була Хәлим. Үзе дә сизмәстән, берәр нәрсә күреп, ачыш ясый, ана йотлыгып карый, аны күнеленә ятлап, беркетеп калдырырга тырыша. Бервакыт яралы каен тәненнән агып яткан татлы суны күргәч, ул аеруча тетрәнде; оясыннан егылып төшкән сандугач баласын ниндидер ерткыч кошлар чукып үтергәч тә үзен кая куярга белмичә йөргән иде. Бер көнне ике әпә дүрт төлке баласы алып кайтты. Әниләрен үтереп, тиресен тунап алганнар. Чыелдашып капчык төбендә яткан бу сабыйларга карап та күнеле әрнеде Хәлимнең. Бу жан ияләрен сулы чиләктә тончыктырып үтерделәр, аннары, куркыту, өркетү өчен булса кирәк, кош-корт абзары артындагы куакларга элеп чыктылар...

Әпәләр... Хәлим өчен ачылып бетмәгән сер алар. Бигрәк тә чәнти бармагы булмаган ир. Кем ул? Хәлимнең әтисе дә чәнтисез булган бит. Хәтта кушаматы да "Чәнти", имеш. Күлдәге вакыйга да бик серле. Аны чынлап та үтерергә теләделәр, чәнти бармагын өскә чыгарып күрсәткәч кенә су төбеннән тартып алдылар.

Кыш буе Хәлим әпәләр белән аралашмады. Аларның үз эшләре, Хәлимнең үз хезмәте дигәндәй, кичке аш өстәле артында тавыш-тынсыз гына очрашып-ымлашып алалар да,шуның белән вәссәлам!

Шулай да, Хәлим чәнти бармаксыз әпәнең карашын гел тоеп яшәгән икән. Лапас утары булү өчен киртәлек агач аударганда тойды ул беренче мәртәбә бу үткен карашны. Мавыгып кына эшләп йөргәндә, ниндидер зәһәр ут-нур аның арка миен кимергәндәй булды. Нәрсә булыр бу! Хәлим, үзен-үзе белештермәстән, кискен генә артына борылып карады: юан гына усак агачы төбендә, ана төбәлеп, чәнтисез әпә карап тора иде. Хәлим аның очкынлы күзләрендә ниндидер серле көлемсерәү, хәтта, куану төсмерен күреп кала алды.Бу әпә белән икенче тапкыр күзгә-күз очрашу да урман эчендә—утардан шактый еракта булды. Хәлим кабан сукмагына куелган капкыннарны карарга барган иде. Кабан—ерткыч хайван. Кулында коралың булмаса, һич жинеп булмый аны. Утарда мылтыкның булганы да юк. Хәлим кабанга капкыннарны сакланып кына куя иде. Берәр кабан эләгә калса да, көтүләп килеп алалар, ялгызын гына алып кайтам димә. Син капкындагы кабанны сөйрәгән арада башкалары өстеңә ташланмасын.

Бу юлы да шулай булды. Хәлим капкынга эләккән, инде тәмам хәлсезләнеп беткән кабан дуңгызын ычкындырмакчы булып иелгән генә иде, янәшәдәге куак артыннан икенче бер дуңгыз атылып чыкты да, әллә нинди зәһәр ырылдавык тавыш чыгарып, Хәлим өстенә ташланды. Әмма корбанына килеп житә алмады, аның сыртына гөпелдәп нәни генә балта килеп кадалды. Чытырдап шартлап сынган ботак тавышына башын борырга өлгергән Хәлим каяндыр очып килгән һәм бөтен йөзе белән кереп баткан балта тырпаеп торган кабан гәүдәсенең жирдә бәргәләнеп-тәгәрәп йөрүен генә күреп калды. Бераздан агачлар арасыннан серле елмаеп әлеге таныш әпә килеп чыкты. "Артыннан күзәтеп килгән өчен гафу ит",—дигән кебек, ул оялчан гына инбашын сикертеп алды, кулларын жәеп жибәрде.Үзе шундук, йөгереп барып, жан бирергә өлгермәгән дуңгызны чалып жибәрде.

Кыш ахырында, аланнарда кар каткач, чәнтисез әпә Хәлимне поши ауларга алып чыгып китте. Кечкенә балталарын билләренә уралган бауга кыстырдылар да, бер көнлек ит-икмәк алып, юлга кузгалдылар, аякларына, олтанлы киез итек өстенә, юкәдән үреп, кар өстендә йөрү өчен махсус эшләнгән канатлы чабаталарын киделәр. Кулларына бер башы йомры, икенче башы үткен итеп юнылган тәпәчләр тоттылар.

Ин элек поши эзенә төшергә кирәк иде. Көн үзәгенә табан, ниһаять, яна эзгә килеп чыктылар. Бернichә сәгать элегрәк үткән булырга тиеш. Туктала-туктала, кайры кимереп, ботак очы чемченеп бара, димәк, бик тиз куып житәчәкләр.

Менә ул! Әпәнең күзләрендә очкын пәйда булды. Хәлимнең үзендә дә ниндидер бер кыргый хис уянды, чүгәләп күзәткәндә аның бөтен торыш-тәртибе кыргый жәнлектән бер дә ким булып күренмәс иде.

"Һау-һау"лап куа башладылар. Поши шундук күздән югалды. Әмма

бу куркыныч түгел, иң мөһиме, эзне саташтырмаска. Менә тагын куып життеләр! Тагын югалды, тагын якынайдылар... Берничә сәгать куышкач, каты кар өстендә батып-батып калган поши эзләрендә алсулык күренде. Димәк, тояк бәкәлләре жәрәхәтләнгән. Таштай каты кар шулай бетерә поши аягын. Канлы жәрәхәттән әрнегән аякларын кая куярга белмичә, тыпырчынып егылганчы куасың пошины. Бөтен ау шуннан гыйбарәт, мылтык-мазар да кирәк түгел.

Әпәнең беренче авы түгел, ахры. Ул адымын һаман тизләтә, ә Хәлимнең хәле бетеп бара. Шулай да калышмый. Поши эзендә кан күбәйде. Димәк, озак калмады инде. Караңгы төшкәнче барып тотачаклар, башына сугып мингерәүләтәчәкләр дә, шунда ук чалып, тунап, яхшы итен капчыкларга салып, утарга кайту ягын караячаклар.

Кар өстендә кан күргән саен Хәлимнең йөрәгендә нидер чәнчеп куя. Әнә—еракта поши шәүләсе дә шәйләнә инде. Ул адымнарын акрынайткан. Әмма әлегә үз хәлендә, үз аягында.

Шунда әллә нәрсә булды Хәлимгә. Ул әпәнең чабуыннан килеп тотты да пошига таба төртеп күрсәтте. Аннары, "Кирәкми" дигән кебек, акрын гына як-якка башын чайкады.

Әпә бераз гажәпләнеп калды. Аннары пошига озак кына карап торды да уң кулын үз корсагы өстеннән йөгертеп алды. Хәлим берни дә аңламады. Әпә тагын, корсагын алга чыгарып, куллары белән сыйпап куйды. Аннары күкрәгенә бала кыскан кебек, учларын түшләренә куеп, йөреп китте. Үзе әле пошига, әле үз корсагына төртеп күрсәтүендә булды.

Хәлим шунда ук аңлап алды:"Поши авырлы, аның корсагында бала бар",—димәкче була бит әпә. Менә нидә икән хикмәт! Менә ни өчен поши тиз бара алмый икән! Хәлим, аңлавын белдереп, баш какты. Аннары, поши ягына кул селтәп, кайту сукмагына ишарәләде.

Кайтканчы сөйләшмәделәр, әмма аларның күзләре сөйләшә иде бу минутта. Шунда беренче мәртәбә якынлык, хәтта, туганлык хисе кичергәнен хәтерли Хәлим ул мәхлук әпәгә карата.

Ә күнел алдамый ул. Сүз алдый, хәтта күз дә алдый, ә менә күнел алдамый. Бу әпә—кем ул? Хәлимнең кеме? Кайчандыр урман юлында гаиб булган әтисе—Кушйөрәк Чәнти микәнни?

## XXIV

Язны аяк өстендә үткәрделәр. Эш күп булды. Үзалдына озак юанып торырга вакыт тимәде. Әмма табигатьнең кануны бар: яздан соң жәй килә. Жәйге жылы кеше күнелен иләсләндерә, аны бераз бушатып, туарып жибәрә, хөрлеккә,иреккә өнди, матурлыкка ымсындыра. Яз көне жан-күнелдә шытып калган сөю-мәхәббәт күзәнәгенә шифалы яңгыр яудыра, жылы кояшның бәрәкәтле нурын коя...

Хәлимнең күнеле дә сизде, тойды бу табигать канунын. Ләкин инде кошлар сайравы да, агачлар шавы да, күктәге йолдызлар да, хәтта, туганы кебек булып киткән Аксай да (атына ул шундый исем бирде) күнелендә көчәеп баручы дәрт ташкынын, яшәү гамен, жан сагышын баса алырлык хәлдә түгел иде.

Ана Майя кирәк иде. Аның күнеле, жаны-тәне, күзләре Майяны сагынган иде. Хәлим моны жәйнең бер жылы көнендә, бакчага су ташып йөргән мәлдә аеруча нык тойды. Түзеп булмаслык итеп тойды. Һәм ул, арба-чиләкләрен ташлап, Майяны... эзләп китте.

Башта ул Майя бик еш йөри торган яшелчә бакчаларына барды. Аннары келәт-амбарлар яныннан узды. Ул тирәдә дә күренмәгәч, туп-туры алачыкларга китте. Карчыклар янына аның бервакытта да болай чакырусыз кергәне юк. Бу юлы үзеннән-үзе шулай килеп чыкты—Хәлим карчыклар бүлмәсенә барды да керде. Идәнгә жәелгән жәймә өстендә борчак чүпләп утыручы карчыкларны күреп тә гажәпләнмәде. Тирә-ягына каранып, Майяның юклыгына ышангач, борылып чыгып китте. Карчыкларның бер-

берсенә карашып жилкә уйнатуларын да күрмәде Хәлим...

Хәзер кая барырга? Каян эзләргә Майяны? Ул, бөтен зиһенен туплап, бу араларда кызның жиләккә йөрүен исенә төшерде. Утар аланыннан арырак күк чәчәкле бер алан бар, аның кояшка караган итәгендә жир жиләге күп була, Майя да шул яктан кайтып йөри. Бүген дә шундадыр әле. Берочтан тышаулап жибәрелгән Аксаена да күз салыр...

Хәлим ялгышмаган булып чыкты. Майя шунда иде. Әмма ул үзе генә түгел. Кыз янында Хәлимнең газиз аты—Аксай тора. Майя, атның алдына ук килеп баскан да, зифа муенынннан кочаклап, колагына нидер пышылдый, сөйли...

Хәлим посыбрак кына якын килде. Талгын җәйге жил Майяның тавышын бик тиз китереп житкерде:

—Хәлим... Хәлимем минем... Ник син мине күрмисен? Ник син мине оныттың?.. Ә? Ник дәшмисең, Хәлим?.. Ник эзләмисең мине?..

Хәлим авызыннан үзеннән-үзе, кош кебек, канатлары белән иреннәренә орыла-бәреләә, салкын кыш буе күңел төпкелендә тоткын булып яткан сүз очып чыкты:

—Майя!..

Атның ялын бармаклары белән тарап торучы Майя сискәнеп китте. Башын калкытты. "Син шулай сөйләшәсенме?"—дигән кебек, атның күзләренә үрелеп карады, аннары бөтен тирә-якны күзәтеп чыкты, бераздан, тынычланып, сөйләшүен дәвам итте:

—Исәрләнәм бугай инде мин, Хәлим. Колагыма әллә нәрсәләр ишетелә. Их, белмисең син минем хәлемне, күрмисең минем күзләремне... Күрсәң иде күзләремне... Күрсәң, аңлар идең, сине ничек сагынуымны, өзелеп көтүемне аңлар идең... Бик яратам бит мин сине, Хәлим...

—Мин дә, Майя...

Бу сүзләрне дә Хәлим үзе әйтмәде. Аның әрнүле жаны-бәгыре әйтте. Бу юлы Майя аерымачык ишетте. Тавыш килгән якка борылып карады. Һәм шул минутта ук якындагы куак артында багана булып басып каткан Хәлимнең мөлдерәүле күз карашына кереп чумды. Кабат чыкмаслык, кабат калыкмаслык булып, Хәлим күзләренең, юк, Хәлим тормышының ин төбенә төшеп китте.

... Алар бу көнне аланда озак юандылар. Әллә ни сөйләшмәделәр дә. Гашыйк жаннар кебек, кочаклашып-сөешеп тә утырмадылар. Алар өчен бер-берсенә янәшә тору да, бер-берсенең күзләренә карашу да чиксез бәхет иде. Бер кыш, бер яз буе жыелган сагышны тиз генә, бер очрашуда гына түгеп бетереп буламы соң?!

Күпме шулай сыенышып утырганнардыр, карчыкларның үзәккә үтәрлек карпылдык тавышына сискәнеп киттеләр алар. Майя шундук торып басты, тырысын алып, китәргә жыенды. Аннары, Хәлимгә тагын бер тапкыр өзелердәй булып карап алды да үр артындагы келәтләргә табан йөгерде... Хәлим үз сагышы, юк ла, үз шатлыгы белән ялгызы торып калды.

## XXV

Жәйгә кергәч, авылда кыр эшләре тәмамлангач, ныклап торып печәнгә төшкәнче дип, Хәлимнәр яна йорт өчен бура бурарга керештеләр. Оста булып килергә авылда беркем дә риза булмады, Хәлим, Зөфәр белән барып, таныш мариларны яллап алып кайтты.

Эш гөрләп барды. Авыл халкы йөз чөерсә дә, күршеләр ташламады, бигрәк тә Ак бабай гел янда булды. Мариларга һич тынгы бирмәде ул, әле тегесе ярамый, әле монысы ошамый... Әмма осталар ана үпкәләмәделәр, чөнки... барыбер үзләренчә эшләделәр.

Хәлим дә балта тотып эшләде. Әтисез үскән балага эш өйрәтәсе юк—агач та юнды, агачның көймәсен дә алды, чабатасын да чапты, сызгыч та тотты, чутлады да... Митри мактап, күңелен күтәреп торды. Әллә юри, әллә чынлап—Алла белсен...

Шулай да, Хәлимгә рәхәт иде. Ул, хәтта, бәхетле иде. Анын бәхете тулы түгел, әмма ул бәхетле иде! Менә бит анын кечкенәдән хыялланган нияте тормышка аша башлады. Нигезне яңартачак ул! Яңа йорт куячак! Ир-егет буларак, гомеренен, тормышынын мәгънәсен билгеләрлек зур, мөһим эш эшләячәк! Әнисен сөендерәчәк! Шушы нигездә гаилә корачак, нәселен дәвам иттерәчәк...

Нарат агачын юкка гына "кояш агачы" димәгәннәр бит. "Нурлы агач", "утлы агач" дип тә әйтәләр. Хәлимнәр капка төбендә балкып яткан алтынсу нарат бүрәнәләрдән, чынлап та, бөтен урамга, бөтен авылга ниндидер көчле энергия ургылып тора, шифалы, якты нур бөркелә кебек. Хәлимнең күнеленә гел бер уй килә: бу бүрәнәләр, бу бура, бу өй мәшәкате булмаса, нишләр иде икән ул, ничек чыдар иде икән башына уптым ишелеп төшкән хатирәләр ташкынына? Җаны-йөрәге ярылыр иде яисә берәр яры чыгып чабар иде мөгаен...

Атна-ун көн эчендә бураны, урталай бүлеп, капканын ике янына утыртып та куйдылар, матчаларны, түбә бәпкәлекләрен юнып-чистартып, үлчәп-кисеп, бура өстенә тезеп чыктылар. Калган агачларны, ярырга алып бару өчен җайлап, койма буена өйделәр. Митри алып килгән марилар белән алыш-бирешне өзгәч, озак кына күңел ачып утырдылар. Сания бөтен булган байлыгын, сыен чыгарды, урам күршеләре дә күчтәнәчкә әллә күпме ризык керткән: кем каклаган үрдәк, кем бал, кем май-каймак алып килгән... Эчемлек тә күп эчелде. Марилар нык эшли дә, нык эчә дә. Моны һәркем белә. Сания дә эчемлекне күп әзерләгән. Хәлим үзе дә ким куймады. Урманнан чыкканнан бирле анын бу кадәр эчкәне юк иде. Улынын йомшап, мәлҗерәп калган гәүдәсен чоландагы сәкегә кертеп салгач, Сания анын яныннан китәргә куркып утырды. Курыкмады да ул, нигәдер шикләнде, шомланды. "Аңсыз-сансыз килеш ничек ялгызын калдырасын инде аны, анлы килеш тә урлап алып киттеләр бит үзен..."—дип уйланды ул.

Хәлим тыныч кына ятмады, ыңгырашты, саташты, нидер эндәште, кем беләндер сөйләште, бәхәсләште, хәтта, кулларын болгый-болгый сугышмакчы булды... Сания чак-чак кына тынычландыра алды аны. Хәлим һаман бер исемне кычкыра, шул исем белән кемнедер ялварып чакыра иде:

—Майя! Майя!.. Майя...

—Улым! Улым дим... Ярый инде... Тынычлан... Әйдә, борылып ят... Менә шулай...

Сания Хәлимне таңга кадәр саклап утырды, анын тирләп чыккан битен сөрткәләде, танда кояш яктысы белән котыра башлаган чебен халкын якын җибәрмичә куып торды.

...Хәлим күзен ачканда янында ярым оеп әнисе утыра иде. Бик кызганыч тоелды ул Хәлимгә. Әнә ничек картайган, арынган...

—Әнкәй...

—Ә? Хәлим?...—Сания сискәнеп күзләрен ачты.

—Әнкәй... Мин исергәнмен...

—Әйе шул, балам... Ярый, бер мәртәбә генә ярый ул. Дөнья гаменнән онытылып тору өчен ярый.

—Ачуланма, яме, әнкәй... Үземнен дә эчәсем, эчеп онытыласым килде... Башка бер дә эчмәм, әнкәй... Менә—сүз бирәм...

—Ярый, балам, ярый, эчмәссең... Мин сиңа ышанам, ничек ышанмыйм ди... Син бит минем бердәнберем, улым, Хәлимем...

Беразга тын калдылар. Хәлим тагын ойый башлады. Сания анын озын үскән чәченнән сыйпап утырды. Кинәт сорап куйды:

—Хәлим, кем ул Майя?

Оеп яткан Хәлимне ток суктымыни—анын озын, матур керфекләре сискәнеп ачылып китте, бу керфекләр эченнән балкып зәнгәрсу күз алмалары килеп чыкты... Алар, кин ачылып, түшәмгә бактылар, аннары, Саниянен борчулы күзләрен эзләп табып: "Каян белден бу хакта, әни?"—дип сораган кебек кабат озын керфекләр куелыгында юк булдылар. Хәлим җавап бирмәде. Бары тик:

—Майя...—дип, яратып, йөзенә бәхетле елмаю чаткылары чыгарып кабатлады.

—Матур исем,—диде Сания,—тик... безненчә түгел, татарча түгел, дисәм...

—Татарча ул, кешегә гомер бирүче алиһә ул, ягъни, Яшәү алласы. Мин күрдем аны, әнкәй... Бер сөйләрмен әле. Сина ул ошаячак... Син аны яратачаксын...

Сания берни дә анламады. Чын аналар кебек, ул анламаганын улына белгертмәде, Хәлимнен сүзен җөпләп:

—Ярый-ярый, яратырмын, ул да мине яратыр,—диде.

Хәлимнен күнеле, уйлары әнкәсе янында түгел иде бу вакытта. Бу минутта ул бер еллык гомерен урлап калган һәм ана бетмәс-төкәнмәс бәхетен—Майясын бүләк иткән урман дөньясында, ике албасты карчык хакимлегендә, мари урманнары уртасында посып яткан серле утарда иде. Дөресрәге, әлегә бу каргышлы дөньяга кереп бетмәгән, бәлки, ана керү өчен кирәк булган мөһим код-исемне генә пышылдый иде:

—Майя... Майя...Майя...

## XXVI

Күкчәчәкле аланда күрешкәннән сон Хәлим Майяны башка оныта алмады. Һәр минуты, һәр сәгате, һәр көне Майя белән тулы булды. Анын күзләре дә һәр җирдә Майяны күрә, нәрсә генә әйтсә дә "Майя" исеме әйтелә, хәтта, тәнендәге һәр күзәнәктә Майянын нәни генә күзәнәге, тамырындагы һәр бөртек канда Майянын каны, һәр сулышында Майянын кайнар сулышы бар иде. Йөрәге дә "Май-йа, Май-йа..." дип тибә иде.

Аланда, утарда чакта, нәрсә генә эшләсә дә, кая гына барса да, һаман Майяны эзләде, алачыктагы бүлмәсендә чакта Майя яшәгән дөнья белән тоташтырып торучы бердәнбер урыннан—диварга чокылган тишек янынннан китмәде. Ходай каргаган бу утардагы ин изге урын булгандыр ул. Күпме сөю сүзләре әйтелгән, күнел җылысы тибрәлгән, күпме хис-тойгы кайнаган бу урында! Күпме сер ачылган, күпме хыял туган, күпме яшь түгелгән монда! Алар арасында шатлык яше дә, сагыш яше дә күп булгандыр. Кыскасы, шушы урында Хәлим кабат туды, кабат уянып, яши башлады. Хәтере кайтмаса да, күнеле ачылып, бөтен хисләре кайтты, бу хисләрдән бөреләнеп, яна хыяллар, киләчәккә яна өмет туды.

Карчыклар Майя белән Хәлим арасында кабат кабынган сөю уты хакында шактый вакыт белмәделәр. Әллә белмәмешкә генә салындылармы? Һәрхәлдә, Майяны да, Хәлимне дә тыючы, былтыргы кебек, зәхмәтле җәзаларга тартучы, кара сихер белән өшкерүче булмады.

Хәлим белән Майя да бу юлы акыллы эш йөрттеләр. Карчыклар утарда булганда якыннан аралашмаска тырыштылар, очрашканда да аска карашып узалар, хәтта, монын бер чиге, ахыры буласын да чамалыйлар иде, шулай да, хуҗабикәләрне үртәмәскә тырыштылар. Хәлим үзе хакында уйламады, карчыкларнын кызны тагын кыйнап, бәйләп, ябып куюыннан курыкты.

Мәхәббәтне яшереп була димени?! Утны капчыкка салып булмаган кебек, сөю хисен дә кеше күзеннән яшерү мөмкин түгел. Ымсынышкан тәннәрне дә бер-берсеннән яшерү мөмкин түгел икән. Ходай бар бит ул. Шушы тәмуг авызында яшәп яткан ике ятим баласына тәннәре белән кушылырга җай чыгармаса, юк та дияр идең. Андый җайны Майя белән Хәлимгә дә бүләк итте Ходай тәгалә.

Ул көнне карчыклар тоз эзләп сәфәргә чыгып киттеләр. Бу хакта Майя иртән иртүк дивардагы тишек аша хәбәр иткән иде.

—Эшкә кая барасын?—дип сорады ул Хәлимнән.

—Ат белән бакчага су ташыйм.

—Мин дә шул тирәдә булам, бүген аргы бакчадагы кыяр түтәллә-

рендә эшлим.

—Майя...

—Әү, Хәлим...

—Барсам... ярыйдыр бит?

—Кил, Хәлим...

Алар көндез очраштылар. Кыяр түтәлләренең аргы башында куыш бар иде. Хәлим барганда Майя шул куыш алдындагы ышыкка ашъяулык җәеп өлгергән. Аның өстенә төрле тәгам-ризыклар тезгән, шунда ук шешә белән сөт тора, өлгереп килүче яшел кыярлар тәгәрәшеп ята.

Майя Хәлимне ерактан ук, күз карашлары белән яратып, сөеп каршы алды. Чакыруын чакырды, тик икесенең дә тамакларына аш бармады. Берберсенә карашып утырдылар да утырдылар алар. Майя, тарагын алып, Хәлимнең сакал-мыегын тарады, бер очтан мангаендагы миненә кагылып үтте... Кинәт ул сикереп торды һәм сүз әйтергә дә ирек бирмичә:

—Сал өстеңне, бигрәк катkансың, китер юып бирәм, көн кызуында хәзер кибә ул...—дип такылдый башлады.

Хәлим аптырап калды. Ничек инде—Майя алдында шәп-шәрә калсынмы? Хәлимнең уйларын сизгәндәй, кыз әйтеп куйды:

—Юк ла, карамыйм, бар, куышка кереп чишен. Киемнәрең кипкәнче шунда утырырсың. Әпәләр бүген көтүдә, беркем берни белмәс... Йә, бар инде, тиз бул...

Хәлим куыш эченә кереп чумды. Тиз генә өстендәге сәләмәләрен чишенеп атты, кыенсынып кына куыш алдына килеп, киемнәрен тышкы якта басып торган кызга сузды.

Майя юып, элеп килгәнче Хәлим куыш эчендә ятты. Кипшенә башлаган яңа печән исе борыннарга кереп кытыклый, тәнгә генә түгел, җанга да сихри бер иләслек, рәхәтлек бирә. Шунда ук җиләк исе... Яңгыр исе... Мәтрүшкә исе... Кояш исе... Җир исе... Майя исе...

Әйе, Хәлимнең искә алганы бар: Майяның да үз исе бар. Дөньядагы иң тәмле, иң татлы, тылсымлы, исерткеч истер ул... Мең төрле чәчәк исе бергә кушылып кына барлыкка китерә аладыр бу хуш исне. Әле аңа да чишмә исен, чык исен, җәй исен өстәргә кирәктер...

Хәлим, шәп-шәрә калган килеш, рәхәтләнеп чалкан төшеп ятты, аякларын, кулларын як-якка сузып җибәрде, киерелде... Күзләрен йомып, тирән итеп сулыш алды... Болай туарылып, изрәп күптән, бик күптән ятканы юк иде аның. Бала чактан бирле. Әле дә хәтерендә: Ак бабай белән атлар көтәргә баралар да шунда кунып калалар иде, көтүче куышында таң аттыралар, офык артыннан кояш калыкканын күзәтәләр... Ак бабай, алдындагы учак каршына утырып, төннәр буе сугышта булган хәлләр хакында сөйли, йә булмаса борынгы каһарман бабаларыбыз турында риваятьләр көйли...

Хәлим таң аткач кына йокыга китә, шул йоклавыннан төшкә кадәр тормый ята. Ул уянып киткәндә кояш югары була инде, көн җылынган, үләндәге чык кипкән, авыл көтүе төшкелек ялга—утлауга җитеп килә... Ак бабай да үзенең атлары белән әллә кая китеп барган... Табигатьнең сихри тавышларына уянган Хәлимнең торасы килми, ул, баш очындагы хуш исле печән өемен рәтли-рәтли, тагын урынын җайлый, тагын изрәп йокыга китә...

...Тәмле-татлы уйларга бирелеп йокыга оеп барган Хәлим, тәненә салкын куллар кагылудан сискәнеп торып утырды. Шул ук салкын куллар, аның күкрәгеннән этеп, кабат ятарга куштылар. Хәлим буйсынды. Шунда гына ул, куыш ишегеннән төшкән яктылыкка коенып, балкып басып торган бер сылу гәүдәне күреп алды. Майя бит бу! Шәп-шәрә! Хәлим кинәт үзенең дә яп-ялангач ятуын исенә төшерде һәм куш куллап җан җиренә барып ябышты... Майя үзен бик сәер тотты. Менә ул Хәлим өстенә иелде, аның кушырып капланган кулларын ике якка алып куйды. Аннары Хәлимнең баштан аякка кадәр бөтен тәнен җентекләп карый, өйрәнә башлады... Назларга керешге...

Хәлимгә болай яту бик кыен иде. Әмма ул үзенең җиргә Майя сихере белән ябыштырып куелганын тойды. Башын калкытырга теләде,

куллары буйсынмады. Хәтта теле дә юк иде анын бу минутта. Кызга исеме белән дәшмәкче булды, авызын да ачты, беренче авазны ишеттерү өчен иреннәрен дә кысты... Әмма авыз ачып сүз әйтә алмады. Анын күзләре генә, карашлары гына тере, исән иде бу мизгелдә. Шул күзләр каршында дөньянын ин сылу заты, ин гүзәл кызы, зифа тәнен бөгә-сыга, Хәлимнен тәнен назлый...

Менә ул иреннәре белән Хәлимнен колакларын тешләп үтте, сакал-мыекларын, муен тирәләрен иркәләде; икенче бер мизгелдә анын кайнар сулышы Хәлимнен култык асларын кытыклый башлады... Аннары кызнын йомшак сусыл иреннәре егетнен күкрәк очларына кагылып узды, кендек оясын үпте...

Хәлим бу сихри халәттән шаша язды. Анын каны уйнады, мие томаланды. Майя тәненнән анкыган дым исеннән һәм кызнын тыгыз күкрәк очларындагы салкын төймәләрнен тәненә тиеп-тиеп алуыннан ярым һушсыз яткан Хәлим, ниһаять, кулларын кузгатып, бу сихри тәнне кочаклап алырлык, үз тәненә, күкрәкләренә кысып назларлык, иркәләрлек, яратырлык хәлгә килде. Нindидер бер илаһи сәгать сугып, ике тән бер-берсенә кушылды, ә жаннары... жаннары аларнын күптән бергә иде инде.

Алар әле табигать балалары кебек сөешә-яратыша белмиләр, сулышларында, хәрәкәтләрендә, сүзләрендә ниндидер матур тартыну, кыенсыну бар... Табигатькә, Тәнрегә рәхмәт. Әле дә ул аларнын колагына, юк, жан кошларына, шулай ук күзләренә, иреннәренә, кулларына, зифа ботларына нәрсә эшләргә кирәген әйтеп тора... Үз гомерендә беренче мәртәбә кавышу, кушылу ләззәтте кичереп, ярым шашып, ярым үлеп яткан бу ике жан иясе кешелек дөньясынын, Галәмнен үзәге, төше, асылы һәм яшәү мәгънәсе кебек иде.

...Хәлим белән Майя үзләренен сихри куышларында көн саен очраша башладылар. Тоз эзләп киткән карчыклар тоткарланды, шул китүдән алар бер атналап юкка чыгып тордылар. Ләкин алар барыбер кайтачаклар иде. Хәлим белән Майя арасында булган хәлләрне барыбер беләчәкләр иде.

—Майя, әйдә тагын качып карыйбыз,—диде көннәрдән бер көнне Хәлим,—бу юлы әбиләр утарда юк, сихер көче дә алай ук түгеллер...

—Бу мөмкин түгел,—дип кырт кисте Майя.—Моннан беркемнен дә кача алганы юк әле. Әбиләрнен, куеп калдырган капкыннарына юлыгып, берәр кайда егылып калып, явыз жәнлекләр авызына керүен дә бар...

—Синдә дә бар бит тылсым көче, бүре тикле бүреләрне өркеттен теге чакта...

—И, Хәлим, миндәге тылсым егәренә әбиләр "ыһ" та итмиләр. Алар мине буйсынулы тылсым рухында үстерделәр. Аннары... качып кая барам мин?.. Мин бит урман баласы, бер кыргый зат... Ә син... син кешеләр янында, кешеләр арасында үскәнсен... Синен урынын алар янында. Качсан, үзен генә кач, Хәлим...

—Качып булмый дисен бит...

—Булмый, Хәлим...

—Нинди карчыклар сон алар, Майя? Сине бүре өненнән табып алганнар. Мин мона ышанам. Ә менә алар кемнәр? Кешеләрме, әллә берәр төрле кара рухлармы?

—Мин үзем дә белеп, анлап бетерә алмыйм, Хәлим. Кешеләр бугай үзләре. Кайчандыр кешеләр арасында яшәгәннәр, ахры. Кешеләр аларны ни өчендер куып жибәргәннәр. Әбиләр менә шул кешеләрдән үч алырга йөриләр. Берәр нәрсә кылып кайткач ничек пәри туе ясап утыруларын күрсән аларнын!.. Син дә шул үч белән бәйләнмәгән микән, дип шикләнәм. Син килгәч алар бәйрәм ясап, женләнеп утырдылар...

—Мин кем сон, Майя? Берәр нәрсә әйткәннәре, сөйләгәннәре бармы?

—Синен сер, Хәлим, әпәләрнен берсе белән бәйләнгән. Мин моны төгәл беләм. Безнен алачык диварына бер такта кагылган, анда жиде тамга бар, сихер тамгалары. Син аны беләсен—түгәрәк эчендә тәре сурәте төшерелгән... Син—шул тамгаларнын алтынчысы. Сине алып кайткач, әбиләр

алтынчы тамганы карага буяп куйдылар.

—Әле берсе калдымы?

—Калды... Кешеләрдән аласы үчләре бетмәгән әле аларның... Менә шул синең тамганы алдарак буялган бер тамга белән тоташтырып куйдылар. Ул тамга—чәнтисез әпәнеке булырга тиеш. Чөнки, бервакыт шул әпә югалгач, әбиләр әлеге тамгага күмер чәчеп фал ачтылар, аның кайда икәнен белеп, кабат алып кайттылар...

—Майя... Әйт әле дөресен: минем хәтерне, үткән тормышымны кайтарып буламы?

—Була... Тик моның өчен вакыт кирәк, Хәлим. Мин аның юлларын да беләм, әмма тиз генә эшли алмыйм. Көч-егәрем аз әле минем. Көзгә кадәр мин синең күнеленә керәчәкмен, урман гына шәфкатеннән ташламасын, агачлар гына нурларын кызганмасын, үләннәр генә шифасыннан, жир генә дымыннан мәхрүм итмәсен...

—Их, Майя, тизрәк котылырга иде шуларның зәхмәтеннән!..

—Карчыклар зәхмәтеннән котылып булмый, Хәлим. Алар бит чын кеше түгел. Беләсеңме, алар күзгә күренми дә йөри алалар, әйе-әйе, син белмисең генә, синең янга да кереп йөриләр алар, менә хәзер дә янда басып торырга мөмкиннәр...

—Юк ла, булмаганны...

—Синең гомерлек хәтереңне алдылар бит, телеңне алдылар, Хәлим... Монысына да ышан. Безгә нык сакланырга кирәк. Сиңа явызлык кылырлар дип куркам...

—Алай тиз генә бирешмим әле мин. Ачуны китерсәләр, үзем аларга бер-бер хәл кылып куярмын, билләһи!

—Юк, Хәлим, бу хакта уйлама да. Карчыклар хакында бөтенләй уйлама; алар кешенең уйларын да белеп, сизеп торалар...

—Ә? Уйларын дамы?

—Әйе. Мин уйлаган бөтен нәрсәне беләләр. Бу хакта төгәл әйтә алам.

—Шулай да, качам мин, Майя. Сине дә алам үзем белән. Әйдә качабыз... Бүген үк!

—Тукта! Нидер сизәм мин, Хәлим... Баш очында ниндидер тавыш. Бу—әбиләр галәмәте, алар сихере... Китим инде... Хәзер без еш очраша алмабыз. Жай чыкканны көтәргә кала. Онытма мине, Хәлим...

—Мине дә онытма, Майя...

—Онытмам...

## XXVII

Юк, сизмәгәннәр икән. Әллә сизмәгән булып кыландылар гынамы? Ничек кенә булмасын, Хәлимгә дә, Майяга да тиюче, хәтта, аларны шелтәләүче дә булмады. Утарда тормыш жай гына дәвам итте. Һәркемнең үз вазифасы бар бу катлаулы хужалык мәшәкатьләрендә: кем кыр-басу эшләрендә, кем абзар-курада, кем көтү белән йөри... Хәлимгә авыррак эшләр эләгә: яшь, көчле диптер инде, жир, агач эшләрен, шулай ук су ташуны аңа йөкләделәр.

Беркөнне жыйнаулашып печән чабарга күршедәге Күкчәчәк аланына бардылар. Көне буе рәхәтләнеп, киерелеп-селтәнеп печән чапты Хәлим. Шунда тагын бер мәртәбә сизде: ул кайчандыр печән чапкан булган инде, әнә бит тәне ничек белеп, үз итеп, яратып эшли бу эшне...

Кичкә табан карчыклар кайтып киттеләр. Алар болай да көне буе ирләрдән читтәрәк йөрделәр. Шул ук озын кара күлмәк, туры төшереп бәйләнгән калын кара яулык... Ул яулык ышыгыннан йөзләре бөтенләй дә күренми, очлаебрак торган кәкре борыннары гына, көләсене китереп, килбәтсез рәвештә тырпаеп чыккан... Алар чабылган пакусны әйләндергәләп йөрделәр, төшке аш өчен табын әзерләделәр, соңыннан шул табынны жыеп алып, утарга кайтып киттеләр.

Майя бу көнне әпә ирләр янында булды. Алар еккан пакусларны

юкартып-таратып чыкты. Өсте кибә башлаганнарын кузгатып, күтәртеп йөрде.

Ә Хәлим чапты да чапты... Әллә ни армады да. Куллары кабарып чыкты, аяк балтырлары таштай катты, әмма кичкә кадәр кулыннан чалгысын ычкындырмады. Кайрак та әйбәт иде, ике генә ышкып җибәрәсең...—чалгының йөзе шундук җаныңны кырып алырлык хәлгә килә...

Менә чабып ташланган алан уртасында алар икәүдән-икәү генә калдылар: бер-берсенә мәхәббәтләре ташып торган ике җанны өйрәтәсе юк иде; әпәләр тау артына китеп югалу белән, алар бер-берсенә сарылдылар, аннары яна гына чабылган хуш исле печән өстенә тәгәрәделәр...

...Хәлим белән Майяны карчыклар печәнгә төшкәннең өченче көнендә "тоттылар". Печән кибәне артында бер-берсенә сыенышып утырган чакларында өсләренә килеп чыктылар. Килделәр дә, дәшми-нитми генә, Майяны кулыннан тартып торгызып, житәкләп алып кайтып киттеләр. Хәлим, авызын ачып, кибән төбендә утырып калды.

Кич бик озак йокыга китә алмый ятты ул. Нәрсә булды Майя белән? Тагын кыйнап, бәйләп ташладылар микән? Ничек кенә белергә соң? Дивардагы тишектән бернинди файда да юк. Тәрәзә аша үрелеп караса?.. Бәлки ни дә булса күреп булыр?

Хәлим тиз генә торып тышка чыкты. Мәче адымнары белән алачыкның аргы башына юнәлде. Үрелеп тишек аша эчкә карады. Майя күренмәде, сихерче карчыклар гына, бер-берсенә каршы тезләнеп, күзләрен йомып, ниндидер мәҗүси дога пышылдыйлар...

"Кая куйдылар икән Майяны? Берәр почмакка бәйләп ташлаганнардыр әле, хәшәрәтләр!" Хәлимнең уйлары яшен тизлегендә бәргәләнеп йөрде. Шул уйлануында ул бер хәтәр фикергә барып төртелде: "Әллә... карчыкларга бер-бер хәл кылыргамы? Мәңгегә котылыргамы алардан?"

Хәлим шулай дип уйлап та бетерде, алачык почмагында сөялеп торган юан гына күсәккә барып та тотынды. "Үтерәм, сугам да үтерәм үзләрен! Тиеп кенә карасыннар, үтерәм!.."—дип, эченнән генә ярсып, карчыклар янына керә торган ишеккә омтылды. Шул омтылуында, тупса алдында туктап та тормыйча, эчкә кереп китте. Әмма карчыклар утырган түр бүлмәгә кереп житә алмады, чыра яктысы төшеп торган ян як бүлмә ишегендә бер кара шәүлә пәйда булды. Аның ап-ак йөзенә үлек төсләре кергән, ә карашлары караңгылык, салкынлык бөркеп тора. Албасты карчыкларның берсе иде ул. Каны кызып, нәрсә эшләгәнен белмәс дәрәҗәгә житкән Хәлим аңа кулындагы авыр тәпәч белән сугарга кизәнде. Әмма аның куллары, иясен тыңламыйча, күтәрелгән килеш эленеп калдылар... Шулвакыт теге карчык ике кулын да алга—Хәлимгә таба сузып җибәрде, үзе, йөзен чытып, күзләрен кысып, ысылдап куйды. Карчыкның кулы бу якка хәрәкәтләнгән саен Хәлим үзенең артка таба ава баруын тойды; ниндидер күренми, беленми торган җил сулышы аны үз ихтыярына алып, артындагы стенага илтеп тәрәде... Хәлим, аркасы белән "ыһ" итеп шул стенага барып бәрелде дә идәнгә шуып төште...

Башка берни дә хәтерләми ул. Тик теге албастыларның баш очында эленеп торган, җыерчык баскан, кара тимгелләр белән чуарланган килбәтсез йөзләрен генә шәйли, колак төбендә каркылдап торган сөйләшүләрен генә ишетә...

—Йөзенә ак сызам... Йөзенә кара сызам... Кара акны бетерә, кара акны үтерә...

Карчыкларның хәшәрәт йөзләре Хәлим өстендә салмак кына селкенәләр дә селкенәләр, һаман бер сүзне кабатлыйлар:

—Хәлимгә ак таш, Хәлимгә күк таш, Хәлимгә кара таш... Ак таш күк ташны яба, күк таш кара ташны яба...

## XXVIII

...Хәлим баш очындагы томан пәрдәсе артында беленер-беленмәс кенә селкенгән ике йөзне күзәтеп ята. Шул ук таныш тавыш:

—Ак таш күк ташны яба, күк таш кара ташны яба...

Таныш тавыш бит бу... Мәймүнә карчык тавышы! Теге имче Мәймүнә тавышы. Тагын Хәлимне сихерләргә килгән микәнни? Тагын өшкерептөчкереп, җәфалап бетерәләр икән...

Хәлим күзләрен ачты. Ул тәмам айнып җиткән иде. Түшәгеннән үк торып утырды. Сания дә шунда икән:

—И балакаем, бигрәк нык куркыттың. Төне буе саташып, кем беләндер тиргәшеп, сугышып чыктың. "Үтерәм-үтерәм!"—дип, кычкырып үрсәләнден... Менә, сине тынычландырыр өчен әби карчыкларны да чакырдым. Мәймүнә әбиең тирә-якта беренче имче. Синдәге зәхмәт орлыгын чыгара алмас микән, дип чакырдым инде... Мәрткә китәсең дип торабыз бит, балам...—Сания, дымлы күзләрен мөлдерәтеп, сөйләде дә сөйләде, ә Хәлимнең бу минутта үкереп елыйсы, рәхәтләнеп бер бушанасы килде. Төштәге хәлләрне исенә төшереп, өндәге йөрәк әрнеткеч галәмәтләрне күреп, аның күңеле тулды, чынлап та, күзләреннән берничә бөртек яшь бәреп чыкты, әмма Хәлим иркенләп елап җибәрә алмады. Әллә янында Мәймүнә карчыкның төкеренеп йөрүе комачау итте, әллә ул бу зәхмәтле елда ничек еларга кирәген оныткан иде...

Васимә карчык белән Мәймүнә карчык дога пышылдый-пышылдый чыгып киткәч, Хәлимнең зиһен савытында бәргәләнгән беренче уй шул булды: "Монда да шул ике карчык! Кайчан котылам инде мин бу җен албастыларыннан?! Ичмасам, төшен дә күреп бетермәде бит... Тукта! Ул бит кача алмады. Ул бит тотылды... Хәлим шунда тагын төшенә әйләнеп кайтты. Юк, ул инде тәмам уянган, урмандагы хәлләрнең калган очын хәтер төбеннән капшап табарга тырышып ята иде. Улының кинәт кенә тынып, уйчанланып калуын күргән Сания куркып-шикләнеп ("Ычкынмаганмы бу бала?") сорап куйды:

—Балам, бер-бер хәл булмагандыр бит? Башың авыртамы әллә?

—Юк-юк, әнкәй. Бар җирем дә таза. Ялгызымны гына, үземне генә калдыр әле, әнкәй.

—Ярый, балам, мин монда гына. Кирәк булсам, чакыр, яме...

Хәлим тагын хәтер ишеге төбенә килеп басты. Әйе, ачык хәтерли Хәлим—ул төнне карчыклар яшәгән алачык бүлмәсенә имән таяк күтәреп барып кергән иде. Шунда башланды да инде әкәмәт хәлләр. Беркем сукмаган килеш, таягы-ние белән стенага очты ул. Аннары, идән чүпрәге кебек, йомшап-мәлҗерәп, идәнгә килеп төште... Тагын нәрсә булды соң әле? Карчыклар аны сихерли башладылар—битенә, шәрә тәненә ниндидер ак, кара ташлар белән сызыклар сыздылар, өстенә көл сиптеләр, әллә нинди үләннәр белән йөзен чәбәкләделәр... Аннары... аннары, күзләрен бәйләп, үзләренең сихер алачыкларына—гыйбадәтханәләренә алып кереп киттеләр. Хәлим төштәге кебек кенә хәтерли: үзе атлый, үзе... атламый, җирдән аз гына күтәрелгән килеш, очып бара, ахры. Менә сихер тамгасы сызылган ишек шыгырдап ачыла башлады; алда—ике карчык, уртада Хәлим сөйрәлә—алар явыз Аждаһа авызына кергән кебек, сихер алачыгының караңгылык, салкынлык, шом анкып торган ишегенә шуышып кереп киттеләр.

Кергәч нәрсә булганын Хәлим ачык кына хәтерләми. Ниндидер как сәкегә яткырдылар. Өстенә юеш, сасы тире яптылар... Башына, маңгай турысына үзле балчык сыладылар, йөзенә косасыны китерерлек тәмсез су бөрекләделәр, әчкелтем төтен өрделәр... Тагын ниндидер ачы тавыш яңгырап тора Хәлимнең колагында:"Хәли-и-им!.." Таныш тавыш бит бу... Майя!..

Башка ул берни дә белми.

Уянып киткәндә Хәлим үзенең алачыгында—түшәк өстендә ята иде. Билдән югары ялангач. Тәне пычранып, буялып, тырналып беткән... Иреннәренә ком, көл кунган, хәтта авыз эчендә дә тәмсез, әчкелтем-тозлы тузан тешкә тиеп, шыгырдап тора.... Күзләрендә дә ком-тузан. Бөтен тәне сызлый. Гүя куллары-аяклары үзенеке түгел... Кыймылдатырга да куркыныч. Кузгала башласа, хәзер бөтен тәне таралып, сүтелеп китәр төсле...

Кузгалмыйча озак ятты Хәлим. Авырту зиһенен томалаган, ахры.

Берни хакында да уйлыйсы, исенә төшерәсе килми иде аның. Хәлим бу юлы тәгаен сизенә: карчыклар аның бәгыреннән Майяны өзеп ала алмаганнар. Чөнки ул Майя хакында да, кичә кич, бүген төнлә булган хәлләр хакында да төгәл белә, димәк, сихер аны ала алмаган... Менә ул үз бүлмәсендә ята. Сак та юк... Куллары, аяклары да бәйләнмәгән... Хәтта хәтеренә, зиһененә дә әллә ни хилафлык, зыян килмәгән...

Шулай да ниндидер хикмәт бар монда. Майя кайда соң? Карчыклар белә: Майяны ташлап китмәячәк Хәлим. Шуңа күрә дә кызны яшереп, качырып тоталардыр... Хәзер торып, Майяны эзләп карарга кирәк. Бу юлы күсәк тотып йөрмәячәк инде. Хәйлә белән алырга кирәк ул явыз албастыларны...

—Хәлим!..

Кемдер Хәлимне дәшә түгелме соң? Каян булыр бу тавыш, кем ул? Әллә тилегә сабыша инде?

—Хәлим!..

Түшәмнән дисәң... Әһә! Дивардагы тишектән килә бит бу тавыш. Хәлим, көч-хәл белән генә торып, тишек янына килде.

—Кем бу?

—Мин—Майя... Хәлим, әбиләр чыгып китте. Мина тышка чыгарга ярамый. Сүз бирдем... Сүземдә тормасам—сине харап итәчәкләр. Бу—безнең килешү. Мин сиңа якын бармыйм, алар сиңа тими... Харап була яздың бит син, Хәлим... Ярый әле барып таптым үзләрен... Башка үртәмик әбиләрне; безгә барыбер бергә булырга язмаган. Белеп тор: без башка күрешмәячәкбез... Ә инде күрешә калсак... Кабат килә калсаң... учына кендегенне кысып кил... Ул сине сихер зәхмәттән саклар. Син озакламый кешеләр арасында яши башларсың... Мин калам... Әмма мин үземдә синең җан бөртегеңне, кан тамчыңны, тән күзәнәгеңне алып калам... Хуш, Хәлим...

—Майя, нәрсә сөйлисең син?.. Әйдә бергә китәбез, Майя! Ташлама мине, Майя!.. Беркая да бармыйм мин синсез. Кешеләр дә, башка дөньялар да кирәк түгел миңа! Миңа син кирәк, Майя...

Үзен үзе белештермичә, Хәлим саман диварны кыйный башлады, үзе бертуктаусыз кычкырды:

—Майя! Майя!.. Майя...

Аннары, хәле китеп, идәнгә шуып төште, башын стенага терәп, тынып калды. Юк, тыштан гына шулай тынып калгандай булды ул, эчтән сулкылдап, ачыргаланып елады Хәлим... Аның калтыранып, мәрткә китеп утыруын күргән һәрбер кеше: “Бу кадәр дә бәхетсез кеше бөтен дөньясында юктыр”, дип уйлар иде...

Юк! Хәлим болай гына бирешергә теләмәде! Ул, бөтен авыртуын, күнел әрнүен җинеп, сикереп торды, ишекне бәреп ачып, юлында очраган читән-коймаларны аударып, Майясы янына йөгерде... Менә ул очып диярлек тузанлы сукмакка чыкты, әмма ерак китә алмады, нәрсәгәдер абынып, нәкъ кое янына барып капланды... Торып китмәкче булды. Аягына басты... Майяны кабат йоткан алачык ишеген дә аерымачык күрде... Әмма ары атлап китә алмады, коеның ике ягында кара багана кебек үрә катып торган албасты карчыклар сихере белән бер урында кадалып калды... Хәлим нишләргә дә белмәде. Аң-зиһене исән-имин, хәтта куллары, башка тән әгъзалары да тере, үз урынында, ә менә аягы җиргә ябышып калган.

Берара нишләргә белмичә аптырап торган Хәлим кое янына куелган тулы чиләкне күреп алды, иелеп, чынлап-зынлап торган башын шул чиләктәге салкын суга тыкты... Моңа гына риза булмыйча, чиләкне ике яктан кысып тотып, өскә күтәрде һәм андагы бөтен суны үз башына койды. Бозлы су Хәлимнең тәнен генә түгел, җанын,бәгырен, күнелен өшетте, туңдырды һәм аның бөтен җан-тән җылысын, шул җылы белән бергә, һушын, хәтерен, аң-зиһенен алып, җиргә агып төште, тапталып, зәгыйфьләнеп беткән үлән бөртекләренә яшәү бүләк итте...

...Бераздан Хәлим, албасты карчыкларга ияреп, урманга кереп бара иде инде. Ярсуы, дуамаллыгы басылган, тәне җиңеләеп, җан-күңеле бушап,

күзләре тоныкланып калган... Аның өчен хәзер Майя да юк, бер еллык урман тормышы да җуелып юкка чыккан, тиздән ул бу карчыкларны да, бу урман юлын да, тәнендәге, җан-бәгырендәге авыртуларны да тәмам онытачак, ярты көнлек урман дөньясы кичеп, бер ел элек килеп туктаган юл буена, андагы серле багана төбенә килеп утырачак, шул мәлдә, албастылар сихере белән, аның элекке хәтере кайтачак, аң-зиһене сафланачак, әмма ул, шуның бәрабәренә, урманда яшәгән бер еллык гомерен онытачак...

## XXIX

Ниһаять, Хәлим барысын да исенә төшерде. Аның өчен хәзер һәр нәрсә көн кебек ачык. Ул сихер-зәхмәт корбаны булган, бер ел буе ниндидер хәшәрәт албастылар белән яшәгән, нәрсә кушсалар шуны эшләгән, ничек теләсәләр —шулай йөргән, утырган, яткан, ашаган, йоклаган, хәтта уйлаган, хисләнгән... Бу бит коточкыч нәрсә! Бу... Бу—иң әшәке коллык... Бу—кешенең кешелеген урлау, гомерен урлау, үткәнен генә түгел, киләчәген, бәхетен урлау...

Бәхетен? Юк, бу коллык аңа бәхетсезлек яисә кимсенүле гомер генә бүләк итеп калмаган, ул аңа Майяны да биргән, димәк, бәхетен дә...

Нишли икән анда Майя? Ничек яши икән? Сагына микән, онытмаган микән Хәлимне? Их, бер тапкыр гына, күз чите белән генә күрергә үзен! Әллә... Әллә? Эзләп чыгып китәргәме? Таба алырмы ул Майясын? Һичшиксез табар! Мәрхүм әбисе әйтә иде:“Һәр сөюнең үз йолдызы бар. Адашканнарга, юлсызларга шул йолдыз юл күрсәтә”,—ди торган иде. Аннары... Майя үзе дә чакырып калды бит аны:“Кабат килсәң, киселгән кендегеңне учлап кил”,—диде... Тукта, ничек инде “киселгән кендегеңне”? Ә!.. Аңлашыла... Мәймүнә имченең бу хакта сөйләгәне бар: “Баланың киселгән кендеге аны гомере буе кара сихердән, явыз зәхмәттән саклар, ташламагыз, югалтмагыз, пычратмагыз аны”,—дигән иде ул күршедәге Минзифа дигән хатын бала тапкач. Ә бәлки Хәлимнең кендеге дә саклангандыр? Бәлки, бу кендек киләчәктә аның җан һәм тән сакчысы булыр, ә?

—Әнкәй! Әнкәй дим!..

—Әү, балам, нәрсә кирәк, хәлең аруландымы? Ашыйсың-эчәсең килмиме?

—Юк-юк, әнкәй... Әйт әле, мин тугач, киселгән кендегемне кая куйдыгыз?

Мондый сәер сорауны көтмәгән Сания башта һушын җыя алмыйча торды. Аннары әйтте дә бирде:

—Ә-ә-ә, кендекме? Бар ул, бар. Беренче алган чәчең белән бергә төреп, синең түшәк очындагы матчага кыстырып куйган идем, балам... Хәзер дә шундадыр, кайда булсын...

Нигә, ни өчен кирәген дә сорап тормыйча, Сания түргә узды, нәкъ Хәлим баш очындагы матчаның түшәм ярыгын капшый башлады. Бераздан шыгырдавык кәгазьгә төрелгән кендек белән чәч бөртекләрен тартып та чыгарды.

Бик озак карап торды Хәлим аларга. Кибеп, караеп беткән ит бөртеге әллә ни кызык тоелмады, шулай да, бу сәер ядкәрне күргәч, аның йөрәге ешрак тибә башлаган кебек булды...

Сания, улының сөйләшә башлавын, тормышка кайтуын күреп, тынычланды, ахры, сорап та карамыйча, өстәлгә аш-су әзерләргә кереште. Аннары:

—Ашый тор, улым, Ак бабаңны, Васимә әбиеңне чәйгә чакырып керәм әле,—дип тышка чыгып китте.

...Васимә карчыкны ияртеп кайтып кергән Санияне коры түшәк, ярым бушап калган өстәл каршы алды. Өстәлдә язу. Ашыгып сырланган юлларны Сания чак-чак кына таный алды.: “Әнкәй! Ачуланма, мин бәхетемне эзләп киттем. Майяны эзләп киттем... Көт безне! Борчылма, кендегем мине саклаячак. Хәлим”.

Сания, буыннары йомшап, караватка утырды.

—Улым! Балакаем!.. Тагын ташлап киттеңмени мине... Ярабби, тагын нинди сынаулар җибәрдең миңа?! Хәзер нәрсә эшләргә инде миңа? Каян эзләргә Хәлимне?..

—Көтәргә, көтәргә, Сания!..—бу сүзләрне ишек төбендә басып торган, бер караудa барысын да аңлап алган Ак бабай әйтте. Үч иткәндәй, тышта да: "Сания апа! Сания апа!"—дип кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелде. Өйдәгеләр тәрәзәгә капландылар. Тавыш озак көттермәде, балага узып, гәүдәгә тулыша башлаган Нәфисә булып, ишектән килеп тә керде:

—Сания апа! Беләсезме, аркасына капчык аскан Хәлим урманга таба китте... Барыгыз инде, нишләп утырасыз, куып тотыгыз үзен, тагын югалачак бит ул... Сания апа! Нәрсә булды? Нигә дәшмисез? Барыгыз дим... Алып кайтыгыз Хәлимне!..

Сания, бермәл нишләргә белми торганнан соң, ишеккә омтылды, әмма аның беләгеннән Ак бабай тотып калды, чыгып китәргә ирек бирмәде:

—Юк, кызым, барма... Бүген тотсаң, иртәгә китәчәк ул, иртәгә дә тотсаң, берсекөнгә китәчәк. Язмышы шул аның... Язмышы чакырып йөртә малаенны... Хәзер көтәргә генә кала... Түземлек, сабырлык бирсен сиңа Ходай, барыбызга да түземлекләр, сабырлыклар бирсен...

—Амин, шулай булсын...

—Амин...

—Шулай булсын...

## XXX

Урман юлыннан аркасына солдат биштәре аскан берәү бара. Авылына кайтып барадыр дисәгез, нык ялгышырсыз, ул әле генә туган нигезен, газиз анасын калдырып чыгып китте. "Кая бара ул?"—дигән булып, сүз уйнатып тормыйм. Без барыбыз да беләбез: Ул—Якты дөньяның бер үксез баласы. Аның соңгы ике ел эчендә күргәннәрен кайберәүләр гомерләре буе күреп бетерә алмыйдыр. Әле күрәселәре күпме аның? Ә беләсезме—бу адәм баласы үзе теләп албасты өненә кереп бара. Чөнки аның максаты бар, аның олы, көчле йөрәге бар, нык ихтыяры, әсәк акылы, бетмәс-төкәнмәс сөюе бар! Аны инде болай гына алып булмый, бер сихер-ым, зәхмәти дога, кара йола белән генә буйсындырып булмый, чөнки аның күкрәк-түшендә сихер кайтара торган гомер ачкычы—кендек иясе бар, ә түш кесәсендә әнисе салган догалык-бөти бар...

Юлы ерак аның. Күпме барасын ул үзе дә белми. Бер көн барырмы, бер атна, бер ай, бер ел барырмы? Әллә гомере буе барып та максатына ирешә алмасмы? Укучым, син түгел, хәтта, мин үзем дә бу хакта төгәл генә әйтә алмыйм. Каһарманнарны ак кәгазьдә тудыру гына җиңел бит ул. Бер тәпи баскач, яши, сөйләшә, шатлана башлагач, алар сиңа әллә ни игътибар итмиләр, үз юллары белән, үз язмышларына каршы чыгалар да китәләр, бер киткәч, тиз генә әйләнеп кайтырга теләмиләр.

Хәлим дә мине тыңламый инде. "Үз өенә кайт, әниеңне куандыр, беренче мәхәббәтеңне бәхетле ит, ул сине өзелеп ярата бит, рәхәтләнеп яшәгез, күп балалар үстерегез",—дип карыйм, ә ул минем сүзләрне колагына да элми. Үз туксаны туксан! Аның башында бары бер генә уй бөтерелә: "Ничек тә Майяны табарга! Табарга! Табарга!" Шулвакыт... Аллаһы тәгалә яраткан аяз күк өстендә әллә каян гына Майяның соңгы сүзләре пәйда була. "Мин үземдә синең җан бөртегеңне, кан тамчыңны, тән күзәнәгеңне алып калам",—дигән иде ул саубуллашкан чакта.

Кем белә, бәлки, Хәлимне албастылар өненә әнә шул җан бөртеге, кан тамчысы, тән күзәнәге чакыргандыр, әгәр шулай икән, барыбыз да тыныч булыйк: менә кадәр Табигатьнең үз балаларына карата бер мәртәбә дә явызлык кылганы юк әле!

*Ахыры киләсе санда*

# Şiğriət
# Шигърият



## Наис Гамбәр

### ЮГАЛТЫРЛЫК ТҮГЕЛ... ЮГАЛТМАМ

Алдыма өзелеп төшәләр
Саргайган
Парашют-яфраклар;
Көчкә асылып торганчы
Бу, бәлкем, яхшырак та.
...Алдыма өзелеп төшәләр.

Мең сере бардыр яшәүнең—
Кайчак та
Бик түзем булу кирәк;
Усак яфрагы күк җилферди
Җилсез дә—тузган йөрәк.
...Мең сере бардыр яшәүнең.

Ышанып йөргән буласың
Яктырак
Киләчәк житәсенә;
Тибә дә—язмыш-ат
Тормышның киртәсенә.
...Ышанып йөргән буласың.

Басасым килми—тередер!—
Кыштырдый—

Наис ГАМБӘР (1947)—*шагыйрь, тәнкыйтьче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Баш очымда—Кояш» исемле шигырьләр китабы (1991) авторы . Казанда яши.*

Өзелгән яфракларга.
Юл алам—бераз читкәрәк,
Аланга—яктыракка.
...Кыштырдый... Яфрак тередер!..

❧

Китүдән дә кайту авырырак
Бу дөньяның чиксезлегендә;
Яшәү белән Үлем арасында
Яши кеше—үз читлегендә.

«Мәңгелеккә!»—диеп килгән идем,
Узсам—узганмындыр бер саплам;
Сәхәрдә дә бер сүз, ахшамда да:
«Югалтырлык түгел, югалтмам.»

Гомер җебе кыска—бер саплам.

❧

Эндәштеләр дә киттеләр:
—Ниләр, ни булды?!
Кайтарып әйталмадым:
«Тулган... Ай... тулды!
Тулган... Ай... тулды!»
/Айга берни дә булмады,
Күңелем тулды./

Шәрә ботак арасыннан
Сузылды мең кул.
Ялгыз кеше—ялгыз агач...
Төнге урман. Юл.

Үләннәр буйлап шуыша
Агалар күләгәсе...
/Бер минут ташып туласың,
Ел буе түләнәсең./

Әйләнеп кайтты авазың:
«Тулган... Ай... тулды...»
...Ертык болытлар күзендә
Йолдыз тотылды.

❧

*Төн кундым Гаташның*
*Алмагач бакчасында.*
*Яшьлек язы... Уртак юллар,—*
*Яңарттым барчасын да.*

Алмагач тирәли Җир шарын
Урап үтте Ай бер төн;
Күршеләр яккан учактан
Күземә керә төтен.

Дидем: «Ялкыны сүнгән лә,
Бу бит соң бары төтен.»

Дөньям ярылган урталай,
Тулган Ай гына бөтен.

...Күршеләр яккан...
Төтен...
Әле ярый Ай бөтен.

❧

Әйләнеп карыйсың: тирәндә—
Күбәләк,
кырмыска,
бөҗәк!
Аңлыйсың килсә дөньяны—
Барыбер бер Фабр[1] булу кирәк!

Аныңча—
Үләндә дә бар йөрәк.

❧

Ходай сиңа: «Бирмеш көнеңәчә
Тугры юлда үләрсең,—дигән.—
Киеп йөргән кәлүшеңә чаклы
Черемәс...
Өч йөз ел биргән!»

❧

Алиһәләр кунды кочакларда,
Соңгы сулышы булды: «Ү-ләм! Ү-ләм!»
Бер рәхәтнең мең газабы булып
Шытып чыга җиргә кеше-үлән.

❧

Бер эзгә басу кыендыр
Мең кеше үткәннән соң;
Сөюнең булмый үткәне,
Ялганына хәтле... чын.

❧

Янымда юк берәү, җанымда
Хис белән акыл тату;
Тәкмәрлек атып китимме?—
Аһ, дөнья нинди мату-у-у...
Мату-ур!

---

* Бөек француз табигать белгече.

❧

*Р. Ф. га.*

Түмәр бүләк иттең:
—Алып кайт әле үзеңә,
Карама син кеше сүзенә,
Һәркем яши бары үзенчә.

Ташлап калдыралмыйм...
Бүләк ич бу!
«Сүгеп» кайтып киләм түрәмне,—
Түмәр түгел, яшәү бигрәк авыр,
«Түмәр басып тора түбәмне.»

Кайтып киләм...
Колачларга сыймас
Мең яшәрлек түмәр иңсәмдә;
Егыласы килми,
егыласы,—
Вакытлыча башым исәм дә.
Тагын нәрсә кирәк исәргә?!—
Хәлем бетсә, килеп утырам да
Колач җитмәс каен түмәргә...

Миңа авыр, сиңа да бик авыр,
Сиңа түгел—миңа бик авыр.
Түмәр кебек гомер басып тора,
Дөньялары бигрәк болгавыр.
Аһ, авыр!

❧

*Г. гә.*

Атларым чабар сыман ла,
Юлын да табар сыман;
Ничек аерып алаем
Җиде ят арасыннан?

Башлымы сөлгеләрең лә?—
Ташлама өлгеләрен;
Чигелде күңел түремә
Җуелмас билгеләрең.

Ут мәллә эчләреңдә лә,
Тут кунган төсләреңә;
Башыңны саласыңдыр да
Ак мендәр өсләренә...

Югалды бердәнберем лә,—
Түрдәге яран гөлем;
Янган утларга салдың да,
Сибелде кырга көлем.

❧

«Гөлләр инде, гөлләр шиңгәннәр,
Орлыкларын җиргә күмгәннәр—
Алсуланып торган йөзләре
Салкын карлар кебек—күм-зәңгәр.

Җирдә туа, Җирдә сүнә Яшәү,
Соңгы тәхет—Җирнең кочагы.
/Гөл орлыгы—җирдә йоклый булыр
Төштә күрә-күрә кыз чагын./
Яшәү—Үлем аша; гөлдән тамган
Бу орлыклар язын гөл булыр;
...Җаным Сездә кала,
Тән үлгән көн
Яңа тормыш туган көн булыр.»

Шундый уйлар белән чыгып киләм
Чәчәкләрнең каберлегеннән;
Аh, яшәгән саен бу тормыш
Газаплырак...
Кадерле генә!

❧

Ераклардан килгән тавыш сыман
Уяна да хәтер... Бөтерелеп,
Бөтеренеп—кечерәеп алам;
Тоныгая истә калган төсең,
Кайчандыр үз, изге якын кешем!—
Син барыбер миңа сабый бала.
...Ераклардан килгән тавыш сыман.

Агачларны үлән кебек кенә
Ерып чыгарсың күк үткәннәрдән,—
Пәрәвезләр сарыр иңнәреңне.
Ташландык бер йортның каршысында
Бүкәннәргә утырып көткән мәлдә
Җилләр җилфердәтә җиңнәремне.
...Агачлар да үлән кебек кенә.

Бер көнен дә калдырмыйча яшәп
Уза гомер—ага гына; чәчрәп
Улаклардан аккан су сыман.
Сөю—дәрья, ярларына тулмый,
Аккан суга кабат кереп булмый,—
Ярда калам... Бәхил шушыннан.
...Бер көнен дә калдырмыйча яшәп.

Әлсерәтте еллар, әлсерәтте...
Яшьлегемнең соңгы тәэссораты
Карап тора агач артыннан.
Мин әлегә туган туфрагымда;
Гомеремнең сыңар яфрагын да
Бирмәс идем көмеш-алтынга...
...Әлсерәтте еллар, әлсерәтте.

Тып-тын гына август җиле исә
Ераклардан килгән тавыш сыман.



## Илдус Гыйләҗев

### САГЫНДЫРЫП ТӨШЕП ИСЕГЕЗГӘ

### Җитми төсле...

Шигырь язар өчен, тәү нәүбәттә,
Үз халкыңны кирәк белергә:
Тукай шагыйрьлеге җитми безгә—
Татар җанын ачып бирергә.
Шикләндерә ярып сүз сөйләргә,
Курку хисе китә тамырга.
Җәлил кыюлыгы җитми төсле—
Нәфрәтеңне әйтеп салырга...
Яр сөйгән бар, гыйшык утларында
Туры килде бик еш янарга.
Сибгат яратуы җитми төсле—
Мавыктыргыч сүзләр табарга.
Сыкрау катыш моң-зар ишетәсең,
Кемгә генә барып кагылма.
Туфан сабырлыгы җитми төсле—
Түзем кеше булып калырга.
Бүген никтер шулар җитми төсле
(Күбен күп тә бездә шәп ирләр...)
...Шигырьләргә сеңгән холкы белән
Тәрбияли безне шагыйрьләр...

### Менә шундый хәлләрдә...

Дуңгыз булып мыркылдап,
Маржа булып шаркылдап,
Хәрам сулар эчертеп,
Маймыл ясап исертеп,
Корал белән куркытып,
Ялган тарих укытып,
Чиркәүләргә чакырып,
Акырып вә бакырып,

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946)—*шагыйрь. «Җир китабы», «Җилкенү», «Мәгарә», «Хак сүз» һ.б. китаплар авторы. Азнакай районында яши.*

Томалыйлар аңымны,—
Кайнаталар канымны,
Җәфалыйлар җанымны,
Туздыралар малымны...
Үзгәртергә телиләр,
Колга нигә тел? —диләр.
Чалып алар екмакчы,
Кабып кына йотмакчы.
Менә шундый хәлләрдә...
Юк, кирәкми җәлләргә!
Каршы тору сәләтен,
Хөрлек сөю гадәтен,
Безгә биргән бабайлар,
Әткәйләр һәм агайлар.
Баскын чигәр, түзалмас,
Татар рухы үзгәрмәс!
...Татар мәңге тезләнмәс...

## Сагындыра шулай да

Истәлеккә нәрсә алыр идем,
Балачакка кире кайтып булса?
Ис китәрлек әйбер юк та кебек,
Шөкер итә идек тамак туйса.
Үкчәләре кыек чүәкләрне
Бәйрәмнәрдә генә кия идек;
Атланмалы чалбар, җитен күлмәк
Булды бугай безнең бөтен милек.
Ябык муеннарга—кызыл байлык—
Өчпочмаклы мунчак тагып йөрдек;
Кәлҗемәдән күчеп бәрәңгегә,
Дөнья базарына барып кердек...
Муллык ташып торган бу заманга
Ул еллардан тагын нәрсә хаҗәт?
Җиңгә борын сөртеп йөргән малай
Сагындыра бик еш, шунсы гаҗәп...

## Дезертир да, түгел дә

*Мин дезертир бугай, командир!*

Һади Такташ

Шул халәттә булам мин дә бик еш,
Әллә качкын, әллә «ышпиун».
Тукай әйтмеш, түгел читтә генә,
Үз илендә кайчак «эш кыен».
Басар идем сафка корал тотып,
Кемгә каршы барыйм орышка:
Чечнягамы, Әфган халкынамы?
Кемне кыйныйм тора-торышка?
Үчем юк бит, шөкер, берсендә дә,
Күңел күркем—дуслык, туганлык.

Шушы хисем, җәйсәм байрак итеп,
Җир шарымны дүрт-биш уралрлык.
Кыргыйлыктан арынырга вакыт
Җиткәндер бит инде, җиткәндер:
«Мин—тынычлык яклы!»—диеп, Татар,
Бар дөньяны кат-кат сискәндер!
Мин дезертир бугай: Такташ кебек,
Хәрби эшкә соңга калынган.
...Татар полклары юк шул хәзер,
Командирлар башка кавемнән...

* * *

Көнкүрештә тыйнак була белү
Килә торгандыр ул тумыштан.
Җан дусларны юк-бар йомыш белән
Артык борчымаска тырышам.
Анда да бит калыр шул гадәтем,
Авыр чаклар булыр, түзәрмен.
...Сагындырып төшеп исегезгә,
Үзәкләрегезне өзәрмен...

## Барда кызлары

Очраштырды безне Казан—
Белем, яшьлек каласы.
Гыйлем аша якынайтты
Барда—Казан арасын:
Солтанайның Әнисәсе,
Озын Ялан Фәнисәсе,
Үтәйбашның Рәисәсе,
Каенавыл Фәнүсәсе.
Чибәр, нәфис иде алар,
Сүзләре—кош сайравы;
Мәңгелеккә кыйбла итеп
Татарстанны сайлады:
Солтанайның Әнисәсе,
Озын Ялан Фәнисәсе;
Үтәйбашның Рәисәсе,
Каенавыл Фәнүсәсе.
Сагынам да, сәфәр чыгам,
Урыйм яшьлек елларын.
Сезне уйлап үтеп барам
Казан—Барда юлларын:
Солтанайның Әнисәсе,
Озын Ялан Фәнисәсе;
Үтәйбашның Рәисәсе,
Каенавыл Фәнүсәсе...

## Җан бирмәк

Син бит аны яратасың,
Күз карашың әйтеп тора.
Нишләтим соң сине, бала?
Карт акылым исәп кора:
Каршы килсәм, гомер буе
Үпкәләрсең төсле миңа...
Риза булсам, күңел тартмый,
Ул пар түгел кебек сиңа.
Яхшы беләм, утырсам да
Аркылыны буйга чутлап—
Мәхәббәтне тыеп булмый...
Аны була бары хуплап.
«Ир бирмәк ул җан бирмәк»,—дип
Әйткән мәкальне без белмәк.
Хатын-кызга шулайдыр ул...
Әти өчен шул—кыз бирмәк...

## Мин әйткәнчә

Синең миңа хакың бар,
Минем сиңа хакым бар.
Ул хакны бит никах белән
Теркәп куйды хөкемдар.
Синең миңа антың бар,
Минем сиңа антым бар.
Шул антыңа тугры булсаң,
Кирәк түгел алтыннар.
Синең миңа назың бар,
Минем сиңа назым бар.
Әйтәм ич мин: безнең язмыш
Югарыда язылган...

## «Карт» гашыйк

Сезнең авыл бик-бик якында,
Урман сарган таулар артында.
Өметләрне юлга түшим дә,
Чыгып китәм хыял атында.
Дилбегәсе—синең кулларда,
Уйларны гел тарта шул якка.
Мин бәхетле, барып җиталсам,
Синең эзләр калган сукмакка.
Аннан ары үтү ярамый,
Тыясың ич:—Кеше күрмәсен.
Картаеп беткәч гыйшык уйнап
Йөриләр,—дип, яшьләр көлмәсен.
Йөрәкне тотып, йөрим ары да бире,
Узып китәм сезнең турлардан.
...Дару үләннәре җыеп кайтам
Бакча артыгыздан, урманнан...

## Чират синеке

Нигә кирәк булды инде
Мине эзләп килү?
Рәнҗетелгән хисләремнән
Тагын бер кат көлү.
Беләсең ич, авыр миңа
Сине кабат күрү.
Бер котылган ут эченә
Бу бит кире керү.
Кызык тапсаң, пешеп кара,
Калып тере көе.
Күмерләрен сиңа бирәм...
Миңа калсын—көле.

## Теләгем бар

Көтеп алган шатлык иде
Безнең күрешүләр.
Татлы булып истә калган
Тәүге үбешүләр.
Аз идеме, гашыйклар дип,
Үртәп көлүчеләр?
Көнләшүдән, чыдый алмый,
Дошман күрүчеләр.
Бар иде бит сокланучы,
Хуплап йөрүчеләр.
Кош теледәй хатларымны
Илтеп бирүчеләр.
Җиңеп чыктык, мәңгелеккә
Булды килешүләр.
Шундый язмыш телим сезгә,
Арттан килүчеләр...

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Зөлфәт Хәким

## УЙЛАР УЙНАВЫ...

1

Үзе өчен көрәшә алмаган кеше халык өчен көрәшә алмый.

2

Кешене үзенең хаерчелеге түгел, ә бәлки башкаларның ана: «Хаерче!»— диюләре куркыта.

3

Яшәүнең мәгънәсе—яшәү мәгънәсен эзләү.

4

Ул халык өчен көрәшә, дисез. Әмма ләкин озак көрәшүчене түгел, ә бәлки җиңүчене мактарга кирәк. Көрәшүчеләр күп. Җиңәргә кирәк! Мәңге көрәшүдән ни мәгънә?!

Сабантуйда озак көрәшүчене түгел, җиңеп батыр калучыны данлыйлар!

5

Балыкның кайнар табага эләгүендә кармактагы суалчанны гаепләргә маташучылар да бар.

6

«Милләтне коткаручылардан» кайвакыт милләтне коткару мәслихәт.

7

Каһарман. Куркак булудан курыкканга күрә курыкмый.

---

Зөлфәт ХӘКИМ (Хәкимханов Зөлфәт Зөфәр улы, 1960)— *язучы, драматург, композитор, җырчы. Сигез китап һәм егермегә якын пьеса авторы. Казанда яши.*

8

Алда үлем көткәнгә күрә генә яшәү мәгънәгә ия.

9

Үткәннәрне генә түгел, бүгенгесе дә бөек булса гына халык бөек санала.

10

Банкет—хәерчеләр, ялагайлар һәм шамакайлар оҗмахы.

11

Ялгызлыкны күтәрерлек көче булмаса кеше дус-иш эзли, төрле мәҗлесләргә йөгерә, халык арасына керергә тырыша. Шулай итеп ул эчке бушлыгын ни белән булса да тутырырга маташа. Ә ялгызлыкта калса, андый кеше үзенең төпсез бушлыгына егылып төшәчәк. Ялгызлыкны күтәрү һәркемнең дә хәленнән килми.

12

Монын хәле бөтенләй үк хөрти түгел—анын яшисе килә.
Тегенең дә алай ук чарасыз дип әйтмәс идем—аның үләсе килә.
Ә менә монысына нишләмәк кирәк—яшисе дә килми аның, үләсе дә?!

13

Яшәү юк!
Үлемнең вакытлыча булмый торуы гына бар.

14

1917 ел—нәтиҗә! Сәбәп түгел!

15

Аллага үзләренә кирәк чакта гына ышанучы кешеләр арасында яшим мин.

16

Һәрнәрсәнең сәбәбе бар. Йә Ходаем, син дә нәтиҗә микәнни?!
Хәер, син сәбәп булсаң яхшыракмыни?!

17

Гадәттә көчсез һәм үзенең сәләтенә ышанмаган кеше төрле оешмаларга керергә омтыла (союз, клуб, җәмгыять һ. б.). Чөнки үзендә житенкерәмәгән нәрсәне ул уртак казаннан чумырып алырга ниятли.

18

Кем эшләми, шул яшәми.

19

Хәерчеләр ишәйгән чорда затлы чиркәүләр, биек мәчет манаралары һәм башка төрле купшы гыйбадәтханәләр, сарайлар төзүне Алла ничек кабул итәр икән?.. Бәлки иң элек хәерчеләргә ярдәм итәргә кирәктер. Аллага затлы, биек биналар түгел, ә бәлки кеше үзе әһәмиятледер. Алланы күпсанлы ялтыравыклы гыйбадәтханәләр түгел, кеше үзе кызыксындырадыр.

20

Мәхәббәте аз булган кеше мәхәббәт турында күп сөйли.
Яратырга сәләтле кеше сөйләми. Ул ярата.

21

Коллар илендә хакимнәр дә—коллар. Хакимнәре коллар булганга күрә коллар иле бит бу!

22

Көнләшү—мәгънәсезлек. Әгәр хатынын хыянәт итә икән, көнләшеп бернишләп, бернәрсәне үзгәртү мөмкин түгел.

Әгәренки хатының хыянәт итми икән, бу очракта көнләшү бөтенләй урынсыз. Кыскасы, ике очракта да көнләшүдән мәгънә юк.

Ә бит шушы ике очрактан кала башка очраклар юк! Димәк, көнләшү, ничек карасан да, һәрвакыт—мәгънәсез!

23

Җинаятьче үзенең яман эш кылуын анламый, җинаятенен асылына, аның сәбәбенә төшенми. Анласа, ул җинаять кылмас иде.

Нәрсә өчен хөкем итәргә кирәк икән аны: кылган җинаяте өченме, әллә анламаганы өченме?..

Мөгаен, җинаяте өчендер. Әмма ләкин бу бит асылда анламаганы өчен хөкем итү булып чыга. Ә бу ярый торган эшме сон?!

24

«Куприн, Аксаков, Карамзин һ. б., һ. б.—татарлар»,—дип мактанырга яратабыз. Бәлки, кайгырырга кирәктер? Бу татарнын фаҗигасе ләбаса!

25

Үлемгә, бетүгә таба барган ил белән, гадәттә, картлар идарә итә.

26

Юл кагыйдәсен бозуларын иң нык теләүче кеше—ГИБДД инспекторы.

27

Гаепне башкалардан эзләмә. Ул бары тик синең үзеңдә.

Дөреслекне дә читтән эзләмә. Анысы инде күптән үзеңдә.

Ә үзеннән читтә нәрсә бар сон? Бары тик синең кебек эзләүчеләр генә.

28

Нишләп Рәсәй рәтле тормыш кора алмый?

Чөнки Ватан хисе юк. Бер халык та бу илне үз Ватаны дип санамый.

29

Берәү үтерү хәленнән килмәгәнгә үтерми.

Икенче берәүнең үтерергә кодрәте җитә, әмма ул вәхши түгел, шуна күрә үтерми.

Минем өчен икенчесе кыйммәтрәк.

30

Элек яшәгән шәхесләрне ныграк яраталар, аларга хәтта табыналар.

Бу күренеш асылда бүген яшәүче шәхесләрне күрмәмешкә салышу, инкарь итү, алардан көнләшү галәмәте.

31

Минем бәйсезлегемне син авыр кабул итәсең. Сизәм, хөрлегемнең серен беләсең килә.

Сере гап-гади. Син үзеңне шушы гомеренә, менә монда теркәп, бәйләп куйгансың һәм аяк астындагы чүплектә казынасың. Ә мин исә Мәңгелектән Мәңгелеккә үз иманым белән сәфәремне дәвам итәм. Син казынып ятканда мин офыктан офыкка таба үтеп барам.

Син—Вакыт колы, авыр сулап: «Гомер үтә»,—дисең.

Ә мин үзем үтеп барам! Гомер түгел, мин үзем үтәм.

Анлыйсынмы?

Анлау гына да аз шул әле...

32

Һәйкәлләрне коллар ясап бастырып куя. Шунысы кызык, ул һәйкәлләрне барыбер коллар җимерә.

33

Әшәкелегенне, начар сыйфатларынны, көнеленнен пычраклыкларын күрсеннәр өчен күп нәрсә кирәкми. Бары тик соры халык төркеменнән өскәрәк калку мәслихәт. Һәм менләгән адәм актыклары сине: «Адәм актыгы!»—диячәк.

34

«Кешеләрне яратам!»—дигәннәрен еш ишетәм. Болай дип оран салучы үзенең әйткән сүзенең мәгънәсезлеген һәм мәнсезлеген аңларлык дәрәҗәдәге акылга ия түгел, әлбәттә. Аңласа, ул алай димәс иде.

Минемчә, кешеләрне гомумән яратырлык түгел. Гомумән алганда инсаният мәхәббәткә лаеклы түгел. Аерым алган кешеләрне генә ярату мөмкин. Аерым алган шәхес бөтен кешелек дөньясына караганда кызыграк. Монарчы яшәп килгән әдәбият, сәнгать тә бит аерым кешеләр турында иҗат ителгән. Халык төркеме түгел, шәхес кызыграк. Әле бөтен дөнья халкы турында әсәр иҗат иткәннәре юк.

Бөтен инсаниятка мәдхия җырлаучы, минемчә, шәхесләрдән «качыр» өчен, алардан үзе өстен булу нияте белән яки аерым алган кешегә ярдәм итәргә теләмәүдән (һәм көченнән килмәүдән) «халык», «кешелек дөньясы», «кешеләр» дигән һ. б. төшенчәләр белән сату-алу итә.

35

Куркытучының куркытуында куркучы үзе гаепле.

36

Тавышын ишетеп һәм күзләрен күреп, кешенең кем икәнлеген әйтеп була.

37

Бездә хайваннарны яратудан түгел, ә бәлки кешеләрне күралмаганга эт асрыйлар.

38

Хатынының барлык уйларын белсә, ире аны шул көнне үк аерыр иде.

39

Трусигыңны юган хатын кайчан булса да сиңа әшәке сүз әйтми калмый.

40

Мактасалар ышанма.
Хурласалар ышанма.
Эндәшмәсәләр, ышан—сине йә мактарлык, йә хурларлык.

41

Син матур, дисәләр, димәк, син матур.
Син ямьсез, дисәләр, димәк, син бик матур.

42

Ул хатын көнеленнең бер өлешен үзе белән алып китте, дисең. Моның белән хәтта горурланасың. Ә син үзеңә сорау биргәнең бармы: көнеленнен ул өлешен мәңге үзе белән йөртерме, әллә берәр сасы чүплеккә ташлап калдырырмы?..

43

Безне өмет яшәтә. Ә өмет өзелгән чакта нәрсә яшәтә? «Әле өмет кабыныр...»—дигән өмет, ахрысы.

44

Колдан беркем дә оялмый.

45

Үзеңнең чын бәянне, урыныңны белер өчен должностеңне, әшнәләреңне, кодаларыңны, таныш-белешләреңне, акчаңны—барысын да читтә калдыр да, ялгызың яшәп кара.

46

Бәхетсез гаилә—«Кеше гаилә корып яшәргә тиеш!» дигән канун буенча өйләнү нәтиҗәсе. Гаилә тормышына эчке ихтыяҗ булмаган килеш гаилә коручылар аркасында киләчәк буыннар михнәт чигә һәм фаҗигаләргә дучар була.

47

Хәерче илдә шагыйрьләр күп була.

48

Һәркем шагыйрь, һәркем җырчы.
Аерма фәкать сыйфатта гына.

49

Нәрсә ул бәхет?
Бәхет—бәхетсезлектән арынып торган мизгел.

50

Минем гомерем бик сәер вакытка туры килде. Бердәнбер котылу чарасы—вакыт үзе... Сәер түгелмени?!

51

Мин һәрвакыт күз карашымны иркәләгәнгә һәм күңелемә хуш килгәнгә гашыйк булдым.
Мин беркайчан ямьсезлеккә гашыйк булалмадым.
Шулай булгач, ничек мине яхшы кеше дип әйтсеннәр?!

52

Монда үлем бөек сер түгел.
Монда үлем—чара.

53

Монда яшәүгә каршы көрәшкәндә генә яшәү мәгънәле була.

54

Монда: «Бер янагыңа суксалар икенчесен куй»,—диләр һәм шул вакытта башыңны чабып ташлыйлар.

55

Мәңгелек дан турында хыялланмагыз! Алла гына мәңгелек. Ул үзенә үз куллары белән конкурент яратмас бит инде.

56

Кояшның чыкканын күргәнем бар.
Минем аны мөнбәреннән иң югары ноктасында күргәнем бар.
Кояшның баеганын күргәнем бар.
Ләкин минем аны баеганнан соң күргәнем юк. Шуңа күрә ул минем өчен көн саен яңалык һәм кételмәгән булып чыга.

57

Ачык кыр уртасында капка төзеп куйдыгыз. Ул капкадан үтмәсәм дә, мин офык сызыгына юл тотам.

58

Тормыш авырлыгыннан түгел синең явызлыгың, ә бәлки шул авырлыкны жинә алмаганыңнан.

59

Бу дәүләт мин начар булсын өчен бөтен көчен куйды. Хәзер инде ул аны начарайтуга бөтен көчемне куюдан курыксын.

60

Туган бала—ата-ананың уй-ниятләре, дөньяга мөнәсәбәтләре, күңел халәтләре нәтиҗәсе. Тәрбия нинди әһәмияткә ия дер, белмим. Ләкин, минемчә, ата белән ананың кавышкан чакларында ук карында барлыкка киләсе бала «ясала» башлыйдыр. Һәм дә бала табу—поступок, кешенең бөек карары. Тирәнрәк уйлап баксаң, бу карар—йә гөнаһ нәтиҗәсе, йә саваплы эшләр гамәле.

61

Берәр тавыш ишетелсә як-ягыңа карарга ашыкма. Иң элек үзеңә колак сал—синең үзеңнән килмиме ул аваз.

62

Өндәүчегә игътибар белән карасаң күрерсең: кешеләрдән үзендә житенкерәмәгән сыйфатларны таләп итә ул.

63

Жан газабыннан жан бизү коткара ала.

64

Талант—бүләк түгел, талант—жәза.
Ижат кешеләре арасында бәхетлеләрен күргәнегез бармы?!

65

Кеше гомере—юл. Үзеңнән—үзеңә.

66

Халыкның сабырлыгыннан политиклар файдалана.
Халыкның куркаклыгыннан уголовниклар файдалана.
Халыкның наданлыгыннан язучылар файдалана.
Нинди бетмәс-төкәнмәс файда хәзинәсе ята синдә, халкым!

67

Үзеңә: «Нишләп соң мин кешеләрне күралмыйм?»—дигән сорауны кешеләрне чынлап яратучы кеше генә бирә ала.

68

Кешене нининдидер тискәре сыйфаты өчен ачуланганчы иң элек: «Нигә андый соң ул?»—дигән сорауны бирергә кирәк.

69

Бай кешегә малы хезмәт итә, ә хәерче исә үзенең барлы-юклы малының колы булып яши.

# *Яңа исемнәр*

*Узган елның азагында, декабрь башларында татар яшьләр поэзиясендә әлегә күзгә артык нык чалынмаган, әмма вакыт аралыгы бездән ерагая барган саен әһәмияте калкурак тоемланачак бер вакыйга булды. "Мәгариф" нәшрияты "Сәләт" китапханәсе" сериясендә яшь шагыйрьләрнең "Җәйнең җиде төсе" дип исемләнгән җыентыгын бастырып чыгарды. Китапка сәлкешләрнең, ягъни "Сәләт" белән язмышларын бәйләгән, әдәби иҗатта көчләрен сынап караучы яшьләрнең иҗат үрнәкләре тупланган. Җитәкбаш һәм "Сәләт"нең редакция-нәшрият советы рәисе буларак, ул китапка фатиханы да миңа бирергә, аңа кереш сүзне дә язарга туры килгән иде.*

*Кемнәр соң алар сәлкешләр, җитәкбашлар, "Сәләт" хәрәкәте үзе нәрсәдән гыйбарәт? Сәлкешләр (бу алар үзләре уйлап чыгарган атама) ул сәләтле балалар дигән сүз. "Сәләт" хәрәкәте исә аларны үз янында туплаган, таныштырган һәм дуслаштырган иҗтимагый оешма, җитәкбашлар дигәне исә—аларга дәресләр бирүче, тәрбия эшендә катнашучы өлкәннәр: күренекле галимнәр, язучылар, сәнгать эшлеклеләре.*

*Замананың иң егәрле фәннәреннән кибернетика белән математикага мөкиббән, инде берничә чит телдә яхшы ук сукалап маташучы һәм компьютердан гайре башканы белмәгән һәм белергә дә теләми дип йөргән сәлкешләребез Галиҗәнаб шигърият бакчасында да үзләрен судагы балык кебек хис итәләр икән ләбаса! Үтә нечкә хис-тойгылар, кешеләр арасындагы гаять тә катлаулы мөнәсәбәтләр, дөньяны масштаблы күзаллау, халкыбызның киләчәге өчен борчылу... Болар берсе дә аларга, аларның иҗатына ят күренеш түгел.*

Сынган кылыч, суынган көл—
Минем илем икән.
Кабер ташында "үлгән тел"—
Минем илем икән.
Мин, имеш, дәүләтен җуйган
халык баласымын.—
Бусага өстенә
Тарих
ясый кара сыным.
Нигә әле шул карт рәссам
Миңа аяк сөртә?!
Тартып алам пумаласын,
Манам...
ап-ак сөткә.

*Дөньялыкта әле нибары унҗиденче язын каршылаган Гөлназ Вәлиеваның бу юллары, дөнья гамен, ил, Ватан язмышын, фаҗигале тарихыбызны йөрәгенә сыйдыра алуы, яшьләрчә кискенлек белән тарих исемле карт кулыннан "пумаласын тартып алып", ап-ак сөткә манарга теләве мине сискәндерде дә, сокландырды да... Мин бу яшьләргә ышанам. Алар безнең буыннар эшли алмаганны эшләр, без әйтә алмаганны әйтер.*

*Гөлназ әле бик яшь. Ул Казан педагогия университетының беренче курсында гына укый. Ләкин ул инде ике китап авторы. Былтыр шигырь һәм проза белән язылган парчаларын туплаган "Тылсым" исемле җыентыгы "Милли китап" нәшриятында басылып чыккан иде. "Казан утлары" журналы битләрендә Гөлназ Вәлиева беренче тапкыр күренә.*

*2001 елның беренче санында басылып чыгу ул дәрәҗә һәм өлкән иптәшләренең олы өмете дә. Иҗатыңда кыю бул, бәхетле бул, Гөлназ сеңлем!*

**Флүс ЛАТЫЙФИ**



# Гөлназ Вәлиева

## ТЫЛСЫМ

Биектән бәхет эзләмим:
бик текә яр,
сикерсәң дә—ташлы, сай су,
басмасы тар.
...Киң үзәннән
иркен генә агып килгән
Инешемнең басмасында
утырасым бар!

## Илһам

Төн уртасы. Казан йоклый,
Кар юрганын ябынып.
...Каләмем егылды әле,
Уйларыма абынып.

Өзелде фикер тәсбихем.
Кәгазьгә карап торам:
Ап-ак намазлык өстендә
Онытылды кебек
Догам.

Тынлыкны уятмый гына
Йөрәк тибешен саныйм...
Шулчак кинәт...
Сәгать суга!
Мин аңа бармак яныйм:

«Чү!—дим,—Илһам фәрештәсен
Качырасың, кагынып».
...Төннең кара савытыннан
Шигырь чыга савылып.

## Тылсым

Серләрең ач, әкият,
сихер-тылсымга өйрәт!

Кайда соң серле мәмләкәт?
Кайда—
үлемсез мәхәббәт?
Кайда явыз убырларың?..
Чәчеп тылсымлы нурларын,
төнлә чәчәк ата торган
Абагалар корыганмы?!

Әллә инде тылсым беткән,—
Терек чишмәләрең кипкән?..

Юк...
Әкият яши, исән!

Кайда, ничек, кайчан, дисәң...
Дөнья үзе—тылсымлы ил,
Күңел—шунда сихерле күл.
Ә каләмем—алтын балык—
ялтырап ятыр ак кәгазьдә,—
хәйран калыр әле халык!

## Оныттым

Мин яраттым. Яраттыммы?
Яратсам, ник оныттым?

...Салкында—кояшым идең,
Эссе чакта—болытым.

Мин елаганда син көлдең,
Көлгәндә—син кайгырдың.
Мин кош тоткандай сөендем—
Син канатын каердың.

Мин су сиптем гөлләремә—
Син тамырын корыттың.

Мин дә синең кебек иттем:
Яраттым да... оныттым.

## Айсыз төн

Айны йотты Кара Болыт,
Йолдызларны да йотты.
Этләр шомланып тын калды:
Кара Болыт
Ауга чыкты.

Кучкыллы-кара шәүләсе
Тәрәзәмә таянды:
«Бу төнгә мин хуҗа»,—диеп,
Миңа бармак янады.

Куркытты кара күзләре,
Шомлы кара авызы...
Мин аңа җавап бирмәдем.
...Мин бары
Шәм кабыздым.

Чын сылулар, тыйнак гүзәлкәйләр
Күләгәдә торды оялып.
...Егетләрнең башын әйләндерде
Тик бер «матур»—
килгән буянып.

Таң аткачтын
сүнде
ул «матур»ның
төн корымын яккан күзләре.
Кояш яктысында эреп акты
балавыздай баллы сүзләре.


Юмарт бул, и кояш!
Гаделлекне
төн карасы йота алмасын.
Асыл кызлар,
ачылып өлгермичә,
тагын күләгәдә калмасын!

*Сөт калыр, ватан китәр!*
Дәрдмәнд.

Сынган кылыч, суынган көл—
Минем илем икән.
Кабер ташында «үлгән тел»—
Минем телем икән!

Мин, имеш,—дәүләтен җуйган
халык баласымын.—
Бусага өстенә
Тарих
Ясый кара сыным.

Нигә әле шул карт рәссам
Миңа аяк сөртә?!
Тартып алам пумаласын,
Манам...
ап-ак сөткә.



Әгъдәс Борһанов

# УРЫС СӨЙМӘС ҖАН ТҮГЕЛМЕН, МИН—ТАТАР

ӘГӘР дә үземнең милли мәсьәләгә карата мөнәсәбәтемне белдермәсәм, бу—минем тарафтан эшләнгән монафикълык-икейөзлелек булыр иде. Дөресен әйткәндә, үземне миллилек ягыннан башкалар белән тәңгәлләштерептиңләштереп, чагыштырып карыйсым да килә. Һич тә гади генә мәсьәлә түгел бу.

Эш шунда ки, урыс телен сигез яшьтән үк үзләштереп, ун яшемнән урыс мәктәпләрендә укып, аннары урысча югары белем алгач, гомерем буе шул телдә сөйләшеп-аралашып килгән шәхес буларак, хактыр—мин урыс зыялы-мәдәни даирәсенә тартылган кеше. Урыс әдәбияты һәм музыкасыннан башка мин үземнең тормышымны, яшәү рәвешемне күз алдыма да китерә алмыйм. Урыс халык җырларын,—ә минем музыкаль зәвыгым шулар йогынтысында тәрбияләнгән,—аерым алганда, яшүсмер һәм егет чагымда күңелемә сеңгән, урысча «волжские страдания» дип йөртелгән көй-моңнарны ишеткәндә, дулкынлану-тәэсирләнүдән күзләрем дымлана, бүлмәдә ялгыз гына булсам, бетмәс-төкәнмәс такмак-такмазалары—«частушкалары» ритмына тыпырдап биеп тә җибәргәлим. Бигрәк тә Себер талантлары Заволокиннар гаиләсенең «Уйна, гармун!» дигән телевизион тапшырулары әсир итә мине, алар Рәсәй җирендәге нинди генә талантларны эзләп тапмыйлар да, тамашачыны нинди генә гүзәл җыр-музыка белән сокландырмыйлар! Аларны тыңлаганда миемне бер сорау бораулый: шушы кадәр сәләтле халыкны ничек итеп бүгенге кызганыч хәл-хәләтенә төшерергә, милләт буларак деградациягә—бетеп баруга дучар итәргә мөмкин икән?

Әнә, хәтта Рәсәй президенты Владимир Путин да: «Алга таба да шушы хәл булса, урыс милләте юкка чыгачак. Ел саен бер миллионга якын урыс үлә...»—дип, тирән борчылуын белдерде.

Моңа кем гаепле? Урыс халкы үземе, әллә башка яшерен көчләрме?

---

*Әгъдәс* БОРҺАНОВ *(1920).—Россия Дәүләт гуманитар университеты профессоры. Ул—Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы. Тарих фәннәре докторы. «Казан утлары» журналының даими авторы. Мәскәүдә яши.*

Бу мәсьәләгә кереп батмастан, чөнки максатым ул түгел, үземә әйләнеп кайтам: әйе, урыс мохитендә яшәсәм дә, үз туган халкым татарлардан да һич ваз кичмәдем мин, туган телемне онытмадым, ул миңа үз милләтемнең мәдәни тормышыннан аерылмаска терәк булды. Гомеремнең күп өлешен чит милли мохиттә үткәрүемә карамастан, үз татарларыбыз белән туган телемдә иркен аралаша алам, алай гына да түгел, катлаулы әдәби һәм социаль-сәяси әдәбиятны да, сүзлекләрне бик актармыйча гына, укыйм. Еш кына урысча уйлап, татарчага сүзгә-сүз күчерү шикеллерәк булса да, татарча яза да алам, әмма моңа бик күп вакыт сарыф ителә. Кызганыч ки, гомерем кояшы баеп бара—димәк, вакыт дигәнең дә шәм кебек эри-кими тора... Шунлыктан, фәнни хезмәтләремне татар телендә язарга тырышып үземне җәфаламыйм. Бары тик милләттәшләрем-дусларым белән хатлар язышканда гына туган телемдә язышам. Кызганыч хәл, әлбәттә. Әмма факт...

Сүз уңаенда әйтеп узыйм, фәнни хезмәтләрем, публицистик мәкаләләремне татарчага тәрҗемәләүче әдип вә журналистларга, аерым алганда, Кыям Миңлебаев, Марс Шабаев, Рәфикъ Юныс, Ркаил Зәйдулла һәм башкаларга чиксез рәхмәтлемен. Беләм: мин аларны бик зур, авыр хезмәткә дучар итәм, хезмәтләрем артык фәнни, артык катлаулы тел белән язылган була, шуңадыр да, бәлки, бер тәрҗемәчем «җиде кат тир түгәм» дип юкка гына әйтмидер. Шунысын да истә тотарга кирәк, урысчадан һәм теләсә кайсы Европа телләреннән татарчага тәрҗемә итү татар теленең фәнни термин-гыйбарәләргә ярлы булуы белән дә катлаулана. Ә бу ярлылык исә күп гасырлар элек дәүләтчелегебезне югалтуга барып тоташа, аннары совет хакимияте елларында «өлкән туганыбыз» урысларга бик ярарга тырышкан кайбер галимнәребезнең татар теленнән борынгы тәрки һәм гарәп-фарсы сүзләрен кысрыклап чыгаруы да зур зыян китерде дип саныйм. Латин, инглиз һәм башка телләрдән, шул исәптән, тәрки-татар теленнән дә (!) алынма сүзләре булмаган, шулардан «чистартылган» урыс телен күз алдыгызга китереп карагыз әле! Аңардан ни-нәрсә генә калыр иде икән?

Мине ишетеп-укып кына түгел, күреп-аралашып та йөргән татарстанлы урыслар—«урыс җанлы» урыслар (!), аларны «шовинистлар» дип үк әйтәсем килми, шулар күз алдында мин—татар милләтчесе.

Әле советлар заманындагы кире мәгънәсендә, «халык дошманы» төшенчәсенә тиң мәгънәдәге «милләтче» икән мин! Мине якыннан белгән, аралашып-сөйләшеп йөргән казанлы бер урыс галиме мине хәтта «русофоб», ягъни «урыс сөймәс җан» дип тә саный. Урыс милләтенең дә ачы язмышка дучар ителгәнлеге өчен янганым-көйгәнемне белгәнгә күрәдер инде, мөгаен...

Табигатем белән туры сүзле һәм катгый фикерле булгангамы, күңелемдә ни-нәрсә бар, шуны тартынмыйча әйтә торган, үзем уйлаган бәяне бирә торган гадәтем бар. Урысларга үзләре турында үзләре мактанып сөйләнгән сүзләре җитәдер, алар «урыс җанын-рухын» үзләре тәнкыйть итү дәрәҗәсенә тәки күтәрелә алмаган килеш калган...

Миңа калса, авыру җәмгыятьне юатырлык мактау сүзләре белән дәвалап булмый, аның чын хак гаеплесе булган дәүләт бюрократиясен—түрәләрне иркәләргә түгел, типкәләргә кирәк. Мин, түрәләр үзләре теләгәнчә, бюрократияне һич тә халык белән бергә бутарга уйламыйм. Хәер, кем әйтмешли, халык үзе дә гөнаһсыз түгел. Аңа да туры сүзне әйтергә вакыт: бәхетсез язмыш халык катнашыннан башка гына була алмый. Язучы Федор Абрамов урысларның табигате «эшләнеп җиткерелмәгән» дип дөрес язган, минемчә. Алар «башсыз-тәвәккәл дә, киң күңелле дә, тыелгысыз шашкын да, шул ук вакытта... кол да». Ф. Абрамов «Верколадагы йорт» әсәрендә әле болай дип тә яза: «халыкны ладан төтене белән ыслау-төтәсләү, берәзлексез аны мактап тору—иң зур явызлык, культ, нинди генә кыяфәткә кермәсен, халык өчен һәрвакыт куркыныч».

Рәсәйнең бүгенге кызганыч вәзгыятендә халык үз өлешенә төшкән гаепне үзе кабул итеп алса да, артык булмас иде кебек. Халык бүген нинди булса—монысы дәүләтнең аны шундый итеп «тәрбияләве» нәтиҗәсе. Ә бит киресенчә булырга—дәүләт халык тарафыннан, аның сәяси оешмалары

тарафыннан үзе тәрбияләнергә-камилләштерелергә тиеш. Әмма мәсьәләнең болай куелганы юк һәм әле тиз генә булачагы да күренми. Ничек кенә булмасын, халык үзе кереп тәртелгән бу тупыйктан үзе чыгарга дучар ителгән. Әгәр дә булдыра алса... Димәк, урыс халкына үзтәнкыйть су белән һава кебек кирәк икән. Аңа «без—бөек халык!» дигән шапырынуларыннан арынып, үз тарихына аек күз белән карарга да бик вакыт. Мин, мәсәлән, үз татар милләтебезнең чын-хак тарихын бер дә алсу буяуларга манып, «без бөек халык!» дип лаф орып йөрмимен. Ә бит күп кенә «даһи» урыс тарихчылары урыс халкы тарихын шулай күзалларга тырыша. Миңа урысларның да чын-хак тарихы дөньякүләм галимнәр тарафыннан бәяләнүе кирәк, чөнки минем яки теләсә башка кемнеңдер тарихны үзебезчә боргаларга-сыргаларга теләвебезгә карап кына тарих барыбер үзгәрә алмый. Ул инде булган-үткән хәл, аның «ах, болай булса иде, тегеләй булса иде» дигән шарт фигыльләре юк: ничек булган—шулай бар, бетте китте!

Бу, әлбәттә, үткәннәрне бәялəгәндә тарихка әйләнеп карарга, яңа фәнни ачышлар нигезендә аңа яңача карашлар да булдырырга кирәкми, дигән сүз түгел. Мин бөек урыс тарихчысы Дмитрий Лихачевның: «Урыс халкы т ә ү б ә г ә килергә тиеш, ул шуңа мохтаҗ»,—дигән сүзләренә биш куллап ризамын. Т ә ү б ә г ә к и л ү—димәк, үз намус-вөҗданыңны ата-бабаларың элек кылган явызлыклардан да, үзең кылган начарлыклардан да арындырырга, шул рәвешле, ул «гөнаһлардан» чистарынып-арынып, үз тырышлыгыңны изге гамәлләргә юнәлдерергә кирәк, дигән сүз ул. Бу җәһәттән, бигрәк тә бөек милләтләр шундый адым ясарга мохтаҗлар, чөнки алар күпсанлы һәм явызлыклар кылырга һәрвакыт мөмкинлекләре бар. Моның ачык мисалы—Чечнядәге канкойгыч сугыш. Бу очракта мин үрнәк итеп немец халкының сәясәтен китерер идем, аларның җитәкчеләре-юлбашчылары милләтче социалистлар—нацистлар күп газап-бәлаләр китергән барлык халыклардан да гафу үтенүне үзләренең зарури бурычы дип саныйлар. «Немец могҗизасын» тудырган, сугыштан соңгы Германияне аякка бастырып, гаҗәеп икътисади нәтиҗәләргә ирешкән Конрад Аденауэр үзенең канцлерлыкка сайлануына шарт итеп нәкъ менә шуны—халыкның, т ә ү б ә г ә к и л е п, башка милләтләр алдында гафу үтенергә ризалыгын көн тәртибенә куйган иде. Бу изге эш әле дә булса дәвам итә, Германиянең хәзерге канцлеры, 2000 елның апрелендә Грециягә рәсми визит белән баргач, грекларның азатлык хәрәкәте өчен көрәшчеләреннән 700 кешене атып үтергән немец фашистлары кылган җинаятьләр өчен грек халкы алдында гафу үтенде. Шундый ук изге гамәлне Рим (Ватикан) Папасы Иоанн Павел Икенче дә башкарды: ул католик чиркәве исеменнән урта гасырларда ук ясалган рәхим-шәфкатьсез тәре походлары өчен гарәп һәм яһүдиләрдән (!) гафу үтенде.

Милләтара мөнәсәбәтләрдә электән булган начарлык-явызлыкларны яңадан күпертеп-куертып җибәрүнең кирәге юктыр. Ни кызганыч, моңа омтылучылар байтак күренгәли әле. Әмма тарих шул ук вакытта үткәннәрне алсу төсләргә манып-бизәп, караны ак дип, ачыктан-ачык ялганга баруга да мохтаҗ түгел. Ә бит кайбер философ-публицистлар, инде хәзер шактый мәгълүматлы, хәбәрдар халыкның ачуын китереп, нәкъ шундый кирәкмәгән эш белән мәшгульләр.

Мәсәлән, В. Аксючиц дигән бер кемсә (милләте белән кемдер—анысы безгә мәгълүм түгел) абруйлы гына үзәк газетларның берсендә, һич икеләнеп тормастан, болай дип расларга тырыша: «Дәүләтчелек оештыручы урыс халкы бер генә халыкны да басып алып буйсындырмый, юк итми һәм көчләп чукындырмый гына күпмилләтле дәүләт төзеде»,—дип яза ул. Һәм шушы ялган әле җитмәсә «дөнья тарихында тиңе булмаган факт» дип тәкъдим итеелә. *(«Новая газета», 26. 02. 2000).* Үзен Россия христианнар партиясе (шундый партия дә бар икән!) лидеры-юлбашчысы дип йөргән бу кемсәгә үз карашлары белән аңа якын торган ултугызынчы йөз урыс язучысы К. Леонтьевның бик тә гыйбрәтле сүзләрен исенә төшерү кирәктер: «Христианин изге булырга да мөмкин, әмма ул намуслы була алмый». Моңа урыс дәүләтчелегенең тарихи шартлары сәбәпче булганлыгын шәрехләп торуның кирәге юктыр. «Намуслы була алмаган» Аксючицның «изгелеге» дә шул кадәр генә икәнлеге хакында сүз куертып тору да кирәкмәстер...

Шул уңайдан, Казан дәүләт университеты архивларында саклана торган тарихи документлардан берничәсен генә китереп үтәм.

«... мөселман татарларны Казаннан куып чыгардылар, ә мәчетләрен җимереп бетерделәр. Шәһәрдә, урыслардан кала, бер генә татарга да яшәргә рөхсәт ителмәде».

Урыс патшасы Федор Иванович Указыннан өзек *(тарихи документ буларак, урысча китерәм. Ә. Б.)*: «А которые новокрещеные крестьянские веры крепко держати и поученья митрополита и отцов духовных слушати неучнут, и вы бы тех велели смиряти, в тюрьму сажати и бити, и во железа и в цепи сажати и проч.»

Бу бик артык «грамоталы» булмаган җөмләдән шуны аңларга була: патша хәзрәтләре яңа чукындырылган крестьяннарны (ягъни мөселманнарны. Ә. Б.), динне каты тотмасалар һәм митрополит белән башка төрле дәрәҗәдәге руханиларның вәгазьләренә колак салмасалар, төрмәгә утыртырга һәм бик каты кыйнарга, тимер чылбырлар белән богаулап куярга һәм башка шундый рәхимсез-шәфкатьсез гамәлләр эшләргә боера. (Җае туры килгәндә, шунысын да әйтеп китик: урысның «тюрьма»сы төрки халыкларның тәрәзәсез «тирмә» сүзеннән кереп киткән икән ләбаса. *Ә. Б.*)

Патша Алексей Михайловичка (Романовка) зар-шикаятьләрен белдереп татарлар болай дип яза *(шулай ук урысча китерәм. Ә. Б.)*: «Воевода Алексей Малышкин посадил нас, холопей твоих, в тюрьму и мучил, сажал в цепи и в железа, и нудил нас, холопей твоих, сильно креститься в прав. христ. веру, а мы, холопы твои, желаем быть в своей басурманской вере». Ягъни татарлар воевода Алексей Малышкинның аларны төрмәгә утыртып җәзалауларыннан, чылбырлар белән богаулап куюларыннан, христиан диненә чукынырга мәҗбүр итүеннән зарлана һәм «басурман динебездә» (монысы мөселман дине була инде, мөгаен, шикаятьне язучысы шулай «төзәтеп» язгандыр. *Ә. Б.*) калырга телибез, дип сорый.

Көчләп чукындыруларга каршы көрәш баш күтәрүләргә дә этәрә һәм ул берничә гасырга сузыла. Ә Аксючицча исә «Данлы үткәннәрне аңлау—лаеклы киләчәкнең дәлиле» икән!.. Моны, урыслар һаман да элекке рухта дәвам итсеннәр, вак санлы башка милләтләрне буйсындырсыннар, йотсыннар, дип аңларга кирәктер инде.

Россия Федерациясенең Борис Ельцинга яраклаштырылып кабул ителгән Конституциясендә дә милли дошманлыкка чакыруларга каршы торырга тиешле маддә бар. Әмма... бүгенге Россиядә ни-нәрсә тора соң ул Закон?!

Урыс кораллы көчләре җиңелгән беренче чечен сугышы (1995-1996) белән чагыштырганда «бүген,—дип тантана итә бу Аксючиц дигән кемсә,—җиңү яулана, чөнки дәүләтнең ихтыяри көч билгеләре бар, дәүләтебездә патриотик күзаллау уянып килә». 150 миллион халыклы Россиянең йөзләрчә самолетлары, танклары, авыр артиллериясе булган, сан ягыннан бөтен Чечня халкы саныннан да артып киткән «данлыклы» армиясе (Оборона министры Грачевның шул вакытта мактанып: «Бер атнада Чечняны үтүкләп чыгам!»—дигән сүзләрен генә исегезгә төшерегез») авыл-калаларны җир йөзеннән юк итеп, чечен халкын бар дөньяга чәчеп бетереп, калган качакларны кыш өстендә салкын палаткалы шәһәрчекләргә—концентрацион лагерьларга куып кертеп җиңү яулый, имеш, һәм шуның белән мактана. Миңа калса, бу фаҗигане киләчәктә тарих дәреслекләреннән укып беләчәк яшь буыннар кызганыч—алар оят-хурлыкларыннан нишләргә белмәсләрдер, мөгаен...

Россия мөфтиләр шурасының аналитик үзәк рәистәшләре Ф. Әсхәдуллин белән А. Полосин үзләренең «Ислам һәм хәзерге Россия дәүләте» дигән мәкаләсендә *(«Ислам мәнбәре», № 3, 2000)* болай язалар: «Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы тарафыннан хупланып расланган күп кенә дәреслекләрдә бөтен Россия тарихы Мәскәү кенәзлеге тарихына гына тәңгәлләштерелеп бирелә, аның Бөек Казан ханлыгын яки Бөек Новгород җөмһүриятен сугышып яулап алуы тышкы дошман булган шведларны Полтава янында җиңүгә тиңләштерелеп күрсәтелә. Шул рәвешле, ялган каһарманлык рухын яңадан тергезергә тырышу, Россия тарихын урта гасырдагы Мәскәү кенәзләренең рәсми дини карашларына тиңләп карау бердәм Россия дәүләтчелегенең нәкъ йөрәгенә үк китереп суга. Мәгариф

министрлыгындагы түрә һәм белгечләрнең наданлыгы (ай-һай, наданлыктан гынамы икән?! *Ә. Б.*) шуңа китерә ки, хәтта бу оешма хуплаганнан соң нәшер ителгән балалар әкиятләрендә дә урыс баһадирлары «кабәхәт татарларны» («поганых татар») һәрвакыт җиңәләр, «татар» сүзе үзе үк кире мәгънәгә ия сыйфатларны гына гәүдәләндерә. Мондый ялган патриотик «әсәрләрнең» авторлары Россиядә яшәүче җиде миллионлы татар халкыннан (бу сан—рәсми мәгълүмат буенча гына. *Ә. Б.*) һәм тагын тамырларында татар каны аккан, якын туган-тумачалары булган дистәләрчә миллион рәсәйлелеләрдән нинди уңай мөнәсәбәт, уңай караш көтә ала икән? Болар бит бары тик милләтара дошманлыкны гына арттырачаклар».

Мин бу фикерләр белән тулысынча килешәм.

Иманым камил: катарсис вакыты—чистарыну-арыну, тәүбәгә килү вакыты җитте. Һәркем өчен дә. Милләте белән кем генә булса да—һәркем өчен дә! Чечен халкына карата, тукталып тора-тора, менә инде өч йөз еллап алып барыла торган рәхим-шәфкатьсезлек, чикләнмәгән явызлык Россия халкына сиздерми генә башкарыламы әллә? Тагын да яманрагы шул—җәмәгатьчелек фикерен сораштырудан күренгәнчә, «антитеррористик операция» дигән сылтау белән Чечняда алып барыла торган сугышка күпчелек халык теләктәшлек күрсәтә. Онытмаска кирәк—тарихи хәтер җуелмый: гасырлар үтәр, әмма геноцидка—тулаем юк ителүгә дучар булган халыкның нәфрәте-каһәре үтмәс, бетмәс. Россия никадәр иртәрәк тәүбәгә килсә, империя пычрагыннан арына-арына, яңа чор цивилизациясенә тиң булу, чистарынып-сафланып дөнья халыкларының бәхетле гаиләсенә кушылу сәгате дә шулкадәр тизрәк булыр.

Әйтәсе килгән сүзләремне мактануым дип кабул итмәсеннәр иде. Юк, мин бары тик кайбер фактларны гына искә төшереп үтмәкче булам. Урыс милләтенә, аның тарихына һәм аның халәтенә иң лаек вә иң дөрес билгеләмәне беренче булып тамырларында татар каны аккан урыс философы Петр Чаадаев биргән: Россия Европа тарихыннан төшеп калган, дигән ул. Аннан соң «урыс идеясен» һәм гомумән урыс халкының үзаңын ныклап өйрәнү-тикшерену белән икенче урыс философы, шулай ук чыгышы белән урыслашкан татарлардан булган Николай Бердяев шөгыльләнгән.

«Кайлардан һәм кайларга барасың, Россия?» дигән китапның авторы буларак, мин дә шул ук бурычны башкарырга алынган идем. Китапны татарча да бастырып чыгару мәсьәләсе кузгатылгач, кульязманы мин бер җитәкче галимгә укыттым. Укып чыкканнан соң, ул: «Бу теманы күтәреп тулы яктырткан кешенең татар галиме булуы белән горурланам»,—диде.

Тук-имин тормышлы татар авыллары белән үлеп-бетеп бара торган ярлы-хәерче урыс авылларын чагыштырып карыйм да (ә мин аларны байтак күрдем), ике арадагы кискен аерымлыкны күрәм. Мин урыс кешесенең чит җирләрдә ни өчен тамыр җибәрә алмаганын, аның яулап алу сугышлары яки күчереп утыртылу нәтиҗәсендә һаман да ни өчен килмешәк калганлыгын аңлатырга тырыштым. Югыйсә, яулап-басып алынган чит җирләрне үзләштерергә, шунда ныклап тамырланырга дүрт-биш гасыр гомер җитәргә тиеш тә бит. Юк шул. Алай булып чыкмаган. Төп үз җире, үз чыгышы булган кара туфраксыз урта Россиядә дә (Нечерноземье), мәсәлән, шундый ук хәл күзәтелә. Димәк, урыс халкының бер урында гына тамырланып китә алмавының сәбәпләре байтак, шул исәптән, чит-ят, башка милли мохит-тирәлек, чит милләтләрнең урыс халкына төрле дәрәҗәдәге хөрмәтсезлеге яки турыдан-туры күрәлмәүчелек-нәфрәт белән үз җирләреннән кысып чыгарырга тырышуы да бар. Чечня, Абхазия, Таулы Карабах, Көньяк Осетия ише төбәкләрдә ачыктан-ачык нәфрәт булса, калганнарында, әйтик, Урта Азиядә, Казакъстанда, Россиянең милли республикаларында астыртын дошманлык булыр һәм аны берниндиг сугышлар белән дә бастырып калып булмаячак.

Әмма төп сәбәп—иманым камил,—анда гына да түгел, төп сәбәп—җирнең бервакытта да гади урыс кешесенең, шулай ук яулап алынган башка милләт кешеләренең дә хосусый милке булмавында. Шуның өчен дә урыс халкы тамырсыз, шуның өчен дә күбәләк-җилбәзәк, тузганак кебек, «өф» итсәң, очып-таралып китәргә генә тора. Үз җире булмагач, «оҗмахтай җирләрне» эзләп күчеп китәргә дә, яу-талау, басып алуларга да һәрвакыт әзер ул.

Кайбер исәпләүләр буенча, унтугызынчы-егерменче гасырларда Россия ике йөзләп милләт-халыкны үзенә буйсындырган, җирләрен басып алган. Сугыш, юлбасарлык урыс халкының төп һөнәренә әверелгән. Һәрвакыт зур армия тотарга мохтаҗ дәүләт үз халкына үз ватанында тамырланырга мөмкинлек бирмәгән, бернинди хосусый мал-мөлкәтсез халык беренче чакыру белән үк сугышка чыгып китәргә әзер торырга тиеш булган, әмма нәкъ әнә шул хәл урыс халкын бөтен дөньяга чәчеп тараткан да.

Бүген дә шул ук сәясәт дәвам итә: халыкның дәшми-тынмый риза булып торуыннан файдаланып, дәүләт, сәгате-минуты эчендә дигәндәй, бер селтәнүдә җирен дә (асылда, кайчандыр яулап-басып алган җирләрен дә), шул җирләрдә яшәүче урыс халкының биштән бер өлешен дә «сызды да ташлады», шул рәвешле, ул төбәкләрдә яшәүче 25-30 миллионлы урыс халкы кимлек-хурлыкка, икенче сортлы халык язмышына дучар ителде.

Ә элекке заманнарда, гомерлек нужадан, ярлылык-фәкыйрьлектән, патша түрәләренең эзәрлекләвеннән гарык булган халыкның күпмесе чит җирләргә күчеп яки качып киткән! Хосусый милексез, мал-мөлкәтсез кеше—гомерлек сукбай, бүгенге тел белән әйтсәк,—бомж ул. Менә шул тамырсызлык—урыс кешесенең төп рухи сыйфатларының асылыдыр, бәлки.

Күпләр ошатмаска да мөмкин, әмма мин урыс халкына ярдәм итәргә телим, үз тормышына күзен ачып карасын иде ул. Күзен томалап торган күзелдереген алып ташласын, Россиянең һәм урыс халкының бөеклеге дигән татлы сүзләргә алданмасын иде. Ул сүзләрне халыкның хәерчелеген һәм хокуксызлыгын яшереп торучы идеология итеп, хакимият башында утыручылар астыртын максатлар белән генә такылдыйлар бит.

Берләшкән Милләтләр оешмасының «Алгарыш программасы» нигезендә хәзер теләсә кайсы илнең дә казанышлары аның индустриаль, хәрби яки финанс көчлелеге белән генә билгеләнми. Хәер, Россиядә алары да ташка үлчим генә инде. Ул хәзер «кешелек үсешенең индексы» дигән төшенчәдәге төп өч казанышка нигезләнә: уртача гомер озынлыгы, реаль хезмәт хакы һәм халыкның укымышлылык-гыйлем дәрәҗәсе. Бу җәһәттән Россия иң соңгы урыннарның берсендә, кайдадыр исемлектәге сигезенче дистәдә тора. Аннан алда үзләрендә нефть-фәлән кебек җир асты байлыклары булмаган Англия, Франция, Германия һәм барлык Европа илләре, Америка Кушма Штатлары, Канада, Япония, Австралия һәм башкалар гына түгел, хәтта Кипр, Барбадос, Чили, Фиджи, Латвия ише илләр дә алдарак. Урыс кешесенең үз җиренә үзе хуҗа була алмавы, җир аның хосусый милке булмавының кызганыч нәтиҗәләре әнә шундый. Чөнки аның ватанында, Л. Радзиховский сүзләре белән әйтсәк, «Россиянең мәңгелек җиңүчесе—хакимият башындагы номенклатура» тантана итә. Бу вөзгыять Россия Федерациясенең беренче һәм икенче президентын сайлауларда да бик ачык чагылды.

Менә шуннан инде халыкның өметсез гаҗизлеге туа. Хәтта карашлары белән бик тә урыс яклы (русофил) әдип В. Кожинов та урыс кешесенең тискәре сыйфатларыннан үтә гамьсезлеген билгеләп уза. Күпчелек урыс халкының хосусый мал-мөлкәте юклык кешеләрнең иҗади-иҗтиһади җегәрен нык киметкән, аларда хезмәткә җиңел генә төкереп карау тәрбияләнгән, чөнки халык, кагыйдә буларак, үзенә эшләми, ә «теге агай»га эшли, шуңа күрә «эш—бүре түгел, урманга качмас» дип кенә әйтеп җибәрәләр дә. Боларның барысы бергә айнымас сәрхүшлек-исереклек белән төмамлана.

Бер генә намуслы кеше дә башкаларның бәла-казаларына, кайгы-хәсрәтенә шатланып карый алмый. Бигрәк тә бу күршедәш халыкларның хәлләренә карата шулай. Тарихи шартлар шундый булган: татарлар белән урыслар бик күптәннән үзара тыгыз бәйләнештә яшәгән. Яхшысын да, яманын да үзара бер-берсенә йоктырулары да гаять көчле аларның. Соңгы вакытларга кадәр «өлкән агай» тарафыннан яманы күбрәк тә эшләнмәдеме икән әле? Үзгәртеп кору чоры башлангач, татарларның урысларга булган йогынтысы да юнәлешен үзгәртә төште шикелле. Борынгы заманнарда Алтын Урда мирасы үрнәгендә урысларга империячел дәүләт төзергә булышкан булсалар, хәзер инде унитар Россия дәүләтен федераллаштыру үрнәген дә татарлар күрсәтә. Алдагы икенче адым илнең базар мөнәсәбәтләренә күчүенә сизелерлек өлешебезне кертү булыр дип уйларга кирәк. Иртәме-

соңмы шулай булыр. Ельцин хакимияте, реформалар үткәрүдә уңга-сулга тайпылгалап, бүгенге вәзгыятькә шактый буталчыклык кертсә дә һәм бу буталчыклык әле яңа президент эшчәнлегендә дә чагылыш табып торса да, демократик үзгәрешләр котылгысыз. Авыр булыр, әмма алар барыбер котылгысыз булыр.

* * *

ҮЗЛӘРЕН зыялыга—«элита»га санап йөргән кайбер урысларның һәм, бигрәк тә, урыслашкан татар манкортларының һаваланып йөрүләренә исләрең китәрлек! Аларның тәкәбберлекләре, борын чөюләренең чиге-чамасы юк. Күптән түгел генә шундый бер «кызыклы» сөйләшү булып алды. Үзем якыннан белгән кешеләр белән әңгәмә вакытында мин: «Бүген зур урында утыра торган бер татар кешесе белән очраштым. Бик матур сөйләшеп утырдык. Озата чыккач, ул миңа исәнлек-саулык теләп: «Тагын да шулай очрашкалап торыйк, Әгъдәс абый»,—диде. «Шуңа бик күңелем булды»,—дип сөйләгән идем. Әңгәмәдәшләремнән берсе—урыс зыялысы шунда ук үз «бәясен» чәпәп тә куйды: «Авыл бәрәңгесе икән». Икенчесе—татар манкорты аны куәтләп өстәде: «Татарлар авылчарак яшиләр шул әле, алар, урыслар шикелле, тиз генә шәһәрләшеп китә алмыйлар—культуралары җитенкерәми»,—диде. Аныңча, мөселманнарга хас сыйфат—өлкәннәргә хөрмәт күрсәтү хәзер инде кирәк тә түгел шикелле. Шул җәһәттән, урыс язучысы Петр Проскуринның бер романыннан укыган вакыйга искә төште. Срогын тутырып төрмәдән чыккан бер урыс, ни сәбәпледер, туган якларына кайтып китә алмый, шунда—зонада эшләргә кала. Үзе янына яшь балалы хатынын да чакыртып ала. Балалары әле имидән дә аерылмаган икән. Менә шул сабый, урамнан уйнап кергәч, әнисенә барып ябыша: «Әни, бе...т, имәргә бир әле!»—ди. Әнисе ни әйтергә белми, имәнеп китеп, иренә карый. Ире әйтә: «Әй, исең китмәсен лә! Монда шулай сөйләшәләр инде, андый сүзләрне әшәке сүзгә дә санамыйлар»,—ди. «Шәһәрләшкән» урысларның сөйләшүләрен генә тыңлап карагыз сез! Шул ук «мат-перемат», ике сүзнең берендә сүгенү сүзе кыстыру... Хәтта чибәр генә кыз-ханымнар да, авызына кыстырган сигаретын төкерә дә, «матур итеп» сүгенеп куя. Бербереңә гашыйк егет белән кызның да авызларында шул ук сүзләр... Йә, шулай түгелмени? Менә сезгә «шәһәр культурасы!»

Алгарыш-тәрәккыят үткәннәрне себереп ташлау юлы белән бармаска тиеш. Ата-бабаларыбыздан калган матур гореф-гадәтләребезне без әле искә алып киткән «шәһәр культурасына» алмаштырып бетерсәк, ни-нәрсә килеп чыгар соң? Дәүләтнең үз гражданнарына карата күп гасырлык кырыгый рәхимсез мөнәсәбәте үз җимешләрен биргән: кешеләр бер-берсенә карата да рәхим-шәфкатьсезгә әйләнеп бетеп бара. Бу күренеш бигрәк тә егерменче-утызынчы елларда ил өстеннән үткән террор-репрессияләр давылы белән бәйледер. Мул тормышлы, хәлле крестьяннарны, «кулак» мөһере сугып, сөргеннәргә сөрү, халыкның каймагын—генофондын «халык дошманнары» дип күпләп юк итү... Әгәр дә тиран юлбашчы үлеп китмәгән булса, моның чиге-чамасы булыр идеме икән? Ахыры нәрсәгә китереп чыгарыр иде икән? Белмим, әйтә алмыйм...

Хәзерге вәзгыятьтә урыс булмаган, әмма урысча яза торган әдип яки галимнең хәле бигрәк тә четерекле, ул һәрвакыт төрле кимсетелүләргә дучар. Әмма мин үзем, әйткәнемчә, һәр ике халыкның мәдәнияте йогынтысында тәрбияләнгән кеше буларак, урыслар белән аралашканда бу «четереклелекне дә, кимсетелүне дә» тоймыйм. «Мин эшләмәсәм, моны кем эшләр соң»—дигән инануым бар, шуңа таянып эш итәм. Һәм урыс иптәшләрем-хезмәттәшләремнең, һәм «үз татарларымызның» шуны аңлавын бик тә телим. Миндә икегә бүленү, икегә «ярылу» тойгысы юк, мин «татар урысымы—урыс татарымы»—барыбер бербөтен шәхес, Россия дәүләтендә үзенә күрә Алтын Урда ханлыгы токымы шикеллерәк, шул социаль-сәяси симбиозның синтетик җимеше шикеллерәк шәхес. Татар милләтенең бүгенге хәл-әхвәленә карап, шулай да шәхесемнең татарлык ягына басым ясарга тырышам. Чөнки мин манкорт түгел!

Ә инде «миллэтче» дигән тамгага килгәндә, мин аны үз милләтемә нисбәтле рәвештә кабул итәм. Татарларның милли идеясе дип, Россия Казанны яулап алганнан соң, менә инде дүрт-биш гасыр дәвамында туктаусыз авыр ассимиляция-йотылу шартларында да, үз-үзебезне милләт буларак саклап калу һәм үстерү идеясен саныйм, шуның өчен көрәшәм. Бу изге эштә татар зыялыларының катнашуы аеруча зарур, аеруча әһәмиятле. Зыялыларыбыз халыкны хосусый милекчелеккә каршы булган хәерчелек карашларыннан арындырырга ярдәм итсен иде, чөнки бу психология милләтне яманаты чыккан «сыйнфый көрәш» юлына—бүлгәләнеп-таркалып бетү, һәлак булу юлына этәрә. Безгә милләтне берләштерә торган чаралар табарга кирәк, аның узаңы үзгәрергә тиеш. Бүгенге бер урыс милләтчесе бик акыллы сүзләр әйтә. «Милләт тойгысы—тормыш-яшәешнең төп асыл сыйфатларыннан берсе, төп кыйммәте. Миллилек хисе кешегә борын-борыннан ук хас, аңа аерылгысыз береккән тәшенчә. Аны сакларга, якларга, үстерергә, тәгәлрәге—яңадан торгызырга, яңартырга кирәк»,— дип яза ул. *(А. Севостьянов. Как и почему я стал националистом. Русской интеллигенции пора вспомнит о том, что она русская.—«Новая газета—сценарии», 06. 02. 2000).*

Без татарлар да нәкъ менә шулай көрәшергә тиешбез. Татарлар гынамы, һәр милләт өчен изге гамәл бу. Большевикларның «пролетар интернационализм» дигән ялган шигаре белән дөньяның этник картасыннан күп халык-милләтләрне сызып ташлау процессын туктатырга вакыт. Хакыйкать шулдыр: кешелек үзенең күптөрлелеге белән яши. Юкка чыгып, үлеп-бетеп бара торган милләтләрнең «Кызыл китабын» булдырырга кирәк, ул кешелек генофондына янаган куркынычны искәртеп торырга тиеш. Аз санлы халыкларның этнос буларак юкка чыгуын ишәйтү кешелек дөньясы өчен ахырзаман булырга да бик мөмкин. Аерым халыклары бетә барудан кешелеккә, аның биологик, социаль һәм мәдәни саулыгына килгән зыянны тикшереп өйрәнү зарур. Homo sapiens бар булсын, бетмәсен, яшәсен өчен алдан ук тиешле чаралар күрү сорала. Бер генә милләт бетсә дә, ул дөнья мәдәниятенә зур зарар китерәчәк, кешелек дөньясының тагын бер чишмәсе кибәчәк, дигән сүз. Ә ул чишмәләрдән һәр милләт, үзенең үсеш-өзерлегенә карап, үзенә кирәклесен «эчә»—тәрәккый итә. Бу фәнни-логик фикерләүне дини карашлар белән дә беркетеп куюя урынлы булыр. Барлык диннәр дә, кешелек дөньясын ничек булса, шул халәтендә Аллаһы Тәгалә бар иткән, ул яраткан һәм Аның кодрәте белән генә кешелек дөньясы яши, мәңгелек үсештә, дип өйрәтә. Димәк, аз санлы халыкларны «бөек» милләтләрнең йотып бетерергә тырышуы Аллаһының изге гамәлләренә каршы хилаф эш булыр иде...

Мәсьәләнең шәхескә кагылышлы субъектив ягы да шактый мөһим. Һәркемнең дә тумышыннан үзе булып каласы килә, бу аның табигый хаклы теләге һәм ул аның канында-геннарында яши. Кешелекнең хәзерге алгарышы чорында, тарих пьедесталына шәхес, һәркемнең кабатланмас үзенчәлеге-аерымлыгы күтәрелгәндә, кешелек дөньясының исән калуы һәм тәрәккыяте һәр шәхеснең табигать тарафыннан бирелгән гаять зур мөмкинлекләрен саклап калу һәм үстерелүенә бәйле бер вакытта, бу бигрәк тә әһәмиятле. Шәхеснең теге яки бу милләт кешесе булуы аңа ана сөте белән керә, бишектәге сабыйга үз ана телендә бишек җырлары җырлап сеңдерелә, аны акыл-аң белән генә аңлатып бетереп тә булмыйдыр. Шулай булмаса, үз туган җирләреннән әллә кайчан ук инде бөтенләйгә аерылган кешенең, берәр җирдә ялгыш кына үз халкының балачактан канына сеңеп калган җыр-моңнарын ишеткәндә, күзенә яшьләр килер идемени?! Тумышыннан кеше кайсы милләт халкыныкы булса, шул аң-тойгыны саклап калу һәм үстерүнең бәһаләп бетермәслек әһәмияте менә шулдыр инде. Һәр милләтнең, хәзерге тел белән әйтсәк, үз менталитеты, ягъни үзенә генә хас һәм уңай, һәм тискәре сыйфатлары бар. Бу сыйфатларның уңайларын кадерләп үстерү, ә тискәреләрен бетерү өчен рәхимсез көрәшү зарур.

Татар халкының уңай сыйфатларыннан мин тормыш сөючән, максатчан үҗәтлеген, теләсә нинди шартларда да яшәүчән-исән калучан булуын, үзе

иманган эш-гамәлләрдә фидакарьлеген-каһарманлыгын, дуслык тойгысының искиткеч булуын билгеләп үтәр идем. Тормышымда дуслык сынавын бары тик үз татарларым һәм бер дус яһүди генә сынатмый үтә алды. Безнең халык тикмәгә генә «аерылмыйк, дускаем» дип җырламыйдыр шул инде. Мин тагын бигрәк тә татарларның башка милләт халыкларына тигез карашын, аларны кимсетү, дошман күрү тойгысының булмавын аерым басым ясап әйтергә тиешмен. Булса да, кайберләребездә мәгълүм тарихи шартлар аркасында,—Явыз Иван патшаның Казан ханлыгын басып алуыннан соң гына,—урысларга шикләнебрәк-саграк карау шикеллерәк хисләр генә калгандыр. Бөтенләй чит-ят тел булган урыс телен, калада яки салада яшәвенә карамастан, һәр татар диярлек күпмедер дәрәҗәдә үзләштерә. Татар теләсә нинди милләт кешесе белән бик иркен-җиңел генә күршеләр булып китә, гаилә корып җибәрә, эшлекле мөнәсәбәтләргә керә ала.

Бу җәһәттән, урыс дәүләте белән идарә иткән патшаларның үз халкына бер гыйбад итеп, хайван (быдло) итеп караганнары хәтергә килә. Хәер, урыс халкы алар өчен үз булдымы икән соң әле? Үзара ызгыш-тарткалаш, яу-сугышлардан гарык булган урыс кенәзләре илне укмаштырып идарә итәргә варяг Рюрикларны чакырган бит. Үз илләрендә юлбасарлык белән көн күргән варяглар урыс җиренә дә үз дружиналары белән килә һәм шул баскынчылык һөнәрләрен биредә дә дәвам иттерә. Алардан соң килгән Романовлар нәселе исә чыгышы белән, нигездә, немецлардан, аларда немец каны. Бәлки шуның өчен дә хаким сыйныф славян халыкларын сөймәгән-күрә алмагандыр, шуның өчен дә, башка халыкларга караганда, аларны коллыкта озаграк тоткандыр. Россия империясе составында Балтик буе халыклары бу коллыктан иртәрәк котылган ич. Соңгы Ватан сугышында Сталин да түзем халыктан миллионнарча корбан биреп кенә җиңүгә иреште, үзенең җинаятьчел хакимлеген дә коточкыч ГУЛАГлары, төрмәләре белән «томалап» кына тотып торды. Ә халык аңа кадәрге сугышларда ничек туп азыгы булса, бүген дә шулай ук булып кала бирә түгелме соң? Менә сезгә тарихның ачы сабагы: халык хакимлекне үз милләтеннән булган, үз халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын, телен һәм мәдәниятен белгән шәхесләргә генә ышанып тапшырырга тиеш. Бары тик шундый Илбашлары гына үз халкын хөрмәт итә, ярата, башка халыкларга карата да дошманлык, яратмау хисләре күрсәтми.

Катнаш никахлар—татар егет-кызларының башка милләт кешеләре белән никахлашуы,—өйләнү-кияүгә чыгу мәсьәләсен һич тә читләтеп үтә алмыйм. Фәүзия Бәйрәмова һәм аның кебек кайбер башкалар тәкъдим иткән шикелле, андый никахлашуларны катгый тыеп та булмый бит, чөнки, шагыйрь әйтмешли, «мәхәббәт ул үзе—иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта...» Әмма шул ук вакытта, катнаш никахларны хуплап, аларга теләктәшлек белдереп тору да кирәкмидер, минемчә. Алай гына да түгел, үсеп килә торган яшь буынны, «икегез дә пар килгәнсез—тигез гомер итегез» дип, үз кавеме-халкы арасыннан үз парын табу рухында бала чагыннан ук тәрбияләү зарурдыр. Мондый тәрбия бирүдә, яшьләрнең «күзен ачуда» һәрвакыт милләтне саклап калу максаты күз уңында тотылырга тиеш. Күп гасырлар дәвамында ирексез-хокуксыз яшәү аркасында татар халкы шактый югалтулар кичерде: аның байтак өлеше манкортлашты һәм хәзер халкыбызга милләт буларак юкка чыгу куркынычы яный. Һәрхәлдә, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез,—ә алар халкыбызның дүрттән өч өлешен тәшкил итә!—өкренләп йотылып бетүгә дучар була бара. Халкыбыз, үз хәлен үзе аңлап, кичекмәстән нәтиҗәле чаралар эзләү эшенә керешмәсә, моны безгә Үзәктән—Мәскәүдән беркем дә «китереп тоттырмас». Ельцин һәм аның иярченнәре кабул иткән милли-мәдәни мохтарият турындагы закон, асылда, шул ук бөекдержавачыл шовинистик карашларны алга сөрә, аның яшерен максаты һаман да бер—аз санлы милләтләрне урысларның йотып-ассимиляцияләп бетерүе. Җәмгыятьтә, иҗтимагый фикерләүдә хакимият тарафыннан хәзер бик куркыныч бер караш туктаусыз алга сөрелә, газет-журналлар, радио-телевидение—кыскасы, гаммәви мәгълүмат чаралары көн-төн шуны тукый: имеш, милли республикаларны бетереп яки, инде бик булмаса, элекке тулысынча буйсынган, кол автономия хәлендә

калдырып,—монысы урындагы җирле түрәләрне сатып алып җиңел хәл итәлә ала,—Россияне губерналарга бүлеп чыгу кирәк. Безгә, әлбәттә, «бөек урыс шовинизмы» тегермәненә су коеп тору һич килешмәс, ә шуны эшләргә теләүчеләр юк түгел һәм табылып тора. Без моңа каршы үзебезнең «милләтчелегебезне» күтәреп чыгарга тиешбез. «Милләтчелек» дигәндә, мин үз милләтебезгә мәхәббәт тойгысын яңарту, аны саклау һәм үстерү өчен көрәш-омтылыш ише гамәлләрне күз алдымда тотам. Ул һич тә башка милләтләргә шулай ук үз милләтләрен саклау-үстерүгә комачау итмәскә тиеш. Әмма моның бик мөһим бер шарты бар: бер генә милләт тә башка милләтләргә зыян салырлык гамәл кылмасын.

Инде катнаш никахлар мәсьәләсенә яңадан әйләнеп кайтыйк. Без үзебезнең иң укымышлы, зыялы-белемле яшьләребезнең, башка милләт вәкилләре белән никахлашып, әкренләп эреп бетүенә ваемсыз карап торырлык күпсанлы халык түгелбез. Кызык бер закончалык бар: татар егете яки кызы башка милләт вәкиле белән гаилә корса, балалары, кагыйдә буларак, һич тә татар булып кала алмый. Булса да, мондый мисаллар бик сирәк, бары авыл җирендә генә булырга мөмкин. Ни өчен шулай сөйлимме? Мин моны үз тормышымның ачы тәҗрибәсеннән чыгып сөйлим. Минем кызым—талантлы галим, берничә чит тел белә, әмма, әти-әнисе—без һәр икебез татар булсак та (гаеплебез...), татар телен белми үсте. Ул урыска кияүгә чыкты (гаеплебез...), теле белән дә, паспорты буенча да урыс ул үстерде. Менә шул оныгыбыз татар кызына өйләнде, кызлары урысча сөйләшеп үсә (гаеплебез...), теле белән дә, паспорты буенча да маржа булыр инде... Мин, хатыным үлгәннән соң, урыслашкан белорус хатынына өйләндем, безнең Тимур исемле улыбыз туып, үсеп җитте, теле һәм мәдәни тәрбиясе урыс булса да, безнең катнаштан башка гына, үз теләге белән паспортына милләтен «татар» дип яздырды. Хак хакыйкатьне әйтергә мәҗбүрмен: әнисе аны татар теленә өйрәтүемне үтенде, аның өчен татарча балалар газет-журналлары алдырды һ. б. Ә мин моңа «вакыт таба алмадым» (гаеплемен...). Әгәр дә кулымны күкрәгемә куеп, борганланмый гына әйтсәм—улымны татар итеп тәрбияләргә бик әлләни атлыгып та тормый идем. Үз ачы язмышым шуңа этәргәндер, күрәсең... Аннары, Сталинның милли сәясәте безне бит дөньяда, төп биш телдән кала, барлык милли телләр дә бетәчәк, дип өйрәтте. Ә калачак телләр: урыс, кытай, инглиз, француз һәм испан теле бугай (әллә немецмы?) иде. Бу сәясәтнең нәтиҗәләре аяныч. Безнең гаилә мисалы бер бездә генә булдымы әллә? Минем бер дустым (хәзер мәрхүм инде, урыны җәннәттә булсын) зур галим иде. Хатыны белән икесе дә чын-чынлап татар зыялылары булдылар, ә менә аларның балалары һәм оныклары—урыслашкан татарлар яки бөтенләй... урыслар. Тагын бер дустым, татар халык язучысының кызы сәләтле филолог, берничә чит тел белә, хәзергечә әйтсәк, бик уңышлы «бизнес» эшли, әмма татарча белми... Тагын бер танышым бар, анысы һәр чат саен үзенең татарлыгын кычкырып йөри, ә балалары татарча белми... Һәм башкалар, һәм башка шундыйлар... Болай санауны һәркайсыбыз теләсә күпме дәвам иттерә алыр иде...

Әйе, ни аяныч, татар милләтенә тиз генә төзәтеп, кайтарып ала алмаслык зыян ясалган. Хәзер безгә аны савыктырырга, аякка бастырырга кирәк. Безнең халыкка ясалган зыян—ул бөтен кешелек дөньясына да ясалган зыян. Чөнки, һәр организмга аның һәр әгъзасы кирәк булган шикелле, кешелек дөньясына да аның һәр әгъзасы, һәр өлеше зарур, кыйммәтле.

Тагын да әйтәсем килгәне шул: миллилек тойгысы беркайчан да бөтенләй юкка чыкмый, иң ахыр чиктә ул черем генә итә һәм иртәмесоңмы барыбер бер уяна. Тукайның «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән ачынулы сүзләре дә шуңа ишарә. Безнең чынбарлыгыбызда Россиянең бөек урыс шовинизмы һаман да даими дәвамлы рәвештә гамәлдә кала бирә. Һәм ул безгә һич тә гамьсезваемсыз булырга, «йоклап ятарга» ирек бирми. Бюрократ түрәләр хаким сыйныф булып калган вакытта аларга шовинистик милләтчелек һәрчак хас булачак, алар кулында—хакимият, алар дәүләтнең бердәнбер хаким сыйныфы.

Марксизм-ленинизм тәгълиматы, «милләтчелек буржуазиягә генә хас сыйфат» дип раслап, тирән ялгыша: икътисадны һәм хакимиятне үз кулына туплаган, димәк, бар капиталга да хуҗа булган олигархлар интернациональ—алар өчен милләт төшенчәсе әллә бар, әллә юк.

Шәхеснең милли хис-тойгылары ешрак өлкәнәя төшкәч, картлыкка таба атлаганда уянучан була. Картлык—шатлык түгел, юлларында язгы май аеның аллы-гөлле чәчәкләре дә күренми. Ә яшьлек исә, алдын-артын уйлап тормастан, үзенең мәхәббәте белән тизрәк кавышырга ашыга, булачак хәләл җефетенең милли тойгылары иртәме-соңмы бер кабынып-дөрләп китәчәген исенә дә кертми. Һәм нәтиҗәдә еш кына гаилә фаҗигасе килеп чыга. Ир белән хатынның һәр икесендә ана сөте белән канына сеңгән милли хисләр, тормыш-көнкүрештәге гореф-гадәтләр, йолалар баш калкыта. Күз алдыгызга китерегез: бәхетле балачагыңны, кадерле әти-әниең һәм туганнарыңны, күңелгә якын басу-кырларны, урман-болыннарны, елга-күлләрне хәтереңдә яңартып, татлы рәхәтлек бирүче—кыскасы, үз туган халкың-милләтең җирлегендә сине үстергән, кеше иткән, синең бар булмышың булган хис-тойгыларыңны кузгатырлык үз җыр-моңнарыңны да тыңларга зар-интизар булып яшәп кара әле?.. Шуны онытмаска кирәк—һәр халыкның үз яшәү рәвеше, үз тормыш-көнкүреше һәм ул башка халыкларныкына һич тә тәңгәл килә алмый.

Бу аерымлык-үзгәлек, бу яраша-яраклаша алмау бигрәк тә хатын-кызлар язмышында ачык чагыла. Менә бер мисал. Явыз Иван Казанны яулап алганнан соң, ир-атларны—хәтта арба көпчәгәсе буе малайларны да!—кырып бетерергә әмер биргән, әмма татар хатын-кызларын, чисталык-пөхтәлек үрнәге итеп, саклап калырга боерган, имеш, дип сөйлиләр. Күрәсең, патша татар хатын-кызларының ул асыл сыйфатлары марҗаларга да күчәр дип өметләнгәндер. Бу уңайдан, тагын бер мәсьәләне искә алырга кирәк. Нәкъ шуның чишелешен белмәү 25-30 ел бергә гомер иткән гаиләләрнең таркалуына төп сәбәп тә була торгандыр, бәлки. Хикмәт шунда ки, хатын-кызның табигате ир-атларныкыннан күпкә баерак-юмартрак, хатын-кыз, ни-нәрсәдер алуга өмет итүгә караганда, әҗере булырын-югын уйлап тормастан, бирергә күбрәк ярата. Һәр хатын-кызга тумыштан ана булу хисе хас, шуңа күрә ул иренә хатын гына түгел, ә бәлки ана шикелләрәк тә була. Табигать биргән шушы сыйфат хатын-кызларның җенси мөнәсәбәтләрендә дә чагыла. Әмма шунысы бар: табигать хатын-кыз затына нинди милләттән булуына карамастан, шундый сыйфатлар бирсә дә, күп кенә милләт хатын-кызлары, үз милләтендә андый сыйфатларны күреп-тәрбияләнеп үсмәү сәбәпле, аны аңлап бетерә алмый. Ә менә татар милләтенә бу күренеш хас. Татар хатын-кызы,—ә бәлки ислам дине рухында тәрбияләнгән барлык мөселман хатын-кызлары да,—үзенең җенси теләгә-дәрте бармы-юкмы икәненә карап тормый, иренең теләгән үтәүне үзенең бурычы итеп саный. Ул ир хакын хаклый. Иренә рәхәтлек-ләззәт бирә. «Ир хакы—Алла хакы». Бу әйтемдә нинди тирән мәгънә ята! Гаиләсен саклау хакына шулай эшли ул аны. Гомумән, әхлакый таза һәм яхшы күңелле кеше өчен, әйтик, кемгәдер матди ярдәм күрсәтү—бирү дә кемнәндер нәрсәдер алуга караганда күңеллерәк гамәл бит.

Күрдегезме, милли хис-тойгыларым, татарлыгым мине кайларга алып кереп китте!

Тыйнаклыктан үлмәячәгемне истә тотып, бу язмамны Мәскәүдәге бер җитәкче хезмәттәшем әйтә торган сүзләр белән тәмамлар идем, ул минем белән күрешкәндә һәрвакыт: «Иң яхшы татарга сәлам!»—дип күрешә. Ул дөрес әйтә: татарларның да яхшылары, уртача-гадәтиләре һәм начарлары бар. Начарлары арасыннан урысны сөймәс җаннар—русофоблар чыга да инде. Урыслар арасында да нәкъ шундый ук хәл: бар яхшылары, уртачалары һәм бар бик начарлары—татарны сөймәс җаннар—татарофоблары. Язмам башында мине «русофоб» дип атаган бер урыс турында телгә алган идем, менә ул үзе татарны сөймәс җан—татарофоб түгелме икән?

*Мәскәү*

# АНТ ҺӘМ ӨМЕТ



Язучылар
**Адлер**
**ТИМЕРГАЛИН**
һәм
**Мәгъсум ХУҖИН**
әңгәмәсе



**Мәгъсум Хуҗин**. *Адлер туган, мин синең үзең турында, һәм иҗатың турында, сөйләргә яратмавыңны беләм. (Бу хакта алда да искәрткәләрмен). Шулай да укучыларыбызга синең хакта үз авызыңнан чыккан сүзләр белән ирештерәсем килде. Шулай кирәк саныйм. Һәм мин моңа күпмедер дәрәҗәдә ирешермен дә кебек. Минем кайбер мәсьәләләрдә үҗәтлегем сиңа мәгълүмдер, шулай булгач, кирелләнмә.*

*Әйдә, башлыйк әле сүзне... Тукай илә. Мине синең Габдулла Тукай иҗатына һәм, гомумән, аның шәхесенә мөнәсәбәтең кызыксындыра. Бу сорауга җавабыңны тәфсилләмәсәң дә, син тәгаен-төгәл сүзеңне әйтерәңә ышанам, чөнки синең карашыңны нигезле дәлилләвеңне беләм. Тукайның иҗатын тулысынча, бөтенләе белән, диик, бәлки, кабул да итмисеңдер, аның холкындагы кайбер сыйфатлар, бәлки, сиңа ошап та җитмидер. Әмма мин «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» белән синең кайбер әсәрләреңдә, төгәле «Сәнгать бакчасында» исемле хикәяңдә вакыйганы хыялый чолганышта (әллә даирәдәме?) тасвирлавыңда якынлык күрәм (кабатлау түгел). Әдәбият фәнендә «качырымлык» дигән термин да кулланылган, ул «символизм»нан киңрәк мәгънәдәдер. Заман идеологиясе кысаларыннан чыгарга тырышумы бу? Әллә ялгышаммы? Мондый алымның әдәбиятта-сәнгатьтә электән килүен һәм шундый әсәрләр белән әйбәт таныш булуыңны (Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт»ен искәрик) беләм. Шулай да моңа төшенү миңа алдагы соравымны нигезләү өчен кирәк.*

**Адлер Тимергалин**. Без барыбыз да Тукайдан чыкканбыз, дияр идем, чөнки ул—безнең чишмә башыбыз. Хәреф тануыбыз да анардан, «Кәҗә белән сарык»тан, «Шүрәле»дән ич. Тора-бара мин Тукайдан ераклаштым, күпмедер вакыт башка әдәбият әһелләре «Бәләкәй Апуш»ны томалап, каплап та торды, әмма, житлегә төшкәч, мин барыбер Тукайга әйләнеп кайттым. Һәм минем күңелдә ул Толстойлар, Бальзаклар, Блоклар белән янәшә урын тапты. Тукайга мин рәссам Хажи-Морат Казаков күзләре белән карыйм кебек. Анын «Бәләкәй Тукай» дигән картинасын әйтәм. Ә Хажи-Морат Казаков белән мин шактый якыннан таныш идем. Анын әтисе Сталин культы чорында репрессияләнгән, шуннан сон аларга Бауман урамындагы квартираларыннан бер генә бүлмә калдырып, гаиләне тәмам кысрыклаганнар, бик күп китапларын алып киткәннәр...

Хажи-Морат Казаковны тиешенчә танып житкермәделәр. Халтура белән шөгыльләнмәгәч, анарга кыен ашарга да туры килгән, дип беләм. Пенсиягә чыгар алдыннан кайсыдыр бер үзбәк эшлеклесенен портретын ясап биргәне (фотодан булса кирәк) өчен, ана, үзе һич тә көтмәгәндә, өметләнгәненә караганда биш тапкыр (әллә унмы инде) күбрәк акча килеп төшкәч, рәссамнын бик тә куанганын хәтерлим. Югыйсә ана бәләкәй генә пенсия чыгасы иде, шушы үзбәкләр акчасы ана аруырак пенсия алырга

мөмкинлек бирде. Хажи-Морат өчен мин дә куандым! Менә шушы нечкә күңелле зат сурәтләгән Тукайда никадәр моң бар... Бу моңны ул, үз кальбеннән алып, картинасына күчергән. Ихтимал, үзбәк эшлеклесенен күзләренә дә ул тирән сагышын салган булгандыр.

Әйе, мин Тукайга рәссам Хажи-Морат күзләре белән карыйм. Әлбәттә, мин Тукайның, кем әйтмешли, ялгыш адымнары, гөнаһлары турында да беләм. Ләкин Тукай—татар кешесе гөнаһларын да кичерә торган сирәк затларның берсе. Бу мәсьәләдә мин халкым белән бергә, әлбәттә.

«Бугазыннан кочкан» (Олжас Сөләймановча әйтсәк) системада яшәргә, түзәргә көч бирә торган шәхес ул Тукай минем өчен. Мин аның мескен Шүрәлесен дә яратам. Былтырны гына түгел. Мин хәтта икенче юлы урманга барганда Былтырга Шүрәленен бармакларын дәваларга бирер төрле «дару» да биреп җибәрер идем әле...

Тукае булган халыкның вөҗданы бар һәм иртәгесе көне бар.

Тукай егылгач, аның сазын Дәрдмәндләр, Бабичлар чиертеп карады, ләкин фаҗигале язмыш сазны Туфанга дип атап куйган икән... Туфаннан соң бу коралны кем тотар? Кемнең кулы җылы? Кем ул анда—яна фаҗигалар кочагында—үз кендеген үзе кисеп тернәкләнгәч, аягына баскан да, изге саз кылларын тартып маташа? Кем ул? Аның исемен мин белмим, ләкин шунысы хак—Тукайның Туруны ул.

Иртәгесе көн Тукай Туруннарын көтә. Әйтелгән бит: «Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата». Иртәгесе көн яктырак булыр, дип өметләнәм.

Кызганыч, тарих сәхифәләре әкрен, бик әкрен ачылган сыман тоела. Әмма башкача булмыйдыр, шушылай булырга тиештер, дип уфтанам мин.

Кире беткән оптимист буларак, мин Тукай Туруннарына өмет баглыйм. Пессимист буларак, аларны да фаҗигаләр әйләнеп узмасын беләм. Аларга да эләгәчәк.

Бүген безгә, чорыбызга Тукайлар, Фатих Әмирханнар житми. Графоман шагыйрьгә:

Тау башында тимер бөкән,
Типкәләмә, Думави!

— дип әйтерлек бәхәссез, мотлак авторитетыбыз юк. Бәшировлар, Еникиләр китеп баргач, без тулы ятим калдык. Потка табынйык, диюем түгел, өлкәннәрне, бөзергеләрне-бөекләрне тыңлыйк, диюем.

Ишми ишан кебек тарих өчен файдасыннан бигрәк зыяны күп булган затларны утлы табада биетердәй вөҗданлы каләм иясе күренми. Ә бит бүген—егерменче гасыр азагында!—әлеге бик мәгълүм ишанның абсолют томана китапчыкларын бастырып йөрүчеләр һәм шуларны нәшер итүче дә табылды... Хурлык!

Шигърияткә аз гына мөнәсәбәте булмаган такмазалар күпме! Имамнарыбыз һәм абыстайларыбыз да, гөнаһ шомлыгына каршы, шигырь әвәләргә тотындылар, алар язганны шомартып, кыргычлап, шигырь рәвешенә китереп, китап итеп чыгаручы тырыш журналистлар бар. Китапның, шигырьнең дәрәҗәсен төшерик, дисәң, моннан да яхшы ысул табылмас.

Күп, күп борчылырлык нәрсәләр... Заманыбыз болгавыр.

**М. Х.** *Тормышыңның кайсы баскычында мантыйкый фикерләүгә килдең? Тормыш серләрен тегә заман идеологиясеннән тайпылмыйча белеп булмасын кайчан аңладың? Студент чактамы әллә элегрәкме? Әтиең Камил абый сиңа бу тарафта нинди сабаклар бирде?*

*Минемчә, кеше, хаклыкны тормышы кредосы-мәсләге итсен өчен, вакытның һәм киңлекнең (пространствоның) чиксезлеген аңларга тиештер. Син әлеге чиксезлекне аңында кайчан «чикли» алдың? Университетта укыгандамы? Гомумән, студентлык елларыңның фаҗигале өзелүе турында сөйләсәң иде. Бу хакта исеңә төшерергә яратмавыңны беләм, шулай да әлеге фаҗигә синең тормышка карашың белән бәйледер, дип саныйм.*

**А. Т.** Әти Камил исемле, әни Хәтирә исемле. Алар укытучылар иде, Сарман районындагы төрле авылларга (мин шул районның Иске Минзәләбаш авылында туганмын) күчергәләп тә йөрттеләр безне, моның да тормышны белү, кешеләрне тану өчен файдасы тимичә калмагандыр. Әти—партия әгъзасы—коммунистик идеалларга ихластан ышана иде. Хәтта гомеренен соңгы елларында да—инде башкача фикерләү өчен мөмкинлекләр туа башлагач та—ул коммунизм идеяләрен тулаем читкә какмады. Әти-әни мине—һәм бүтән туганнарымны да—инсафлы, кешелекле, гыйлемле итеп тәрбияләргә тырыштылар, ягъни һәр ата-анага хас бурычны үтәделәр. Рәхмәт аларга!

Минем, Сталиннар салган «туры» юлдан барганда, читкә кереп китүемдә әтидән

йоккан сыйфат юк, сәясәттә тегеләй итәсене болай итәргә кушып пышылдаганы да булмады аның.

Әйе, «бөек юлбашчылар» юлыннан кырт борылуыма сәбәп (әллә сәбәпләрме?) бүтәндә иде͏дер. Моның шулай тиешлеген мин нәкъ менә кинлекнен һәм вакытның чиксезлеген күз алдына китерә башлагач аңыштым, дип саныйм. Данлы университетта астрономлыкка укый идем ләбаса—ни өчен әле мин сәясәттә дә, тулаем иҗтимагый тормышта да киңрәк (чиксезрәк!) уйланмаска тиеш ди?!.

Дөньяга карашым тамырдан үзгәрүгә, ихтимал, даһи Сталинның җитмеш еллык юбилее сәбәп булгандыр. Ул көннәрдә барлык газета-журнал Сталин рәсемнәре белән тулды, радио аның бөеклеген кат-кат «дәлилләде», Сталин турында яңа шигырьләр, җырлар яңгырады. Ничектер бервакыт бер газета битендә Сталин исеме ничә тапкыр очраганын санап карадым. Йөздән ашканлыгы хәтеремдә. Сталин исеме Ленин исеменнән дә ешрак телгә алына иде.

Шул көннәрдә мин, студент кеше, әйткәнемчә, булачак астроном, Бауман урамындагы Матбугат йортына килгәли идем. Хәтта бер хикәямне («Уяну» исемле) Габдрахман Әпсәләмов дигән яшь язучыга укырга да биргән идем. Габдрахман абый бу хикәяне анализлап, шөребен шөребкә аерып, бүсеп (тузгытып) ташлады. Мин хикәяне алып, ертып атарга ниятләгән идем, әмма Габдрахман Әпсәләмов: «Әйдә, без аны секциядә тикшерик, укысыннар, киңәшләр бирерләр, файдасы тияр»,—диде...

Ике ай чамасыннан соң үткәрелгән секция утырышында миңа катнашырга туры килмәде, чөнки мин иректә түгел идем инде.

Нәкъ шушы көннәрдә мин Сталин биографиясен чынлыклап өйрәнергә тотындым. Юлбашчының рәсми биографияләрендә аның шәхесенә кагылышлы конкрет мәгълүматлар таба алмыйча гаҗиз булдым. Эзләнә торгач, француз язучысы Анри Барбюсның Сталин турындагы китабына тап булдым (ул рус телендә берничә тапкыр басылып чыккан иде). Язучы күзе күпне күрә, дип өметләнеп ялгышканмын. Китап гомуми сүзләр, газеталарда көн саен кабатлана торган «хакыйкатьләр» белән тулы, ә конкретика юк иде. Фәкать генсекның «айлык хезмәт хакы» шактый аз булуын, Сталинның Кремльдә ике бүлмәле квартирада торуын, бер улының сандык өстендә йоклавын гына белдем бугай... Кыскасы, Барбюс китабы да агитпропаганда җимешеннән башка нәрсә түгел иде, ягъни аның төше юк иде.

Ә бит шул ук вакытта без Владимир Ильич Ленин турында шактый күп нәрсә белә идек. Аның балачагы, үсмер вакыты турында, сөргендә һәм чит илләрдә нинди эшләр майтаруы турында хәбәрдар идек. Төрмәдән кат-кат качкан Котовскийның «батырлык»ларын әйткән дә юк инде. Ә Сталинның ничек алты-җиде тапкыр сөргеннән качуы турында ләм-мим. Әйтерсең лә, ул сихер көченә ия булган.

«Сталин табышмагы»ның җавабы миңа каяндыр «югарыдан» иңгән кебек булды. Математикада күп билгесезле тигезләмәнең гомуми чишелеше юк. Ә «Сталин табышмагы» шундый күп билгесезле тигезләмә иде.

Көннәрдән бер көнне минем күзем ачылгандай, зиһенем яктырып киткәндәй булды. Мине борчыган бик күп сорауларга җавап бирү өчен, әлеге тигезләмәдә «даһи юлбашчы Сталин» дигән серне «даһи җинаятьче Сталин» дип кенә алыштырасы иде. Шуннан соң теге тигезләмәдә «икс»лар һәм «игрек»лар барысы да билгеле була...

Нindirәк сораулар?

Мәсәлән, Галимҗан Ибраһимов кебек күренекле каләм иясен нигә юк иткәннәр? Нәкъ шушы көннәрдә мин үзем квартирада торган йорт хуҗасының такта сараенда Галимҗан Ибраһимовның гарәп хуруфатында чыккан «Тирән тамырлар» романын табып укыдым. Бер очтан гарәп хуруфатын да «сукаларга» өйрәнгән идем.

Ә Хәсән Туфан кайда? Маяковский нигә һәлак булган?

Шул ук сарайда утызынчы еллар башында чыккан «Биология» дәреслеге тапкан идем. Мәктәптә мине гомуми биология—«Дарвинизм нигезләре» бик кызыксындыра иде, ләкин безгә аның элементларын гына һәм асыл нигезләрен—генетиканы төшереп калдырып укыттылар ул заманда. Без бакчачы карт Мичуринны, яровойлаштыру белән бөтен ил башын катырган Лысенконы гына белә идек. Баксаң, генетика гадәттән тыш төпле, нигезле, кызыклы фән икән ләбаса! Матур фән! Чын фән! Математика кебек төгәл фән икән! Мендель кануннарын аңлагач, мин инде Лысенкодай шарлатаннарга һич кенә дә ышана алмый идем. Менә шушы ин күбе колхоз бригадиры булып кына эшләргә тиешле бәндә Авыл хуҗалыгы академиясен җитәкли, ә Сталин бабаң аны яклый.

Бөек акыл иясе Мендель кануннарының гүзәллеген күрергә тиеш түгел идемени?

Сталин боларны күрми дә, аңламый да, әлбәттә. Ул, Лысенколар белән бергәләп, бөтен илне ач тотуда гаепле. Менделист-морганист-вейсманистларның эштән куылуын, репрессияләнүен әйткән дә юк инде.

Бу көннәрдә мин гадәттән тыш зур ачыш ясаган кеше кебек исәрләнеп йөрдем бугай. Дөнья күзенә карап: «Эврика!»—дип кычкырасым килә иде.

Ләкин нигә соң мин—тәҗрибәсез, гыйлемсез, наив авыл малае—шушы олы хакыйкатьне ачтым, ә башкалар (мин кылларын тартып караган кешеләр) аны күрми? Күрмәмешкә салышамы? Саклык, куркаклык—болары да бар, әлбәттә.

Мин совет хакимиятенең ун ел саен антисовет элементларны (хәзергечә әйтсәк, диссидентларны) «җыештырып» торганлыгын да аңладым. Алар күбесе «лагерь тузаны» булганнар...

Совет системасы шул рәвешле үзенең тотрыклылыгын сакларга тырышкан, моның өчен исә ана халыкның, милләтнең иң асыл затларын утап, кырып барырга туры килгән. Интеллектуаль генофонд саеккан. Илдә куркак куяннар һәм буар еланнар гына калган, диярлек. Сталин—буар еланнарның атасы.

Менә шушыларны аңлаганнан соң, мин нишләргә дә белмәдем, фикердәшләр юк, оешма (организация) юк, мин көчсез, зәгыйфь идем.

Үземчә көрәшергә тырышып карадым.

Ничек кенә сабыйлык тоелмасын, мин нәкъ шул көннәрдә үз-үземә сүз биреп, ант иттем (Герцен кебегрәк). Гомерлек ант! Бу системага каршы көрәшүне максат итеп куйдым—һич югында аның бер кирпечен булса да җимерергә! Фикердәшләр табарга, мөмкин икән—тәрбияләргә... Сабыйлыкмы? Белмим.

Калганнарына тукталып тормыйм.

Моннан соң үткән еллар минем барлык шик-шөбһәләремнең һәм гөман-фаразларымның нигезле булуын күрсәттеләр.

Миңа «тере менделистлар»ны да күрергә, хәтта алардан үзенә бер төрле лекцияләр тыңларга насыйп булды («тегендә», әлбәттә). Релятивизм теориясенең башлангычлары белән мин дәфтәргә карандаш белән немец телендә язылган текст буенча таныштым (Соломон Шулейн). Буржуаз Эстониянең соңгы президенты Пяцны күргәнем бар. Беренче Россия җинаять кодексы авторларыннан Александр Григорьевич Гойхбарг белән чын мәгънәсендә дуслаштым. Ул Вышинскийның кан дошманы иде. Ап-ак чәчле бу карт профессор да үзенең карашларын һәм белемнәрен яшьләргә калдырып китәргә ашыга иде. Румыния, АКШ, Франция, Япония гражданнарын да очратканым булды. Ихтимал, мәшһүр Рауль Валленбергны да күргәнмендер. Әгәр дөнья җәмәгатьчелеге аның эзен Казанда таба алса, мин бик куаныр идем, чөнки хәтеремдәге кайбер детальләр аның Казанда газап чигүенә ишарәли. Менә шул детальләрдән.

Ул кеше, кайсы телдә (мин немецча пупалый идем) эндәшсәң дә, җавап кайтармый иде. Без аның инде сөйләшә алырлык хәлдә түгеллеген аңладык, аны ябылуда шушы хәлгә китергәннәр икән. Кешеләр хокукы өчен батыр көрәшче (әгәр ул Рауль Валленберг булган икән) хәтта күз карашы белән дә уйларын сиздерә алмый иде. Ул көненә ике тапкыр тәмәке тарта, аны бик азапланып төрә иде. Мин, аны кызганып, тәмәкесен төреп бирергә теләвемне кул хәрәкәтләре белән аңлаттым. Ул каршы килүен белдермәде. Төкереклә ябыштырыйммы, дигән соравымны... күрсәттем. Битараф калды. Ябыштырдым. Тәмәкене авызына каптырып кабыздым. Ул җирәнмәде. Тагын бер хәл. Иртән (гафу!) бәдрәфкә кергәч, ул утырыр алдыннан унитазны кәгазь кисәге белән озаклап сөртер иде...

Бу хәлләр Арча кырындагы мәгълүм йортта булды. Әйе, мине анда да тотып карадылар. Хәер, сәяси тоткыннарны андый йортларда тоту гадәти санала иде ич.

Махсус «Сары йорт»та безнең белән бергә интегүчеләр арасында үз тәне температурасын тиешле дәрәҗәдә тота алучы Порфирий Ивановның—үз сәламәтлеген үзе көйләүче-җайлаучы, хәзер күпләргә мәгълүм Ивановның да булуын ишеткән идек.

Күп иде анда ихтыяры сынмаган кешеләр!..

Чагыштырмалылык теориясенә—релятивизмга бәйле кайбер нәрсәләрне дә әйтик.

Эйнштейн теориясе турында күбебез ишеткән булса да, аның нәтиҗәләре бездән нык яшерелгән, ә Эйнштейнның үзен идеалистлар белән тиңлиләр иде. Ни өчен? Без, чагыштырмалылык теориясен өйрәнү хокукыннан мәхрүм булган хәлдә, ничек итеп аны тәнкыйтьли алыйк икән?

Галәмнең кинәю мәсьәләсендә дә сүз куертмаска тырышалар, чөнки мондый фараз, дөнья бер ноктадан кинәя башлаган, дигән фикергә, ягъни дөнья яратылышы идеясенә китерә сыман иде.

Болар—әсасый (фундаменталь) фәннәр өлкәсеннән. Ә инде сәясәткә, экономикага, милли мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы четерекле сораулар санап бетергесез, һәм аларны бернинди капиталистик чолганыш, халыкара солидарлык, саботаж һәм башка әкиятләр белән аңлатып бетерү мөмкин түгел иде. Димәк, фәкать ялганлау гына кала. Халыкның башын, миен ялган белән тутыру ягъни.

Шул рәвешле, мин Олы ялган илендә яшәвебезне аңладым. Күп еллардан соң АКШ президенты Рейган аны «Явызлык империясе» (русчада—«Империя зла») дип атаячак...

**М. Х.** *Чиксезлек мәсьәләсенә бәйләп, физиклар һәм лириклар турында искә төшерик. Немец физигына (исеме онытылган) бер шәкертенең шагыйрь булып китүе турында әйтәләр. Галим моңа каршы, дөрес иткән—аның хыялы чамалы-чикле иде, дигән. Бу фикердә сәерлек, «ябышып бетмәү» бар кебек. Әллә юкмы? Син үзең дә лириклыкка физиклыктан килдең ич. Тик син физиклыгыңны да ташламадың. Җавабыңда әдәби иҗатыңнан мисаллар китерсәң иде, фантастик әсәрләр язуыңа киңрәк тукталсаң икән.*

**А. Т.** Фантастиканы «жанр» дип атау гадәткә кергән. Ләкин әдәбият проза, поэзия, драматургия жанрларын гына, ягъни шул өч терминнарны гына белә. Ә фантастика үзе ук прозага һәм башка жанрларга бүленә. Гомумән, фантастик сәнгать бар, дип әйтергә ярый.

Бу хакта элегрәк тә уйланган идем. Мондыйрак фикергә килгән идем.

Логик (мантыйкый, фәнни) фикерләү бар. Монысын, дөньяны фәнни танып белү, дип атыйк. Янә китереп, сәнгати күзаллау (фикерләү, танып белү) бар. Монысы сәнгатькярларга хас. Шигърияттә бу аеруча ачык күренә. Шагыйрьләр еш кына һичбер дәлилләрсез хакыйкатьне таба, чынлыкны күрә алалар. Ләкин әле мифологик һәм мистик фикерләү (аңлау) дә бар. Ниһаять, дини танып белү (дини философия) кешелек дөньясына, тарихка бик тә зур йогынты ясаган.

Фантастика да, миңа калса, фикерләүнең бер төре, фикерләү ысулы, модельләштерү юлы белән танып белү ысулы. Бик ихтимал, фантастика әлеге фикерләү ысулларының күбесен, бәлки, барысын да, берләштерә торгандыр (синтез). Мин, әлбәттә, чын фантастика турында сөйлим, графоманнар көчәнеп язган примитив саташуны күздә тотмыйм.

Минә шуңа күрә дә чын фантастика киләчәкне алдан күрә ала, ягъни фантастларга мәгълүм дәрәҗәдә пәйгамбәрлек хас. Алдан күрү генә түгел, фантастика ысулы кичәгене дә, үткән заманны да исккиткеч тулы итеп күз алдына китереп бастыра ала, аларны сүз һәм сурәтләр ярдәмендә башка кешегә житкезә ала. Мондый сыйфатка, әйткәнемчә, шагыйрьләр дә ия, ләкин гадәттә алар томанлы сурәтләр белән генә эш итәләр, кайчак аларның шигъри сурәтен гади сүзләр белән аңлатып та булмый. Ә фантастика иң югары хакыйкатьне дә гади кеше аңына китереп ирештерергә сәләтле. Күп кенә бөек әдипләрнең вакыт-вакыт фантастикага мөрәҗәгать итүе дә шуннан киләдер.

Бу хакта минем фикерләрем шундыйрак, хыялыйрак, димме. Хәер, фантаст буларак, минем моңа хакым да бардыр лабаса...

Безнең буын балачактан ук фантастик әсәрләрне күп ук укып (татарча) үсте. Дөнья әдәбияты үрнәкләреннән «Серле утрау», «Су астында сиксән мең километр» исемле әсәрләрне мисал итү дә житәдер. Фантастик һәм мажаралы әсәрләр мине бик тә җәлеп итә иде, һәм мин, шулар йогынтысындадыр, мәктәптә укыганда ук «романнар» (әлбәттә, бала акылы белән) яза башладым. Яза башлап ташланган «әсәрләр» арасыннан канатлар үстерелгән кеше турындагысы гына бераз истә калган.

Ә син баштарак искәрткән «Сәнгать бакчасында» исемле хикәям... Хәер, аның турында соравыңда әйткән фикерләрең—үзләре үк җавап. Әйе, заманасы качышлы уйнарга мәҗбүр итә иде. Тик гел «качып» булмады, шуңа күрә кыен ашарга да туры килде. Син, «Иләк йолдыз» исемле хикәя язасым бар, дисең. Мин «Өлкәр» (Иләк йолдызның икенче исеме) дигән хикәямне яздым инде. Анда да күчеремлек-качырымлык бар...

**М. Х.** *Син тел мәсьәләсендә (һәм бүтән тарафта да) төгәл фикер йөртәсең, сүзне кадерлисең. Төгәл фәннәр буенча русча-татарча сүзлекләр төзүдә катнаштың, кайберләренең редакторы булдың. Шулай ук сүзлекләр төзүгә яшь галимнәрне оештыруда*

*да хезмәтең мактаулы. Белүемчә, һәр термин-атаманың татарчасы булырга тиеш, дигән фикердә тормыйсың. Чыннан да, әйтик, инглиз теленнән алынган «трамвай» сүзенең татарчасын «тудыру»ның кирәге дә юк. Әмма төгәл фәннәрне, термин-атамалар мәгънәсен белүнең әдәби иҗатыңа тәэсире-йогынтысы бармы? Әдәби иҗатыңда һәм тормыш итүеңдә физиклыгың мисаллары күпме? Моннан элекке сораудагы физиклык һәм лириклык мәсьәләсенә тагын әйләнеп кайтыйк әле.*

**А. Т.** Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә, техника, физика, астрономия буенча сүзлекләр, авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге төзүдә якыннан катнаштым. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең өченче томы редакторларының берсе идем. Соравыңда әйткәненчә, русча-татарча техник терминнар сүзлекләрен әзерләүдә, авторлар коллективларын туплауда башлап кайгыртырга туры килгәләде. Шунысы куанычлы— билгеле күләмдәге хезмәтемнең нәтиҗәсе күренде, белгечләргә күпмедер ярдәмем тигәндер, дип уйлыйм. Мондый сүзлекләр киләчәктә тулырак булып ешрак басылсын иде. Фән-техника бер урында таптанмый ич—егерменче гасырда колачын киң җәйгән техник прогресс яна гасырда тагын да колачлырак булачак . Шиксез монысы.

Аңа телебезне, кирәксә-кирәкмәсә дә, төрле фарсы, гарәп алынмалары белән, урамнан кергән, бозылган сүзләр белән чүплибез. «Ырынбур» дип язсак, янәсе, татарча була! «Нижгар», «Ижау», «Ырынбур» кебек атамалар рәсми матбугат, дәреслекләр һәм фәнни әдәбият өчен яраксыз. Алар—гади сөйләм, җирле сөйләш сүзләре, һәм, фәнни атама булудан бигрәк, кушамат сыманрак яңгырыйлар. Матбугатыбызда «Ырынбур» сүзен күргәләгәч, «ыстырам» дигән алынма сүз искә төшә.

Физиклыктан киттемме?.. Әлбәттә, китмәдем. Һәм китә дә алмаячакмын. Төгәл фәннәрне мин мәктәп елларыннан ук яраттым, аларга бирелүем гомерлеккә. Хыянәт— минем өчен иң киме яп-ят нәрсә! Аннары саф лириклыкка күчеп кунакласам, «Адашкан йолдыз», «Кабул булсын теләгең», «Таш Алиһә», «Космостан кунаклар» кебек китапларымны яза алмаган булыр идем.

Тормыш итүемдә физиклыгым мисалымы?.. Бар икән андый мисаллар. Менә берсе—радиотехникага бәйлесе, радиотехниканың үсеш баскычларына туры да килә ул. Мин яшь чагымда детекторлы, аннары лампалы, соңыннан транзисторлы радиоалгычлар ясадым. Кайбер эшләргә кулым бара иде кебек.

Инде, лириклыкка килеп җиттенме, дип сорасаң...

**М. Х.** *Життең! Күптән түгел «Казан утлары» журналында басылган «Игезәкләр» исемле әйбәт повестең шуны раслый.*

**А. Т.** Рәхмәт.

Фантастик әсәрләр язганда исә бик тә әзерлекле булу таләп итеЛә.

**М. Х.** *Табигый, моның өчен күп укырга кирәк. Ә синең китапханәң бай икәнлеген күптәннән беләм. Китапка мөкиббәнлегең төгәл фәннәргә генә карамыйдыр бит.*

**А. Т.** Һич юк. Дөнья классикларының тупланмалары җыелды, төрле-төрле белешмәлекләр, сүзлекләр ишле үк. Гомумән, төрле өлкәдән. Белемемне күтәрүдә беренче чыганак булды миңа озаклап тупланган китапханәм.

Арада истәлекле китаплар да бар. Менә егерменче елларда чыгарылган «Литературная энциклопедия»нең бер томы (монысы утызынчы елда басылып чыккан. Аңа шәмәхә кара белән Taqtaş дип язылган. Икенче якта Такташның хатыны Гөлчәһрәнең уллары Аванга изге теләкләре гарәпчә алфавитта теркәлгән, әчтәлегеннән аңлашылганча, монысы инде шагыйрьнең вафатыннан соң язылган. Бу китап букинист кибетеннән алынды...Шулай да диплом белән беркетелгән югары белемгә ия була алмадым мин. Укытучылар институтын (икеъеллык кына иде ул) тәмамлаган килеш калдым, анысында да, «тегеннән» чыккач, Урта Азиягә барып укырга мәҗбүр булдым. Тирәнме-саймы белемем бар икән, бу—«тегендә» күренекле кешеләрнең «лекцияләре»н тыңлау һәм хәзинәмдәге китапларны җентекләп укуым нәтиҗәсе. Күптән түгел күп кенә китапларымны Яшьләр китапханәсенә бирдем.

**М. Х.** *Реабилитация мәсьәләсен әйтмичә ярамас бит...*

**А. Т.** Син искәрткәнчә, бу хәлләр турында сөйләргә яратмыйм. Менә син бераз телне ачтырдың, әкрен-әкрен җаена китердең. Әңгәмәдә коточкыч хәлләрне өстән-өстән генә искә төшерү дә мине озак газаплаячак әле...

**М. Х.** *Гафу... Мондый сорауны бирмичә кала алмадым. Аннары сүз хакимият тарафыннан пычратылган исемне хакимият үзе үк чистартырга мәҗбүр булуы турында бара.*

**А. Т.** Җинаятьләр кодексының илле сигезенче маддәсендәге унынчы пункты буенча гаепләделәр мине. Асылы сәясәт инде. Ә реабилитацияләнүем туксан җиденче елда, ягъни ярты гасырлап «халык дошманы» саналдым, «невыездной» идем, ягъни чит илгә чыгарга ярамады. Ә мин чыктым! Ничекме? Дөнья әдәбиятының күренекле әсәрләрен укып һәм «тегендә» абруйлы кешеләрнең безнең кебек яшьләргә укыган «лекцияләре»нең эчтәлекләрен кат-кат барлап, хыялымда гиздем мин Җир шарын һәм Галәм киңлекләрен!...

**М. Х.** *«Тегендә» иң исеңдә калган вакыйга нинди?*

**А. Т.** Камераның юан тимер рәшәткәле бәп-бәләкәй тәрәзәсеннән бервакыт яшьләребез җыры ерак-еракта килеп җитеп, хәтта ишелеп (шулай тоелды гынамы) бәреп керде... Җыр исән икән ич! Үзенә богау салдырмый икән ич безнен җырыбыз!

**М. Х.** *Сорауларым озынрак булды. Моның сәбәбе синең иҗат үзенчәлегеңә, шуны аңларга тырышуыма бәйле. Шуңа күрә фәнгә дә кереп кителгәләде, башта ук Тукайны да искә төшердек. Тукай да бит коеп куйган «поэт» кына түгел, син дә язучы гына түгел, гыйлем иясе, галим кеше—шуңа да басым ясарга теләдем. Аннары синең өчен (һәм дә укучыларың өчен) истәлекле һәм шатлыклы вакыйга уңаеннан синең олы иҗатыңны бәяләргә теләвем дә сорауларны тәфсилләргә этәрде.*

*Туган көнең, яңа гасырның беренче көненә туры килүче җитмеш яшьлегең белән котлыйм сине, Адлер туган!*

**А. Т.** Рәхмәт.

**М. Х.** *Инде кыскарак сорау.*

*Укучыларыңа (мин дә сине зур хезмәтләрең өчен хөрмәтләүче) әйтер сүзең нинди?*

**А. Т.** Бу кыска соравыңа җавабым бераз озынрак булыр.

Иң элгәре укучыларыма, заман катавасияләрен-тәртипсезлекләрен бетерүдә үз өлешләрен салып, бәхетле яшәүләрен телим. Заманалар болгавыр, дигән идем. Тычкан таяк тотып йөргән чак хәзер, халыкчарак әйтсәк. Баксаң, куркак куян дигәнебез дә буар еланга әйләнеп маташа, чөнки ул, астыртын, гомер буе шул турыда хыялланып яткан икән. Адәмнең күңел төпкелендә Иблис тә яши. Камил кеше әнә шул ләгыйньне богауда тотарга тиеш. Ягъни мин укучыларымны камиллеккә омтылырга чакырам. Һәм аларга олы үтенечем бар.

Үзем турында мин шактый күп нәрсәләр сөйләдем. Бу хәл мактану булып аңлашылмасын иде. Һич тә! Эреләнү сыйфаты миңа беркайчан да ябышмаганлыгын син беләсең, укучыларым да шуны аңласын иде. Инде ачылып киткәләгәнмен икән, моның сәбәбе менә нәрсәдән гыйбарәт. Теге замандагы системага каршы көрәшүне максатым итеп куюымны югарыда әйткән идем. Мин яшьлек антыма тугры булып калдым. Шуны аңлатасым килде—ниятем бары тик шул гына иде.

...Озак еллар буена инде мин «Миллият сүзлеге» төзим. Нигездә аңа инде нокта да куелды, әмма шомарту туктаусыз дәвам итә. Күләме зур, машинкада бер мең ярым бит чамасы. Үзенчә аңлатмалы бу сүзлектә дини, тарихи мәгълүматлар бар, аңа фәнгә, әдәбиятка, сәясәткә һәм халык хуҗалыгына кагылышлы кыска мәкаләләр дә керә, күренекле шәхесләр, гореф-гадәтләребез һәм башка, һ. б. мәсьәләләр турында да сөйләнә. Укучыларыма әйтергә теләгәннәрем әнә шушы күләмле хезмәтемдә урын алды. Әңгәмәбез, әйе, Габдулла Тукаебыздан башланган иде. Тукай турында мин алда әйткән фикерләр әнә шушы сүзлектә киңрәк тасвирда китерелде.

«Миллият сүзлеге» укучыма минемчә барып житсә, теге чактагы антыма тугры булуымны аңлар иде ул. Өметемне өзмим—сүзлегемне укучым кулында күрермен, дип ышанам.

**М. Х.** *Бирсен Ходай!*

# ЖАНРНЫҢ ЯЗМЫШЫ ҺӘМ ЯҢАРУЫ

Озын тарихлы һәр әдәби традициядә халыкның иҗтимагый аңы, үз-үзен танып белүе билгеле бер баскычларга күтәрелгәндә, милли үзаңы формалашуын күрсәтә торган махсус әдәби гыйльми жанрлар була. Шундыйлар исәбенә төрле юльязмалар—сәяхәтнамәләр дә керә. Бер карауга аларда теге яки бу халык вәкиленең чит-ят җирләрдә үз башыннан узган хәлләре, күргән-белгән нәрсәләре хакында хикәя итү белән чикләнгән кебек. Ләкин мондый әсәрләрдә, төптәнрәк уйлап карасаң, башка илләр, бүтән халыклар белән танышу, укучыларын да таныштыру өстенә, авторның үз иле, үз халкы хакында да уйлануы (борчылуы яки горурлануы) урын алганлыгын күрүе кыен түгел. Әлбәттә, күп очракларда андый фикерләрнең кыеклап әйтелгән, шактый яшеренгән хәлдә булуы да ихтимал. Чөнки, башкалар хакында теләсә ничек язсаң да, укучыда үз-үзеннән: «Без нindирәк икән», яисә «бездә нигә болай?»—дигән кебегрәк сораулар, уйланулар туарга мөмкин һәм туачак та. Әсәрләрнең нинди теләк һәм максат, нинди сәбәп вә шартларда (авторның үз инициативасымы, яисә махсус заказ буенчамы) барлыкка килгән, язылган булуына карамастан. Шулай булмаган тәкъдирдә, минемчә, андый жанр тумас, туса да, озак яшәмәс, дөресрәге, дәвамлы булмас иде.

Сәяхәтнамәләр жанры, гомумән, үзенең барлыкка килүе, үсүе җәһәтеннән шактый борынгы чорларга барып тоташа. Моның шулай икәнлеген борынгы юнан, кытай, гарәп һәм фарсы, соңрак чорларда тернәкләнгән аурупалы халыклар һәм русларның әдәби мираслары мисалында да күрергә мөмкин. Без бүген, үз халкыбызның элекке чор тарихын өйрәнгән чакта, еш мөрәҗәгать итә торган борынгы китаби истәлекләрнең күпчелеге дә шундый юлъязма һәм сәяхәтнамәләрдән гыйбарәт. Мәсәлән, Әхмәд Ибне Фазлан, Әбү Хамид әл-Гарнатыйның болгарлар, Ибне Баттутаның кыпчаклар хакындагы язмалары һ. б. Гарәп телендә иҗат ителгән мондый әсәрләрне дистәләп-дистәләп санарга мөмкин. Һәм бу жанр әсәрләренең мул булуы шул милли әдәбиятның, шул җирлек фәненең нык үскәнлеген, дәүләтчелек һәм халык культурасының югары дәрәҗәгә ирешкәнлеген күрсәтә. Кыскасы, географик гыйльми әсәрләр белән публицистик әдәбият арасындарак тора торган бу жанр бай тарихка ия.

Укучыда шундый сорауның тууы ихтимал: бездә, татар язма традициясендә мондый жанр кайчанрак барлыкка килгән? Һәм гомумән татарча сәяхәтнамәләрнең язмышы ничегрәк?

Сорауларга өздереп кенә беркатлы җавап бирүе кыен, әлбәттә. Чөнки мәсьәлә махсус рәвештә җентекләп өйрәнелмәгән әле. Шулай да Газиз Гобәйдуллинның болгарлар чорында ук илләр гизгән Идел буе кешеләренең дә андый әсәрләр иҗат иткәнлеге мөмкин, дигән бер фикере, һичшиксез, игътибарга лаек. Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында да андый әсәрләрнең язылган булуы ихтималдан ерак түгел. Моны кыеклап раслый торган бер факт та бар. Мәсәлән, XVI йөзнең беренче яртысында Казанда яшәгән, андагы сәяси, иҗтимагый эшләргә актив катнашкан, хәтта идеолог дәрәҗәсенә күтәрелгән Шәриф Хаҗитархани (Колшәриф) «Зафәрнамәи вилайәте Казан» исемле 1550 елда язылган әсәрендә ерак Госманлы дәүләте кешеләрен Казан җирендәге хәлләр белән таныштыруны максат итеп куя. Игътибар итегез: үз иле белән башкаларны таныштыру бу. Димәк, мондый аң булган җирдә башкалар белән үз иле

кешеләрен таныштыру ихтыяжының да яшәгәнлеге табигый. Ләкин андый рухтагы татарча әсәрләрнең сакланмаган булуы ихтималга якынрак.

Элеккерәк чорларда иҗат ителгән язма әсәрләребезнең күпчелеге харап булуга артык гаҗәпләнергә нигез юк. Идел буендагы Болгар, Биләр, Җүкәтау, Сарай, Үкәк, Гөлестан шикелле кайчандыр гөрләп торган зур шәһәрләрдән таш өстендә таш калмаганлыгын, хәтта Казан булып Казанның да элекке биналары тәмам җимерелеп, алар урынына бөтенләй яңалары килеп утырганлыгын алыйк. Димәк, кәгазь китапларның юкка чыгуына бер дә гаҗәпләнәсе түгел икән...

XVI гасыр урталарында Идел буйлары тәмам яуланып, халык авыр коллыкка төшерелгәннән соң, табигый ки, сәяхәтнамәләр хакында уйлау түгел, бәлки бөтен кайгы җан саклау һәм ризык эстәүгә кайтып калган. Бары яңа шартларда, беразаякка баса башлагач кына, ягъни сәүдә эшләре тернәкләнә төшеп, татар кешеләре дә азмы-күпме дәрәҗәдә илләр гизү, башка дөньяларны күрү мөмкинлекләре тугач, сәяхәтнамәләр язылуга шартлар барлыкка килгән. Бу дәвердә, төгәлрәк әйткәндә, Пугачев яуларыннан соң беркадәре үзгәргән шартларда, татар кешеләренә хаҗга барып кайту, чит җирләрдә сәүдә кылу, ягъни ерак илләргә сәфәр чыгу мөмкинлекләре туган...

Менә шундый социаль һәм иҗтимагый үзгәрешләрнең нәтиҗәсе буларак, XVIII гасырда татар телендә яңа сәяхәтнамәләр барлыкка килә башлый. Шул күренешнең мисалы сыйфатында Исмәгыйль Бикмөхәммәд угылының утыз ике елга сузылган ил гизүе хакындагы юлъязмасын (Оренбург—Бохара—Әфганстан—Гыйрак—Һиндстан—Гарәбстан—Сүрия—Төркия—Русия), шулай ук Мөхәммәдәмин Гомәр угылының хаҗ сәфәре тасвирламасын атарга мөмкин. Ике әсәр дә XVIII йөзнең икенче яртысындагы сәяхәткә багышланган.

Дөрес, бу ике әсәргә кадәр дә бер хаҗ сәфәре хакында кыскача язма булган. Ул 1698—1699 елларда Мортаза ибне Котлыгош дигән Казан арты кешесенең хаҗга барып кайткач язып калдырган бәләкәй генә истәлегеннән гыйбарәт. Ләкин язманың гаять кечкенә күләмле һәм информациянең артык коры, формаль булуы аны махсус сәяхәтнамәләр исәбенә кертергә җитәрлек җирлек тудырмый. Шулай да, омтылыш буларак, ул да игътибарга лаек нәрсә. Моның белән чагыштырганда Исмәгыйль сәяхәтнамәсе белән Мөхәммәдәмин язмасы, һичшиксез, татарча сәяхәтнамәләр жанрының яңадан тууына—торгызылуына мисал була ала. Болардан иң оригиналы, әлбәттә, Исмәгыйль әсәре. Мөхәммәдәмин язмаларының шактый өлеше исә шул беренче әсәрнең аерым битләрен үз язмасына кертүдән гыйбарәт...

XIX гасырның башында да татар кешеләре тарафыннан язылган тагын ике-өч әсәр булу хакында кайбер мәгълүматлар бар. Ләкин алар әле махсус тикшерелмәгән. Аларның кайберләре өтек-өзек кулъязмалар хәлендә КДУның гыйльми китапханәсендә, икенчеләре Петербургта саклана.

Бездәге сәяхәтнамәләр жанрының чын-чынлап җанлануы, иҗтимагый әһәмиятле тарихи документ дәрәҗәсенә күтәрелгән әсәрләр язылу, һичшиксез, милли аң тәмам оешып житкән XIX йөзнең икенче яртысы белән XX гасырның башына туры килә. Дәүләтчелек, мөстәкыйльлек аңы сүрелтелгән, зәгыйфьләнгән халыкта андый жанр янарсын өчен, күрәсең, яңадан хосусый милеккә ирешә башлау, капиталистик мөнәсәбәтләр белән бергә милли үзаң ныгу кирәк булгандыр. Шундый иҗтимагый әһәмиятле сәяхәтнамәләр рәтенә иң элек Шиһабеддин Мәрҗани язмасын («Рихләте Мәрҗани») һәм Заһир Бигиевнең «Мауәраэннәһергә сәяхәт» исемле мәгълүм әсәрен кертергә кирәк. Дөрес, Мәрҗани үз әсәрен тәмамламыйча калдырган булып, аны соңрак Риза казый Фәхреддин бераз кыскартып бастырган. З. Бигиев әсәре хакында әдәбият тарихы буенча моңарчы беркадәре мәгълүм инде.

Шулай да иҗтимагый әһәмиятлелек ягыннан иң мөһим татарча сәяхәтнамәләр XIX йөзнең ахыры белән XX гасырның башында дөнья күрәләр. Болар арасыннан мин иң элек Фатих Кәриминең өч әсәрен—«Аурупа сәяхәтнамәсе», «Кырым(г)а сәяхәт» һәм «Истанбул мәктүбләре»н (1902—1914), Садрый Максудиның «Англиягә сәяхәт»ен (1910) һәм 1906—1917 елларда татар вакытлы матбугаты битләрендә басылган күпсанлы мәкаләләрне, җөмләдән Галимҗан Идриси, Нәүширван Яушев һ. б. эчтәлекле, гыйбрәтле язмаларын күрсәтер идем. Чөнки нәкъ шушы әсәрләрдә мин югарыда чын сәяхәтнамәләргә хас, зарури дигән хосусиятләр—башкалар турында сөйләп, кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр хакында хикәя итә-итә, үз илен, үз халкын,

аның узганы, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйланырга этәрә торган сыйфатлары—тулысынча диярлек гәүдәләнгән дияр идем. Җыеп әйткәндә, XIX гасыр ахыры белән XX гасыр башындагы әдәби процессыбызда, кайчандыр яшәп тә, соңгы өч-дүрт гасыр коллык чорында тәмам сүндерелә язган юлъязма—сәяхәтнамәләр жанры янадан кабынып, тулы гәүдәсен күтәреп дигәндәй аякка баскан иде.

Ләкин совет хакимияте елларында иҗтимагый фикеребез, әдәбият һәм сәнгатебезнең төрле өлкәләре белән берлектә бу үзенчәлекле жанр да янадан сүнеп калуга дучар ителгән иде. Канлы ватандашлар сугышы, коточкыч ачлык еллары, аннары бер-бер артлы кайткалап торган репрессияләр чорында иске вәзгыять тагын кабатланды диярлек: янә җан саклау, ачтан үлмәү мәсьәләсе беренче планга чыгып, халыкның төп кайгысына әверелде. Дәүләт чикләре бикләнүдән тыш, үз илендә дә иркенләп йөрү, сәяхәтләр ясау мөмкинлекләре беткән иде. Әгәр сәяхәт һәм «сәяхәтнамә» дип, Себергә сөрүләрне, Беломорканалда черүләр белән, «кулакландырылып» таланганнан соң ач-ялангач тинтерәп йөрүләр хакындагы басылмаган, дөресрәге язылмаган йөзләгән-йөзләгән «юл мажаралары»н исәпкә алмасаң... Сугыш елларында Мәскәү яныннан ук Берлинга кадәр түшен белән шуышып баруларны да беркем дә «сәяхәт» дип атамады шикелле. Хаклы рәвештә.

Ара-тирә генә, ничә елга бер-ике кешенең, гадәттә түрә кисәкләре һәм куштаннарының махсус инструкцияләр уза-уза, «тимер пәрдәнең» теге ягында бер күренеп кайтуларын, кайткач акны кара дип, караны акка чыгарып, гәзитә мәкаләләре бастыруларын да исәпкә алуы шөбһәле. Чөнки мондый язмаларда күргән-белгәннәрне дөрес итеп сөйләүдән бигрәк, «күрмәгәненне күрсәтү» галәмәте өстенлек итә иде. Алар уйландыру һәм уйлануны түгел, бәлки уйламыйча гына ышануны, ягъни автор тәкъдим итә торган фикерләрне «чәйнәмичә» генә йотуны максат итеп куя иде. Шул рәвешчә чын сәяхәтнамәләр жанры тагын бөтенләй диярлек сүнгән, үтерелә язган иде. Мин, мәсәлән, совет чорында татар кешесе тарафыннан үз ана телендә язылып дөнья күргән бер генә әсәрне хәтерлим. Ул элекке Мәгариф министры Мирза Мәхмүтовның 50 еллар ахырында Һиндстанга сәфәре хакында 60 еллар башында чыгарган шактый кызыклы кечкенә китабы. Хәер, анда да чор идеологиясенә хас чикләнгәнлекләр үзен нык сиздерә иде...

Әмма ләкин «дөнья—куласа...» дигән шаяртуда да дөреслек бар икән. Гасырыбызның 80 еллары ахырыннан башлап, «тимер пәрдәләр ертылып», Берлин диварлары җимерелгәч, татарча юлъязмалар—сәяхәтнамәләр жанры тагын җанлана, тернәкләнә башлады. Үзгәртеп кору омтылышлары китергән беркадәре иркенлек нәтиҗәсендә халкыбыз вәкилләре башка илләргә барып кайту һәм, иң мөһиме, күргән-белгәннәрен үзләре ышанганча дөресрәк итеп язу, аны да курыкмыйча гәзитә-журналларда бастыру мөмкинлекләренә иреште. 80 еллар ахырыннан алып хәзергә кадәр, радио һәм телевидение чыгышларын да исәпкә алсаң, йөзгә якын эреле-ваклы язмалар дөнья күрде дип әйтерлек. Хәтта берара һәрбер турист, кыска вакытлы командировкага барып кайткан һәр хезмәткәр, галим кисәге дә үз сәфәре хакында ни теләсә шуны өстән-өстән язып чыгаруны, сөйләп бирүне фарыз дип исәпли башлаган иде. Һәрхәлдә 80 еллар ахыры белән 90 еллар уртасына кадәр чит ил сәфәрләре хакында матбугат битләрен бизәү билгеле дәрәҗәдә модага да әйләнә язган иде.

Шунысы да характерлы: элек, мәсәлән, Төркиягә барып кайткач, анда көрәшкән милләттәшләрен «совет дошманы», «сатлык җаннар» рәвешендә сурәтләгән авторлар, шуларны ук хәзер инде «милли герой», «хөрмәтле дустыбыз» дип, олылаудан тайчынмадылар. Күрәсең, «бәйдән ычкыну» процессының бер гыйбрәтле чагылышыдыр бу...

Әлбәттә, соңгы елларда дөнья күргән татарча юлъязма һәм сәяхәтнамәләр арасында шактый тирән эчтәлекле, күләмле һәм мәгънәле, мәсьәләне өйрәнеп-белеп язылганнары да аз түгел. Шундыйлардан мин иң элек Тәүфикъ Әйдинең бер төркем әсәрләрен күрсәтер идем. Дөрес, аларның кайберләре кыскарак рәвештә элегрәк тә гәзитә-журнал битләрендә дөнья күргән иде. Мәгәр язучының сәяхәтнамә жанрында иҗат иткән төп язмалары соңгы ике елда «Аваз» нәшриятында чыгып килә торган әсәрләр җыелмасының дүрт китабында тәгәлрәк тупланган.

Һәр әсәрнең эчтәлеген төпченеп ачуны бурыч итеп куймасам да, шул дүрт китапка кергән язмаларны махсус атап чыгып, аларның кайберләре хакында киңрәк фикер алышуны кирәк табам.

Ләкин шуны да искәртергә кирәк: әгәр минем күзәтүдә ул китаплардагы кайбер бәхәсле мәсьәләләргә тукталып, кайберләренә карата тәнкыйть сүзләре әйтелә икән, мин моның белән үзенчәлекле холыкка ия Т. Әйдине «төзәтүне» күз унында тотмадым. Минем максат бездәге юлъязма жанры янадан аякка баскан чорда барлыкка килгән үзенчәлекләрне генә билгеләргә омтылу.

Мин башлап укыган беренче китап **«Йөртә безне язмышлар»** дип атала *(Казан, «Аваз», 1999, 318 б.; алга таба «I, II... китап» дип тә күрсәтелер).* Китапка исем биргән беренче әсәргә «Алмания дәфтәреннән» дигән өстәмә баш куелган. Ул 1990—1991 елларда Германиядәге Ной-Үлм, Мюнхен шәһәрләрендә булып, шундагы милләттәшләрнең кайберләре белән очрашуларны, әңгәмә һәм бәхәсләрне, шул илдә үзе күргән гыйбрәтләрне тасвирлауга багышланган.

Беренче булып укылган әсәрдәге минем игътибарны җәлеп иткән сыйфатларның берсе—ул авторның үзе хикәя итә торган хәлләрне өстәмә әдәбият буенча да өйрәнә-өйрәнә тасвирлаган булуы иде. Ләкин юлъязма авторының төп информациясе, иң элек, үзе күреп белгән хәлләрне хәбәр итүдән гыйбарәт. Әле телгә алган «өстәмә әдәбият» мәгълүматлары исә шул үзе очраткан шәхесләр, алар хакындагы белешмәләрне тулырак, дөресрәк яктыртырга ярдәм иткән.

Әлбәттә, «Алмания дәфтәре»ндә кайбер дәлилләнеп бетмәгән хөкемнәр дә очраштыргалый. Юк-юк та автор фикерләренә зарар китерә торган бәхәсле раслаулар да күзгә ташлана. Болар хакында алга таба аерым сүз булыр.

**«Кечкенә дә төш кенә»** дип исемләнгән, Эстония сәяхәтенә багышланган икенче әсәр *(1, 174—186 б.)* миңа аерата ошаганы булды. Нәкъ менә шушы язмасында Т. Әйдинең югарыда бер күрсәтелгән сыйфаты—хикәя итә торган хәлләрне төпченеп өйрәнүе, кайбер мәсьәләләрнең асылына, «төп тамырларына» җитәргә омтылуы тулысынча диярлек гәүдәләнә. Әсәрнең 1976—1994 еллар арасында Эстония якларына берничә мәртәбә барып кайту, сәфәрләр арасында төрле белешмәләрне, эстон әдәбияты үрнәкләрен ныклап өйрәнүе һәм, иң мөһиме, шул халыкның кайбер вәкилләре белән якыннан танышуы нәтиҗәсендә барлыкка килгәнлеге ачык күренеп тора. Мәсьәләне дәвамлы өйрәнү исә авторның кайбер хөкемнәре үзгәрүне, төгәлрәк әйткәндә, аның фикри җәһәттән үсә төшүен дә тәэмин иткән. Мәсәлән, бер урында автор болай яза: «... баштарак монда һәрнәрсәгә сокланып, куанып йөрдем [...] Әмма килгән саен танышлык тирәнәю, тыштан әйбәт күренгән чынбарлыкның аскы катламында инде дәһшәтле үлек жыйналып, эстон милләтенең алдынгы вәкилләрен төн йокыларыннан мәхрүм итүен, аларның тормышын агулавын күрү мине дә айнытты» *(1, 222—223 б.).* Авторның фикердә һәм хөкемдә шулай үсә баруы, һичшиксез, игътибарга лаек күренеш...

**«Идел тамагында»** дип исемләнеп, Әстерхан якларындагы милләттәшләребезнең борынгы һәм бүгенге хәлләренә багышланган әсәр дә *(288—317 б.),* күләменең кечкенә булуына карамастан, 1976—1991 еллар дәвамындагы сәфәрләр нәтиҗәсендә язылган. Үзенең материалы буенча бу әсәр сәяхәтнамә жанры белән беркадәре тарихка, шулай ук бүгенге хәлләргә дә багышланган публицистик очерклар төре арасындарак тора. Минемчә, ил эчендәге сәяхәтләргә багышланган мондый катнашрак жанрлы язмаларның да әһәмияте бәхәссез. Югарыда бер әйткәнемчә, сәяхәтнамәләрдәге төп максат башка илләр, бүтән халыклар хакында хикәя итү өстенә үз илен, үз халкың хакында да уйлану, борчылу яки сөенүдән гыйбарәт. Димәк, язучының чит ил сәфәрләре белән бергә үз илендә төрле төбәкләрдә яшәгән милләттәшләренә дә юлъязмалар жанрында әсәрләр багышлавы табигый күренеш икән.

Мондый характердагы язмаларның күпчелеге, сигез-тугыз әсәр, **«Аһ, туган каумем газиз!»** дип исемләнгән икенче китапта урын алган *(Казан, 1999, 334 б.).* Гәрчә китапка исем биргән беренче әсәрдә *(3—94 б.)* сүз Көнбатыш Кытайда, Шәркый Төркестанда яшәгән татарлар хакында барса да, әсәрне чын-чынлап сәяхәтнамә дип әйтеп булмый. Дөресрәге ул китаплар уку, кайбер кешеләрдән сорашып-белешеп мәгълүмат туплау нәтиҗәсендә язылган тарихи-публицистик әсәр булып чыккан. Шуна күрә аны шартлы рәвештә «китаби сәяхәт» дип атарга мөмкин. Автор үзе күргән, өйрәнгән күренешләр хакында шәхси тәэсирләрен язудан, «жанлы» хөкем чыгарудан бигрәк, анар информация биргән китапларның, аерым кешеләрнең хәбәрләрен тәртипкә салырга, теркәп барырга тырышкан. Вакыт-вакыт аның башка кешеләрнең

хөкем-фикерләренә ияреп киткәләве дә шул хосусыяттан килеп чыккан.

Икенче китапта төп урынны, югарыда ишарә ителгәнчә, Үзбәкстанда, Себердә һәм Идел-Урал буйларында яшәүче татарлар хакындагы язмалар алган. Авторның үз милләте вәкилләренең нилектән шулай сибелеп-таралуы, яңа җирләргә барып төпләнгәч нәрсәләр белән шөгыльләнүе, кайберләренең хәзер нинди аяныч хәлдә калулары белән төпченеп кызыксынуы очерклар буенча кызыл җеп булып уза. Язучының үз күзләре белән күргәннәре, төрле чыганаклардан укып белгәннәре, бергә үрелеп үскән хәлдә, аның йөрәгә аша үткәрелгән. Шуна күрә вакыт-вакыт «үҗәт фактлар», нигезле дәлилләр белән янәшәдә сөенүле яисә борчулы хисләр дә бергә килсә, һич тә гаҗәп түгел. Чит өлкәләргә сәяхәтләр арасына үз республикасының кайбер төбәкләренә барып кайтулар да урынлы: чагыштырып караганда реаль чынбарлык яхшырак аңлашыла.

**«Оҗмах утравы»** дип исемләнгән өченче китаптагы *(Казан, 1999, 318 б.)* әсәрләрне, жанр күзлегеннән караганда, чын сәяхәтнамәләр дип әйтеп була. Аларда язучының 1984—1994 еллар арасында Болгариядә, Молдова һәм Румыниягә вә Кыбрыс-Кипр утравына ясаган сәяхәтләре, шул якларда күргән-белгәннәре шактый тәфсилле һәм кызыклы итеп тасвирланган. Әйтергә кирәк, бу әсәрләрендә дә Т. Әйди үзенең принципларына һәм язу, фикер йөртү стиленә турылыклы булып кала.

**«Гөлчәчәкләр илендә кара болыт»** дигән *(3—121 б.)* һәм «Дунай буендагы кардәшләр» (122—176 б.) дип аталган ике әсәрдә сүз Болгария һәм Румыниядә яшәүче татар вә башка төрки кавемнәрнең кыскача узган тарихлары, бүгенге хәлләре хакында шактый тәфсилле язылган мәгълүматлар тупланган. Дөресен әйткәндә, бу язмаларны укуы файдалы да һәм авыр да булды. Чөнки моңарчы бездә аз мәгълүм Болгария һәм Румыния (Добруджа) татарлары хакында күбрәк, киңрәк белүе күңелле булса да, шул «Халык республикалары» дип олыланган «тугандаш социалистик илләрдә» аз санлы милләтләргә карата уздырылган геноцид сәясәте белән якыннан танышу җиңел түгел иде. Вакыт-вакыт Тәүфикъ Әйди китергән (башка яклап та раслана торган) фактлардан, кем әйтмешли, йөрәкләргә кан саварлык булды. «Иң алдынгы социаль төзелеш»кә дәгъва иткән илләрдә йөз биргән мондый күренешләр төрле яклап уйланырга мәҗбүр итә. «Югарыга карап фикер ит, түбәнгә карап шөкер ит»,—дигән мәкаль дә искә төшкәләде. Бер үк вакытта милли сәясәттәге мондый коточкыч модельнең үрнәген иң элек кем барлыкка китерде, кем күрсәтте дигән сорау да уйландырды.

**«Исәнме, Гагаузстан»** дигән язмада *(177—253 б.)*, автор дөрес билгеләгәнчә, сүз моңарчы безгә аз таныш булган төрки кавем хакында бара. Аннан шактый мул һәм кызыклы мәгълүмат алырга мөмкин. Ә инде китапка исем биргән «Оҗмах утравы»нда *(254—317 б.)* кайчандыр Кипр-Кыбрыс утравына барып төпләнгән, бүген исә сәер генә сәяси һәм иҗтимагый шартларда үзенчә гөрләп яши торган төрекләрнең һәм кызыклы, һәм гыйбрәтле хәлләре шактый киң колач белән тасвирланган.

Бу китаптагы язмаларда да Т. Әйди күп кенә мәсьәләләрне, үзенә хас булганча, җентекләп тикшереп, өйрәнеп яктыртырга тырышкан. Шуңа да игътибар итәргә кирәк: соңгырак елларда ясаган сәяхәтләрендә авторның элекке наиврак хөкемнәреннән арына төшкәнлеге сизелеп тора. Дөрес, кайбер борынгы чор тарихына кагылганда... Хәер, бу хакта да алга таба махсус сүз булыр.

Күрсәтелгән өч том белән танышкач, миндә алар хакында фикер язу теләге туган иде. Тик сәяхәтнамәләрнең дүртенче китабы да басылып ятуын ишеткәч, сүз әтрафлырак әйтелсен өчен, анысын да көтәргә булдым. Һәм ул чыннан да көтәргә лаек китап булып чыкты. **«Кардәшләр кочагында»** дип исемләнгән том *(Казан, 2000, 381 б.)* тулысы белән 1992—1993 һәм 1999 елларда Төркиягә оештырылган сәфәрләр вакытында туган тәэсирләргә багышланган. Сәфәрләрнең кат-кат булуы, авторның күп җирләрне гизеп, күп кешеләр белән очрашуы һәм иң мөһиме, һәр очракта диярлек үзе кагыла торган мәсьәләләр буенча киңрәк мәгълүмат туплавы һәм шулар хакында укучыларга күбрәк хәбәр итүгә омтылу сыйфаты Т. Әйдинең бу китабы өчен дә характерлы.

Шул ук вакытта авторыбыз кайларда булуы, кемнәр белән очрашуы,ниләр хакында сөйләшүләре турында хәбәр итү, ягъни сәяхәт маршрутын тасвирлау белән генә чикләнми. Бәлки ул Төрки дәүләтенең, төрек халкының ерак һәм якын узганына да, бүгенге хәленә дә әзлекле рәвештә туктала-туктала укучыларына әтрафлы белем бирергә тырыша. Һәм, әйтергә кирәк, теләкләренә ирешә дә. Чөнки бу китапны укып

чыгу процессында Т. Әйдинең кайларда булуы, нәрсәләр күрүен генә түгел, ул тасвирлый торган илнең, халыкның, кешеләрнең нәсел һәм асыллары белән хәзерге шөгыль һәм хәлләре хакында да киңнән мәгълүм аласын.

Җыеп әйткәндә, язучының бу китабы да, кулъязма тибындагы элекке әсәрләрендәге кебек үк, башкаларны да, үз-үзенне дә танып белү, аңлау өчен кирәкле, зарур фактлар, мәгълүматлар белән шыплап тутырылган. Хәтта миндә кайбер очракларда: андый хәбәрләр, фактлар кирәгеннән артыграк күләмдә бирелмиме икән?—дигән сәер сорау да туып куйгалады.

Хәер, укылган әсәрләрнең башкаларына карата да булган иде мондый сәер сораулар. Белем өчен кирәкле фактларның бер вакытта да «артык» булмавын аңлаган һәм таныганым, хәтта шуңар ышанганым хәлдә дә! Чөнки артык май боткадан күңел кайтарган кебек, әдәби әсәрдәге «артыклык та» бик үк мәгъкуль нәрсә түгел икән. Мәсьәләнең эстетик җәһәте дә бар бит әле...

Сәер сорауның, минемчә җавабы да еракта ятмый шикелле. Чынлыкта ул фактларның күплегеннән түгел, бәлки бер типтагы ситуацияләрнең, тема һәм мотивларның кабатлануыннан, әсәрдән әсәргә күчә баруыннан, шуларның үзара охшашрак фактлар белән дәлилләнүеннән килеп чыга торган эффекттан гыйбарәт. Мәсәлән: бездәге милли-мәдәни хәл һәм «аларда» шуңа охшаган яки башкача булган вәзгыять; бездәге гомум ярлылык—«алардагы» муллык, байлык; бездә хөкем сөргән ирексезлек—«алардагы» хөрлелек; бездә китап-журнал чыгарудагы кысанлык—«алардагы җинеллек» ише гомумән милли язмыш мәсьәләсе фонында бирелгән шундый антитезаларның еш кабатлануы нәтиҗәсендә килеп чыга торган тәэсиргә кайтып кала ул кабатлану эффекты.

Күрәсең, ул очерклар, кулъязмалар аерым-аерым басылып, бер-берсенә бәйсез рәвештә укылган чакта мондый бертөрлелек, кабатлану күренеше сизелмәс тә иде. Ләкин бер китапка кергән өч-дүрт әсәрне һәм тема, мотивлар, хәтта теләк-омтылышлар буенча үзара «кардәш» өч-дүрт томны берьюлы укыган вакытта әлеге кабатлану һәм «артыклыклар» үзләрен ныграк сиздерәләр.

Кыскасы, бер зур проблематикага багышланып, янәшә томнарда басылган әсәрләрне җыелма рәвешендә нәшергә әзерләгән чакта аларны җентекләп укып, махсус редакцияләп һәм кыскартып чыгу эше башкарылмаган икән. Моны текстларның профессиональ редакторлар (һәм башка кешеләр!) кулыннан сыналып, үлчәнеп узмыйча, «гаилә подряды» рәвешендә үзешчән нәшрият тарафыннан чыгарылуның объектив нәтиҗәсе дип бәяләргә кирәк. Әгәр профессиональ язучы Тәүфикъ Әйди, редактор буларак, башка берәр авторның шундый томнарын басмага әзерләсә, андый житешсезлекләргә бер дә юл куймас—кабатлануларны кыркып барыр иде. Ә үз-үзенне кискәләве, әлбәттә, җинел эш түгел шул...

Китапларның «гаилә подряды» белән үз көченә таянып басылуында уңай күренешләрнең барлыкка килүен дә онытмыйк. Әгәр рецензияләнә торган әсәрләрнең язмышлары бюрократик метастаздан буылып ятучы дәүләт нәшриятларына тапшырылган булса, аларның дөнья күрүенә, иң кимендә, дүрт-биш ел вакыт кирәк булыр иде...

Кулъязма һәм очеркларда, кызганычка каршы, дөрес үк булып җитмәгән, әсәр сыйфатына, автор дәрәҗәсенә беркадәре зарар да китерә торган бәхәсле хөкемнәр, урынсыз «сузып-тартулар» да очраштыргалый. Андыйларның һәммәсен санап тормыйча, кайбер мисаллар белән генә чикләнәм.

Мине иң нык гаҗәпләндергән һәм сагайткан нәрсә—ул Т. Әйдинең вакыт-вакыт «сенсация» тәэсиренә бирелеп, кайбер тарихи күренешләрне ясалма рәвештә аяктан башка әйләндереп кую шаукымына ияргәләве. Мәсәлән, Морат Аҗи сүзләренең күп өлеше гел урынсыз һәм әрсез дәгъвалардан, бармактан имелгән оятсыз ялганга корылган раслаулардан гына тора (шуларны кабатлау бар, 2, 30, 31 б. ). Ярар, әлеге бәндә раслаганча, дин белән дәүләтчелекне дә, тел белән язуны да, «зәңгәр күз белән сары чәчне» дә һәм гомумән барлык мәдәни өстенлекләрне дә Аурупа халыкларына, җөмләдән немесләргә дә, кыпчаклар биргән дип «кабул иттек», ди. Алайса, шул кыпчакларның турыдан-туры варислары дип исәпләнгән комыклар белән карачай-балкарларның, нугай һәм казакъларның үзләрендә әлеге «нигъмәтләрдән» нигә бер нәрсә дә калмаган, сакланмаган икән?!

Үз кавеменнән, үз ата-бабаларыннның яхшы исеме, дөрес дәрәҗәсе өчен

горурлану, кайгырып яшәү яхшы омтылыш, әлбәттә. Ләкин каш ясыйм дип күз чыгарырга да ярамас. Әйтик, кайчандыр зур мәдәнияткә ия булып, башка халыкларга унай йогынты ясаган кавемнең үзе соңрак шул байлыктан бернәрсә дә, хәтта «зәңгәр күз белән сары чәчне дә», ичмасам, әзрәк кенә булса да, саклый алмавы өчен ана нинди бәя бирергә?—Шалкан бәясе, әлбәттә...

Кыскасы, урынсыз шапырыну, юк-барны дәгъва итү ата-бабаларны күтәрү урынына, аларны мыскыллау һәм хурлауга китерәчәк. Мәсьәләнең тышкы кабыгына, өстә йөзеп йөргән буш күбегенә түгел, бәлки асылына карарга кирәк. Әлбәттә, тарих дигән белемнең күп очракта ярты ялган белән ярты дөреслек дигән ике өлештән торуы мәгълүм нәрсә. Ул аның хәтта табигый сыйфаты да. Тарих өлкәсендә намуслылык һәм намуссызлык төшенчәсе дә бар. Һәм ул әлеге ике өлешнең кайсы ягына күбрәк авышу белән билгеләнә. Соңгы елларда чәчәк атып киң таралган фальсификацияләр җөмләсеннән булган «Кыпчак кыры әреме» ише нәрсәләр исә элекке «яртылашларны» бер читкә ташлап, тарихи белемне миф-экиятләргә әверелдерү омтылышыннан туган нәрсә генә. Дөрес, андый әсәрләрнең шактый сәләтле каләм белән оста итеп язылганнары да була. М. Аҗинын китабы шундыйлардан. Ләкин миф белән әкиятнең оста язылуыннан, матурлыгыннан гына чыгып, тормыш, реаль чынбарлык нәкъ шундый булган, дип әйтмибез бит! Кырлай урманыннан шүрәле дә эзләмибез...

Китапларның Идел буе, Кыбрыс һәм Анадол җирләренең борынгы тарихларына караган кайбер сәхифәләрендә автор, башкаларга ияргән рәвештә, тарихи күренешләрне ясалма рәвештә борынгылату, яки тарих битлеген кигән, тик бармактан имелгән яңа заман мифләренә урын биргәли *(мәсәлән, I, 291 б., III, 261 б. һәм IV, 9 б. һ. б.)*. Сизелеп тора, мондый очракларда, омтылышлары белән асылда кырыс реалист булган автор, әлеге раслауларга үзе дә ышанып бетми кебек. Ләкин ни өчендер күчерә аларны... Минемчә, мондый алым белән шаярудан китапның төп һәм дөрес өлешләре дә, авторның дәрәҗәсе дә отмый, бәлки оттыра гына.

Китапларда китерелгән материалларның дөреслек мәсьәләсенә мин монда очраклы гына кагылмыйм. Т. Әйди йөргән җирләрнең, илләрнең шактыеннан үзем дә узган, андагы шартларны ярыйсы гына белгән һәм ул очрашкан шәхесләрнең дә зур өлеше белән үзем дә таныш кешеләрдән буларак, шуны өздереп әйтә алам: юльязма һәм очеркларда китерелгән мәгълүматларның, фактларның төп һәм зур өлеше (кимендә йөзнең туксаннан артыгы дип әйтерлек өлеше) тарихи һәм бүгенге дөреслекне яктырта. Шуңа күрә югарыда күрсәтелгән кебек «бетчәләрнең» сәяхәтнамәләргә килеп керүе ярты кашык дегетнең бөтен бер мичкә балга янавы кебегрәк тәэсир калдырды миндә.

Чит-ят җирләрдәге милләттәшләреннән кайберләренең кыен хәлләре хакында язучының көенүе, икенчеләренең төрле казанышлары өчен сөенүе, горурлануы табигый күренеш. Тик кайбер очракта татарлык белән генә горурлануның чамадан чыгып, гел бер якка салулавын да күрергә мөмкин. Мәсәлән, Кытайга барып чыгып, анда искитәрлек зур дәрәҗәләргә ирешкән Борһан Шәһиди (Шаһидуллин) турында язганда Тәүфикъ минем «Ябылмаган китап»тагы кайбер фикерләремә карата ризасызлык белдереп, Б. Шәһидине татар булганы өчен генә яклау юлына баскан *(II, 37—38 б.)*. Аның тәнкыйть итәргә омтылуыннан китапның да әчтәлеге үзгәрми, минем дә укам коелмый. Ләкин бер принципиаль мәсьәләне ачыклау зарур: зур дәрәҗәләргә ирешү юлында теге яки бу шәхес (безнең татар кешесе) башка кешеләрнең, башка халыкларның мәнфәгатьләренә файда эшләгәнме, әллә зарар китергәнме? Миндә нәкъ менә шундый сорауга җавап бирелгән. Борһан Шәһиди исә уйгыр халкының милли-азатлык көрәше тамырларына балта чаба-чаба зур дәрәҗәләргә ирешкән кешеләрнең берсе. Татар булганы өчен генә моңа күз йому гаделлеккә илтмәстер, шөт. Ә инде Тәүфикъ Әйди әңгәмәләшкән уйгыр кешеләренең әлеге факт хакында әйтеп тормауларын дөрес аңларга кирәк. Беренчедән, мондый тактлылык күрсәтеп, уйгыр зыялылары татар халкына карата булган үзләренең тулаем ихтирамын саклаган. Икенчедән, алар, Б. Шәһидинең, ул никадәре югары дәрәҗәләргә менсә дә, ахыр чиктә Маочылар кулында марионетка—уенчык кына булганлыгын да истә тотканнар. Һәрхәлдә, Т. Әйдинең, бу мәсьәләгә кагылганда, минем китапның тиешле битләрен өстән-өстән генә карап чыкканлыгы, мәсьәләнең асылын аңламавы сизелеп тора (өстән генә карауга тагын бер мисал-дәлил: минем

язмаларда КГБ мөнәсәбәте белән сүз Мәргуб хакында түгел, бәлки Әсгать Исхаков турында бара).

Юльязмалар белән очеркларның кайберләрендә укучыларның беришеләрендә ризасызлык һәм бәхәсләр тудыра торган, әмма, минемчә, үзем өчен аңлаешлы, тагын бер мәсьәләгә тукталыйк. Ул Т. Әйдинең чит илләрдәге, бигрәк тә Алманиядәге күп бүлмәле фатирларны, андагы келәмнәр, кәнәфиләр белән башка затлы җиһазларны, шулай ук гаилә саен ничә машина булуын тәфсилләп, вакыт-вакыт артык мавыгып тасвирлавына карата булган мөнәсәбәт. Безнең укучыларда мондый юлларны укыган чакта ризасызлык тууы табигый хәл: без, беренчедән, гел үзебезне мактарга, үзебезне генә шәп торучы дип исәпләргә күнеккән халык; икенчедән, үзеннән башкалар, бигрәк тә «череп таркалган капиталистик илләр» белән чагыштырганда начаррак яшәвеңне белүе дә психологик җәһәттән күңелле түгел. Мондый очракларда акылга караганда хис алдарак йөри...

Ләкин Тәүфикъ китергән материаллардан совет тәрбиясендә үскән безнең ватандашлар гына түгел, бәлки әлеге мул тормышлары, бай җиһазлары тасвирланган алманияле татарларның кайберләре дә канәгать түгел икән. Мәсәлән, Алманиядә булган чакта, әңгәмәдәшләремнен кайберләре—язмаларның журнал варианты белән танышып өлгергәннәре—миңа: «Нигә ул кешенең милкен, байлыгын тикшерә соң?»—дигән кебегрәк сорау бирделәр. Мин аларга сәяхәтнамә дигән жанрның фәлсәфи табигатен, үз иле укучыларында фикер уятырга билгеләнгән булуын аңлатырга тырыштым. Тыңлавын тыңладылар, ләкин тулысынча канәгать булмыйча, «шулай да...» дип, сүзне башка темага бордылар. Әйе, чит илләрдә, бездән үзгә буларак, кыеклап кына булса да, кеше акчасын санаганны яратмыйлар. Хәтта, бик якыннан дуслашмасаң, хезмәт хакын сорауны да өнәп бетермиләр... Ләкин шунысы да хак: кайбер очракта безнең авторыбыз чыннан да чама хисен онытып җибәргәләгән.

Тәүфикъ Әйди китапларында моның ише бәхәс тудыруга сәләтле башка материалларны да анализлап булыр иде. Ләкин мин, моңарчы күрсәтелгән бәхәсле, кытыршы моментлар белән чикләнеп, ул әсәрләрнең файдалы һәм уңай сыйфатларына тагын бер кат игътибар юнәлтү белән бу күзәтүне тәмамларга теләр идем. Артык сузмас өчен андый өстенлекләрнең иң әһәмиятлеләрен санап чыгу белән чикләнәм.

**Беренчедән**, язмаларның һәммәсе өчен диярлек төрле характердагы мәгълүматларның, статистик белешмәләрнең күп һәм бай булуы характерлы. Бу хәл аларның кыйммәтен күтәрә.

**Икенчедән**, барлык әсәрләрдә диярлек игътибар үзәгендә иң элек кешеләр, шәхесләр торып, аларның рухи һәм эчке дөньяларын яктыртуга киң урын бирелгән.

**Өченчедән**, һәм, иң мөһиме, Тәүфикъ Әйдинең бу хезмәтләре белән (әйе, тулаем алганда, баш хәреф белән аталырга лаеклы Хезмәт башкарылган) бездә монарчы татарлыкка карата хөкем сөргән тар карашны, ягъни милли даирәне бары республика кысалары белән чикләүгә—махсус юнәлтелгән идеологик киртәләрне җимерү эшенә саллы өлеш кертелә.

Кыскасы, җыеп әйткәндә, шактый күптән барлыкка килгән, заманында сизелерлек уңышларга ирешкән, ләкин вакыт-вакыт сүрелеп калган—татар әдәби вә иҗтимагый фикеренең мөһим төре, тармагы булган сәяхәтнамәләр һәм юльязмалар жанры соңгы елларда аякка баскан, ярыйсы гына тернәкләнеп өлгергән дип расларга мөмкин булса, шушы процесста Тәүфикъ Әйдинең үз урыны да барлыкка килгән икән.

Моның шулай икәнлеге киләчәктә тагын да ачыграк күренер...

**Миркасыйм ГОСМАНОВ,**
*академик*

## 6—ӘНГАМ (МАЛ–ТУАР) СҮРӘСЕ

**(Әнгам сүрәсе 165 аятьтән тора. Анда дөя, сыер, сарык, кәҗә кебек дүрт аяклы хайваннар турында сөйләнгәнгә күрә, Әнгам—Мал-туар исеме бирелгән.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күкләрне һәм Җирне яралткан, караңгылыкны вә яктылыкны бар иткән Аллаһка мактау вә дан. *(Шуңа да карамастан)* кяферләр Ана тиң зат дип, ялган тәңреләргә табына.

(Ике төрле яктылык турында сөйләнә. Көн яктылыгы, ут яктылыгы һәм кешенең күңелендәге яктылык, белем яктылыгы, Корьән яктылыгы. Караңгылык та нәкъ шулай: ике төрле була. Төн караңгылыгы һәм наданлык, көферлек караңгылыгы.)

**2.** Сезне балчыктан яралтып, соныннан әҗәлле иткән дә Улдыр. Аның хозурында тагын бер әҗәл *(Кыямәт көне)* бар һәм сез әле һаман *(Аллаһ кылганнарга)* шикләнәсез.

**3.** Күкләрдә вә Җирдә ул Аллаһ. Сезнең яшерен кылганыгызны да, ачыктан-ачык эшләгәннәрегезне дә белеп торучы, ни казансагыз шуны белүче.

**4.** Алар *(кяферләр)* Раббыдан нинди генә аятьләр килсә дә, йөз чөерделәр.

**5.** Шуңа күрә, үзләренә Хакыйкать *(Корьән)* ингәч, аны тиз генә ялганга чыгарырга тырыша башладылар. Ләкин аларның *(Корьәнне)* көлкегә калдырырга тырышулары турында хәбәр *(җәза)* тиздән киләчәк!

**6.** Үзләреннән элек килеп киткән ничәмә-ничә нәселләрне һәлак иткәнебез турында алар белмиләрмени? Юкса, без аларга сезгә биргән шартлар кебек шартлар бирдек, үзләренә Күктән мул итеп яңгырлар яудырдык, аяк асларыннан ермаклар агар иттек. Гөнаһлары аркасында, без аларны һәлак кылдык. Вә алардан соң да яңа токымнар барлыкка китердек.

**7.** Әгәр дә Без сиңа кәгазьгә язылган бер китап иңдереп, алар шул китапны тотып баккач:

—Бу сихер эшеннән башка нәрсә түгел,—диеп инкарь итәрләр иде.

*(«Корьән Җәбраил фәрештә аша Пәйгамбәребезгә иңдерелде. Ләкин иңдерелгән аятьләр китап хәлендә түгел иде. Пәйгамбәребез ул аятьләрне яттан өйрәтеп, кешеләргә тарата иде. Ләкин кяферләр исә ул аятьләрне инкарь итеп, аятьләрнең кәгазьгә язылганын күрергә теләделәр. Аллаһ Тәгалә аятьләрен Корьән хәлендә иңдергәч тә, кяферләр ышанмадылар. Чөнки аннан әүвәл Муса пәйгамбәргә язылган Тәүратны иңдергәч тә алар аңа ышанмады».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**8.** —Әгәр дә аңа *(Пәйгамбәр янына күзебезгә күренердәй)* берәр фәрештә иңдерелсә иде,—диделәр.—*(Без аңа ышаныр идек.)*

---

**Журнал өчен Рабит Батулла әзерләде.**

Әгәр дә Без шундый *(кеше күзенә күренә торган, тавышы ишетелә торган)* фәрештә төшергән булсак, әлбәттә, эш тәмам булыр иде, *(алар инде күз ачар дәрәҗәдә булмас иде).*

*(Ягъни Ахырзаман җитеп, бар да һәлак ителер иде, җавап бирер вакыт килеп җиткән булыр иде.)*

**9.** Әгәр дә Пәйгамбәрне без фәрештә итеп, янадан аны адәм сурәтенә кертеп иңдерсәк, янә дә шөбһәдә калган булыр идегез.

*(Пәйгамбәр ул—кеше. Шуңа күрә кяферләр: син дә безнең кебек гап-гади кеше, нигә әле без синең Аллаһ илчесе икәнеңә ышанырга тиеш?—ди. Әгәр Аллаһ фәрештәне кеше кыяфәтендә кешеләр арасына иңдерсә, кешеләр аны да гади кеше, дип уйлаган булыр иде. Кяферләр барыбер иман китермәс иде. Ни өчен соң Аллаһ Тәгалә фәрештәләрне үз кыяфәтләрендә иңдерми?—дигән сорауга җавап бик гади: фәрештәләр нурдан яралтылган, әгәр дә алар кеше күзенә күренә калса, кешеләр аңламас, аларны кабул итә алмас иде. Кешенең аңы ул төшенчәләрне кабул итәр дәрәҗәдә түгел, күрәсең. Аллаһ галәмнең бөтен серләрен ачып салса, кешелек акылдан язар иде. Электрон, нейтрино, квазарларны да бик тар даирәдә генә аңлыйлар, гади кешенең аңа башы җитми. Килер заман, алар гади халык өчен дә аңлаешлы булыр. Яки: бөтен халык шуны аңлар дәрәҗәгә үсеп җитәр.)*

**10.** Сиңа кадәр килгән пәйгамбәрләрне дә алар мыскыл итте, мыскыллаганнары кадәр алар җәзасын да алды. **(11)** Әйт син аларга:

—Дөнья буйлап сәяхәт итегез вә пәйгамбәрләрне «ялганчы» дип мыскыллаган бәндәләр белән ни булганын күрерсез,—диген.

**12.** Тагын әйт син аларга:

—Күкләрдәге вә Җирдәге нәрсәләр кемнеке?—диген.—Алар барысы да Аллаһныкы,—диген.—Ул рәхмәтле булуны Үз өстенә алды.

Һичшиксез киләчәк Кыямәт көнендә Ул сезне Үз хозурына туплаячак. Иман китермәгән кешеләр үзләренә үзләре зарар китерүчеләрдер. **(13)** Төнен дә, көндезен дә хәрәкәттә яшәгән барчасы Аллаһныкыдыр. Ул ишетеп, күреп торучыдыр. **(14)** Әйт син:

—Күкләрне, Җирне юктан бар иткән; ашатучы, ләкин Үзе ашауга мохтаҗ булмаган Аллаһтан башка бер затнымы Аңа тиң күрим?—диген һәм тагын әйт:—Иң беренче мөселманнарның алдынгысы булу миңа йөкләнде. Мөшрик була күрмә, диелде,—диген.

**15.** Әйт син:

—*(Хәтәр көннең, Ахирәтнең)* газабыннан курыкканга күрә, мин Аллаһка *(каршы)* гыйсъян итмим,—диген.

**16.** Кем ул Көнне газаплардан котыла, димәк, шул кеше Аллаһның рәхмәтенә лаек булган. Бу мотлакан *(абсолют)* котылыш булыр.

**17.** Әгәр дә Аллаһ сиңа бер бәла китерсә, Аллаһтан башка берәү дә ул бәладән сине коткара алмас. Әгәр Ул сиңа бер нигъмәт китерсә *(аны да берәү дә синнән тартып алалмас).* Хакыйкатән, Аллаһ һәрнәрсәгә кодрәтле.

**18.** Ул коллары белән идарә итә, һәрнәрсәгә хуҗа вә җиңүчедер. Ул хөкем хуҗасы вә һәрнәрсәдән Ул хәбәрдар.

**19.** —Иң яхшы шаһитлек нинди шаһитлек?—дип сора һәм болай җавап бир: Минем белән сезнең арагызда Аллаһ шаһит,—диген.—Бу Коръән сезне һәм балигъылыкка ирешкәннәрне кисәтер вә нәсихәтләү өчен миңа иңдерелде. Аллаһ белән бергә башка илаһларның да булганлыгынамы сез шаһитлек итәсез?—диген.—Мин *(ул эшкә)* шаһитлек итмим,—диген, тагын әйт:—Ул—бердәнбер Аллаһ. Мин Аллаһка тиңләштерелгән нәрсәләрдән ерак торам,—диген.

*(Мәккә халкы Рәсүлуллага: синең пәйгамбәрлегеңә шаһит юк, диделәр. Шуннан соң шушы аять иңдерелде.)*

**20.** Үзләренә китап иңдерелгән бәндәләр аны *(Пәйгамбәрне, Аллаһның хөкемнәрен)* үз угыллары кебек беләләр. Нәфесләренә юл куйган *(үзләренә зыян кылган)*нар исә чын кяферләр булыр.

**21.** Аллаһка каршы уйдырмалар сөйләүче, аятьләрен ялганга чыгаручылардан да залимрәк кем бар икән *(бу дөньяда?)* Шунысы хактыр ки, ул залимнәр *(җәһәннәмнән)* котыла алмас.

**22.** Ул Көнне аларның барысын да бергә туплаячакбыз. Сонра Аллаһка тиң башка тәңре эзләгәннәргә әйтәчәкбез.

—Сез уйлап чыгарган ул затларыгыз кайда соң?—диярбез.

**23.** Аларның:

—Раббыбыз Аллаһ исеме белән ант итәбез ки: без Синнән башка бөек зат эзләмәдек,—дип әйтүдән башка чаралары калмас.

**24.** Менә кара: алар ничек итеп үз өсләренә ялган өя вә уйлап тапкан *(табынган)* затлары аларны ташлап качты.

**25.** Алар арасында сине игътибар белән тыңлаганга салышучылар да бар, шуңа да карамастан, Без аларның күңелләренә, сине аңламасыннар дип, пәрдә кордык, колакларын да ишетмәс иттек. Хәтта һәр аятьне күреп торган килеш тә алар инанмыйлар. Алар синең янына сүз куертыр өчен генә килә вә:

—Һәй, бу *(Корьән аятьләре)* борынгылардан калган әкиятләр генә бит,—дип сөйләнәләр.

**26.** Алар кешеләрне пәйгамбәргә *(ул өйрәткәннәргә, Корьәнгә)* якынлаштырмаска тырыша, үзләре дә аннан *(иманнан, Хакыйкатьтән)* ераклаша. Шулай итеп алар үзләрен һәлакәткә илткәннәрен үзләре дә белми.

**27.** Тәмуг уты янына килгәч, аларның ни кыланганнарын күрсән!

Алар:

—Их, фани дөньяга кире кайтсак иде дә, Раббыбызның аятьләрен ялганга чыгармас идек, мөселман булыр идек,—дип үкенерләр.

**28.** Элек яшертен генә кылганнары *(гөнаһлары)* бүген ачылды. Әгәр дә аларны фани дөньяга кире кайтарсаң, алар барыбер ярамаганны кылыр иде, чөнки алар асылда ялганчы.

**29.** Мөшрикләр:

—Дөнья тормышыннан башка тормыш юк, үлгәннән соң янадан терелү дә юк,—диләр.

**30.** Аллаһ хозурына китерелгәннән соң *(Кыямәт көнне)* аларның ни кыланганнарын күрсән икән! Аллаһ аларга:

—Хакыйкатькә инандыгызмы инде? *(Ягъни, яңадан терелүгә)*—дигәч, алар:

—Әйе! Ант итәбез ки, Раббыбыз,—дип әйтерләр.

Аллаһ аларга:

—Алайса, *(дөньяда чакта Аллаһны, Корьәнне, Пәйгамбәрне, Ахирәтне)* инкарь иткәнегез өчен хәзер җәзагызны татыгыз,—дияр.

**31.** Кинәт кенә кыямәт көне килеп җиткәнгә кадәр Аллаһ хозурында тереләчәкне ялганга чыгарганнар бик тә мөшкел хәлдә калачак, кылган гөнаһлары аларның сыртына өеләчәк, алар *(шул авыр йөкне күтәргән килеш):*

—Аһ, фани дөньяда кылган гөнаһларыбыз-хаталарыбызны каһәр суксын!—дип үкенәчәкләр.

Белеп торыгыз, аларның йөге нинди яман бер йөктер.

**32.** Фани дөнья хәяте ул вакытлыча алдавыч бер уен гына. Ахирәт хәяте исә *(гөнаһ эшләүдән курыксыннар өчен)* бик тә хәерле. Сез шул кадәресен дә аңламыйсызмыни соң?

**33.** Ий, Мөхәммәд, алар сөйләгән нахак сүзләргә көенгәненне дә белеп торам; ни генә кылансалар да, алар асылда сине ялганчы дип әйтә алмый. Ул залимнәр Аллаһның аятьләрен инкарь итә.

*(«Мөхәммәд Пәйгамбәргә Әбү Җаһил: без сиңа ялганчы, димибез. Чөнки синең никадәр гадел, тугры кеше икәнлегеңне барыбыз да яхшы беләбез. Без бары тик Аллаһның аятьләренә генә ышанмыйбыз, аларны инкарь итәбез,—диде».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**34.** Синнән алда килгән пәйгамбәрләрне дә алар ялганчыга чыгарырга маташтылар. Аллаһтан ярдәм килгәнгә кадәр, алар *(кяферләрнең)* ялганчы, дип әйтүләренә һәм җәберләренә сабыр иттеләр. Аллаһ сүзләрен үзгәртергә беркемнең дә хакы юк. Хактыр ки, *(башка пәйгамбәрләргә)* күндерелгән хәбәрләр, әлбәттә, сиңа да килеп ирешә.

*(Ягъни, башка пәйгамбәрләрнең ничек интегүләре, аларга җәфа чиктергән кяферләрнең Аллаһтан нинди җәза алулары турындагы хәбәр.)*

**35.** Әгәр аларның синнән йөз чөерүе сине хафага салса, *(Аллаһ илчесе икәнеңне исбатлар өчен)* син Җирне ярып чыгар идең яки Күктән аятьләр алып төшәр өчен, биек бер баскыч ясар идең, шундый могҗиза эшләсәң дә, алар сиңа һич тә ышанмаган булыр иде. Әгәр Аллаһ ихтыяр итсә, әлбәттә, аларны бергә туплап, тугры юлга бастырган булыр иде дә... Син сак бул, җаһилләрдән булма.

*(«Бу аятьтән күренә ки, могҗизалар ясау пәйгамбәрләр кулыннан килми икән. Пәйгамбәрләр могҗиза эшләргә бик теләгән чакларда, Аллаһ аларга могҗиза күрсәтү форсаты бирә. Ләкин һәрвакытта да түгел».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**36.** Саф күңелдән *(иманга)* бирелгәннәр генә *(Аллаһның)* чакыруын кабул итә ала. Үлгәннәр дә, Аллаһ аларны яңадан терелткәч, Аллаһ хозурына кайтарылачак.

**37.** —Пәйгамбәргә Аллаһтан бер могҗиза иңдерелсә иде,—диделәр. Әйт син:
—Могҗиза иңдерергә Аллаһның кодрәте киң,—диген. Ләкин аларның күбесе *(могҗиза артыннан үзләренә афәт киләчәген)* белми.

**38.** Җир йөзендә сезнең кебек өммәт булып яшәмәгән һичбер хайван вә Күк йөзендә канатлары белән очкан һичбер кош токымы юктыр. Китапны кимчелекле итмәдек. *(Анда барысы да язылган, бернәрсә дә төшереп калдырылмаган.)* Соңра барысы да кубарылып, Аллаһ хозурына кайтарылачак.

*(«Өммәт» дигән сүз бу очракта хайваннарның да, кош-кортларның да кешеләргә охшаганлыклары турында сөйли. Хайванат та, кошлар да кешеләр кебек ук, төркемнәр, көтү, чирү булып яши, ашый-эчә, курка, үрчи, үлә.)*

**39.** Аятьләребезне ялганга чыгарырга тырышучылар дөм караңгылыкта калган телсез-чукраклар кебек. Аллаһ ихтыяр итсә, теләсә кемне саташтыра, теләгәнен тугры юлга чыгара.

*(Коръәнне белмәгән, Аллаһны инкарь иткән кешеләр дөм караңгыда калган, тома сукыр, телсез-чукрак кебек яши, аларның маңгай күзләре күрә, әмма аларның күңел күзләре сукыр.)*

**40.** Ий, Мөхәммәд, әйт син:
—Әгәр дә сез хаклы икән, сезгә Аллаһның җәзасы килсә яки кыямәт килеп, якагыздан тотса, шулвакыт Аллаһтан башка берәүнеме ярдәмгә чакырырсыз?—диген.

**41.** Рас, сез Аңа ялварыгыз, Ул да теләсә, сезне бәлаләрдән коткарыр һәм сез үзегезнең уйдырма тәңреләрегезне онытырсыз.

**42.** Хактыр ки, синнән алда килгән өммәтләргә дә Без пәйгамбәрләр җибәрдек һәм *(ул өммәтләрне дә)* без җәфаларга, кайгыларга салдык, *(ичмасам, шул җәзалардан соң алар Аллаһка)* буйсынырлар, дип. **(43)** Аларга газаплар җибәргәннән соң Аллаһка ялварсыннар иде, ичмасам. Ләкин аларның күңелләре каткан иде инде, шайтан аларның кылмышларын гүзәл итеп, бизәп күрсәтте *(яман эшләрен яхшы, дип ышандырды).*

**44.** Кисәтеп әйтелгәннәрне *(ягъни, Аллаһ вәгазьләрен, гөнаһ эшләүдән куркуны)* онытсалар да, дөньяви эшләрендә *(Без аларга)* киң мөмкинлекләр бирдек. Хәтта алар Аллаһ биргән байлыкка шатланып, мактанып яши башладылар. Ләкин Аллаһка шөкер

итәргә, гыйбадәт кылырга оныттылар. Шуна күрә, Без аларны кинәттән тотып, җәза бирдек. Алар өметсезлеккә төшеп, кайгыга баттылар.

**45.** Шулай итеп, золым итүче нәселнең тамыры киселде. Галәмнәрнең Раббысы Аллаһ кына мактауга лаектыр.

**46.** Әйт син:
—Аллаһ сезне саңгырау итсә, сукырайтса, күңелләрегезне томалап куйса, бу бәлане Аллаһтан башка нинди тәңре кире алыр икән?—диген.
Уйлап бак: Без нинди төрледән-төрле дәлилләр китерәбез, әмма барыбер алар *(аятьләребездән)* йөз чөерә.

**47.** Янә дә әйт син:
—Аллаһның җәзасы кинәттән яки күз алдыгызда сезнең өскә килеп төшсә, кяферләрдән башкалар да һәлак булачакмы, дигән уй башыгызга килдеме?—диген.

**48.** Без пәйгамбәрләрне *(җәннәт турындагы)* сөенечле хәбәрне әйтер өчен яки *(җәһәннәм барлыгы турында)* кисәтер өчен генә күндерәбез. Иман китергәннәргә вә тугры юлга басып төзәлгәннәргә *(алда)* куркыныч юк, аларга кайгы иңмәс.

**49.** Аятьләребезне ялганга чыгарырга маташканнарга, әшәке гамәлләре аркасында, җәза бирәчәкбез.

**50.** Әйт син:
—Мин сезгә: Аллаһның хәзинәсе минем кулда, димим. Яшерен серләрне дә беләм, дип әйтмимен. Мин—фәрештә, дигән сүзне дә сезгә әйтмәдем. Мин бары тик үземә иңдерелгәнгә генә инанамын,—диген.
Тагын әйт:
—Сукыр белән күзле бер булырмы? Шул турыда һич тә уйлап бакмадыгызмы?—диген.

*(«Аллаһның хәзинәсе Мөхәммәд Пәйгамбәр кулында булса, ул үз ихтыяры белән кешеләргә байлык өләшә алган булыр иде, яшерен серләрне белсә, һәр сорауга җавап бирер иде, фәрештә булса, адәми зат кыла алмаган могҗизалар күрсәткән булыр иде. Юк, пәйгамбәрләр—адәми зат, алар Аллаһ рөхсәт иткәннәрдән гайре, башка эш майтара алмый.*

*Мөшрикләр Мөхәммәд Рәсүлуллага, син Аллаһ тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәр булсаң, Аллаһыңнан ялварып сора да, ул безгә мул итеп байлык бирсен. Шуннан соң без синең Аллаһ илчесе икәнлегеңә ышанырбыз, диделәр.*

*Шуннан соң шушы аять иңдерелде. Һәм Аллаһ теләгәргә мул итеп нигъмәт бирде. Аларны баетыр өчен түгел, Мөхәммәднең Пәйгамбәр икәнен исбатлар өчен шулай кылды».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**51.** Раббы алдында *(җавап бирергә)* тупланачакларын белгәннәрне шушының белән *(Корьән белән)* үгетлә, кисәт. Аларга ул вакытта Аллаһтан башка яклаучы дус булмас. Бәлки алар *(акылга килеп)* иман китерер, тәкъва булыр.

*(«Кураешның бай мөшрикләре Мөхәммәд Пәйгамбәргә: әгәр дә син яныңнан фәкыйрьләрне кусаң, без сиңа ияреәчәкбез,—диделәр. Аларның сүзенә карап, хәзрәти Мөхәммәд фәкыйрьләрне үз яныннан кумак булды. Менә шуннан соң илле икенче аять иңдерелде»).*

**52.** Раббының ризалыгын яулар өчен, кич-иртән Аллаһка ялварганнарны *(намаз укыганнарны, фәкыйрь булсалар да яныңнан)* кума. Алар кылганга—син, син кылганнарга алар җаваплы түгел. Аларны кусаң, син дә залим булырсың.

صدق الله العظيم

*Дәвамы киләсе санда*

## *Һади Такташның тууына 100 ел*

# ҮЗГӘРМӘЯЧӘК МӘХӘББӘТ СҮЗЕ

ЭССЕ

*Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны*
*Егълатырга... Әйе, миндә көчле Байроннар җаны.*

Һ. Такташ

Башта ук шул сораудан башлыйк әле. Кем ул бүген, нәкъ менә яңа гасырга кергәндә, 100 еллыгы бәйрәм ителә торган шагыйрь Һади Такташ? Әйе, кем ул безнең өчен—хәзерге бик тә катлаулы дәвердә—егерменче йөзнең авыр, чишелмәгән мәсьәләләрен тулаем диярлек егерме беренчегә алып килгән, милләт, халык язмышы үзе дә (ничәнче кат инде!) кыл өстендә торган, гүяки әлеге инкыйраз котылгысыз булып алга баскан чорда—өченче меңъеллык башланганда?... Әмма ... әмма диик, бу сорауга җавап биргәндә, без үзебезнең дә әле яңа узган, димәк, тулаем Такташлы гасыр кешесе булуыбызны онытып җибәрмибезме? Әйе, безнең өлешкә—әле исәннәргә тигән кайсыдыр ки, илле, алтмыш ... җитмеш еллык гомерләр—әлбәттә, бик күп, ул—Тукайлар, Бабичлар, Такташларга бирелгән кыска вакыт белән чагыштырганда, чамасыз озындыр. Бәлки, бөекләребезнең зур исемнәре, шанлы гомерләре янында безнекеләр—Такташка тирән мәхәббәт саклаучы олуг бер замандашыбыз әйткәнчә, «озын-озак балачак» кынадыр? Әмма без бер генә даимдә дә алардан аерылмадык, рухан бергә тоташып яшәдек бит! Хәзер дә, киләчәктә дә шулай булачак дип беләм...

Әле кичә генә кебек: Такташыбызның 90 еллык бәйрәмен уздырдык. Тинчурин театрында булган тантаналы кичәдә шагыйрь турында кереш сүз әйтү бәхете миңа тигән иде. Ул докладны Уфада да кабатлап, анда узган зур кичәдә чыгыш ясаган идем... Суверенлык өчен көрәш барган чорда, бөтен төбәкләрдә Татар иҗтимагый үзәкләре оешып, милли горурлык, үзаңның янә баш калкытуы, зур өметләрнең тагын чәчәк атуы вакытындагы кичәләр бу! Анда җитәкче даирәләр дә, совет чоры әдәбияты—инде мирасыбыз турында ярсып бәхәсләшә башлаган әдипләр дә, шагыйрьгә, шигърияткә гашыйклар да бердәм катнашты... Чынлап та, әле генә тоталитар системадан котылдык дип сөенгән, «фикердәге коллык җебен» өзә башлаган каләм ияләре, әһле зыялыларыбыз үзләренең милли көрәшендә дә Такташны—байрак (әлбәттә, беренче урында—изге исем саналган Тукаебыз йөрде!), аерым очракта, шагыйрь үзе язганча, «мишень итәләр» иде. Уфада узган әлеге кичәдән шагыйрь дустым Рим Идиятуллинның янып сөйләгәне хәтердә калган: «Такташ, хыялланып, язган, омтылган киләчәкне без төзи, күрә алмаганга ул гаепле түгел, ә без—үзебез... «Айга шлем кидер»мәдекме? Үзебезнең гаеп... Ә шагыйрь сүзе, хыялы, образлы күзаллавы, фаразы—ул мәңгегә изге, пакь... Аңа сүз тидерү, бүгенге үзгәрешләрдән чыгып, аны гаепләү, бу—кощунство... Әйдәгез, үзебезнең гаепләребезне үзебез күрә белик»—дигән иде ул.

Бу фикернең—Такташка мәхәббәт хисләребезнең бүген дә,—Казандамы, Уфадамы, йәки чит илләрдә, диаспорадамы булсын—халкыбызда һаман шулай үзгәрмичә дәвам итүен әйтсәм, моңа минем иманым камил! Такташ дисәм, студент чак, аның гашыйгы, «яклаучы»сы Хатип ага Госман күз алдыма килә. Профессорыбызның лекцияләре—шагыйрьгә мөкиббәнлек ташып торган ягымлы, ораторларча тәэсирле тавыш белән әсәрләнеп аны яттан укуы... Замандашы бит ул—аның кече каләмдәше. Икенче Хатип—яшь Миңнегулов

та минем «восторг»ка кушыла иде... Йәки—без әле ишетеп кенә белгән әдәби «скандаллар»! Сәбәпчесе—Такташның әле үзе исән чагындагы ук «оппонент»ы, үҗәт, кырыс, әмма зур талантлы, батыр рухлы, озын гомерле шагыйрь Салих Баттал, имеш! Һаман шагыйрь белән бәхәсләшә, үзенең элекке фикерләрен яклый, ди. Язучылар берлегендә моңа, Такташның шундый ук гашыйк замандашы, аңа тугры, усал Шәйхи Маннур, партком, һәм бәлки, обком сүзе белән «нокта куела» («Такташка хат»ы—С. Батталның соңгы бәхәсе булмады—ул аның атаклы «Батый ханга мөрәҗәгат»енә кадәрге сынау өчен куйган «мина»сы иде!). Билгеле, барлык язучылар Такташны «яклап чыкты»... без, студент шагыйрьләр дә—Равилләр, Шамилләр—»ревизия ясаучы»га, бердәм протест белдердек. Шулай булмыйча, Такташ бит ул, Такташ! Безнең хәтердә—дусты Хәсән Туфанның аңа багышланган мәгълүм циклы, соңрак язылган, икесенең Ф. Әмирхан белән көрешүләре, шагыйрьләр яшьлеге турында «кичке поэма»сы—«Могикан»... Ә. Фәйзи, Ф. Кәримнәрнең мәхәббәт-табыну тулы шигырьләре, Нур Баянның мәгълүм «Шагыйрь үлгәч» мәрсиясе, Ф. Хөсни, Ә. Еники истәлекләре... Сибгат ага Хәкимнең күпсанлы чыгышлары, мәкаләләре, Такташка тиң булырга омтылышлы горур юллары: «Безнең дә бит, дускай, бар томнар!»... «Очрашырбыз: «Фазыл чишмәсе»нә «Урман кызы» килер сукмактан»... Бездән, яшьрәкләрдән алай әйттермәсләр иде ул чорда—«ранг»лар инде күптән бүленгән 60-70 еллар бит бу! Хәер, без барыбыз да диярлек, Такташка шәкертләрчә мәхәббәт белдерүдән башладык ул елларда. Безгә кадәрге мәйданда—Гамил Афзал, Шәүкәт Галиләр, Х. Камал, М. Шабайлар шулай иде. Ә Илдар Юзеев? Аны хәтта Такташка иярүдә үк гаепләделәр башта; ә аннары традицияләрен дәвам иткән өчен озак мактадылар. Чыннан да ул—әле бүген дә дип уйлыйм!—аның иң тугры шәкерте, шигырьдә Такташ мәктәбенең иң тәртипле, әдәпле «пишкадәм»е булмады микән? Шундый ук рыцарь шагыйрь—Әхсән Баян иде, дисәм, сез аның «Кышкы чәчәкләр» поэмасын күз алдына китерерсез, мөгаен. Чор фаҗигаләре белән шагыйрь шәхесен, язмышын бәйләп, кыю фикерләр әйткән җитди әсәр ул! ... Ә безнең яшьлекнең Такташ эзләнүләрен, аның «бунты»н, шигырьдәге өслүбен, кабатланмас интонациясен үз итүе?!

Такташтан—Гаташка килгән изге нур, язмышның—мәрхәмәтле мәхәббәте ул минем өчен, шәхсән. Рәшит Әхмәтҗан, Гәрәй Рәхимдә дә бу шулай иде. Ә менә, гаҗәпме бу?!—яңача, ирекле шигырь башында торып, үз мәктәбен булдырган, бу юлда хәтта Такташ белән бәхәсләшеп тә алган шагыйрьләребездә дә Такташ рухы, интонациясе, аның омтылышлары, киңлек-колачы, күзаллавы, сүздә иркенлеге яши иде ләбаса! «Көрәшчеләр», «Гадиләргә гимн» (Р. Фәйзуллин), «Минем дәүләтем», «Күз карасы» (Р. Мингалим) кебек ирекле калыпта, иркен ритм—интонация белән язылган үрнәкләрдә Такташ сизелмимени? Йә—Ренат Хариста? Күптән түгел мин «ирекле еллар» буенча чордашым, тынгысыз җанлы, күпъяклы талант, гаҗәп уңган шагыйрь Айдар Хәлимнең бу мәсьәләгә багышланган «трактат»ын укып сөендем. Шулай! Ул да Такташны, С. Рәмиев, хәтта Дәрдмәнд белән бергә, (соңрак Ә. Давыдов эзләнүләрен дә онытмыйча) ирекле шигырь, ритмик-интонацион яңалык, димәк, яңа шигырь өчен көрәшүче элгәрләрдән берсе итеп санавын белдерә. 60 елларда! Ә бүген? Төрле үзгәрешләр, үсеш юлындагы котылгысыз тәҗрибәләр белән киләчәк яңа буын, яңа «дулкын» Такташсыз гына яши алырмы? «Юк!»—дим.

... Алдымда—шагыйрь әсәрләренең өч томлыгы, соңгы елларда басылып чыккан сувенир басма—«Җир уллары»; «Урман кызы» исемле бизәлгә мәҗмуга... Баш өстемдә—аның тирән уй, гамь белән өретелгән, ниндидер фаталь бер язмыш иясе икәнен әйтеп торучы фотосурәт күчермәсе. Аны шагыйрьнең кече улы Аван үзе миңа бүләк иткән иде... Шунда ук—гаҗәеп бер илһам белән сынчы Фәһим Фәсхетдинов эшләгән гипс бюсты—әйе, Такташ сыны, югары сәнгать әсәре, шагыйрь портреты. Шундый ук шагыйрәнә сурәтен җитмешенче елда рәссам Л. Насыйров ясаган иде: омтылышлы, дәртле, ялкынлы булуы, шигърилеге белән әсир иткән иде ул безне, яшь шагыйрьләрне! Һәм ул Тукай клубында, Актерлар йортында Такташка багышлап яшь иҗатчылар уздырган, Батулла атлы шулай ук тынгысыз зат, үҗәт, бай рухлы шәхес, күптөрле талантка ия әдип җитәкләгән-оештырган атаклы кичәләрне дә ямьләп торды. Әле дә күз алдында кебек!

«Мин Такташка ... һәм «акбаш»ка гашыйк», дип язды ул көннәрдә Зөлфәтебез; шагыйрьнең Уфадагы мәңгелек гашыйгы—зур талантлы Ә. Атнабай сүзләрен дә хәтердә яңартып. Ә. Рәшитов, Роб. Әхмәтҗан, Ш. Маннап, М. Әгъләм, Р. Миңнуллин, Р. Вәлиев, Л. Шагыйрьҗан, З. Мансуров, Р. Низами, Х. Әюп, соңра Г. Моратлар буыны да публицистик көчне, гражданлык үрнәген нәкъ менә Такташтан алдылар бит! Формаль яктан гына аңлап өйрәнүчеләр дә булды—һәм ул бүген дә бар. Һәм Такташны, шагыйрь буларак, инкарь итүчеләр дә очрый—бусы да гаҗәп түгел! Яңалыкка, яңа шәкел-фикергә омтылганда, үзен раслаганда, һәр яңа талант канатын киң җәеп, башкаларга орынып-тиеп алу табигый. Талант кына булсын! Ә вакыт... аяусыз, гадел хөкемдар—Вакыт барсын да үз урынына куя, сайлый, җайлый, оныттыра, йә хәтерләргә кире кайтара. Ул—Алла, иң зур көч!

Ә мин аны алтын чорыбызның егерменче гасыр башы корифейлары—газиз баганалары—Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, Гафури, Бабичлар белән бергә күрәм. Нәкъ менә шуларның—барсы да олпат, зирәк акыллы, философларча сабыр, горур, энциклопедик талант ияләренең, кабатланмас язмышларның, олуг шәхесләрнең иң лаеклы энесе, хаклы варисы—алардан соңгы чорны яңача җыр биеклегенә күтәрә алган әдип ул Такташ! Классик мираска безне ул ялгый һәм үзенең әлеге Алып агалары янында һич тә бәләкәй күренми, ул—аларның табигый дәвамы. Һәм ул үзенең кыска гомерендә шул чордан күчеп килгән исән агалары белән дә иңгә-иң торып язды, бергә кайнап яшәде: аның Г. Ибраһимов, М. Гафури, Камаллар белән мөнәсәбәте—үзе үк поэмаларга лаек тема... Яки Сәйдәшләр белән, Татар театры артистлары белән дуслык...

... Классик мираска ул ялгый, дидек. Һәм ул аннан безне аера да. Мең еллык мирасны үзләштереп, Шәрекънең иң затлы традицияләр мәктәбен үткәч, егерменче йөздә Гареп шигыре белән кушылуның биек бер ноктасына күтәрелгәч кенә... әллә Г. Ибраһимов сүзен тыңлап, нәкъ менә Такташ барлык «күперләрне яндыра»... Үзенең декларациясендә әйткәнчә, Бакырганидән алып Тукайгача килгән шигъри өслүб—форма җимерелергә тиеш... бүгенге шигырь—яңа чорның музыкасы булырга тиеш дип белдерә. Һәм менә шушы юлда өр-яңа шигырь системасы тудыруына ышанып, ышандырып яшәгән шагыйрь язмышы—үзе нинди поэма иде? Әллә трагедия идеме? Әллә унҗиденче елда исергән җан өчен бу табигый идеме?

Үтте еллар... эзләдем мин, эзләдем бер тугры дин.
Тапмадым, әмма югалттым бар иман, Алламны мин.

Үзенә кадәрге бөек талант—Бабич өзгәләнүләре, фаҗигасе кебек бит бу!

... «Ватаным Татарстан» газетасында Такташның җан дусты, ул чорда яңа шигырьгә юлдашы, көрәштәше Х. Туфанның бер хаты басылганын хәтерлим. Ул анда Такташтан соңгы утыз елдагы кичерешләре, зур афәтләрдә сыналулар тәҗрибәсе күзлегеннән чыгып: «без ул чорда Тукайдан, халыкчан традицияләрдән китеп нык ялгышканбыз»—дигән нәтиҗәгә килә. Бу—үткәнгә кабат кайтып тирәнтен уйлану иде. Әмма егерменче еллар башында Такташ, Туфан, Кутуй, Нәҗмиләр—башкача була ала иделәрме? Алар урынында без булсак? Юктыр. Яңа шартларда, яңа тормыш, яңа матурлык өчен яңа шигырь кирәк дигән шарт—революциянең иң беренче атрибутыннан иде. Такташ та шуны сөйли:

Кичәге матурлык бүген үлсә,
Бездә туа аның яңасы.
Безнең тупас куллар—киләчәктә
Туар матурлыкның анасы...

Инде иске дөнья мәңге кайтмаячак, хәзер мәңге үзгәрмәс яңа тормыш, яңа иман килде дип ышанган һәм шул чорның җырчысы булырга тиешлеккә чын-чыннан (әйе-әйе!) инанган шагыйрьләрнең берсе иде Такташ. Русның—Блогы, Маяковские, Есенины, грузинның—Табидзелары, әрмәннең—Чаренцы, чувашның Сеспеле кебек. Алар шикелле үк, «Йөрәкләр революция музыкасын тыңларга, аңа кушылырга» тиеш дип санады Такташ һәм шушы юлда халкына хезмәт итәчәгенә чын күңелдән ышанды. Тумыштан бунтарь, романтик җанын

үзе теләп шушы стихиягә ташлады. Әйе, дусты Хәсән Туфан кебек үк, политик җайлашуны белмәүче, хәйләләрдән, карьералардан, яраклашулардан ерак торган гайре табигый мишәр, бүген нигәдер безгә сирәк очрый торган «ыштансыз» җанлы, беркатлы мишәр, Алла колы... юк, үзе теләп, бары матурлык, Шигърият колы булган бөек мишәр иде ул. «Шагыйрь ул элек шигырьне үз тормышында тудырырга тиеш»—дип язды Такташ.

Әгәр баскан эзем җирнең күкрәгендә
Югалмаслык уелып калса иде,
Җырлаган җырларым һаваларда
Утлар белән язылып барса иде.
Килер кешеләр
Күреп шул җырларны әйтер иде:
«Кара, чыннан ла,
Чабаталы даһи—усал бунтарь
Җырлап үткән икән моннан да»...

Бүген, шул килер чор кешеләре, без, шагыйрьлек символы итеп, гаҗәпмени?—нәкъ менә Такташның үзен таныйбыз: күзләре, чәче, йөз сызыклары, бар самимилеге, гадилеге, җанга үтеп кергән сүзләре белән дә... Ул туган, хәзер инде аяныч язмышлы, сүнеп барган Сыркыды—татар авылы исеме—безгә иң шигъри тоела; Такташ яшәп киткән шәһәрләрне—Оренбург, Бохара, Ташкент, Кәттә Курганнарны да аның исеме белән бәйләп күзаллыйбыз... Ниһаять, Казанның күпме урыны бары Такташны хәтерләтә. Бу театр-сәхнә дә—Такташ шигырь сөйләгән, «Җир уллары»нда Идеяне үзе уйнаган һәм һаман ул трагедиянең яңадан куелуын көткән изге урын... Казан әле шагыйрьгә һәйкәл куелганны көтә. Такташ эшләп киткән «Авыл яшьләре» газеты, «Чаян», «Азат хатын» («Сөембикә») журналлары да аның нуры белән өртелгән кебек... нindидер тарихи сер калган аннан. Үзбәк, казакъ, азәрбайҗан, кырым-татар, һ. б. тугандаш халыкларның Г. Голәм, С. Рөстәм кебек әдипләрен дә Такташ дуслары итеп яраттык, Уфаның Такташка гашыйк С. Кудаш, С. Агиш, Г. Сәламнәр яшәгән чорын сагындык. Бүгенге Ташкент та шагыйрьнең улы, хөрмәтле Рафаэль яшәгәне өчен—борынгы Төркестанда ул калдырган илче резиденциясе кебегрәк, якын тоелды... Әдәбиятларны, халыкларны, чорларны җыр якынайта. Такташка мәхәббәтебез бу!

Шигъри яшьлегендә чиксез галәм, дөнья турында мәңгелек мәсьәләләр, сораулар борчыган «Мәңгелек әкият»ендә: «Адәм каян килгән? Кая китә?»—дип янган, кеше һәм шәхес эзләнүләрен, аның бунтын җырлаган шагыйрь, әйткәнебезчә, Шәрекъ һәм Гарепнең—Г. Хәйям, Дәрдмәнд, С. Рәмиевларның һәм Мильтон, Байроннарның тәҗрибәсен өйрәнеп, «Җир уллары», «Үтерелгән пәйгамбәр», «Күктән сөрелгәннәр», «Газраилләр» кебек гүзәл әсәрләрен бирде. Болар—гаҗәеп рухлы, яңа фикерле, киң колачлы, татар шигырендә әле дә кул җитмәс биеклектәге оригиналь әсәрләр иде. Яки романтик мәхәббәт әсәрләре—«Урман кызы», «Кояш күктә мәңге шулай йөзәр», «Зәңгәр күзләр», «Сагыну»... Бөек романтик остазлары—Байрон, Һейнелар кебек үк, Мәңгелекнең, Матурлыкның серен эзләүче бөек гашыйк һәм бунтарь—1923 елда Г. Рәхим язып чыкканча, «Нәләтләр шагыйре», чын гыйсъянчы кушыла алган аларда. Ни өчен Такташ менә нәкъ шушы кабатланмас, көчле рухлы шигъри яшьлеге белән саубуллашты соң? Кырт кисеп, «Такташ үлде» дип язганда нинди үзгәрешләр кичерде ул? Рухи яктан үзгәрдеме? Идеалларын алмаштырдымы? Әллә матурлыкның яңа сурәтен үзе яшәгән чордан эзләп ялгыштымы? Әллә күңелендә һаман «ике мин» яшәп, аны гел борчып килдеме? Үзе дә аңламыйча ук, тоталитар системаның бер корбаны булдымы? Әллә—алда көткән афәтләрне, Сталин лагерьларын күрмәве—иртә киткәне өчен дә бәхетле җанмы ул?

Әйе, бу—үзе үк бер трагедия темасы. Фәүзия Бәйрәмова аны «Үтерелгән пәйгамбәр» диде... Такташны аңлаган һәркем шуны әйтә алыр иде: ул ихлас, гөнаһсыз, саф килеш китте һәм шигъриятнең бәхетенә—ул үзе нәтиҗәдә җиңүче булып калды: соңгы чор иҗатында да халык шагыйре булып, нәкъ аның үз улы сыйфатында халыкның бай рухын, җанын ачу юлында шигъри

сүздә искиткеч зур байлыклар калдырды. Өр-яңа сурәтле шигъри форма, мәктәп тудырды —һәм без инде 70 ел буе гаҗәеп сер булган Такташ шигырен өйрәндек... Гадилеккә, халыкчанлыкка тәренгән яңа Матурлыкның, шигъри яңа сүзнең, шигъри музыканың, ниһаять, Моңның җиңүе иде бу. Халык та аны нәкъ шулай дөрес аңлап, һәр ике Такташны бүлмичә үзенеке итеп кабул итте. Чын шигъриятне үтерергә хокук алган 30, 40, 50 нче елларда Такташ шигъри сүзе, Такташ моңы укучының, халыкның эстетик зәүкын саклап килде, рух югарылыгын билгеләп, әдәбиятка мәхәббәтен тәрбияләде. Бу да—аның җиңүе иде. Менә шуңа күрә дә, эзләнүле, яңача, симфоник яңгырашлы поэмалар—«Давылдан соң», «Гасырлар һәм минутлар», пластик сурәтле, тормышчан нигезле, җанлы, халыкчан, юморлы, лирик һәм патетик эндәшле поэма үрнәкләре «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу», «Мокамай», «Киләчәккә хатлар» әле дә безнең күңелдә. Яки «Югалган матурлык» кебек драмалар, проза әсәрләре, публицистика һәм хатлары... Хатлары—үзе бер дөнья. Хәтеремдә, журналыбызда аның беренче хатыны Гөлчәһрәгә язган хатлары басылды. Җан авазы иде ул, тетрәткеч аһәң иде шагыйрь хатлары... Ә «яңа тормыш» тудырган персонажлар—эшче Нигъмәтуллин, Мохтар карт, Алсу, Мокамайлар—шул чорның дөрес чагылышы булып тоелмас, бәлки. Әмма шигъри моң, сурәт дөреслеге, камиллеге, форма матурлыгы белән—алар бүген дә сокландыра: анда да шагыйрьнең илаһи сүзе, җаны бар!

Менә җитмеш-сиксән еллар инде шагыйрь безне Матурлык, Хис, Йөрәк, Акыл иленә чакыра, үзенең шигъри мәктәбендә укыта, безнең тиңсез укытучы булып кала. Ышанып әйтергә мөмкин: Такташ иседе белән бәйле чорда бер генә «укучы бала» аңардан начарлыкка, юньсезлеккә һәм денсезлек, имансызлыкка өйрәнмәде (Шагыйрьләр турында да шулай әйтә алабыз!). Өйрәнмәячәк тә—иманым камил. «Нәни разбойник», «Картайдым шул» кебек шигырьләрендәге бунтарьлык, Алла белән, муллалар белән тиргәшүче шаян яшьлек моңа нигез була аладыр, бәлки? Әмма бу бит, заманында Есенинның «хулиганлыгы» кебек үк, шигъри декорация, елмайту, көлдерү алымнары, халыкчанлык атрибуты, шартлы сурәтләр генә. Заманында тәнкыйть аның һәр шигырендә «шытырдап торган ата казлар»ны күргәч, гаҗиз булган Такташ үзе үк боларны аңлатып биргән иде. Ә бит укучы ул чакта да, бүген дә бу «нәни шаярулар»ны бик дөрес аңлый, әхлакый саф, югары әсәр итеп кабул итә: шулай булмыйча, шагыйрь бит ул, Такташ... Ә чын шагыйрь изгелекне генә сөйли!

Яки Маяковскийча «көн кадагына сугып» язган шигырьләре белән—сыйнфый уяулыкны, үч һәм кан коюны җырлаган шагыйрь дип беликме? Әйтик, солтангалиевчеләрне дөрес аңламаган дип?.. Заманына, ил агаларына нык ышанып ялгышу, талант фаҗигасе түгелме бу? Яраклашып, премияләр, түрәлек урыны өчен шулай язганмы әллә ул? Һич юк. Аны Сталин режимы җырчысы итеп күрсәтергә тырышу һичкемне ышандырмас, ул системаның әле «чәчәкләр»ен генә күреп тә, күпме көлү, һөҗү шигырьләрен язып калдырды. Шул чор түрәләрен, бюрократларын гына түгел, гүя бүгенгенең чиновникларын да, халкына, туган телгә төкергән маңкорт ответработникларын да алдан күргән шагыйрь:

Сүз юк,
Урыс телен белү кирәк нәрсә,
Ләкин
Кирәклеген аның бутыйлар,
Урысчадан доклад укыйлар.
Урыс теле инде урыс белән
Сөйләшергә, әйтик, яраса...
Татар теле ул бит татар белән
Аңлашырга ярый лабаса.

Яки:

Килер бер көн: җирдә сыйныфлар да,
Партияләр дә бетеп китәрләр.
Ә без—«Зур стажлы партиясезләр»
исемен алырбыз.

Мондый шигырьләре өчен заманында тәнкыйтьләр аз эләкмәгән аңа. Юк, бүгенге күзлектән карап ревизия ясау омтылышына буйсынмый Такташ. Хәер, бу һәр сүз остасына карыйдыр... Аның шигъри тылсымын тәрҗемә аша да бирүе кыен. Хәтта атаклы Мартынов та русчада яңгырата алмады (үпкәләсә дә, аның үзенә бу хакта С. Хәким, Н. Нәҗмиләр Мәскәүдә Такташның 70 еллык юбилей кичәсендә әйттеләр.).

Ә менә соңгы еллардагы үзгәрешләребез Такташыбызга да кагылып уза башлады. Кемдер аның иҗатында сәяси наданлык, яки «суллык» күрмәкче. Нәкъ егерменче еллар тәнкыйтенең Такташка әдәби суд ясавын, гүя, бүген кире кайтармакчы. Икенчеләр аны педагогик яктан зарарлы дип таба. Дәреслекләргә кергән шигырьләренең этик кыйммәтенә шик белдерә (әлегрәк бит бу турыда эндәшүче дә юк иде!)... Өченчеләр исә аның үлемен үк ялган идеаллардан арынып, үзе теләп дөньядан китү дип аңлата башлады... Ә Такташ? Табигый, аның бу «шаяру»ларга исе дә китми—ул гали, биек урында.

Урамнардан күпме эзләсәм дә
Такташ баскан эзләр табылмас.
Шашкын йөрәкләрнең шат җырчысын
Минем кебек һичкем сагынмас...—

дип язган иде бер шагыйрь Такташ әле үзе исән чакта. Бүген дә шулай. Чөнки шигырьдә безнең бу гасыр—Тукай белән бергә—Такташлы да гасыр иде...

Яңа гасыр да, ышанып калам, моң дәвамы, Такташ тавышы дәвамы булыр. Әйе, Такташ калыр. Такташның безнең күңелләрдә торткан урынын раслау өчен—иң авыр чорларда аңа эндәшеп, киңәшеп, сагынып яшәгән Х. Туфан шигырен искә алу да җитәр кебек:

Әй, талантлы, олы бөек халкым!
Кабул итче тик бер сорауны.
Бирсәнә син безнең сафка тагын,
Бирсәнә бер Такташ сыманны...

Тусын иде ул, Такташ сыман язсын иде, хәтта аның белән ярышып, тагын да биегрәк үссен иде. Аңардан шигъри күзаллавы, сурәт-дөньясы, форма-өслүбе, бай шәхесе белән аерылган яңа бер шагыйрьнең Такташ белән бәхәсләшүе дә гаҗәп булмас иде. Максатта—алар бергә булачак. «Таулар һәрвакыт бер-берсен күрә, таба, аңлаша, сазлыклар гына бер-берсеннән ерак»—дигән М. Цветаева.

Бүген исә халык язмышы, суверен дәүләтебез өчен барган иң авыр көрәшле чорда асыл талантларга—Такташка, Тукайга, Туфанга тел тидерү—ул мең газап күргән бөек халкыбызга—татарга тел тидерү, туган телгә, газиз Моңга кизәнү, тарих агачында үзебез утырган «ботакны чабарга» азаплану. Кабатланмас шагыйрь Такташ бүген нәкъ шуны искәртә кебек!

**Рәдиф ГАТАШ**

# Hadi Taqtaş

## Məngelek əkiət

Əkiət səylim sezgə, tan cillərə!
Tuqtağız da menə tıŋlağız!
Şul urmanda bulğan ber əkiətne
İldən ilgə küçep cırlağız!
Menə urman, çiksez qara urman,
Məŋge şomlı, məŋge qaraŋğı;
Cillər belən işelep haman, haman
Ulap torğan ütkən zamannı.
Şul urmanda yəşren ber urında
Yalğız qəber tora.
Kem anda?
Nigə yalğız anda adaşqan da,
Nigə yəşren cirdə urmanda?
Ul ber yeget qəbre,
Ul yegetnen
Qayğı belən ütkən kənnəre,
Ozın bulğan məŋge ğazap belən
Yoqlıy almıy ütkən tənnəre.
Ul küp, bik küp uylap yərgən:
«Adəm qaydan kilgən?—tağın da
Qayda kitər?» Ləkin moŋa cawap
Tabalmağan üzenen anında.
Tabalmağaç, kilep tezləngən də
Məŋgelektən cawap sorağan.
Ozaq kətkən—
Cawap alalmağaç,
Bolay diep yeget cırlağan:
«Nələt təşsen sezgə, nələt təşsen!
Əy, urmannar, qırlar, dalalar!
Məŋge telsez qatı taşqa əyləngən
Cirlər, küklər, fənnər, allalar!
Cawap kəttem sezdən, birmədegez,
İnde ezləp kitəm—tabarmın;
Keçle qulım belən məŋgeleknen
Timer işekləren watarmın.
Watarmın da ilgə yəşren bulğan
Barlıq serne çişər, açarmın».
Şunnan son ul yəşren urın saylap,
Qəber qazıp cirgə kümelgən;
Mesken yeget, qaytam, diep kitkən
Qaytmas cirdən—upqın təbennən...
Min əle də anın qəbren ezlim
Urmannardan, yəşren cirlərdən,
Min tawışın işetəm, hər kən iştəm
Tan aldında iskən cillərdən.
Ul kiləçək...
Min də qəbren tabıp,
Gəlne üpkən kebek übərmen,
Zəŋgər küzləremnən, ayamıyça,
Qaynar yəşləremne tügərmen.

Zəŋgər küzle yeget qəbren übər,
Yəşlər tügər qəbren əstenə!
Gəllər sibər hər kən tan aldında,
Cırlar cırlar sinen ismenə.
Sin ezləgən yəşren, zur serlərne
Min də ezlim, yeget,—
Tınıç bul!
Sin küzləgən təpsez upqınnarnı
Min də küzlim, yeget,—
Tınıç bul!

*1923*

*Гомәр Бәшировның тууына 100 ел*

# ӘДИПНЕҢ МИРАСЫ

*Татар халкының олы әдибе Гомәр Бәшировның иҗаты белән киң катлам укучылар яхшы таныш. Язучының романнарын, повесть һәм хикәяләрен, публицистик мәкаләләрен халык күп еллар буена яратып укыды һәм киләчәктә дә укыячак. Соңгы елларда иҗат ителгән, әмма тәмамланып бетмәгән романы «Гыйбрәт» тә Татарстан китап нәшриятында басылып, бу юбилей көннәрендә дөнья күрер.*



*Шулай итеп, әдипнең әдәби мирасын аның дөнья күргән, танылган әсәрләрен санап чыгу белән билгеләргә булыр иде. Ләкин бу исемлек нигездә дөрес булса да, чынында бик үк тулы булмас иде. Әдипнең әдәби мирасы шактый ук киңрәк тә, баерак та.*

*Гомәр Бәшировның васыяте буенча аның бөтен әдәби мирасын туплау, саклау, басмага әзерләп нәшер итү эшләре— барысы да әтинең вафатыннан соң миңа тапшырылды. Әдипнең кульязмалары, көндәлекләре, хатлары һәм башка бик күп төрле язмалары минем карамакка күчте. Алар аерым китап шкафында шүрлекләрне тутырып торалар.*

*Менә бер шүрлектә рәт-рәт булып калын гына папкалар тезелеп киткән. Аларда төрле зурлыктагы һәм калынлыктагы 225 дәфтәр һәм блокнот. Әмма бу әле көндәлек дәфтәрләре түгел. Бу әдипнең һәрвакыт үзе белән калдырмыйча йөрткән дәфтәрләре. Кайда гына булмасын— юлдамы, ялдамы яисә шифаханәдәме, һәрвакыт бу дәфтәрләр язучының кул астында булганнар. Әдип көн саен диярлек үзенең күргәннәрен, ишеткәннәр, уй-фикерләрен матур әдәби тел белән кыскача теркәп барган. Аерым дәфтәрләрдә төрле тормыш маҗаралары, фаҗигаләре, гыйбрәтле хәлләр. Арада халыкның күп еллар буена җыеп килгән тапкыр сүзләре, әйтемнәре, җырлары берничә блокнотта алфавит тәртибендә язылганнар. Кыскасы, әдип бу дәфтәрләрендә үзенең булачак әдәби әсәрләренә азык-чимал җыеп барган дисәң дә була.*

*Бу язмаларның тагын бер үзенчәлеге һәм, минемчә, кыйммәте бар. Язмаларда бөтенләй әдәби хыял юк, барысы да тормышта ничек булса шулай, объектив язылган. Тагын шунысы да бар, әдипнең фикерләре, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып ясаган нәтиҗәләре илебездә ул чорларда хөкем сөргән идеология кысаларына һич тә сыймаган, гомумкешелек, гуманизм идеяләре югарылыгында булганнар.*

*Бу дәфтәрләрне укыганда, мине бер фикер борчып, азаплап торды. Әдип аларны үзе өчен генә язган. Хәзер менә мин, аның варисы укыйм. Шулай итеп, бу язмалар бер генә укучы белән чикләнеп, гомергә йомылып калырлар микәнни? Ә бит аларда шул заманның кайнар сулышы, тормышның объектив һәм талантлы чагылышы, олы әдипнең эчке, тирән уй-фикерләре!*

*Бер дәфтәрнең тышлыгына «Күңел дәфтәре» дип язылган иде. Икенчесе Мирхәйдәр Фәйзинең «Өметең өзмә...» шигыре белән башланган иде. Нинди бәйләнешләре булгандыр, анысын аңлата алмыйм, әмма шул икесе бергә мине тәвәккәлләп әдипнең бу язмаларын «Күңел дәфтәрләреннән» исеме астында матбугатка әзерләргә этәрде. Хәзер миңа укучы хөкемен генә көтәсе калды.*

*Бу язмалар артыннан биек тау булып әдипнең көндәлек дәфтәрләре калкып торалар. Зур форматтагы, калын, өчәр йөз битле биш дәфтәр. Беренче дәфтәр 1931 елда башланган, бишенчесендә—соңгы язмасы 1999 елның май аенда теркәлгән.*

*Бу дәфтәрләрдә әдипнең рухи дөньясы, уйланулары, кичерешләре. Әлбәттә, аларның бик күп өлеше әдәбият тормышына бәйләнешле. Юк, алай гына түгел, көндәлекләрнең мәйданы киңрәк. Аларда халык тормышы, гаме, ил язмышы.*

*Бөтен бер гасыр замандашы, катлаулы тормыш юлы узган, күпне күргән, күпне белгән олы әдипнең уйланулары, тирән фикерләре киң катлам укучының да игътибарын җәлеп итә алыр дип уйлыйм. Аларны дөньяга чыгару, халыкка җиткерү—ул бит әле әдипнең васыяте дә.*

*Әдәби мирасның тагын бер өлешен искә алмыйча булмый—ул хатлар. Алар күп. Һичшиксез, татар язучыларының үзара алышкан хатлары һәммәбез өчен дә кадерле һәм еллар узу белән аларның әһәмияте гел арта барачак. Гомумән, эпистоляр жанр һәрбер халыкның әдәбият хәзинәсенең мөһим бер өлеше булып тора. Әмма монда, һәрхәлдә, минем өчен, бер проблема бар. Гомәр Бәшировка килгән хатлар шактый, әмма ул үзе җибәргән хатларның күбесе юк. Элегрәк вакытта хатлар кулдан гына язылган бит, берәү дә аның икенче нөсхәсен язмаган, сакламаган. Шунлыктан, мин Гомәр Бәширов белән хат алышкан язучыларга һәм, гомумән, барлык шәхесләргә яки аларның варисларына зур үтенеч белән мөрәҗәгать итәр идем: без шул хатларның ксерокопияләре белән алмаша алмас идек микән? Аны Татарстан Язучылар берлеге аша оештырырга булыр иде.*

*Шулай итеп, олы әдипнең әдәби мирасы аның басылып чыккан, дөнья күргән, танылган әсәрләре белән генә чикләнми. Гомумән, олы әдипләребезнең бай әдәби мирасларын мөмкин кадәр тулы итеп халкыбызга җиткерү—ул варисларның изге бурычлары һәм шәхси эшләре генә булып калмыйча, республикабызның дәүләт һәм хөкүмәт органнарының игътибарыннан читтә булмас дип ышанасы килә.*

**Зөфәр БӘШИРОВ**

## Күңел дәфтәрләреннән

* * *

Мин боларны нигә язам?

Бүтән эшем булмаганга түгел, кулым кычытканга да түгел. Мин аларны язып утырырга һич теләмәс идем. Бүгенге чынбарлыкның бер кыйпылчыгы. Лакка, буяуга өретелмәгән үз төсе, үз кыяфәте белән тормыштан бөтен кочагы белән кубарып алып монда ябыштырып куйган бер кисәге.

Үтәр еллар, агар сулар...

Бер заман сугышлар да бетәр. Тормыш тагын җайланыр. Без ул вакытта хәзерге шикелле ашау турында кайгыртмабыз, эшне, иҗатны кайгыртырбыз. Чөнки кеше нормаль яшәгән вакытта ашау өчен кайгыртырга тиеш түгел. Кешенең ашау-эчүе ул бит һава сулаган шикелле үк табигый бер нәрсә. Ул эшләү һәм яшәү өчен хәзер булырга, үзе турында уйлатмаска тиеш.

Менә шул вакытта бу дәфтәрне ачып карарбыз...

*24 март 1943 ел. Норлат районы*

* * *

Бер көн гаҗәп бер төш күргән идем. Шул төштәге усал, ләкин көчле егет әле менә хәзер дә истән чыкмый. Ул егет мине әллә нинди карлы, сулы язгы юллардан чанага утыртып әллә кайларга алып китте. Бик озак барып, әллә нинди ят җирләргә барып чыкканнан соң бер йортка барып кердек. Әле дә күз алдымда: чибәр генә бер яшь хатын тәрәзә янында нигәдер монаеп, ераkларга карап тора, аның янында картрак бер кеше басып тора. Әлеге усал егет аның янына килде дә, шундый властный тон белән: «Ник китмисең син, нигә минем аяк астында буталасың син!»—диде. Теге кешене ул кешегә дә санамый, ул аны бер корт урынына гына күрә, аның хатынын үзенеке булырга тиешле дип исәпли иде. Миңа бу кыю, усал һәм юлбасарларча башсызлык белән эш итә торган егет нигәдер ошады, минем аңа ачуланасым да килмәде (чөнки ул мине дә нигәдер кире якка таба көчләп алып киткән иде), шул ук вакытта ихтирам итүдән дә тыела алмадым. Ул нык, үз сүзле, үз дигәнен эшләтә ала торган гаҗәп көчле татар егете иде.

(Кызык, минем теге әсәрдәге образ шулай булып төшемә кермәдеме икән? Ул аңа кайбер яклары белән бик ошый бит). [1]

*8 июль 1942 ел*

* * *

Урман эчендә, тимер юлдан бик якын гына бер җирдә минем эшли торган урыным бар. Бу арада гел шунда эшләдем әле. Иртәнге чәйдән соң чыгып китәм дә сәгать 2-3 ләргә хәтле язып утырам. Чамалап кайтам, какрас аш вакыты була. Чамам шул: кояш мәһабәт бер нарат турысына килеп җитеп күренмәс була.

[1]Сүз «Татар егете» исемле хикәя турында бара.

Шәп урын дигәч тә анын әллә ние юк. Уртача гына бер каен, анын төбенә берничә аркылы агач салынган. Ул ике агач минем эскәмиям дә, өстәлем дә. Аннан унда куаклар, таллар өстеннән тимер юл күренә. Ике арада сазлык.

Шунысы кызык, минем монда тора башлаганнан бирле бер дустым артты. Мин утырган урыннан 10-15 метр ераклыкта зифа буйлы, биек, ир уртасы матур бер нарат бар. Һәр көнне мин килеп эшли башлагач, шул биек наратнын куе ылыслары арасыннан ботактан ботакка сикерә-сикерә матур гына, житез генә бер тиен баласы килеп төшә. Ул конгырт тузган коерыгын болгый-болгый агач башыннан йөгереп төшә дә, жиргә сикерде инде дигәндә генә, күз иярмәслек тизлек белән кире борылып югарыга менеп китә. Аннан сон ул нарат көпшәсе тирәли кыйгачлап, шаяра-шаяра чабып йөри башлый. Ул түбәнгә таба шундый житез чабып төшә, инде егылды бу дип торасын, ул арада булмый, кечкенә шаян ялт итеп борылып ботакка сикерә дә күздән югала, тик анын жәенке тузгак коерыгын гына күреп каласын.

Беренче көнне тиен малае, үзе уйнап йөри торган агачлар тирәсендә мине күргәч, бик ачуланды. Нарат ботагына басып сырт йоннарын кабартты, гайрәт белән коерыгын болгап тешләрен шыкылдатырга тотынды. Ул зәһәрләнеп әле бер ботакка, әле икенчесенә сикерә, ярсып һаман тешен шыкылдата, мине ничек тә куркытып моннан куып жибәрмәкче була иде бугай. Юләр малай. Ул зур тиен булса, алай кирәкмәгәнгә әтәчләнеп йөрмәс иде.

Урманнын бу кечкенә хужасын борчуым мине бераз күнелсезләндерсә дә мин ул урынымнан китмәдем. Көн саен иртә белән килеп, кич кенә китә торган булдым.

Тора-бара тиен малае бу хәлгә күнде. Ул мине иртә белән һәрвакыт шул биек наратта каршы ала, мин барганда анда булмаса да әллә кай арада ялт итеп ботаклар арасыннан килеп чыга да, шул минем яктагы ботагы өстенә килеп утыра. Без һәр көнне шулай иртән беренче очрашкач, анын белән бераз карашып утырабыз. Анын калку конгырт күзләре һич йомылмыйча минем һәр кыймылдавымны күзәтеп торалар. Аннан сон ул бу кызыксыз шөгыльдән туя. Тиен малае ялт итеп сикереп ботакка менә дә, бер агачтан икенчесенә күчә-күчә, шаяра, уйный-уйный әллә кайларга китеп югала.

Мин дустымны онытам, үз эшемә мавыгып китеп аны бөтенләй истән чыгарам. Бер вакыт ничектер каршыдагы агач ботагына күзем төшә, карасам, нәни малай тагын минем каршыма килеп утырган булып чыга. Мин ана бармак яныйм, ул коерыгын болгап тешен шыкылдатып куя.

Кичкә таба минем нәни дустым каядыр югала, мин урыныма кайтып китәм.

Һәр урынга, гадәткә һәм кайбер кешеләргә мин бик тиз ияләнәм һәм бик нык бәйләнәм.

Менә бүген купеда эшләдем дә урмандагы яза торган урынымны сагынып кичкә таба



*Гомәр ага һәм хатыны Кәримә апа Аккош күлендә (1961)*

шунда бардым. Шундый тын, шундый тыныч. Алла насыйп итеп янгыр яумасын, көннәр жылы булсын иде дә, мин тагын күп көннәр шушы агач төбенә килеп язсам иде. Тынны сөям. Комиссар Чанбарисов[1] турындагы очеркның яхшы чыгуында бу каен төбенең дә, бәлки, бераз гаебе бардыр.

*27 сентябрь 1942 ел*

* * *

Монда килгәннән бирле беренче мәртәбә мин үземнән канәгать булган көннәрнең берсе кичә һәм аның элекке көне. Мин язган нәрсәләремнән канәгать, башкалар да шулай ук. Чанбарисов турындагы очерк күп кешегә ошады. Әле бит мин аны мондагыдан күп яхшы итеп яза ала идем.

Татарстан патриоты, һәрвакытта татарны, аның культурасын, аның бөтен нәрсәсен яклап, аны ничек кенә булса да күрсәтергә, танытырга тырышып йөрүче Хатыйп[2] Госман дигән кара егетнең дә күңеле булган шикелле сизелде.

Бу арада йокыдан һәм газитә эшеннән вакыт урлап Фатих Әмирхан хикәяләрен янадан бер кат укып чыктым. Ләкин вакыт бик аз. Аңа шул эшне бетереп урын өстенә яткач кына, берәр сәгать кенә вакыт бүлеп була.

Буржуй дип аның әсәрләренең күзен дә ачырмаганнар иде бит. Барыннан да элек ул язучы һәм бик олы гакыллы, киң карашлы язучы. Аның әсәрләрен шушы көнгә кадәр бикләп, итәк астына яшереп тотуыбызны белмим инде, ни генә дияргә. Ахмаклык дисән, бик тупас була, юньсезлек дисән—йомшаграк.

Гажәп халык без. Гел шул мескенлектән, үз күләгәсеннән үзе шүрләп йөри торган пишкадәмлектән[3] чыгып булмый әле. Алдынгы яшьләр дә шундый да кыюрак түгел ичмасам, картлардан булмый да булмый инде ул.

Безгә Фатих Әмирханнан качмаска, кыюлыкны һәм культураны аннан да өйрәнергә кирәк иде. Хәер, соң булса да керештек ич инде.

Ярый, хәзер кырын ятып китап укырга керешәм. Өстә һәр төндәгечә немец самолетлары очып йөри. Аларга гадәтләндем инде, моторы улавыннан ук белеп алам.

*30 сентябрь 1942 ел*

## Кеше дөньяда ни өчен яши?

Мине борчый торган нәрсә—моңа кадәр үземнең көчемнән килгәнне күңел канәгатьләнерлек итеп эшләп бирә алмауда. Беренче утыз елым төп максатсыз, җилкәнсез көймә кебек, арлы-бирле чайпалып узды. Нинди еллар бит, нинди гүзәл чаклар, никадәр дәрт, нинди ышанулы омтылыш!

Малай чакта мин рәссам булырга тели идем. Урман, болын буйларының матурлыгына сокланып аларны рәсемгә төшерәсем килә иде. Тукай шигырьләре мине сихерли, «Дим буенда»ны[4] укып жылый идем. 15-16 яшьләрдә чагында минем күңелдә тышкы чын тормыштан үзгә, чынбарлыктан тыш тагын әчке бер әдәби дөнья, хыял дөньясы уянып килә иде. Шундый тойгыларның кузгатып җибәрүе аркасында «Шәфигулланың үлеме»ме, нәрсәме дигән бер хикәя язуым исемдә.

Шулай бер нәрсә истә калган.

Бездә Казаннан килгән Хөршидә исемле бер яшь укытучы тора иде. Шактый укымышлы кыз. Өсте-башы шәһәрчә, пөхтә, иреннәр буяулы, ләкин тар карашлы, мещан гаиләсендә тәрбияләнгән.

Ул миңа үзе белән алып килгән китапларын бирә иде. Кайвакыт сөйләшеп утыргаларга да туры килгәли иде. Әдәбият, язучылар турында сөйләшүебез хәтеремдә. Мин аннан бик күп нәрсәләр сораштым. Язучылар нинди кеше, алар ничек яшиләр, ничек язалар, ничек киенәләр, фәлән.

Мин аларны язган нәрсәләренә карап, кешеләрдән бик өстен тора торган ярым Алла—

[1] Шәйхулла Чанбарисов—батальон комиссары, «Комиссар» исемле очеркның герое (*«Совет әдәбияты», 1943, № 2, 3)*. Соңыннан Башкорт дәүләт университетының ректоры булып эшләде.
[2] Күренекле әдәбият галиме, озак еллар КДУда кафедра мөдире булып эшләде.
[3] П и ш к а д ә м —мәдрәсәдә укуын тәмамлап, шунда мөгаллимлек итүче яки хезмәт урыны көтеп ятучы.
[4] Садри Җәләл әсәре.

кешеләр итеп күз алдына китерә идем.

Хөршит тә шундый уйда булган булса кирәк. Бервакыт әдәбият турында бик кызып сөйләшкәндә, мин үзем дә сизмәстән, бәлки ансыз рәвештәдер, аңа ышанып түгелдер: «Их, язучы булсан иде, шундый әсәрләр язсан иде»,—дидем.

Хөршит миңа зур, матур күзләрен тутырып карады да, минем чынлап әйтүемне белгәч, шаркылдап көлеп җибәрде. Атына-атына көлде дә, минем дәү кулларыма, чабаталы аякларыма карап торды, аннары тагын көлеп җибәрде. «Кара бу чабатаны, кара бу кулларны!—диде.—Кая инде ул чабата белән язучы булу!»

Мин болай урынсызга ычкындырып җибәрүемә үкендем, әмма гарьләнмәдем. Чөнки мин ул хыял югарылыгында йөргән ярым Аллалар янына менәргә лаеклы кеше түгел идем, көчем дә, кодрәтем дә, белемем дә юк иде. [1]

Кыскасы, анысы инде узган гомер. Шулай да әгәр әдәбиятка моннан 20 ел элек килгән булсам, миңа болай пошынырга туры килмәгән булыр иде. Шуны гына әйтәсем килә.

Кеше дөньяда әнисе тудырган өчен генә яшәми. Алай яшәүчеләр бик күп. Болай кирәкми, ягъни кеше булып житү өчен ул гына житми дигән сүз.

Кеше ижатчы. Кешенең гомерен, тормыш юлын баскычтан күтәрелү белән чагыштырырга мөмкин. Чын кеше, үзенең ни өчен Кеше булганлыгын белеп яши торган сәләтле, булдыклы, инициативалы кеше гомеренең башыннан ук әнә шул очсыз-кырыйсыз югарылык баскычына күтәрелә башлый. Һәр баскычны атлаган саен аның өскәрәк күтәреләсе килә, шуның белән бергә никадәр югары менсә дә баскычның чиге югын да, күнеле ни кадәр биеккә күтәрелгәндә дә канәгатьләнмәсен дә белә. Ләкин шулай да бер баскыч өскә күтәрелгән саен аның мохите киңәя, ул күбрәк күрә, күбрәк белә, үзендә бөек идеялар, кешелекне алга илтә торган яңа омтылышлар, теләкләр сизә.



*Гомәр Бәширов һәм Хәсән Туфан (1973)*

Чын кешене мин шулай аңлыйм. Кешенең һәр көне димим, һәр ае, һич югында һәр елы кичәге көненә, аена һәм елына караганда алга китеш булсын. Бер урында таптана икән, димәк ул әрәм узган гомер.

Моның өчен кешенең үз теләге генә житми. Хәтта талант һәм сәләт булу да житмәс иде. Социаль тормыш шулай корылган булырга тиеш. Ләкин бездә кешегә инициатива бирү житеп бетми. Кайбер бюрократлар яшьләргә профессияне үзенең теләвенә-теләмәвенә карамастан көчләп тагалар.

Менә шундый кешене күрсәтә алсам яисә шуңа якыная алсам мин үземнең вөжданымны азмы-күпме канәгать дип хис итәр идем. Юкса, язучы исемен күтәреп йөреп тә, берничә хикәя һәм повесть белән үлеп китсән, ул бик үкенечле булачак. Аның өчен исем күтәрү дә кирәкмәс иде.

## Корбан гаете

Күптән түгел корбан гаете булып узды. Халык бик актив катнашты. Корбан суючылар да күп булды, мәҗлес уздыручылар да. Иртә белән гаеткә баручыларның иге-чиге булмады. Һәр урамнан тәкбир әйтеп килеп чыгалар да зур урамда бергә кушылалар. Урамда һәм мәчет янында милиционерлар тәртип саклаган. Гомумән, мөселман халкы гаетне бик шәп уздырдык дип куанып йөри.

Гает көнне иртә белән Яңа бистәдә бер маржа әби капка төбендә күз яше белән елап тора ди.

—Карасана бу татарларны, ничек күнелле итеп бәйрәм итәләр, ничек күнелле итеп тату

[1] Бу эпизодны автор үзенең «Көзге ачы җилләрдә» исемле повесть-истәлегендә киңрәк итеп тасвирлый.

булып бергә баралар. Менә безнең рус халкында юк бит шушылай бергә йөрүчеләр!—дип әйтә ди.

Сугыштан соң дини тойгылар, дин, шәригатькә инану һәм гомумән динчелек ифрат көчәйде.

Ни сәбәп?

Ватан сугышы үзенең коточкычлыгы, рәхимсезлеге һәм дәһшәте белән дини хисләрне уятты. Кеше үз көченә генә ышанып тынычлык таба алмады. Мондый сугыш дәһшәте эчендә кеше бик зәгыйфь бер нәрсә булып калды. Сугыш дәһшәтеннән бары нинди дә булса читтән тыш бер бөек көчкә генә сыгынырга, аннан гына ярдәм табарга мөмкин иде. Бу бөек көч, борын борыннан ук поэтик бер югарылыкка күтәрелгән, кешенең бала чагында ук аның күңеленә фәүкылгадә[1] бер көч булып урнашып калган җиңелмәс, мәңгелек һәм тиңсез кодрәт, билгеле, бер Алла гына.

Сугыш вакытында динсезләр дә Аллага табына башладылар.

Сугышта үлем авызына килеп җиткән бик күп кеше иң актык таянычы һәм иң актык ышанычы, иң соңгы өмете итеп кискен вакытларда (атакага һәм һөҗүмгә барганда, бомбежка астында һ. б.) Аллага ялварганнар. Исән калсам намазга йөрер идем, фәлән дип нәзер әйткәннәр. Нинди дер бер могҗиза белән алар исән калганнар һәм менә хәзер алар сүзләрендә торалар. Гаеткә генә түгел, җомга намазына да һәм бүтәннәренә дә йөриләр. Өйләнгәндә никах укыталар, үлсә җеназа укыталар, өйләренә чакырып Коръән укыталар.



*Гомәр Бәширов һәм композитор Сара Садыйкова «Җидегән чишмә»*

Бик кызык бер нәтиҗә килеп чыга: кеше үзен-үзе үтерү өчен үзе үк уйлап чыгарган машинасының дәһшәтеннән кан калтырап, кайчандыр бик борынгы вакытларда үзе үк табып та, соңыннан йөз чөергән Алласына янадан ялварып баш ия башлады.

Бик сәер, бик гаҗәп, марксизм күзлегеннән караганда, пацифистлыктыр да бу бәлки. Әмма бөтен дөнья һәм бөтен кешелек күзлегеннән чыгып караганда, шушындый нәтиҗәгә килергә туры килә.

Ай-һай, сәер дә соң бу дөнья!

*28 октябрь 1948,*

Матбугат өчен **Зөфәр БӘШИРОВ** әзерләде.

[1]Фәүкылгадә —галәттән тыш, читтән тыш.

# КҮҢЕЛДӘГЕ СУРӘТ

НИЛ ЮЗИЕВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Мин Нил абыйны бик мөлаем, зыялыларга хас булганча, тыенкы елмаеп, йә сине бераз кызарта, йә үзенең туры әйтелгән сүзе өчен чак кына уңайсызланып, хәтта оялып тыңлаучы чибәр һәм акыллы кеше итеп белә идем. Әмма җанлы аралашу, көндәлек ыгы-зыгы эчендә аны бу чаклы ук матур кеше, эчтән балкып торган гүзәл акыл иясе дип белми идем.

Нил абый Юзиевне беренче тапкыр студент вакытта «Совет әдәбияты» редакциясендә күрдем. (Хәзерге «Казан утлары» ул чак шулай атала иде.) Дөресрәге, мин аны күргәли идем, ишетә, тыңлый идем. Бервакыт «Татарстан яшьләре» редакциясе каршындагы әдәби түгәрәктә үзенең иҗат тәҗрибәсен уртаклашып, Илдар Юзеев «Нил абый белән бергә шигырьләр язып йөргәндә», дигән кебегрәк истәлек тә сөйләгән иде. Кыскасы, шигырь дөньясы белән мәш килгән мин аларның бертуганнар икәнен белә идем. Игътибарым күбрәк яшьләрне «Таныш моңнар» дигән романтик поэмасы белән сихерләгән Илдар Юзеевтә иде. Үзем дә Такташка гашыйк булганга, Такташ аһәңнәрен үзенчә талантлы итеп яңгыраткан шушы чибәр шагыйрьгә кызыгып карый идем.

Шулай да Нил абыйны «беренче күрүем» дигән гыйбарә үзенең асыл мәгънәсендә хата түгел. Чөнки мин аның тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме буларак бик мөһим бер сыйфатын нәкъ менә шушында абайлап калдым.

«Совет әдәбияты» журналының тәнкыйть бүлеген алып баручы Мәҗит Рафиков Әхмәт Рәшитов белән икебезгә Хисам Камаловның яңа чыккан шигырь җыентыгына бәяләмә язуны тапшырды. Без икебез дә университетның дүртенче курсында укый идек. Вакытлы матбугатта инде бик каты тәнкыйтькә очраган лирик җыентыкны шагыйрьнең «Яңадан сафта» дигән беренче китабы белән чагыштырып, җентекле рәвештә анализлап чыктык. Мәхәббәт лирикасында интим хисләргә «артык бирелеп китүен» тәнкыйтьләдек. Аларны «Партиягә гариза» шигыренә каршы куйдык. «Әнкәй үлеменә» дигән шигырендәге «Һавадагы якты йолдызларның трахом төшкән мәллә күзенә»,—дигән юлларны натурализм дип гаепләдек. Әгомумән Х. Камаловның лирик каһарманына хас горурлыкны, көчле сыйфатларны мактадык. Журналның җаваплы сәркатибе Нил Юзиев мине чакырып алды да, шагыйрьне турыдан-туры якламыйча, әйләнгеч юл белән шундый хакыйкатьне төшендерде.

—Рус шигъриятендә Пушкин бар, Некрасов бар. Әмма шунда ук алардан аерылып торган Фет белән Тютчев та бар. Әдәби тәнкыйть һәм укучылар аларның баштагы икесен генә сайлап, боларын кире какмый. Барысын да кабул итә,—диде ул. Бу сүзләр минем өчен ят яңалык түгел иде, алар үз рухыма да бик якын иде. Чөнки инде Дәрдмәнд иҗатын соңгы ике шагыйрь белән чагыштырып өйрәнә башлаган идем. Әдәбиятка киң караш матбугатның йогынтылы бер кешесендә шушындый яклау табуын күрү минем өчен сөенечле иде. Югыйсә аның җитәкчесе—журналның баш мөхәррире Абдулла Гомәр «трахом» турындагы хөкемебезне куәтләп: «Чыннан да пычрак бит, ә!»—дип өстәгән иде. Без монысын кабул итмәдек, әлбәттә.

Әлеге эпизодта Нил Юзиевнең мөһим бер карашы, иманы ниндилеген чамалап калдым һәм күп еллык гыйльми эшчәнлеге дәверендә аның шушы сыйфатлары фән һәм тәнкыйть фикере үсешенә нинди бәрәкәтле йогынты ясаганын да күрдем.

Нил абый белән якыннан һәм тыгыз аралашу минем аспирантура елларында булды. Кафедра мөдире һәм фәнни җитәкчем Хатип ага Госман иде. Нил Юзиев—университетның татар әдәбияты кафедрасында доцент. Утырышларда, җәмәгать чараларында бергә булабыз. Кайчандыр Нил абыйлар җитәкләгән стена газетенең баш мөхәррире итеп мине билгеләделәр. Алмаш мөхәррирләр—Клара Зиннәтуллина һәм Фәрваз Миңнуллин. Н. Юзиев татар бүлегенең әдәби иҗат түгәрәген алып бара. Газетның яңа ел санында дусларча шаярулар урнаштырдык. Х. Госманга, М. Зәкиевкә, В. Хаковка, Ф. Сафиуллинага, ул чактагы студент һәм комсомол оешмасы секретаре Рузәл Йосыповка шундый шаржлар эшләнде. Шигырьләрен мин яздым, рәсемнәрне бик оста итеп бер студент кыз ясады. Аны һәм Язилә, Рузилә исемле тырыш

кызларны комсомол кадрларын әйбәт белүче Рүзәл табып бирде. Нил абыйны суган түтәленә охшаган бер мәйданчыкка лейкадан су сибеп торган кыяфәттә ясадык. Суган кыяклары урынына каләмнәр калкып чыга. Аста шундый шигырь:

Түгәрәкләр бар да түп-түгәрәк
Булмаса да, ышаныйк Нилгә:
Тырышлыгы аның китмәс җилгә—
Әдипләр чүтеки үсәр илгә.

Ә юраганыбыз юш килде: иҗат түгәрәгеннән Равил Фәйзуллин, Радиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим, Шамил Маннап, Тәүфикъ Камалиев, Фарсил Зыятдинов, Булат Сөләйманов кебек шагыйрьләр үсеп чыкты.

Нил абый шигърият фәнендә—Хатип ага шәкерте. Алай гына да түгел, аның иң яраткан укучысы иде. Остаз моны һәрдаим сиздереп торды. Бервакыт кафедра җитәкчелегендә алмаш мәсьәләсе кузгалгач, Хатип ага: «Минә Нил калыр дип торам»,—диде. Нил абый гадәтенчә тыйнак кына елмаеп куйды.

Әмма аны Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият бүлегенә мөдир итеп күчерделәр. Университет укытучысына академик коллектив шартларына күнегеп китү җиңел булмагандыр. Тик ул зур коллективны уртак эшкә туплый алды. Чөнки үзе тирән хәзерлекле һәм талантлы галим иде. Озакламый аның җитәкчелегендә татар әдәбиятының алты томлык тарихын эшләү кебек киң колачлы программа кабул ителде. Аның биш томы инде күптән укучылар кулында. Алтынчы томның хәле генә катлауланып куйды. Яңача фикерләү шартларында күп нәрсәне үзгәртү кирәк булды. Теге елларда барлык төп эшен Флүн Мусин эшләгән булса, соңгы елда авторлар янә бер кат төзәтеп чыктылар. Китап басмага әзер. Бу—асылда Нил абый башлаган эшне тәгәлләү һәм аның истәлегенә хөрмәт чагылышы да булып тора.



*Сулдан уңга: Н. Хисамов, Н. Юзиев, Н. Исмәгыйлев, Ш. Абилов. 1984 ел.*

ТӘҺТИнең әдәбият бүлеге—татар дөньясындагы барлык әдәби тикшеренүләр һәм тәнкыйть процессының концептуаль һәм координацион үзәге. Н. Юзиев үз өстендәге шушы җаваплылыкны тирән тоеп һәм намус белән күтәрде. Матбугатта фикер яналыгы һәм кыюлыгы белән аерылып торган берәр язма чыктымы—Нил абый аны хуплап, күтәреп ала. Шалтыравык, коньюнктур, буш язмалар күрсә, аларны зәһәр принципиальлек белән сүтеп ташлый. Яшь тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләренең сәләт үзенчәлеген ул тиз күрә, бәяли һәм аңа үсеш юлының иң нәтиҗәлесен күрсәтеп бирә. Аны алдарга, аның белән күз буып сөйләшергә мөмкин түгел. Ул фальшьны үтә күрә.

Кайбер фәнни конференцияләрдә шул чор рухындагы янгыравык, буш сүзләр ярдәмендә күзгә чалынырга һәм абруй казанырга омтылган кешеләрнең чыгышларын төп-төгәл һәм кырыс бәяләүче Нил абый була иде.

Мин фәнни эшчәнлегемнең ун елын диярлек академик институтның фольклор бүлегендә уздырдым. XX йөз башы яки урта гасыр тематикасына караган хезмәтләрне укып тикшергәндә, мине дә әдәбият секторына чакыралар иде. Шулай бервакыт Гали ага Халитнең Дәрдемәнд турындагы бүлеген тикшерүгә катнаштым.

Нил абый минем әдәби журналда әледән-әле чыгып торган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы хакындагы мәкаләләремне игътибар белән күзәтеп бара һәм хуплый иде. Менә, ниһаять, бу темага язылган монографик хезмәтем төгәлләнде. Халык иҗаты бүлегендәге тикшерүгә күренекле әдәбиятчылардан Гали ага Халит белән Нил абый Юзиев чакырылды. Халит ага минем иң яраткан галимнәремнән иде. Без аның белән күп еллар дәвамында шактый якын дуслар һәм фикердәшләр булдык. Әмма бу фикер алышуда аның чыгышы: «Нигә тегене язмаган, нигә моны язмаган, нигә теге юк, нигә бу юк?»—дигән дәгъва рәвешендә барды. Бүтән иптәшләр дә әсәрдәге нечкә детальләргә, поэманың чыганаклары һәм бүтән төрдәшләренә артык игътибар итүем өчен шелтәләде, «нюанс» (төсмер) сүзен еш куллануым өчен тәнкыйтьләделәр. Нил абый хезмәт структурасындагы һәм стилендәге иң мөһим моментны төгәл тотып алган булып чыкты. «Уртак сюжетка бик күп әсәр язылганда, нюанслар хәлиткеч роль уйный,—диде ул.—Нурмөхәммәт теманың шушы хасиятен тирән төшенеп, тикшеренүнең дөрес юлыннан киткән». Соңрак, диссертация якларга баргач, Мәскәүнең Дөнья әдәбияты институтында хезмәтнең нәкъ шушы сыйфатларын мактадылар...

Монографияне фольклор бүлегендә тикшергән көнне остазым Хатип ага Лобачевский скверендә мине көтеп утыра иде. Эскәмиясеннән торып, ашыга-ашыга каршыма атлый. «Ничек?»—ди, дулкынланып. Тикшерүне сөйләп бирдем. Нил абыйның хезмәтне аңлап, нечкәләп анализлавын әйттем. «Ичмасам шәкертне табып үстерә дә белгәнсез!»—дидем. Хатип ага бик канәгать иде.

1978 елның азагында, әдәбият тарихының борынгы дәверенә караган I томын редакцияләү өчен, мине Нил абый җитәкләгән секторга күчерделәр. Кол Гали турындагы бүлекне томның, күпчелек темаларын эшләгән Шакир абый Абилов язды. Әмма Нил абый инде Мәскәүнең «Наука» нәшриятында махсус монография чыгарган, миннән дә өстәмә бүлек яздыруны кирәк тапты. Бүлекне яздым. Тикшерүдә катнашырга тиешле бер аркадаш үзенең бәяләмәсен язма рәвештә җибәргән иде. Анда ул минем беренче җөмләмне шик астына алган. Ягъни «Кыйссаи Йосыф» урта гасыр төрки шигъриятенең сюжетлы беренче әсәре» дигән җөмлә янына: «Бу бәхәсле» дип куйган. Нил абый да, шиккә калып, минем белән шактый бәхәсләште. «Сюжетны вакыйгаларның эзлекле бирелеше»,—дип аңлау төшенчәне тарайта. Хәзерге әдәбият фәнендә бу киңрәк аңлатыла, хәтта лирик шигырьнең дә сюжеты бар, дип карала»,—диде ул. Мин килешмәдем. «Анысы аның гавами карашка гына шулай, җитди гыйльми карашка исә, сюжет вакыйгаларның эзлекле тезмәсе дә, дөресрәге, характерлар тарихы,—дидем.—Шуңлыктан ул барыннан да элек һәм башлыча эпик әдәбият төшенчәсе». Берничә ел үтте. Минем язмам «Әдәбият тарихы»нда шул килеш чыкты.

Менә Язучылар берлегенең тәнкыйть секциясендә минем иҗат тикшерелә. Нил абый күзәтүле-анализлы доклад ясый. Утырышка Хатип ага, Ибраһим ага Нуруллиннар гына түгел, Нәкый ага Исәнбәт тә килгән—рәхмәт төшкере! Утырышны секция җитәкчесе Флүн Мусин алып бара. Бу 1982 елның май башы иде. Нил абый, докладын дәвам итеп: «Нурмөхәммәтнең һәр нәрсәгә үз карашы бар, ул—фикерен принципиаль һәм эзлекле рәвештә яклый белә»,—диде. Мин аның нәрсәне күздә тотканын яхшы төшендем: югарыда телгә алынган бәхәскә нокта куюы иде бу. Ул шундый батыр рухлы, гадел кеше иде. Каршыдашының мәгълүм мәсьәләдә хаклы булып чыгуын танырга аның көче җитә иде. Чөнки ул зур галим, шуңлыктан вак җенүдән тәм табучан кеше түгел иде.

Бертуган ике Юзиев тә—бик нечкә юмористлар. Икесе үзара охшашмаган кебек, шаянлыкта бүтәннәрдән дә нык аерылып торалар. Алардагы ирония һәм гомумән юмор, очыннан агу тамып торган чәнечкеле көлү булмыйча, тымызык наянлыкка тартучан, зыялы көлү. Аларның әти-әнисе—укытучылар. Әдәбиятның, фәннең, мәдәниятнең бу ике эшлеклесе—берсе шагыйрь, икенчесе галим һәм тәнкыйтьче—зыялы гаиләдә тәрбия алган кешеләр.

Бүлек утырышларында өлкәннәрдән кайсыдыр артык беркатлы, садә сүз әйтсә, яисә күрәләтә хәйләләп маташса, Нил абый ярсып бәхәскә кермәс, гаепләп, фаш итеп тә маташмас иде. Күз кырые белән генә миңа карап, авыз читен сизелер-сизелмәс кыйшайтып елмаер иде. Чөнки миндә нинди тәэсир туганын ул тоя һәм үзендә дә шундый ук тәэсир була иде.

Үзенең юмор талантын ул бер диссертация яклау вакытында тулы хәрәкәткә китерде. Үткен мәзәкче Хуҗиәхмәт Мәхмүтов афористик жанрлар турында докторлык диссертациясе

яклады. Оппонентларның берсе—Нил абый Юзиев. Ул, яклау тарихында булмаганча, беркетмә традициясеннән читкә чыгып, үзенең текстын тулысынча шаян метафорага корды. Афористик жанрларның җыйнама термины—паремия. Оппонент диссертантны Паремия ханымга гашыйк ир итеп сурәтләде. Шул ханым белән уртак тел табуын, кичләрен аның аркасында өйгә соңлап кайтуын, ахырчик хатынының да Паремия белән аңлашуын һәм аны гафу итүен сөйләде. Зал шаркылдап-шаркылдап көлде. Күрәсең, үткен язылган бу бәяләмәне Югары аттестация комитетында да ошатканнар—диссертация тиз расланды.

1986 елда ТӘһТИ нең әдәбият секторын икегә бүлделәр: әдәбият белеме һәм кулъязмалар белән текстология бүлегенә. Беренчесендә мөдир булып Флүн Мусин калды, соңгысын Нил Гафур улы Юзиев житәкләде. Ике профильле шушы бүлектә ул киң колачлы гыйльми эшчәнлек җәелдереп җибәрде. Ана ин якын торган ике галим: Марсель Әхмәтҗанов һәм Зөфәр Рәмиев бүлекнең ике тармагын тәшкил иткән ике төркемне җитәклиләр. Марсель инде үзенең кызыклы һәм оригиналь хезмәте белән хәзер фән докторы булды. Зөфәр Рәмиевнең дә докторлык монографиясе әзер. Зур бер төркем яшь галимнәрне Нил абый Гаяз Исхакыйның күптомлыгын әзерләү эшенә тартты, сәләтле һәм тырыш аспирантлар алды. Аның яраткан шәкерте Илдар Еникеев хәзер үзе докторлык яза.

Нил абый үз-үзен аямыйча эшләде. Заманында Хатип ага әле, аның еш ютәлләвен күреп, ял итәргә, дәваланырга куша иде. Шушы тын юллары авыруы галимне вакытсыз гүргә дә кертте.

1996 елда Нил абыебыз нык чирләп хастаханәгә ятты. Хәлен улы Айдардан сорашып тордык. Әдәбият һәм фән нык борчылуда булды. Әмма күңелдә өмет сүрелмәде.

Институтта минем докторлык монографиямне тикшерү вакыты якынлаша. Фикер алышуда үзәк фигураларның берсе Нил абый булыр дип көткән идем. Тик аның хастаханәдән әле тиз генә чыга алмаячагы мәгълүм булды. Хезмәтне улы аша җибәрдем. Шактый вакыттан язма бәяләмә дә кулыма килеп керде. Тикшерү вакытында аны мөдирлек вазифасын башкаручы Зөфәр Рәмиев укыды. Нил абыйча, тирән аңлап һәм әтрафлы язылган иде. Менә язын, ниһаять, галим савыгып эшкә чыкты. Шуны ишетеп, янына, Кремль урамындагы эш бүлмәсенә киттем. Нил абый яхшы ук тазарган, матурланган, көләч, ачык. Чәй китертте. Бәяләмәсе өчен ихлас рәхмәтемне әйттем. «Әгәр сау булсам, күбрәк тә мактаган булыр идем»,—диде, үзен бераз гаепле санагандай, тынкы елмаеп.

Ни үкенеч ки, бу безнең соңгы очрашуыбыз булды. Җәйге ялны ул авылдагы өендә үткәрде. Ә җәй азагына аның вафаты мәгълүм булды. Яңгырлы көнне аны авыл зиратына күмеп кайттык. Кайгы мәрасименә татар мәдәниятенең күренекле бик күп эшлеклеләре килгән иде.

Н. Г. Юзиев соңгы елларда бик житди рәвештә үзе житәкләгән гыйльми юнәлешнең концептуаль-теоретик нигезләрен эшләү белән мәшгуль булды. Фәнни конференцияләрдә ул чыганакчылык гыйльменә караган тирән-тирән докладлар белән чыкты. Аның шушы мәсьәләләрне яктырткан монографик хезмәте үзенең вафатыннан соң дөнья күрде. Бу—асылда аның гыйльми васыяте. Бүлек карамагындагы меңләгән кулъязмаларның кыйммәте, текстологлар әзерли торган унлаган һәм унлаган басмаларга аларны нигез итеп алуның юллары һәм ысуллары хакындагы фикер һәм киңәшләре озак елларга якты ориентир булып калыр.

Галимнең академик фәнгә һәм мәдәниятkә биргән иң зур мирасы—аның үзе төзеп үстергән шушы текстология һәм кулъязмалар бүлеге. Ул үзе кебек тырыш, эшчән һәм намуслы гыйльми хезмәткәрләр тәрбияләгән, сәләтле һәм тырыш аспирантлар алган. Алар матур-матур диссертацияләр язып, остазларының юлын дәвам итә. Нил абыйның Тукай бүләгенә лаек булган фәнни хезмәте шигырь гармониясе хакында иде. Теманы ул очраклы сайламаган, чөнки үзе гаять гармонияле шәхес иде. Аның төзеп тәрбияләгән бүлеге дә—үзенә охшаган гармонияле күмәклек. Без бүлектә узган барлык олы тантана һәм мәҗлесләрдә аның бу мирасын тәкъдир итәбез.

Тукай—исеме серле сөеклесенә:

*Сурәтеңнең иң чыны, бел, шагыйрьнең күңлендәдер,—*

дигән.

Статик сурәт, фоторәсем кеше йөзенең бер мизгелен генә терки. Нинди чибәр булса да, ул сурәт шәхеснең тулы һәм чын чагылышы була алмый. Галим һәм кеше буларак мәрхүмнең тулырак сурәте, һичшиксез, аның бәрәкәтле шәхесеннән сибелгән нурлар яктысын үзенә сеңдергән кешеләр, аның каләмдәшләре һәм шәкертләре күңелендә. Мин исә бу гүзәл затның күңелемдәге сурәтен шушы язмада чагылдырырга тырыштым. Ул—минем өчен бик биектә яна торган биш исем йолдызлыгының якты бер йолдызы.

**Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,**
*филология фәннәре докторы*

*Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## КРЕМЛЕБЕЗ—БӨТЕН ДӨНЬЯГА ТАНЫЛГАН КОРЫЛМА

27 ноябрьдән 2 декабрьгә кадәр Австралиянең Кернс шәһәрендә ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирас комитетының 24 нче сессиясе эшләде. Аның 30 ноябрьдәге утырышында Казан Кремлен Бөтендөнья мирасы корылмасы итеп тану турында карар кабул ителде.

Хөкүмәтара комитет Казан Кремленең төрле мәдәниятләр үсешендә буыннар дәвамчанлыгын билгеләүче биниһая зур әһәмиятен билгеләп үтте. ЮНЕСКО белгечләре карашынча, Кремль ханлык чорыннан сакланып калган бердәнбер татар крепосте, кальгасы, уникаль мәдәни һәйкәл булып тора.

Казан Кремленең татар һәм рус архитектураларының үзара йогынтысын, болгар, Алтын Урда, татар, итальян һәм рус мәдәниятләре чалымнарын туплаган үрнәк булуы ассызыклап күрсәтелде.

## СИБЕЛГӘН ТАТАРЛАР ҖЫЕНЫ

28-29 ноябрьдә Казанда «Русия Федерациясеннән читтә яшәүче татарларның милли мәдәнияте үсешенең мөһим мәсьәләләре» дигән темага семинар-киңәшмә булды. Анда Әзәрбайҗан, Белоруссия, Казакъстан, Латвия, Литва, Польша, Үзбәкстан, Украина, Төркия һәм Австралиядән килгән вәкилләр катнашты. Татарстан вице-премьеры И. Хәйруллин Татарстандагы икътисади һәм мәдәни вәзгыять турында сөйләде. Кунаклар Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе академик И. Таһиров докладын тыңлады. Чыгыш ясаучылар исә үз илләрендә яшәүче татарларның хәле белән таныштырды.

Татарстан Мәгариф, Мәдәният министрлыкларында, Президент аппаратының Тышкы элемтәләр департаментында, Халыклар дуслыгы йортында, шулай ук Казан хакимиятендә очрашулар да булды.

## ИСЛАМНЫҢ 1400 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНА

Мәскәүнең Көнчыгышны өйрәнү музеенда «Ислам һәм татар халкының рухи мәдәнияте» дигән күргәзмә ачылды.

—Ислам мәдәнияте кешеләрнең рухи тормышындагы һәммә байлыкны—дин, фәлсәфә, әдәбият, архитектура, музыка, рәсем һәм һөнәрчелек сәнгатен үз эченә ала,—диде экспозицияне ачканда Русиянең Аурупа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил Гайнетдин.—Күргәзмәдә халкыбызның таланты, Ислам мәдәниятенең байлыгы чагылыш таба.

Мәчет һәм сарай диварларындагы бизәкләр һәм арабескалар, шулай ук, көмештән ювелир бизәнү әйберләре, кыйммәтле ташлар, намазлык, чигелгән сөлгеләр, ашъяулыклар, алтын, энҗе һәм сәйлән белән чигелгән хәтфә баш киемнәре бик күпләрнең игътибарын җәлеп итте.

Күргәзмәне ачу тантанасында күренекле дин, мәдәният, сәнгать һәм фән эшлеклеләре катнашты.

## КОМПОЗИТОРЛАР ИСТӘЛЕГЕН ХӨРМӘТЛӘП

ТР Президенты Минтимер Шәймиев Татарстан Республикасының министрлыклары һәм ведомстволары, уку йортлары һәм мәдәни учреждениеләре, иҗади берлекләре җитәкчеләре белән киңәшмә уздырды. Анда иҗтимагый һәм мәдәни оешмаларның композиторлар Салих Сәйдәшев һәм Нәҗип Җиһановның истәлеген мәңгеләштерү инициативасын хуплау турында карар кабул ителде. Татарстан Республикасының Зур концерт залына Салих Сәйдәшев, Казан дәүләт консерваториясенә исә Нәҗип Җиһанов исеме биреләчәк.

## СӘЙДӘШ ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН

* * *

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында Салих Сәйдәшевнең тууына 100 ел тулуга багышланган җырлы-биюле тамаша күрсәтте.

Анда Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик», «Чын мәхәббәт» драмаларына, Кәрим Тинчуринның «Кандыр буе» һәм «Зәңгәр шәл» пьесаларына Салих Сәйдәшев иҗат иткән көйләр, халык җырлары яңгырады.

* * *

Салих Сәйдәшев юбилее уңаеннан 30 ноябрь көнне Зур концерт залында Татарстанның күренекле сәнгать белгечләре катнашында зур фәнни-гамәли конференция үтте. Белгечләр Сәйдәшнең иҗади мирасы турында кызыклы фикерләре белән уртаклашты. Конференциядә шулай ук, «Салих Сәйдәшев гасыры» дигән җыентык тәкъдим ителде. Ул Казан дәүләт консерваториясенең «Татар музыкасына 1000 ел» дип исемләнгән басмалар сериясен ачып җибәрә.

## КОНЦЕРТ ЗАЛЫ АЧЫЛДЫ

18 ноябрьдә Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залын ачу тантанасы булды. Аның адресы: Павлюхин урамы, 70 (элекке Киров исемендәге мәдәният йорты). Зал ачылу уңаеннан бәйрәм рәвешендә сәнгать осталарының зур концерты узды.

## ХӘЙДӘР ВАРИСЛАРЫ

Мәскәүдә мәшһүр җырчы Хәйдәр Бигичевнең истәлегенә багышланган бәйге узды. Анда Мәскәү, Казан, Уфа, Чаллы, Пенза, Петербург, Түбән Новгородтан килгән үзешчән җырчылар катнашты. Бәйгене Мәскәүнең милли мәгърифәт үзәге белән берлектә Х. Бигичевнең туганнары Халидә һәм Наил Бигичевләр оештырган иде.

1 нче урынга Мәскәүдә укучы Алинә Хәсәнова лаек булды. Х. Бигичев репертуарындагы җырларны иң яхшы башкаручы дип Казанда яшәүче Фәнилә Хәбирова табылды. Башкару осталыгы буенча 1 нче урынга Чаллы җырчысы Илшат Әхәлтдинов чыкты.

## ФӘЛСӘФӘ ГАЛЕРЕЯСЫ

Берләштерелгән дәүләт музеенда яңа күргәзмә—Флорит Зарифның «Фәлсәфә галереясы» ачылды. Экспозициягә останың агачжепсел плитәләргә һәм фин катыргыларына төшерелгән 100 дән артык эше куелган. Җиде бүлектән торган бу уникаль иҗатны—фәлсәфә һәм сәнгатьнең табигый бер синтезы дип бәяләргә мөмкин.

## ГАЛИ ШӘХЕС ЯДКАРЕ

Язучы һәм тәнкыйтьче Гомәр Галинең тууына 100 ел тулу уңаеннан Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәдә Г. Галине күреп белгән өлкән язучыбыз С. Сабиров истәлекләре белән уртаклашты, язучылар Р. Мостафин, Р. Батулла, шагыйрьләр М. Әгъләм, Р. Әхмәтов чыгыш ясады.

Тантанада Гомәр Галинең кызлары—Мәскәүдә яшәүче танылган математик Гүзәл һәм Казанда яшәүче, Русиянең атказанган табибәсе Алсу, Нью-Йоркта яшәүче оныгы Лилия ханымнар катнашты. Анда, шулай ук, әдипнең нәселдәшләре, туганнары—«Птицепром» берләшмәсе генераль директоры Марс Алиев, академик Энгель Таһиров та бар иде. Кичә сәнгать осталарының чыгышы белән тәмамланды.

## ҖАМАЛ ВӘЛИДИ ИСЕМЕНДӘ

Әдәби тәнкыйть жанрын җанландыру максаты белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Җамал Вәлиди исемендәге бүләк булдырырга карар кылды.

Бүләк республика матбугатында басылып чыккан иң яхшы әдәби тәнкыйть әсәрләре өчен елга бер мәртәбә биреләчәк.

## ПРОПАГАНДА БЮРОСЫ ЯҢАДАН ЭШЛӘЯЧӘК

Соңгы елларда язучыларның халык белән очрашу, аларның иҗатын укучыга ирештерү мәсьәләсе үзагымына куелган иде. Моңа бигрәк тә әдәбиятны пропагандалау бүлегенең бетерелүе тискәре йогынты ясады. Ниһаять, Язучылар берлегендә әдәбиятны пропагандалау бүлеге кабат торгызылды. Аның җитәкчесе итеп драматург Рәдиф Сәгъди билгеләнде.

## ТАТАР ПИАНИСТКАСЫ АМЕРИКАДА

Санкт-Петербургның М. С. Глинка исемендәге Дәүләт академия капелласында танылган композитор Сергей Рахманинов иҗатына багышланган концерт булды. Петербурглыларны Филадельфиянең Даниэль Спалдинг җитәкләгән «Виртуозы» камера оркестры үзенең сәнгате белән таныштырды.

Шунысы кызыклы, концертта солистка буларак безнең якташыбыз пианистка Халидә Хәйретдинова чыгыш ясады. Ул Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап, соңыннан Санкт-Петербургның Римский-Корсаков исемендәге консерваториясендә аспирантурада белем алган. Бүгенге көндә АКШта яши.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Балалар әдәбиятын үстерүдәге иҗади хезмәтләре өчен Татарстан Язучылар берлеге бүләге—Алиш премиясе язучылар **Рәшит Бәшәр** һәм **Ләбиб Леронга** бирелде.

* * *


Матбугат өлкәсендәге уңышлары өчен «Татарстан яшьләре» газетасы баш мөхәррире **Шәрәфиев Исмәгыйль Сәлмән улына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Серле Казан». *Солтан Исхаков фотоэтюды.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре һәм редколлегия әгъзалары. 2000 ел. *Рөстәм Мөхәммәтҗанов фотосы.*




«Мәгариф» нәшриятына быел 10 ел. Торгызылуына 10 ел дисәк дөресрәк тә булыр. Чөнки ул—нигезе гасыр башында ук салынган шул исемдәге нәшриятның рухи дәвамчысы. Төп максаты—төрле төбәкләрдә сибелгән татар мәктәпләре өчен дәреслекләр чыгару.

«Мәгариф»—Россиядә милли телдә китаплар чыгаручы иң зур нәшрият. Соңгы 10 ел эчендә бередә 13 миллионлап данәдә 700 исемдә китап басылган. «Мәгариф» нәшриятында, дәреслек һәм методик әдәбияттан тыш, балалар бакчалары өчен кулланмалар, һәм белешмә әсбаплар, матур бизәлешле әдәби китаплар да дөнья күрә. Яшь буынны татар һәм дөнья әдәбиятының классик әсәрләре, бүгенге әдипләрнең иң яхшы иҗат үрнәкләре белән таныштыру да—нәшриятның мөһим бурычларының берсе.

«Мәгариф»нең 2001 елда гамәлгә ашачак тематик планы бик бай һәм кызыклы. Быел нәшрият 150 ләп исемдә китап һәм төрле методик кулланмалар чыгарачак. Алар арасында әдәби әсәрләр дә дистәдән артык. Быел «Мәгариф»тә Х. Туфан, А. Гыйләҗев, Роб. Әхмәтҗанов, А. Хәлим, Р. Харис, Т. Галиуллин, Р. Гаташ, Р. Корбан, Р. Вәлиев, Р. Рахман һ. б. язучы-шагыйрьләрнең яңа китаплары басылачак. Шулай ук, темплан мәгълүматларына караганда, «Хәзинә», «Энҗе чәчтем—энҗе җыйдым» серияләрендә дә әдәбиятка бәйләнешле байтак җыентыклар дөнья күрәчәк.

*Нәшриятның адресы:* **420503. Казан, Бауман урамы 19. Тел. 92-49-97**
*Фирма кибетенең адресы:* **420084, Казан, Пушкин урамы 3. Тел. 92-46-47**

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)